# казан утлары

8

АВГУСТ-1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8
АВГУСТ
1975

## Бу санда

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят. Повесть . . . . . . . . . . . 3

ИЛҺАМЫБЫЗ — ИГЕНЧЕГӘ

Ф. ЯРУЛЛИН. Ничек булыр! Шигырь . . . . . 75
Р. ГӘРӘЙ. Шигырь укытучылар. Шигырь . . . . 76
Е. УТКИН. Әнкәй дә гел җыеп ала иде... Шигырь 77
Н. МАДЬЯРОВ. Күзем текәп күксел офыкларга... Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . 77
Н. ӘХМӘДИЕВ. Бодайларның керфек каккан чагы... Шигырь . . . . . . . . . . . 78
Х. ХӨСНУЛЛИН. Сабан туе туган якларымда. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . 78
Г. САДӘ. Иген кыры... Шигырьләр . . . . . . 79
И. ВЕРГАСОВ. Кырым партизаннары. Хикәяләр. . 80
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Чал платан төбендә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 103

САЛИХ БАТТАЛГА 70 ЯШЬ

С. БАТТАЛ. Яшәү мәгънәсе. Шигырьләр . . . . 110

САФА САБИРОВКА 60 ЯШЬ

С. САБИРОВ. Кар астында калган эзләр. Хикәя. 113

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 120
М. ЗАРИПОВ. Киңлекләр . . . . . . . . . . 123

СЕРГЕЙ ЕСЕНИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

С. ЕСЕНИН. Аерым тамга белән тамгалана... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 132

ТӘРҖЕМӘ ТЕОРИЯСЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Р. АХУНОВ. Әдәби тәрҗемәдә компенсация методы . . . . . . . . . . . . . . 137

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Г. ТАҺИРҖАНОВ.** Әдәбият тарихында иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләрнең роле . . . . . 146

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Югары сыйфат, иҗади активлык . . . . . . . . 155
Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында . . . . . . 155
**Ф. МИҢНУЛЛИН.** Беренче нәтиҗәләр . . . . . 158
**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Тәнкыйтьченең осталыгы . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Я. АБДУЛЛИН, Ч. БӘХТИЯРОВА.** Сәнгатьтә милли һәм интернациональ якларның диалектикасы 178
**Ф. ХАТИПОВ.** Тугрылык һәм батырлык . . . . 183

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

**М. САДРИ.** Җырым юлдаш булсын. Җыр . . 192

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/IV-1975 ел. Басарга кул куелды 24/VI-1975 ел. ПФ 09023. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90 000 экз. Заказ Я-195. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары». 1975 ел.

**Аяз Гыйләҗев**

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ ТУРЫНДА ХИКӘЯТ

## Бер-ике авыз кереш сүз



1969 елның көзе искиткеч бәрәкәтле һәм җылы килде. Без, бер төркем татар язучылары, Сарман районының кояшлы авылларында әдәбият атналыгы үткәрдек. Атналык дигәнебез тәп-тәгәл ун көнгә сузылып, чын мәгънәсендә күңелле бәйрәмгә әверелде. Моның ике мөһим сәбәбе бар иде: берәдән, көзнең шундый йомшак, игелекле килүе болай да кунакчыл хуҗаларыбызның күңелен тагын да күтәреп җибәрсә, икенчедән, төркемебездәге байтак язучыларның Кыр ягына, Кыр ягының мәшһүр үзәге Сарманга шәхси мөнәсәбәте булуы иде. Зәңгәр тауларында ак батист яулыклар җилфердәгән, җырлы-моңлы Сарман якларында туган язучылар җыйналышкан идек без!

Мин үзем дә шушы төбәктә — Чукмарлы авылында туганмын...

Кыр ягының кунакчыллыгын тасвир итәр өчен, табын ризыкларының ләззәтен башкалар да тиярлык дәрәҗәдә сөйләр өчен бал авыз булырга кирәк: кулымнан килердәй булмагач, ул эшкә алынмыйм. Мәгәр Нөркәй авылында булып алган бер төнге вакыйга сәфәребездә аерым бер урын тотканга, анысын сөйләмичә дә ярамас...

Көндез, гадәттәгечә авыл-кырлар, мәктәп-клублар белән танышып, агай-эне белән очрашып, сөйләшеп йөрдек тә Чәүкә тавы итәгендәге салам эскертенә утырып хәл җыйдык, туган як хатирәләрен уртаклаштык...

Инде соң гына, басу түреннән бәрәңге алучылар, ерак җәйләүләрдән сыер савучылар кайтып беткәч, шыгрым тулы халык утырган клубта әдәби кичәбезне башлап җибәрдек. Борынгыдан китапка мәхәббәтле, электән үк атаклы мәдрәсәле, тирә-якка мәшһүр ярминкәсе булган Нөркәй авылы халкы тын да тартмыйча безнең хикәяләрне тыңлый, шигырь-җырлардан соң гөрләтеп кул чаба, шаулап көлә.

Кичәнең яртысы узгач, ишек төбендә шикле хәрәкәт, ниндидер ыгы-зыгы башланды. Берәр исерек башы килеп кереп, бәйрәмебезнең ямен җибәрмәсә генә ярар иде дип барыбыз да борчылыштык. Шулай тәмсезләнеп йөргән бәндәләргә юлыккан бар авылларда, бик бар!..

Кутәренке кәефебезне торган саен ныграк бозып ишек бер ачылды, бер ябылды, моңарчы кирәгән белеп кенә әле кәлә, әле яр буендагы балыкчы кебек шым гына утыра алган халыкның игътибары ачык ишек аша әллә кая, серле төн караңгылыгына тышка үрләде; тыңлаучыларыбыз, яхшы сүзнең кадерен онытып, беренче класс балалары күк дәррәү кыймылдаша башлады. Залдагы гөжләү, колактан-колакка күчеп йөргән вакытсыз сорашулар сәхнәдәге тантананың ямен җимерде: халык белән арадашлык бер мәлгә өзелде.

Ишеккә карыйбыз — ул һаман шыгыр да шагыр ачыла да ябыла!

Тәрәзәләргә күз салабыз, күзге төн дөм-караңгы, берни аңлап булмый! Сәхнәдә утырган парторгны да дәшеп чакырып чыгардылар. Әле ярый, ул тиз генә әйләнеп керде һәм шундый сәер белдерү ясады:

— Чүгез, иптәшләр, ягез тыныйк!.. Почмактагылар, гөжләшмик! Әллә ни юк-югын... Кичәбезне дәвам иттерәбез... Җәмәгать, ни, анда бер салам эскерте яна януын, мәгәр тиешле саклык чаралары күрелгән, берүк ахыргача тәртипле генә утырышыйк...

Безнең колаклар үрә торды: эскерт яна?!

Башланган кичә, әлбәттә, дәвам итте, тик залның игътибары хәзер ишек тирәсендәрәк иде: тагын кем килеп керер дә нинди хәбәр җиткерер?!

Гөжләү, юраулар тынмады, барыбыз да бердәй хәвефләнеп кичәне яптык.

Бер заман, кайнап торган халык төркемен көчкә ерып, урамга чыксак, безне бер төркем ир-ат урап алды. Кесә фонарьларын выжылдатып юлны яктырталар болар, «авылыбыз чокыр-чакырга утырган, урамнарыбыз хутсыз, абынып егылмагыз, фәлән-төгән» дип кисәтәләр. Кыскасы, безне тәмам чолгап, сак астында озаталар кебек тоелды.

Урамда сорашырга яхшысынмаган идек, фатирга кайтып кергәч беленде — чыннан да саклап диярлек алып кайтканнар икән безне!

Чәй янында бераз телләр чишелгәч, совхоз партоешма секретаре болай дип аңлатты:

— Гаҗәбрәк әле безнең хәлләр!.. Ие... Октябрьның илле еллыгына багышланган тантаналы җыелыш барган шәптә дә салам эскертенә шулай ут салдылар... Инде килеп, янгын ваемсызлык нәтиҗәсендә, ялгышлыктан чыккан дияр идең, бер-береннән шактый ерактагы ике эскерт янды ул төндә... Алай гына да түгел, шул ук төндә кайсы явыздыр зират киртәсен сикереп кергән дә байтак кабер ташларын кубарып читкә ыргыткан, чардуганнарны ботарлап, аударып, агачларны сындырып йөргән.

Колакларым уттай яна башлады!.. Дөрес ишеттемме?!

Ярый, ул явызның эскерткә ут салырга кулы барсын да ди, кабер ташларына тотынганда ничек йөрәге ярылып үлмәде икән аның? Эшмәшәкатьләрен куеп, дөньялыктан киткән кешеләрдән үч алуымы бу аның, әллә гади ахмаклыгы, җүләрлегеме?!

Беләм, җир йөзендә әллә нинди җинаятьләргә маһир кешеләр барын беләм! Төрлесен күрдек, күреп торабыз. Әмма монда, бездә, тып-тын Нөркәйдә?! Чәүкә тавында?.. Ата-баба рухын аяк астына салып таптау, гүр ияләренең исемен, намен, хатирәсен пычрату, тынычлыгын бозу — бу бит явыз илбасарлар эше! Бу инде чамасыз пычрак җинаять, тиңдәшсез кансызлык, мондый явызлыкны, түбәнлекне дөньяга, кешелеккә бик-бик зур үче булган кара эчле мөртәт кенә эшли алгандыр!

Кем булыр ул?

Яшьме?

Картмы?

Яшь икән — каян килгән аңа мондый йөрәк?!

Карт икән — кайчаннан бирле үч саклый? Ни өчен? Кемнәре өчен? Кемгә?

Монысын бирәү дә белми иде. Бәлки гомергә беленмәс тә. Кырык ел узып та беленми калган кыңгыр эшләр азмы әллә?!. Бу җинаять тә, бәлки, ачылмый калыр, эзе-исе югалыр, шунысы гына үтә аяныч — ул мөртәт тә шушы ук тын зиратка, ата-бабаларының ак сөякләре түшәлгән кара түшәккә килеп башын салыр, туган илебезнең зәңгәр күгендә талпынган тургайларга карап туп-туры үскән ак каеннар ышыгына килеп туфрак булыр... Ялгышмыйк, хаиннар кабере өстендә һәрчак шайтан таягы үсми!..

Күз алдымда клубны тутырып утырган нөркәйлеләрнең сөйкемле йөзләре... Әй күңелдә уйлар, уйлар!..

Иртәгесен мин, таң яралгач та, йөгереп кенә, янган эскерт янына барып килдем...

Әйе, кичә генә шушындагы алтын тауга утырып хәл җыйган идек без, яшьлек хатирәләребезне уртаклашкан идек... Әле кичә генә безнең йомшак тәхетебез булган эскерт урынында бүген сүнеп-сүрелеп тә бетмәгән соры-көрән көл буразнасы ята. Ул дугай-дугай булып, чүл бархannары сыман, я тәбәнәкләнеп сызып, я биегәя-биегәя калкынып шактый озынга сузылган, сыртыннан сыек кына ачы төтен күтәрелә иде.

Чәүкә тавы өсте буп-буш! Ни ялгышып кына бер чыпчык чырылдасын, төнге дәһшәттән куркып алар да еракка очып таралышканнар, күрәсең...

Кара төндә эскерт янына килгән ул бәндәнең йөз-кыяфәтен, авызборынын, киемен, яшен, эти-әнисен, әби-бабасын, бала-чагаларын күз алдыма китереп карадым. Юк, барып чыкмады, ни тырышсам да, бу мөртәтне гади кеше кыяфәтендә каршыма бастырып куя алмадым...

Кеше күңелен төрле яктан аерата баеткан якты, нурлы шәхесләр була. Үз күңелемне теге яки бу юнәлештә баеткан кешеләрне мин бик ачык хәтерлим һәм гомерем буе аларга рәхмәт укыйм...

Ныклабрак уйлап карасаң, мәхәббәт, сөю тойгылары безгә мәгълүм бер кешеләр аша, аларның дөньяга карашы, мәсләге, холкы-фигыле аша сеңеп урнашмыймыни?! Сөю хисләрен татырга булышкан кешеләрне без гомергә онытмыйбыз!.. Ә н ә ф р ә т?! Ул да м ә х ә б б ә т белән янәшә яши ич! Ул хис тә нәкъ менә м ә х ә б б ә т кебек үк мәгълүм кешеләр аша, аларның мәсләге, холкы-фигыле, кылган гамәлләре аша бездә туа, урнаша, ныгый ич! Шулай түгелмени?

Сарман атналыгыннан кайткач, мин Нөркәйдә уздырган төн турында еш уйладым. Үземдә беренче тапкыр м ә х ә б б ә т һәм н ә ф р ә т хисләрен тудырган кешеләр, минем бала чагымның — яшьлегемнең аерылгысыз юлдашлары, сугыш башлангач та авылыбызда булып узган, кайберләренең чуалчык очлары ачылмый калган хәлләр исемә төште...



## 1

Сентябрь урталары гына булса да, авыл урамнары октябрь азакларындагы төсле моңсу, ноябрь пычракларындагы кебек буп-буш...

Торналар китә. Берьюлы ике көянтә. Көянтәләр бер-берсенә хәерле юл теләгән кебек якынлашып та куялар, җилдә тирбәлә-тирбәлә тагын ерагаялар, безнең авылның бәрәкәтле борчак басулары, эре-эре түмгәкле тын сазлыклары белән язга хәтле саубуллашкан төсле, зур бөҗра ясап урамнар өстендә әйләнеп тә алалар... Көн туды исә канлы сугыш кырларына ир-атларны озатып торган хатын-кызлар күкне моңсу сагыш белән тутырып китүче торналарга карап үкереп елыйлар.

Кырык беренче ел торналарын онытырлыкмы соң?!

Минем дә тамак төбе кымырҗый, тик мин еламыйм, унынчыда укыган егеткә елау оят, мин ишегалдыбызда, болдыр баскычында, этидән калган күн итекләрне дегет белән майлап маташам.

Ни уйлап алып төшкәнмендер күн итекләрне, белмим, бу итекләр эти сугышка киткәннән бирле чормада онытылып яткан, җилдә шакраеп кипкәннәр, утын тукмагы белән бәрсәң дә язылмыйлар, очлары рәсемнәрдәге төрек янычарларының кәвеш борыннары шикелле югарыга карап катканнар. Азаплана торгач, үзем дә беләгемә хәтле дегеткә манчылдым, кулымның майлы икәнен онытып, бер-ике тапкыр маңгайны кашып алдым. Көн иртәдән кояшлы булганга, вак чебен котырынды, әрбәлектән туктаусыз тәтәй кашыклар очып чыкты...

Ерагайды торналар, тавышлары ишетелми. Мин утырам да утырам... Ничәү булдылар икән?.. Тик аларны санарга ярамый... Санасаң, торналар юлларында адашалар... Һәр язда Югары авылга кайтып, бала үстереп китүче үз ягыбыз торналарын без бик яратабыз. Адашмасыннар алар!.. Үзләре белән быел чыгарган бала торналарны да алып китәләр бит! Ерак юлларны моңарчы күрмәгән, ерак илләрдә йөрмәгән балаларын!..

Аксаклый-аксаклый болдырдан төштем дә, кунычларын өстә калдырып, күн итекләрне дегет чиләгенә тыгып куйдым. Чиләкне җылыгарак, кояшка чыгардым, җебеми карасыннар хәзер, дегеттә ята-ята иләре килер.

Ни-нәрсәгә менел алдым соң мин бу җәфаны, ятсын иде әти кайтканчы чормада!..

Кул юарга үрелдем, юынгычта тамчы су юк икән, тавыкларга кайтарып аударган сары комда кулымны кат-кат ышкыдым да бәбкә чирәменә сөрттем; дегет исе килә килүен, мәгәр түзәрлек. Үз кулым үземә!

Урам коймабыз терәлгән өй почмагында юан, җиде кыршаулы иске мичкә утыра, суы яшькелт-зәңгәр, иелеп карасаң көзгедән бер дә ким күрсәтми. Иелеп карадым, битем чеп-чиста. Су өстендә дә канатлары сәлперәйгән тәтәй кашыклар йөзә. Фу, чәч бераз артыграк үскән икән, пумала булган, иелгәч, күзгә төшә... Чәчне тимерче Иосыф ала торган иде, хәзер ул да өйдә юк. Сугыш башланган атнада ук аны да алдылар, таза, егәрле ир иде шул, безнең әти белән икесе сигезәр потлы капчыкларны иңнән-иңгә чөеп уйныйлар иде... Сабан туеннан кайткан да бер иңендә симез тәкә, икенче иңендә кәефле чырылдап хатыны Хәтимә апа булыр иде. Әти белән Иосыф абый бер арбага утырып чыгып киттеләр, бер үк шалонга, бер вагонга эләктек дип сөенечле хатлары килде дә, менә хәбәрләре юк, зарыктык, икесе дә тынып тора. Алар артыннан ук диярлек абыйны да алдылар, өйләнмәгән егет иде әле, ярәшелгән кызы калды, Кәҗә башы урамыннан Кайнар Бибисарасы, олырак авызлы, эре сөякле кыз. Безнең Аскы урамга төшкән саен жаен табып мине күрми китми, чакырып чыгара да, олы авызын күрсәтергә оялгандай, яулык чите белән каплабрак:

— Нәнәм, Искәндәр, абыеңнан хәбәр юкмы? — дип сорый. — Хатмазар алсагыз, туры безгә элдерт, сөенчегә кулъяулыгы белән бер янчык чикләвек бирермен!..

Аскы урамны ярып баядан бирле берәү тимер чүки, әллә арба тәгәрмәченә кыршау суга, әллә күчәр тимерли, чакы-чокы ямьсез тавышы колакны яра.

Чатанлап урамга ук чыктым, почта ташучы сипкелле Рузилә узар вакыт, келәт кыегының күләгәсе болдырны каплаган инде.

Капка төбебездә иләмсез дәү соры таш. Бабам алып кайтып куйган. Көчле һәм тәвәккәл кеше булган минем бабай!

Көчле димәктән, безнең авыл гомер-гомергә таш чыгарган. Сарман ягында Әчтәхи боярның аракы заводы булган, шунын озын-озын икмәк складларына дигән ташны безнең авылдашлар чыгарган. Таш базларыбыз янында шактый биек, бер-берсенә тамырлары белән береккән сигез кыя бар. Урал тауларының соңгы тамыры диләр кешеләр. Булса да булыр. Шул кыяларның иң биегенә, «Сөңге» дип аталганына,

гел бөркет куна икән. Таш чыгаручылар «Тикмә таш түгелдер бу, бер-бер хикмәте бардыр» дип шикләнә үк башлагач, минем бабай йөрәксенеп әйтеп салмасынмы: «Шул кыяның бөркет кунган очын ватып, капка төбебезгә алып кайтып куймасам, Җиһангир исеме миңа харам булсын!» дигән. Арба күчәрен тимерләгән, урәчәләрне пеше яшь имәннән ясаган, ничәмә-ничә тәгәрмәч кырган, күпме таҗ бавы өздергән, мәгәр бер үзе менеп кыя башын китеп төшергән, бер ялгызы арбага салган (башкалар тылсымлы ташка орынырга курыкканнар!), әллә ничә потлы ташны ике ат җигеп исән-аман авылга алып кайтып җиткергән. Ташның өстен тигезләп шомарткан, ыспайлаган, шуңа калын такта ипләгән. Мин белгәндә таш базларын япканнар иде инде. Бабам, карт булса да, колхоз эшеннән бушамады, сабан туе тирәләрендә генә шул таш өстенә чыгып утырыр иде. Бабайны җирләп кайткан көнне әти дә беренче тапкыр шунда чыгып утырды...

Бүген мин утырам!..

Ташның бер кырына очлы тимер белән тырнап «Кәлимулла» дип язылган. Аныһы шул армиядәге абыем инде, хәзер Ульянда танкистлар училищесында укый. «Озакламабыз, фронтка чыгып китәрбез, ашыктыралар» дигән хатын Рузилә-сипкел кертеп бирде.

Безнең өйдә хәзер өч кенә җан иясе, сәер дә, күңелсез дә. Нәсимә исемле сеңелем бишенчедә укып йөри, мин унынчыга барырга тиеш. Әллә нигә бер дә укыйсым килми, ир-ат укытучылар да сугышка китеп бетте диярлек, әллә каян хатын-кыз табып бетерделәр, ялдагы карткорыны кузгаттылар, башкасын да: былтыр гына унынчыны бетергән Арзу немец телен укытачак. Арзу да булдымы укытучы?! «Апа» дип тел әйләндереп әйтә аламмы мин аңа?! Гомергә юк! Бәләкәй чагында үзенең чәчен уа-уа кәҗә мае чыгаргач, бик шәплэп «абыем-җаным, матурым-алтыным!» дип биш кат әйттерә торган идем, хәзер күр, эшләр кай тирәгә китте, кара такта янына бастырып «дер, дие, дас» ларга биетәчәк! Аныһын булдырыр! Тьфу!..

Дөресен әйткәндә, дәресләрнең башланганы юк диярлек, башта класс белән борчак эскертләп йөрдек, аннан атлы суккычта тары суктырдык, хәзер безнекеләр бәрәңге ала.

Сул тез капкачымны учым белән кысып соры кыя очында утырам. Нәкъ безнең каршыда гына, куе җәрби куаклары арасында, тимерче Иосыф абыйларның алты почмаклы, калай башлы өе. Тимер тавышы шулардан килә икән, тагын чакылдата башладылар. Урамны аркылы чыгып, капка ярыкларыннан караган идем, исем-һушым китте: йөз яшьлек Рәхимҗан бабай тимер чөй белән пеше карама түмәрләрен ярырга азаплана. Бер суга да артына чүгеп китә, чак егылмый, аннары башын бер якка кыегайтып хәл ала, брезент бияләйләрен салып ташлап, учларын төкерекли дә аһ итеп тагын берне ора, суккан саен хәле бетеп чайкала, гел сызыклардан гына торган маңгаен кул аркасы белән сөртә дә, уфылдап, ярылмаган бүкәне өстенә утыра.

Бетеренде быел Рәхимҗан бабай! Башка елларда печәнгә төшкән көннәрне болынга иң әүвәл ул теркелдәп барып җитә торган иде, өстендә утыртма якалы ап-ак күлмәк, җиңелчә кара камзул, башта өр-яңа кара түбәтәй, кәкре аякларын ерып беренче эзгә ул төшә торган иде! Быел менә бик бетеште, аклан чирәменә сабан туена да төшә алмады, тешсез авызы белән кеткелдәп капка төпләрендә утырып калды. Утын ярырга ук тотынган, гаҗәп. Кереп бу түмәрләрне уңлы-сулы яргалап ыргытасы иде дә, тиктормас җанда бәла бар дигәндәй, моннан бишалты көн элек минем белән бер мәзәк булып алды әле.

Егет чагыннан янгын сараена кереп оялап, шунда гомер уздырган һәм төрле-төрле этлеккә гаять остарган чулак Гыйбадулла кичке уенга төшкән яшьләрне болай дип котырта башлады: «Ягез әле, ягез, күрсәтегез, кайсыгызның сырт сөяге ныгыган икән? Кайсыгызның кавырсы-

ны каты?! Иөрәге нык?.. Ягез әле, янәсе, немецны кырырга кайтыгыз барырлык??»

Чулакның яшь-җилкенчәк арасында тамчы да абруе калмаган, әллә безгә сөйли, әллә эткә, колак салган кеше юк, корыны бушка әвештереп яшәүче алдакчы бер бәндә, бурычка ала — кайтармый, тавык-каз урларга маһирлыгы барлыгын да беләбез, немец дигән сүзгенә колакка керде, җилкенеп киттек. Бил алыш башланды.

Тегермәнче Хәбиб малае мокыт Сирай миңа килеп ябышты. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, каян кичке уенга төшкәндер ябалак, югыйсә, кеше арасына чыкканы да, авыл урамында юньләп күренгәне дә юк иде моңарчы, авылдан ике чакрым түбәндә аның төп оясы. Төп кебек юантык нәмәрсә, алагаем көчле икән үзе, алыйм дисәң биле юк, кысыйм дигәндә муенын бирми, шамбы балыгы кебек култык астыннан шуа да чыга, эре-эре тешләрен ыржайткан, әллә көлә, әллә үчекли, белмәссең. Ә мин көрәшчеләр нәселеннән, Йосыф абыйның үзе белән дә юри-марый гына алышкан бар, аз-маз әмәлен дә беләм дигәндәй, беләкләр дә камыр түгел, шулай да Сирай ят егет, ул мине сыный, мин аны, чабата үкчәләре белән байтак тузан кубардык, алыштык-алыштык та, ялт итеп тегене баш аркылы чөйим дип җирдән кубарып алуым булды, сул аягымның тез капкачы урыныннан купты. Оятыма каршы, сизмәстән акырып җибәрдем, авырта, «тезем-тезем, аһ!» дип аңлатып карыйм, инәләм, берсе дә ышанмый, икмәктер. Сирай билдән алган да башмак иреннәрен чак кыймылдатып пышылдый: «Синдә хәйлә булса, бездә көч!.. Көч, белдеңме?!» Гыйбадулла чулак әтәч сугыштырамыни, көч биреп, учларын шапы-шопы суккалап безнең тирәдә йөри, мин аһылдыйм, тегермәнче малае форсаттан файдаланып мине болгап атарга маташа, үгез күк мышный, нидер мыгырдап та ала. Нишлисең, яраса-ярамаса да хәйләгә керештем, иелгән булдым да баш түбәсе белән тегенең корсак астына берне сөздем, кагыйдәгә сыеп бетмәде бетүен, тәкмәрләп барып төште малаең, чалган дуңгыз төсле чинап җибәрде. Ятабыз икебез ике якта уфылдашып. Гыйбадулла чулак чөгендер төсле кызыл танавын селкетә-селкетә:

— Хәрәмләште, хәрәмләште! Нәселе шундый, хәйләкәр! Хәрәмләште, — дип акыра.

Чулак белән Сирайның дуслыгы турында колагыма чалынганы бар иде, балыкчылар тегермән буасына мурда салса, болар төнлә шуларны чистарта икән дип тә сөйләделәр. Шулайдыр, чындыр. Төн уртасында ут яндырып мәчет манарасыннан күгәрчен тотканнарын үзем күрдем, өсләренә килеп чыктым...

Хәзер Сирай, кай арада исенә килеп сикереп торгандыр, бугазын киереп кычкырырга тотынды:

— Әллә мине тегермәнче малае дигәч тә!.. Хәрәмләшмә! Янәсе, ул гына оста, белдекле! Мине адәмгә санамый, янәсе! Күрерсең әле, күрсәтермен мин сиңа!

Гыйбадулла аның саен Сирайны котыртты, кул хәрәкәтләре белән сугышырга боерды, әмма мине иң гаҗәпләндергәне Сирайның соңгы сүзләре булды:

— Бәхетең, сырт сөягеңне сындыра идем инде... Танавыңны кара канга манчый идем... Карарбыз әле, күрерсең, Арзу кемгә булыр. Белербез!.. Бик теге!

Кыдрачланып якасына барып ябышыр идем, торыр хәлем дә юк, Рәфгать дустым читәннән бер таяк суырып чыгарды, шуңа таянып көчхәл белән фельдшер Нәфисәләр турына барып егылдым, өйләренә керер хәлем калмады, тез капкачы дигән каһәр — судагы агач бөке кебек икән ул, бер кузгалса харап, үз сыекчасында үзе йөзә дә йөри, — кот калмады.

Өйгә кайтып егылуга, Арзу кереп житкән. «Анатомияне онытмадыңмы? Ярдәм кирәкмиме? Сугышка бармаган килеш мәжрух булгансың икән», дигән була, көлә. Кулын маңгаена куюга, кылт итеп Сирайның котсыз сүзләре хәтергә төште... Тукта әле... Арзу диде бит... Өметләнмә, диде... Каян белгән ул? Каян сизгән? Арзуны уйлап йокысыз узган төннәрем турында жан дустым Рәфгатькә дә сөйләгәнем юк бит минем! Берәүгә дә!.. Каян сизенгән ул?! Нигә янады? Әллә аның да күзе Арзуга төшеп йөриме?..

Нәфисә фельдшер бик ныгытып: «Өйдә генә утыр, чыгып йөрмә!» дигән иде, шуңа күрә йорт тирәсендәрәк уралам әле, эшкә чыккан юк. Мәктәпкә дә барасы килми... Арзу да кырда... Торналарны күрде микән? Сирай апара корсакны әйт син!.. Арзуга өметләнеп йөри икән бит!..

## 2

Рәхимжан бабайлар капкасын киң итеп ачтым да каты ук кычкырып сәлам бирдем:

— Алла куәт бирсен, Рәхимжан бабай, исәнлекме? — дидем.

Ул баш чайкап кына сәламемне алды, еш-еш тынын алып озак кына миңа карап торды, терсәкләре ямалган зәңгәр күлмәге манма су, ачык изүеннән гадәттән тыш аксыл тәне, очлы сөякләре күренеп китте. Кимерчәктән генә торган борын очына тонык тир тамчылары асылынган. Менә ул күлмәк итәген кайтарып борынын сеңгерде дә, кулын селтәп, бүкәнгә барып утырды.

— Авыр эшкә тотынган син, Рәхимжан бабай.

— Җегәр бетмәгән икән әле дим... Кем атлы соң әле син?.. Кәлимулласы түгел, Искәндәре бит? Искәндәрме әле? Әйе шул. Йосыф абзаң барында өй-арасында да эш калмый торган иде, «кашык тотып түрдә утыра алсаң, без шунысына бик канәгать» дия торган иде абзаң, хәзер, күрәсең менә, тотынмый ярамас! Хәтәр килә бит мимеч, усал халык! Ундүртенче елның хәлләрен хәтерлим әле мин...

Төрле яктан ботак сарган пеше карама түмәрләрен тотып-тотып карадым да:

— Маташма интегеп, Рәхимжан бабай! Бер ара үзем кереп ваклап чыгармын әле! — дидем.

Шулай дисәм дә, карт башын чайкады, торып басты, бияләен салып ташлап учларына төкерде, төкерегә чыкмады, авызы кипкән, коры учларын бер-берсенә ышкыды да бер дә ычкындырмас төсле итеп балта сабына тотынды.

Тәгәрмәчләре үзеннән дә биек велосипед сөйрәп келәтләреннән Рәхимжан бабайның иң кече оныгы, Йосыф абыйның төпчеге Илдус чыкты. Утырырга тырышып карый, велосипед, малайны нәртеп, дык итеп жиргә барып төшә. «Булышыйммы?» дип карыйм тегеңәргә, малай нәкъ Рәхимжан бабай төсле башын чайкый, кулларын төкереклэп тезенә сөртә дә рульгә ябыша, «үзем, үзем», ди... Йосыф абый да үзсүзле кеше иде, аңа фронтта аерата кыендыр дип уйлыйм. Ул арада Илдус, кәтүк борын, чатан-потан китеп бара, чебиләп беткән кара аякларын рам арасына тыккан да педальләрне әйләндерә, авызы — колакта. Китте тәки. Үз турыбызга гына канәгать түгел әле, Югары очка, үргә каршы элдергән була...

Мин аның артыннан карап калдым да үз авылыбыз урамнарын читтән килгән кеше төсле күзәтә башладым. Озын бер урам булып Югары оч төшә-төшә дә урамнар чалбар балагы кебек икегә аерылып китәләр. Безнең Аскы урам Кәҗә башы урамына борылып китә, икенче балак очында — Имән урамы...

Урамга чыгып уйлана башласаң, күзгә әлләниләр күренә икән! Рәхимҗан бабайларга терәлеп торган йортта Мәүлиха апалар яшәп ята. Аның ире дә сугышта, үзе бер оя — төп-төгәл җиде кыз белән торып калды, берсенен итәгенә икенчесе тотынып үсеп киләләр. «Өйләрендә хатын-кыз сигез җан булса да, бөтен эшне Биктимер үзе башкара, бичара катынша, идән юа, суын ташый, сыер сава, он или, кызларының оегын ямау да аның өстендә, кышлар буе оек-бияләй бәйли, тула баса», дип безнең Түбән очлар җиз поднос төсле киң битле, гаять аз сүзле юаш кешене бик кызганалар иде. Катынша Биктимер ни арада сугышына да барып керде, «Батырлык өчен» дигән медальне алып та өлгерде. «Шул медаль дигәннәренә күпмерәк жалуния чыгар икән?» дип, борчак эскертләгән җиргә, директор янына киңәшкә Мәүлиха апа ике рәт килеп китте.

Мәүлиха апа җиде кызы, җиде кызыннан да бигрәк үзенең ялкаулыгы белән тирә-юньдә атаклы бер хатын иде. Телгә беткәнлеген әйткән дә юк! Бар иде аның хәтәр чаклары! Хәтерлим! Колхоз җыелышларына көндездән үк килеп утырыр, беркем сайламаса да, президиумга менеп кунаклар иде. Янәсе, хатын-кызлардан авыл активы! Җыелыш саен икешәр тапкыр сүз алып сөйләсә дә, гадәти тормышта телчән апа сәхнәгә менгәч һаман бер тирәдәгене тугылар иде:

— Без, изелгән мөселман хатыннары, гомер буе иргә кол булып интегеп яшәдек... Хәзер слабуды! Влач үзебезнеке! Аяк юдыра алмыйсыз хәзер бездән. Әгәренки иптәш Маркс, иптәш Энгельс, иптәш Ленин, иптәш Сталин булмаса, без бүгенгесе көнгә дә һаман җәтмәдәге балык күк калыр идек. Китапта әйтелгән: хатын-кызлар ирләр белән бер хокуклы, диелгән. Димәк, эшнең зурысы алар җилкәсенә төшә! Колхозны алга җибәрик и яшәсен үзебезнең кадерле сәвит влачы!..

Күпертмә җиңле, бәбәй итәкле озын күлмәген җилфердәтеп кенә йөри иде апаң ул чакларда!.. Чулак Гыйбадулла белән кыҗыр-быҗыры да бар икән дип сөйләштергәләделәр, мәгәр анысының төбенә тоз сала алмыйм...

Утауда да, уракта да гел-гел артта кала башлагач, бәрәңге кишәрлеген алабута басып киткәч, Мәүлиха апаның үзенә дә тел-теш тидерә башладылар. Идарә алдындагы баганага фанер кадаклап, ташбакага атландырып иләмсез сурәтен төшергәч, ул беравык дулап йөрде, җыелышларга бармады, идарәдә күренмәде. Аннары тагын иске гадәтен куа башлады, йодрыгын селкә-селкә сәхнәдә тел тегермәнен әйләндерде:

— Үзебезнең кадерле сәвит влачы изелгән хатыннарга якты юл ачты, ирек бирде, кадребезне күбәйтте. Биргән иректән рәхәт күреп калыйк, мәми авыз булып тормыйк!.. Без мөселман хатыннары...

Мондый минутларда Биктимер абый күзләрен чытырдатып йомып идәнгә иңә, җыелышларда ишек төбенә чүгәләп махра көйрәтүдән бушамаган Гыйбадуллалар аяк тибә-тибә кул чабалар, көләләр иде...

Мәүлиха апаның ялкаулыгын авыл-күрше әкият итеп сөйләп йөри, тирә-як авыллар базарда-фәләндә Югары авыл кешеләрен очратсалар, сүз арасында: «Ничегрәк соң анда, Мәүлиха апаң ниләр кыйрата?» дип сорамый калмыйлар...

Атна-ун көн әлек көчле җил исеп узган иде. Мәүлиха апаларның утыртма читәннәрен торыгы-ние белән аударды, торык хәзер дә җирдә ята. Шуңа эчем пошып, ишегалларына кердем, өйгә үк уздым.

— Өйдәләрме болар?

Өйдә җиһаз-фәлән бик аз, бер аягы бау белән бәйләгәнгә генә эләгеп торган өстәл дә түр сәке, озын ян сәке. Ике-өч урындык. Мич буенда тимерле зур сандык. Сандык өстендә, ачуым да бер килмәгәе, йөз мендәр бардыр, түшәмгә хәтле сыртлап өелгән. Мендәрләр өстендә ак бастырык булып олы песи сузылып ята. Стеналар, кече як бүлмә такта-

сы гына түгел, түшәм-матчасы да, мич кучкары да гәзит-журналлардан кисеп алынган рәсемнәр белән тулган. Чуп-чуар. Кәнфит, чәй кәгазьләре белән тышланган иске чиләкләрдә гөлләр. Бихисап күп гөлләр. Тамчылы гөл, яран, песи борчагы, тагын мин белмәгән гөлләр. Өйнең азмаз буш калган урыннарында кызлар. Кайсы кырын ятып сагыз чәйни, кайсы тәрәшле тарагы белән шытыр-шатыр чәч тарый, ике кыз тәрәзә буенда баш карашалар, иң кечеләре мич алдына утырып көлдән борчак чүпли. Иң түрдә, күгәргән калай төсенә кергән көзге янында, чебен чуарлаган рамда Калинин портреты.

— Өйдә без, өйдә.

Миңа җавапны былтыр гына Арзулар белән унынчыны бетергән озын гәүдәле, житен төсле аксыл чәчле Кәримә бирде. «Авыр аяк» диләр анысын, кырык дүртенче размерлы туфли кия. «Кәримәнең аягын күрмәс өчен генә әллә ниләр бирерсең, бар икән ходаем!» ди безнең әни. «Кәримәгә чабата ясый башласаң, ярты урманның юкәсен туныйсың», дип зарлана чабатачы Минәчтин карт.

Күз булса да, уттай эш өсте икәнен белә, әллә әниләре басудамы дисәм, ул да өйдә икән, кече яктан килеп чыкты, күз кабаклары шешенгән, уң янагында кып-кызыл эз — мендәр җеге эзе. Чәчендә каз мамыгы.

— Искәндәр икән, нинди ир-ат йөри дисәм... Ни жимертеп йөрисең, апаем? Тезең рәтләнәме? Төнлә сызлап интектермиме? Төзәлмәсә, песекләп бака яфрагы капла син аңа, апаем. Фельдшер биргәнгә генә ышанып ятма. Нәфисә дә булдымы дуктыр? Ата-анасы ике бозауга кибәк аера белми иде, бабасы шыр дивана булды, мәчет манарасына менеп үлде. Бик аңгыра бит ул Нәфисә, неме, жиденчене өчле-тугызлы бетерде. Мәктәп директорына алты үрдәк, ике батман бал илткәннәрен беләм, мин белмәгәне ничәдер әле аның!.. Шулай бит? Инде килеп, яфрак каплагач та тезең урынына утырмаса, Дөреш күрәзәсенә бар. Кулы бик шифалы. Өч дистә күкәй, ике йомарлам маенны җәлләмәссең бит? Сыерыгыз бик сөтле шул сезнең, авылда бер. Җилене кисмәк диярсең! Бозавын ни сорадым, бирмәдегез... Менә безнең генә имчәге коргыры... И-и, сорамый да торам: атаңның хаты киләме? Акча салам димәгәнме? Тагын ни, Кәлимуллагыз Кәҗә башының алап авыз Кайнарлар кызына язамы? Сигәк диләр бит аны, төннәрен урыны лычма була ди менә...

Мендәр тау өстеннән лып итеп песи сикереп төшмәсә, белмим, Мәүлиха апа кая барып житәр иде икән?! Песи сикереп тә төште, минем аяк арасына кереп сырпалана да башлады...

Сөйли Мәүлиха апа. Ялган икәнен белеп торып, рәхәтләнеп сөйли. Тирә-юньдә ул белмәгән бер генә хәбәр дә булмый. Иртән тора да өй борынча биләмгә чыгып китә, йөргән аякка йөрем, телгә сөрем нярә, диләр...

Ул сөйли тора, мин аның туктаусыз хәрәкәтләнгән авызына, селкенеп-селкенеп киткән колагына карап торам. Әллә юмаганга, әллә табигый шулай, колак эче кап-караңгы икән аның, әрлән тишеге сыман бөтерелеп тирәнгә кереп киткән. Ишеткән гайбәтләрен колак тишегенә тутырып йөриме әллә бу апа дигән сәер уй күңелемә килде. Борыны итекче безе кебек очлы, теләсә кайсы тишеккә сыярлык, күзләре ярма бөртеге кебек түгәрәк, тере, икесе ике якка тәгәрәп тора, ямьсез дә түгел үзе, жиде бала тапса да, гәүдәсе ыспай, килешле.

Нәфисәдән үлеп көнләшә Мәүлиха апа! Аның олы кызы да Нәфисә белән бергә медицина мәктәбенә укырга Минзәләгә барган иде, йомшак жирен чуан басып укуын ташлап кайтты. Кызлары да әниләре төсле ялкаулар, берсенең дә эшкә, укырга дәрте булмады.

— Ауган читәнегезне ташып бетерәләр бит, — дидем мин, ян сәкегә утырып. Песи минем янга сикереп менде, иркәләнеп алдыма сузылып

ятты. — Көтү каршыларга төшкән Югары оч малайлары суырып алып киткәлиләр.
— Бетермәсләр, — диде Кәримә исе китмичә генә.
— Әйдәгез, торгызып куйыйк.
Мәүлиха апа кызларына карады, олы кызы:
— Әнә, Дилбәр күтәрешсен, — диде.
Тыңкыш Дилбәр чәчрәп күтәрелде, киезләнгән чәчен сынык тешле сөяк тарак белән күпертә-күпертә:
— Нишләп мин йөрим? — дип бик гаҗәпләнде. — Әнә Тәслия тик ята, эше юк.
Тәслия үксергә үк тотынды:
— Сабан туенда күлмәкне кемгә алдылар? Кәримәгәме? Чыксын да күтәрешсен!
— Җылак, җылак, җылкы колак! — дип үртәште Кәримә.
— Ә син авыр аяк.
Дилбәр тарагын атып бәрде, идәнгә тибә-тибә чырылдады, минем алда иркәләнеп яткан песи шым гына мич арасына кереп йомылды.
— Әни-и-и, бу кумагың үртәшә!
— Җитәрегезме, фу, туктыйсызмы? Юкмы? — дип яман кычкырып җибәрде Мәүлиха апа. — Егет кеше алдында оялыр идегез, ичмасам, азрак, фу.
— Егет? Кайда ул егет кеше? — дип борын җыердылар кызлар. Шулай да тиз-тиз мине чолгап алдылар. — Әтәч, Искәндәр генә ич бу! Нинди егет булсын!
Мин кычкырып көлүдән чак тыелып утырам. Мәүлиха апа, алъяпкычын салып ташлап, ишеккә юнәлде.
— Тәмамысы адәм актыгына калганчы, әйдәгез!
Кәримә дә безгә иярде, өчәүләшеп маташа торгач, көч-хәл белән торыкны урынына бастырдык.
— Баганасы төптән черегән икән,— дидем мин.— Алыштырырга кирәк.
Алар тотып торды, мин бүселгән чыбыкларны кыстыргалаштырдым.
— Үзе кайтканчы чыдар әле, — диде Мәүлиха апа.
Ишегалларыннан чатлы башлы таяк табып чыгып читәнне терәттем, исән баганага мунчала белән тарттырып бәйләдем, тиргә баттым.
Эш бетеп калды. Мәүлиха апа да таптанып минем янда тора, күрәм, Кәримәнең дә миңа нидер әйтәсе килә, сорыйсы сүзе бармы, читән күтәрешергә дә шул сәбәпле генә чыккан бугай, куе аксыл керфекләрен уйнатып миңа күз кыса, ым сала. Мәүлиха апа ай-ваена карамыйча аны этеп-төртеп кертеп җибәрде, үзе шундук сорашырга керешге:
— Ничегрәк соң, апаем? Арзу апагыз дәрескә кердеме инде? Ишетмәдеңме, күпмерәк зарплата куйдылар икән? Паек та чыгачакмы аңа? Тагын укытучы кирәкмиме мәктәптә? — Бу урында да ул сүрән генә өй ягына карап алды. Без читән белән мавыкканда тынып торган өй эчендә әллә нинди ямьсез тавышлар яңгырый башлаган иде инде. — Менә кызларым әрәм булып ята... Кәримәне генә алыйк, укыганда, беренчеләрдән үк булмаса да, төшеп калган баламы ул? Төсе-бите дисеңме, уңганлыгы, холкы-фигыле... Фәрештә дә фәрештә, кызым аны да уздырып җибәрә. Тач үзем инде менә! Ул тырышлыгы... Сөлге чиккән әле, берәр җае чыккач күрсәтермен. Искитмәле! Сабан туе батырына тот та бир!
Ул тагын ялт кына өй тәрәзәсенә күз салды да мине култыклап читкәрәк алып китте, теле һаман тукталмады:
— Гәҗитен укый, китабын. Юньле эш табылмады бит шул багалмага! Ун класс укыган башы белән калхуз эшендә йөртәсем килми. Бер кара эшкә башың чумса, беттең инде, очсызланасың. Теге Хәнәфине сугышка алмыйлармы әле? Безнең ирләр анда чиләклэп кан койган-

да оялмыйча коммунист башы белән брүн артына качып ничек ята диген син аны?! Сәвит влачы шуның өчен укыткан мы аны? Шуның өчен акчасын, паегын биреп торамы? Утыны бушлай, керәсине бушлай... И-и... Кәримәне урнаштырасы иде бит!.. Башкаларына түзәр дә идем...

Кәримә укыганда ук Арзудан үлеп көнләшә иде. Арзу яңа күлмәк кимәсен инде, Кәримә үкчәсе белән идәнне төя-төя акырып елап бөтен Аскы урамны, Түбән очны сасыта. Тәки күлмәкне таптыра... Арзу чәчен икегә үреп салса, Кәримә дә үзенең тәрәшлесен икегә аерып сала... Арзу тамбур белән чиккән алъяпкыч бәйләде исә, Кәримә дә укра чыгарган тана күк безләп йөри башлый, тәки таба, тәки сатып алдыра... Икенче көнне карыйсың, аның билендә дә алъяпкыч... Алъяпкычта тамбур белән чиккән гөлҗимешләр...

Моңарчы алар гел шулай каулашып килделәр. Кәримәнең көнчелеген Арзу белми түгел, белә, белеп үчекләшкән чаклары да булгаландыр, андый вакытларда аналы-кызлы алар шартларга җитешәләр иде.

Уңынчыны бергә тәмамладылар... Хәзер Арзу — мәктәптә, укытучы! Ә Кәримә аттестатын кочаклап өйдә утыра, таракан саный... Шуңа күрә алар бөтен өй эчләре белән Арзуны дошман күрәләр, моны яшереп тә тормыйлар...

— Я, кайсы төшенә кызыгалар икән шул күкәйче токымының?! Немец телен беләме ул? Белде ди пычагым, татарчасын юньләп сөйләшә алмаганны... Ару кеше булса, аңа дошман телен өйрәтергә кушарлар идеме? Аның ни әвтәритите бар? Анасы бер юньсез иде, атасы эчеп үлде... Бабасы дисәң, шыр тиле, быржин... Авылыбызда юньлерәк, әвтәритетлы кыз балалар беткән идеме? Менә мин үзем ничәмә-ничә еллар актив булып тордым, райун башлыклары кул биреп күрешәләр иде...

Тагын Кәримәне мактарга тотынды, кемнәрнедер эт итте, мин көләргә дә, ни әйтергә дә белмичәрәк өйгә кереп киттем. Әни кай арада эштән кайтып өлгергәндер, читән күтәрешеп йөргәнне күргән икән, төксе генә:

— Түбән очка тәрәү тәрәргә тотындыңмы? — дип куйды:— Тазаргансың икән. Алай көчең дә ташып торгач, бар, коедан су алып кер. Арып кайттым, җеп өзәр хәлем юк. Өйдә тамчы су калмаган, тавыклар табагы мич төбе төсле кипкән... Бу күлмәгеңә каян дегет тигердең әле? И-и, бала, бала. Салып бир! Аны да юып куярмын... Ничә чуман бәрәңге генә бушатканбыздыр бүген, корыда эш итик дип азапланган көн, алар бер этрәт айгыр күк кызлар өйдә бурсып яталар!..

Су беткәнгә ачуланмый әни, Мәүлиха апаларга кергәнне өнәмәгән. Кәлимулла абыйны Мәүлиха кызлары янында күрсә дә, дерт итеп китә торган иде, йомыш табып шундук чакырып алыр иде...

Соңгы бер атнада ике кеше авызыннан Арзуның исемен ишеттем... Сирай да, Мәүлиха да аның исемен кат-кат талкыдылар... Әллә инде Мәүлиха апа да берәр нәрсә сизенәме?..

Сыңар чиләкне тоттым да урамга чыгып киттем.

## 3

Чыксам, җиде-сигез малай күршеләр каршында кәшәкәле уйнарга җыенып яталар. Кәшәкә — шаулы уен, тавышлы-гаугалы уен, шуңа күрә усал, телчән апалар яши торган йорт тирәләренә кәшәкә тотып килә алмыйсың, уен өчен басынкырак кешеләрнең өй турын сайлыйлар. Мәүлиха апалар капка төбенә барып уйнап кара син, кәшәкәңне тартып алып сырт буйлап берне сылар! Арзуларны да юаш дип булмый, мәгәр

алар бабасы белән икәү генә яшиләр, көндезләрен өйләре буш диярлек, шуңа күрә малайлар алар турына җыйнала.

Сентябрьнең коры, мәшәкатьле көннәре тезелеп китте, һәркемнең бәрәңге аласы бар, кышка утын ташып, аны кисеп-ярып, өеп мазаланалар — малайларның уенга чыгуын сәер иттем. Үзебезнең Түбән оч малайлары быел беренче тапкыр кәшәкәле уйнарга чыкканнар...

Кое чыгырын акрын гына әйләндерәм, күзем малайларда, чылбырны тотып чиләгемне батырыйм гына дигән идем, чылбырым җинеләеп китмәсенме?! Чиләкне юньләп бәйләмәгәнмен икән, төен чишелде, чиләк быгыр-быгыр суга батты... Каушап калдым, кое шактый тирән, бурасы тар, бура агачлары черек-чарык, төшкән чиләкне алу бик читен. Су төбендә чиләк калдырыр идең, әнидән яхшы түгел...

Шундый чакта ачу китереп малайлар кычкырдылар:

— Искәндәр, кил!

— Сиңа чокыр калдырдык.

— Суыңны керт тә йөгер!

— Куегыз әле, — дип, кул гына селтәдем дә кабаланып ишегалдыбызга кердем, өй түбәсенә сөялгән багорны сиздермичә генә алыйм дисәм, өйдән әни килде чыкты!

— Мыштырдыйсың икән, хәрәсән ялкавы,— диде ул ачуланмыйча гына.— Кер уарга су кирәк, казаным буш, ятьрәк йөр, тик аягыңа зыян ясый күрмә!

— Хәзер, әни, хәзер, — дип мыгырдандым.

Әни артыннан ишек ябылуга, багорны эләктердем дә титаклый-титаклый кое янына чаптым. Тез капкачым да онытылды, ашыгам! Ә малайлар кәшәкәгә керештеләр, мине оныттылар да, кычкыралар, сызгыралар, кыза уен!

Кояшта торып яргаланган, каралган багор сабын ныгытып чылбырга бәйләдем, ышанычлы булсын өчен чалбар каешы белән дә беркеттем, хәзер ычкынмас! Иплэп кенә аска төшердем дә салмак кына уңгасулга йөртә башладым. Ташка бәреләме, чиләккәме, белгән юк, чакылдаган тавышлар чыга, чиләк бавы гына килеп эләкми. Тирләдем, тозлы тир күз кабакларын ачыттыра, ачуны китерә.

Кинәт күршеләрнең капкасы ачылды, сыңар чиләген тотып Арзу килеп чыкты. Өстендә озын итәкле ак күлмәк, күлмәк өстеннән кигән йон кофтасын ычкындырып җибәргән, ялан баш. Кәшәкә уйнаучы малайлар янына туктап нидер сорады, мин, аны күрмәмешкә салышып, һаман кое суын бутыйм... Аяк адымнары акрын гына якынлашты, килеп җитте дә:

— Әллә чиләген төшергән инде? — дип куйды.

— Төште шул,— дидем, комач кебек янып. Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.

— Икенче кеше чиләк төшерә инде бүген, — диде ул ягымлы, йомшак тавыш белән.

— Кайсы җебегән кулы тагын?

— Мәүлиха апа! — диде дә Арзу пырхылдап алды.

Мәүлиха апа белән минем исемне янәшә куюлары бер дә минем файдага түгел иде, мин маңгаема төшеп сыланган юеш чәчләрне кулым белән артка тарап аларның өйләренә күз салдым. Урам як тәрәзәләргә кызлар сырышкан иде — безне күзәтәләр!

— Чиләкләрен алдылармы соң?

— Кемнәр?

— Мәүлиха апалар.

Арзу «Мәүлиха апаларны белмисеңме әллә син?» дигән сыман күңелле генә көлеп куйды.

Минем каушаудан берни майтармавымны, кирәгеннән артык каударланганны күреп, ул кулымнан чылбырны тартып алды да, мине читкә-

рәк этәреп, кое авызына башын тыкты. Иңенә үреп салган ике калын толымы да коега таба шуышып төште. Коедан дым исе, черек исе килә, суы бик еракта сыман тонык кына елтырый иде.

— Күрәсеңме? — диде ул, иңе белән миңа кагылып.

— Чиләкнеме? Күрмим.

— Юк ла, иң аста кое чистартканда басып торыр өчен таш менбәр калдырганнар. Минем бабам эше булыр анысы. Коены синең бабаң Җиһангир белән бергә казыганнар алар.

— Минем бабайга да өлеш чыгарганың өчен рәхмәт.

— Усалланма,— диде ул калкынып, толымнарын иплэп кенә ике якка ыспайлап салып куйды. Матур кыз түгел Арзу, әмма гаҗәп сөйкемле. Башкалар да шулай диләр, хәтта минем әни дә. (Егет кешеләрнең әниләре, гадәттә, күрше-тирә кызларының гаеп-кыекларын күбрәк табучан була!) Гаять ипле кыз, бер чакта да юкка-барга тавыш күтәрмәс, усалланмас, башка кешеләргә чәтердәп ябыша торган Мәүлиха апага хәтле аның янында тыелып кала. Ата казлар таламый аны, эт тә куа чыкмый, кәҗә тәкәсе дә сөзми, бөтен авылның котын алып торучы, колхозның таудай дәү үгезе «Мирон» да Арзу очраганда сөрлегеп җир казырга тотынмый, түбәнчелек белән генә баш иеп узып китә. Кәҗә башы урамының эпчи карчык Миңлебикә: «Хәбибрахман бырҗин токымы юньле булмас, сихерчедер, хайван телен сихерчеләр генә белә», дигән, имеш...

Ул буйга миннән шактый кечкенә, шулай да көчле, багорны кое эчендә шундый ипле йөртә, кызыгып карап торырсың! Иелеп маташа торгач, күлмәк якасының сәдәфе чишелеп китте, мин Арзуның йоп-йомры, теп-тере күкрәкләрен күреп телсез калдым...

— Сине сихерче диләр бит, Арзу, — дидем тотлыгып. — Әфсенең укы да чиләкне ал!

— Кем сихерче ди?

Ул чылбырны кулыннан ычкындырмыйча гына миңа карап торды.

— Кем дип, сүз иясе белән йөрми.

— Ә син иясез йөргән сүзләргә бик ышанма!

— Үпкәләмәс дигән идем, әллә ачуың китердем инде?..

— Әйе, — диде ул, — бераз ачу да килә! Сугыш башланган көннән күрәзәләр, багучылар, эпчи карчыклары, ногыт борчаклары күбәеп китте. Сугыш башланасын да белгәннәр, төшләрендә күргәннәр, тегесен юрыйлар, монысын лыбырдыйлар... Курыкма, чиләгеңне сихерсез дә алабыз.

Кызуы үтеп тә китте, ул тагын көлеп куйды.

Борылып карасам, Мәүлиха апа кызлары тагын тәрәзәгә өелгәннәр, тасыраешып безне күзәтәләр.

— Бир әле үземә! — дидем мин, чылбырны тартып.

— Бирмим.

— Нигә?

— Сиңа ярамый. Тезеңне кузгатырсың... Әләкми бит! Болай итик, Искәндәр. Хәзер мин тазарак бер бау алып чыгам да коега төшәм!

Мин ык-мык итеп торган арада ул җил-җил атлап капкаларыннан кереп тә китте. Әлбәттә, кәшәкә сугучы малайларның берәрсенә кушсам, сөенә-сөенә коега төшеп менәр иде, әмма мин кое янында икәүдән-икәү генә шулай озак юануыбызга чамасыз шат идем, арага берәүне дә кертәсем килмәде. Кулымнан килсә, Мәүлиха апаларның өч тәрәзәләрен тиң томалап куяр идем!

Хәзер менә Арзу килеп чыгачак! Әнә!.. Мин шатлыгымны яшереп тора алмадым, көлеп җибәрдем...

Арзу алып чыккан бавының ныклыгын сынаган төсле тартып-тартып карады да миңа тоттырды:

— Бәйлә... Чиләк янына мине төшереп җибәрә күрмә!

— Үзем төшимме әллә, Арзу?
— Сине кое чыгыры чыдатмас.
— Ә сине?
— Җиңел ич мин! Ышанмасаң, күтәреп кара!
Ул үзе дә уңайсызланды, «сиңа ярамый, тезең авырта» дип кабатлады, тагын көлде. Тешләре ап-ак чынаяк кебек, ирennәре сусыл чия төсле алсу. Бер-берсеннән чак кына ераграк утырган ягымлы чем-кара күзләре дөньяга ышанып һәм ышандырып карыйлар... Аның матурлыгы күзләрендә иде бугай...
Малайлар кое янында безнең озак маташуны мәзәк иттеләр, өрәңге тубырыннан ясаган шараны юри безнең яккарак тәгәрәтәләр, ачуым килеп, шараны тибеп җибәрим дигән идем, тезем чәнчеште, ыңгырашуымны сизми дә калдым. Арзу:
— Менә, Искәндәр, кая инде сиңа төшү! — диде.
Дилбегәне чылбыр янына чыгырга ныгытып бәйләдем дә очын Арзуга тоттырдым, ул кое бурасына сырышып үскән, елан кабыгына охшаган саргылт мүк кисәкләрен коя-коя түбәнгә төшеп тә китте. Аның баш түбәсе кое авызында күмелүгә безнең янга чәтердәп-кычкырып Мәүлиха апа килеп житте:
— Бетердең Арзуны! — диде ул, кулларын бутап. — Башын бетердең баланың! Әй, җебегән арыш салмасы! Иске кое бит ул, бурасы черек! Чыгыры да какшау, көч-хәл белән сыңар чиләк суны чыдата иде. Ә монда кеше тиклем кешене... Әй, җебегән!..
Ни әйтим, эндәшмәдем, шулай яхшырак иде. Сүз белән мине җиңә алмаслыгын күреп, Мәүлиха апа курка-курка гына кое авызына иелде, Арзуга кычкырды:
— Бетәсең бит, бала! Үпкәңә суык тигерәсең! И-и, тилекәй!..
— Тимәс,— диде Арзу аста су чопырдатып.— Суык тисә, Дөреш күрәзәсенә барырмын! Ишетәсеңме мине-е, Мәүлиха апау, Дөреш күрәзәсенә дим!.. Шушы араларда гына син дә барып кайттың түгелме соң?
Мәүлиха апа кинәт турайды, түшен киереп ачуыннан калтыранып китте, төкеренде, төкереген чабата башы белән баса-баса карганды:
— Менә бит, ниләр генә уйлап чыгармыйлар? Ничек телләре корышып катмый диген? Дөрешкә бараммы мин? Миңа ни җитмәгән? Кияүгә чыгасым бармы? Өй тулы балам... Менә син агай, ә?! Районга бардым ич мин, районга!.. Кайсы тинтәге Дөреш дигән әле?
Ул күз агы белән тагын бер тапкыр кое авызына карап алды да тагын гарьләнеп түшен киерде, кояшта уңган француз яулыгын рәтләде һәм мыдыр-мыдыр укынып абына-сөртенә китеп барды. Бер-ике минуттан аның әче, зәһәр тавышы ишегалдыннан ишетелде. Ул ярсыйярсый кызларына кычкыра, аларны өйгә куа иде:
— Нәрсә акайдыгыз? Аю биетәләрме әллә? Өйгә керегез! Җыеныгыз адәм актыгы, бәягез бер кием чабатага да тормый, барыгыз!..
— У-у, суык! Су анасы ничек түзә икән монда? — диде Арзу астан.
— Йолдызлар күренәме? — дидем мин аның күңелен күтәрергә теләп. Үзем эчтән генә «салкын тимәсә ярар иде» дип хафаландым.
— Бик күренми әле, — диде Арзу көлеп. Аста тагын су чопырдады.— Караңгылама! Салкын мәгәр! Суы саеккан моның, төбе лай гына, тазартасы бар. Әйтәм җирле бик тиз болгана.
Ул аркасын бурага терәп бая үзе күрсәткән менбәргә — чыгып торган олы ташка баскан иде.
— Мәтәлеп китә күрмә.
— Егылмам,— дип гүләде кое ят тавыш белән.— Таптым берсен. Таптым.
— Бәйлә!
Ул дилбегәне какты, мин чиләкне тартып чыгардым. Мәүлиха апаларныкы икән, өр-яңа чиләк. Багор йөртә-йөртә бер ягына тирән генә

ике эз дә сызылган. Тамга салгансыз дип дулар инде. Дилбегәне төшердем дә, караңгыламыйм дип, читтәрәк басып торам, ә малайлар уйнапмы уйныйлар, шаралары төрле якка тәгәри генә! Нигә тынды әле бу Арзу?

— Югалдың син анда,— дидем мин, кое өстенә түшем белән ятып.

— Хәзер, хәзер... Менә... Таптым табуын!.. Монда тагын әллә нәрсә ияреп чыкты әле, багурга дим... Күтәр, Искәндәр!

Чыгырны сыңар кул белән генә әйләндерә башлаган идем, авыр. Ике куллап ябыштым, барыбер авыр.

— Су анасын тотып бәйләдең, ахры, син, кызый.

Майламаган чыгыр шыгырдый, чыгыр баганалары дер-дер килә, күңелемдә шатлык катыш ниндидер хафа бар. «Салкын тимәсә генә ярар иде сиңа, Арзу!» Кое авызына Арзуның башы күренгәч исем китте, мин төшергән чиләккә иярep үзе дә менгән икән! Менә ул чиләкне җиргә ташлады да ике якка терсәкләрен терәде, калкынды һәм җитез генә җиргә сикереп төште, чайкалды, мин аның кулын тотып алдым.

— Боз булгансың, Арзу!..

Аның күлмәк итәгеннән сары су тама, кул аркалары лай гына, яңакларына, чәч толымнарына чүп-чар кунган. Ул иелеп күлмәген сыкты, суыксып дерелдәп китте:

— Өшетте!

— Йөгер өегезгә, кайнар чәй йот!

Мәүлиха апаларның чиләген кертеп бирим дип иелсәм, безнең чиләк янында яткан, бозау чәйнәгән тастымал төсле җебегән зур гына чүпрәкне күреп алдым.

— Нигә алып менден бу шакшыны? — дип сорадым.

— Коеда ятсынмыни? — диде Арзу, сыккач бөгәрләнгән итәк очларын сыпыргалап.

Мин чатанлый-чатанлый Мәүлиха апаларның чиләген илтеп бирдем, борылып килсәм, Арзу кыска таяк белән баягы чүпрәкне актарып маташа иде. Тукта, тукта, чүпрәк дигәнем хатын-кыз күлмәге булып чыкты түгелме соң? Әйе, әйе, әнә бер җиңе, икенчесе, хатын-кызныкы һәм миңа шактый таныш күлмәк ич бу! Арзу күлмәге! Шуныкы! Директор Зөләйха апа белән мәктәп тарантасына утырып районга мәгариф бүлегенә чыгып киткәндә аның өстендә хәзер ком төсенә кергән, ул чагында яшел бизәкле ак батист күлмәк иде бит! Шул баруыннан укытучы булып кайтты, шул күлмәкне киеп кич буе капка төпләрендә утырды, үз язмышыннан канәгать икәнлеген сиздереп, Аскы урамны тутырып көлде... Егетләр җыелган иде, мин дә чыктым... Тегермәнче Хәбиб малае Сирай өч тапкыр аны биергә чакырды... «Нигә төшкән әле бу мүкләк безнең урамга?» дип шул чагында уйладым бит... Кәримә дә бар иде... Әйе, әйе, бар иде, дәшми-тынмый гына утырды бугай...

Кем ташлаган аның күлмәген коега? Нигә?.. Үзе дисәң... Чиләк өчен түгел, күлмәгенең шундалыгын белеп төштеме әллә?..

Күңелемнән берсеннән-берсе шөбһәле йөз уй йөгереп узса да, анык кына бер нәтиҗәгә килә алмадым, аптырап, миннән дә ныграк аптыраган Арзу янына иелдем. Аның ике күз читеннән ике яңагына ике эз сызылган, ул бу мизгелдә күпне күргән, күпне кичергән олы кешегә охшап калган иде. Менә ул кулындагы таяк белән күлмәкнең күкрәк турын чишеп җибәрде, куркудан чак кына чалкан әйләнеп барып төшмәдем: төен эченнән елан кабыгы, бака боты, әллә нинди укмашып каткан чәчләр, киселгән эре-эре сары тырнаклар, кызылга буялган әкәмтөкәм кабыклары килеп чыкты. Арзу ап-ак булды, мин дә курыктым.

— Синең күлмәк түгелме соң бу? — дидем бераздан.

— Минем күлмәк. Минеке, — диде ул. — Минеке. Юып элгән җирдән югалган иде. Яңгыр көнне пленумга барып чыланып кайттым да юып элдем. Кичтән элдек, иртәнгә юк. Эзләмәгән җирем калмады, җил

очырып алып киткәндер дип тә уйладым, эт-мазар сөйрәп китмәгәнме дип тә карадым... Атна узды... Баксаң, ул мине кое төбендә көтеп ята икән.

— Кем явызлыгы булыр соң бу?

— Хат язып, имзасын калдырмаган, — диде Арзу тураеп.

— Берәрсе белән сүзгә килдеңме әллә, Арзу? Елан кабыгы, чәчләр... Бу бит... сихер... бозым! Сине бозарга ниятләгәннәр!

Арзу башта «юкны сөйләмәсәнә!» дигән иде, үзе дә минем белән килеште:

— Шулайдыр, мөгаен... Бозымдыр... Өр-яңа күлмәгемне әрәм иткәннәр.

Малайлар уенның кирәген бирәләр генә, өзәләр! Шат, ваемсызлар, аларга берни дә юк кебек, сугыш та, колхозның алынмаган ярты басу бәрәңгесе дә... Нәкъ тыныч замандагы кебек шаулашалар!.. Миңа ни өчендер менә бу әшәкелек тә сугыш казасыдыр кебек тоела, әгәр сугыш булмаса, мондый күңелсезлек килеп чыкмас иде дип уйлыйм...

Әни кетәдер, беләм, тик минем ачыргаланып басып торган Арзуны һич тә ялгыз калдырасым килми.

— Сөйдергеч ясатканмы әллә берәрсе? — дигән тинтәк сорау телемнән ычкынганын сизми дә калдым.

— Әкәм-төкәм кабыгын коега салып кыз яраттыралармыни? — диде ул кискен генә. Беләм, миңа ачуланмаганын да беләм, әмма бик нык кәефем кырылды. Тел төбемне Арзу аңлагандыр дип уйладым.

— Искәндәр,— диде ул исен җыеп,— кое авызын ябарга кирәк, хәзер үк кадакла син аны. Берәү дә су ала күрмәсен.

— Ярамасмы?

— Күрәсең ич! Анда тагын башка әйберләр дә булып, чир-чор таралса?

— Кое суын эчкән кеше юк, Арзу, йорт кирәк-ярагына гына алалар.

— Барыбер ярамас! Әллә ни булуы бар. Сугыш заманы диләр аны... Агуланган коелар, елгалар турында ишетмисеңмени?

— Күлмәкне нишләтергә?

— Бер аулакка илт тә күм. Бу турыда әлегә берәүгә дә ычкындырасы булма. Сүз таралыр. Сине-мине виноват ясарлар. Бел... Җае белән үзем бер очына чыгармын. Чыкмый калмам. Табармын...

Ул үтенгәнчә, күлмәкне чишмә тыкрыгының иң аргы башына, кue кычытканлыкка тирән генә чокыр казып күмдем. Үзем күмәм, үземнең күңелгә «юк, болай гына кала торган эш түгел бу... Моның белән генә бетмәс әле» дигән шикле уйлар килә...

Әнигә суны бик соң гына алып кайтып бирдем. Кич җитте.

— Тагын азрак эт куасың калган, — диде ул рәнҗеп.

— Чиләк төшердем. Шуны алып маташтык.

— Авызың белән кош тотып йөрсәң, төшми ни, төшәр! Мәүлихаңыкын алдыгызмы?

— Алдык.

— Аңысы йөри тилереп, тавык мие эчкән нәрсә!..

Әнидән бозымнар, сихерләр турында, Мәүлиха апаның ни өчен тилереп йөрүе хакында сорашасым килде, — кыймадым. Безнең әни артык күп белгәнне яратмый, «башың яшь, үскәч белерсең» дип кистереп кенә куя...

Инде күз бәйләнеп килгәндә лапастан калын-калын такта башлары алып чыктым да эре эшләпәле озын кадаклар белән кое өстен кадаклап та куйдым. Әшем беткәч, кое өстенә менеп утырдым да буталчык, ят уйларга чумдым.

Арзулар тәрәзәсендә сыек кына яктылык шәйләнә, үзе бәләкәй якта, ахры, күренми...

4

Утыра-утыра яныма класташым Рәфгать килеп җиткәнен дә сизми калганмын, кинәт эндәшкәнгә сискәнеп киттем.

— Нихәл? — диде ул, авызын ерып. Иң матур чигелгән сөлгегә лаек көрәшчегә сәлам! Төзәләме аяк?

— Яхшыра сыман, ныгый, — дидем дә ышанычлырак булсын өчен, утырган җиремнән аягымны селкедем.

— Болай булгач яхшы, — диде ул, минем янга утырып.

Тез капкачым кузгалуга иң нык борчылган кеше шушы Рәфгать булды, үзенә күрә моның җитди генә сәбәбе дә бар иде.

Рәфгатьнең әтисе байтак еллардан бирле мәктәптә ат караучы булып эшләгәнгә, алар мәктәп ихатасында ук торалар. Мәктәпнең атлар сарае белән Рәфгатьләр мунчасы арасындагы бушлык — малай чакта безнең төп уен урыны иде. Әле бик бәләкәй вакытта тәтәйле уйнадык без анда, кузналы да, сугышлы да, үсә төшкәч «күн-иләк!» дип шаулый-шаулый бакыр акча чөйдек, өй почмагыннан мүк йолкып алып беренче тапкыр тәмәкене дә шунда тарттык, күпне күрде башлар! Тәмәке өчен сиек тал чыбыгы да татыдык...

Рәфгать — үзебезне белә-белгәннән бирле минем дус. Аның белән уйнау да, зәңгәр күккә карап чирәмдә тик яту да рәхәт. Уенда хәрәмләшмәс, җиңелсә — көлеп кенә үткәрер... Барыннан да бигрәк ул дөньяны шактый күргән егет. Аның бер туган абыйсы (әниләре генә башка) Бөгелмәдә автоинспекциядә эшли иде. Авылда машиналар санаулы гына булганга, без ул серле «автоинспекция»нең ни икәнен бик үк күз алдына китереп бетерми идек, мәгәр Рәфгатьнең абыйсы имән кискән кебек таза, кара мыеклы көләч кеше — елына бер тапкыр бишекле мотоциклга утырып шатыр-шотыр Югары авылга кайтып кергәч, басу капкасы төбенә җыелган малайларга карандаш-карандаш пыяла кәнфитләр дә өләшкәч, ул абый безгә дөньядагы иң бай, иң кодрәтле һәм иң бәхетле кеше булып тоела иде. Рәфгать үзе дә ел саен аларга кунакка бара, бара да атна-ун көн торып кайта иде. Бишенчене тәмамлагач, олы малай сыйфатында ул аларда озаграк торды һәм Бөгелмәдә бик шәпләп русча сөйләшергә өйрәнеп кайтты. Сул кулының дүрт бармагына берәр хәрефтән зур итеп «РАФА» дип тә яздырган, баш бармагы турына өч җәпле якорь сурәте дә кадаткан. Бөгелмәдәге урыс малайлары аны Рафа дип йөртәләр, имеш... Авылда кушаматсыз малай-шалай буламы, Рәфгатькә дә «Рафа-җәфа» кушаматы тигәнәк кебек ябышты... Күзен ачырмыйлар иде малайның... Тик артык исе китми иде аның... Озакмыни, чүлмәкчедән күрмәкче, без дә иске кәвеш корымыннан туш ясап, өч нечкә инәне бергә бәйләп, мунчада сукыр лампа яктысында сул кулларыбызга якорь, урак-чүкеч, тагын әллә ниләр кадатып бетердек...

Алтынчы-җиденчедә без мылтык, хәнҗәр, дарылар белән мавыга башладык, зәңгәр якорьлар, кыяр бакчасына төнге сәфәрләр онытылды... Рәфгать чос егет, каяндыр бер дистәгә якын вак калибрлы винтовка патроны кулга төшергән. «Абый алып кайткан, онытылып яткан» дигән булды булуын, аңа кайчагында ышанып бетеп тә булмый, тиешле-тиешсез яткан әйбер-караларны оста гына «җыештырып» уза торган гадәте дә бар аның. Ярый, ни булса, шул булды, без ун патронга хуҗа идек! Авыл малае өчен бу чамасыз зур байлык иде!

Мин «укытучыдан мылтык сорап торыйк та каргага атыйк» дип кыстыйм, Рәфгать «карганы рогатка белән дә атып була, әйдә наган ясыйк» дип үгетли. Һәм без наган ясап карарга булдык. Кул астындагы иң җайлы материал агач булганга, тоттык та беренче наганны агачтан ясадык. Тоткасы да бар, көпшәсе дә барысы да агачтан, резин белән худланган ударнигы гына тимер, ә күрер күзгә чын наганнан бер дә

ким түгел. Без аны карага буяп та җибәрдек... Патронны агач оясына кертеп иплəдек тә су буена төштек, яшелчә бакчасы киртәсенә кунып «кар-кар» дип акырып утырган ач күз каргага атып та җибәрдек... Черт итте, шарт итмәде, «бәхете карганың, осечка!» дигән булды Рәфгать, кысык күзләрен тагын да кысыбрак. Тагын кордык, тагын аттык, наган тавышыннан шүрләп икебез дә күзне чытырдатып йомабыз, аның кулында атылмагач, йөрәксенеп мин тотындым, юк, шартламый гына! Беренче патронның төбен тишеп, иләкләп бетердек, эчендәге дарысы агып чыкты, шуннан соң гына ударникның патрон читенә — нәкъ кәпселенә бәрергә тиешлеген аңладык. Тегеләй көйлибез, болай маташтырабыз, өй белән мунча арасында мәш киләбез, ашау-эчү онытылды, бер заман Чүке елгасы янындагы печән кибәне төбендә наган шартлады... Атылды да юкка да чыкты наган... Патронны да, агач көпшәне дә таба алмадык. Чәрдәкләнеп беткәндер, ахры...

Мылтыкка төшкән гыйшкыбыз моның белән генә төкәнмәде, бакыр көпшә таптык, шуның бер башын бөкләп агач сапка беркеттек, көпшәнең бөкләнгән очына игәү белән сызык тиштек. Көпшәгә мул итеп дары тутырабыз да кәгазь өстәп төябез, вак кургаш ядрәләр салабыз да мунча ишегенә күмер белән сызган түгәрәккә атып җибәрәбез. Шарт та шорт! Беркөн исә... Рәфгать көпшәгә дарыны мулрак салган булып чыкты...

Наганы уң кулында. Наганы күз турында. Наганы ишеккә төбәлгән. Ширпы кабызып сул кулына тоттырдым... Сул кул утны акрын гына көпшәдәге сызыкка китерә...

Чамасыз каты шартлау колакларны ярды, төтен, ут арасында Рәфгать күздән югалды. Ниһаять, мылтык яңгыравы мунча-сарайларга бәрелеп тынганда, дустымның җан авазы белән кычкырганын ишеттем. «Беттем» диде ул... Карасам, ике кулы белән битен каплап Рәфгать җиргә чүккән, бармак араларыннан кырык эз сызып кып-кызыл кан ага...

— Күзеңме, күзеңме? — дип сорыйм, инәләм, йолыккалыйм, ул дәшми, башын гына чайкый...

Җитәкләшеп абына-сөртенә Югары очка медпунктка менеп киттек. Фельдшер өйдә икән, ул Рәфгатьне караган арада мин дер-дер калтырап ишек төбен сакладым. Байтак торгач, ап-ак марля арасыннан сыңар күзен елтыратып Рәфгать килеп чыкты...

Бәхете, ике күзе дә исән калган калуын, көпшә кисәге артка бәреп, малайның уң күзеннән чак кына түбәндәрәк тирән җәрәхәт ясаган икән. «Күзне фәрештәләр саклый» диеште карчык-корчык...

Каш-керфекләр көеп юкка чыккан, борын, маңгай тирәләре, яңаклар мул сибелгән дары бөртекләреннән зәңгәрсу-чуар булып калган иде...

Моңарчы да Рәфгатьне алай матур дип санап булмый иде. Кара шадра иде ул. Җәенке танау, кысык күзләр, иреннәре калын...

Ат кылы кебек эре бөртекле чәчле Рәфгать, ярасы төзәлеп марляларын сүтеп ташлагач, тагын да шыксызрак, шөкәтсезрәк булып калган иде... «Рафа-җәфа»ны онытып, Рәфгатьне «Монгол баласы Дындып» дип йөртә башладылар. (Без үскәндә шундый бер китап бар иде, язучысы гына хәтердә калмаган.)

Чабата-чабата кара шадралар арасына сибелгән Киек каз юлы төсле зәңгәр дары бөртекләрен күргәч, чулак Гыйбадулла:

«Нытяшний Дындып булган син, парин!»—дип кычкырып җибәрде.

Без дә бурычлы булып калмадык, Гыйбадулла печәннән кайтканда арба чәкүшкәсен тартып чыгардык. Ул йөк өстендә киерелеп ятып кайта иде, бер заман тәгәрмәче чыгып арба күчәре дык итеп җиргә төртелде, Гыйбадулла печән өстеннән тузанлы юлга мәтәлеп төште...

Без терекөмеш бөртекләре күк төрле якка сибелсәк тә, танып калган икән, байтак вакыт үчегеп, сагалап йөрде...

«Ворошиловча ату ярышлары»н без шуның белән тәмамладык, сыер мөгезенә тутырып качырып йөрткән дарыны чыгарып түктек... Рәфгатьнең күз төбендәге җәрәхәт бәрабәренә без акыл һәм гыйбрәт алдык. Минем тез купкач, «аксак калмагаең» дип, Рәфгатьтән дә ныграк куркучы булмады. Кул-аягы исән булса да, буйга өрлектәй озын, көчле егет булса да, ул үзен азмы-купме «гарип», «тамгалы» итеп саный, тамгасыннан хурлана, шул җәрәхәте аны иптәшләре алдында, бигрәк тә кызкыркын арасында кыюсызрак тотарга мәҗбүр итә иде... Шуңа күрә һәркөнне кич, бәрәңге басуыннан кайтышлый, Рәфгать безгә кагылып чыга, хәлемне белешү өстенә, үзе дә күңелен ача, серләрен уртаклаша. Беләм, басуда, эш арасында кимсенеп үк тормаса да, Рәфгать бик үк ачылып та китми...

Хәтта миннән дә читенсенә! Менә утырабыз. Икәүдән-икәү. Аны-моны сөйләшәбез. Ул: «Фронтларда ниләр бар икән?» дип сорый. Мин «Кырда ниләр бар?» дим...

Күрә Рәфгать, кое өстен томалаган такталарны да күрә, кадак башлары тоныкына ялтырап тора, янымдагы балта-чүкечне күрә, әмма сорашмый. Үзем сүз башлаганны көтәме? Сораса ни булыр иде инде?.. Көндезге хәлләрне, Арзуны бозарга теләүләрен аңа сөйлисем килә... Юк, гайбәт итеп түгел, һич! Бозымнар, сихерләр турында ишеткәнем булса да, тормышта моңарчы бер дә очратканым юк иде!.. «Сугыш заманында калка инде бөтен чүп-чар!» — диде әни бер көнне...

— Бәрәңге бетми әле, алайса? — дидем мин, гаҗиз булып.

— Кая бетсен? Кызлар төш авышкач кына басуга килделәр... Кар яуганчы алырга калмагае...

Тагын тынлык...

— Әйбәт чыгамы?

— Ташып бетергесез. Үзе эре, үзе чиста. Шунда ызанда күче-күче белән өябез дә сабагы белән томалыйбыз. Дөнья быел бәрәңге!..

Дустым Дындып, Дындып! Рафа-җәфа!.. Кичә сөйләдең ич син шушы ук сүзләрне, өченче көн дә... Тик кызларның соңга калуын гына әйтмәгән идең? Ялыга башладылармы, туйдылармы?..

— Кызлар үз бакчаларында казынып яталар...

— Алайса, аяк төзәлсә дә мәктәпкә бару юк икән,— дидем мин, балта-чүкечемне юри урыннан-урынга күчереп.

— Бер дә барасы булмасын иде анда!

— Нигә?

— Кызык түгел ич. Мәктәптә дим.

— Кызык дип...

Ул күзләрен кысып миңа таба иелде, менә сиңа мә, авызыннан тәмәке исе килә түгелме?

— Әйдә ташлыйбыз! Син йөрмәсәң, әнкәй мине кыстамый. Син укыганга гына йөртә ул мине. Барыбер сугышка алалар ич, иеме?

— Унынчыларга бронь чыга дип сөйлиләр.

— И-и, эбиләр сүзенә ышансаң! Әнә, Кәҗә башы карчыклары «Мәһди күтәрелгән» дип тә лыгырдыйлар икән. «Туфракны ашап килә», ди...

Рәфгать авызын ерса да, мин көлмәдем. Көләрлек хәлем юк иде.

Ул тирә-юньдә таралган имеш-мимешләрдән көлә-көлә кое өстеннән сикереп төште, кесәсеннән тәмәке янчыгы, бөкләп салган газета чыгарды, эре генә кыланып төрде, кабызды, кое тирәсенә ачы ис таралды.

— Әллә пыскытырга тотынган инде?

— Әһә,— диде ул мактанып.— Басуда укытучылар алдында көйрәтәбез. Илһам белән икебез. Көндез шырпы беткән иде. Арзудан алып тордым. Бер сүз әйтмиләр. Мә, суырып кара...

— Тәмсез,— дидем мин, йөткеренеп.— Мүк тәмләрәк иде.

— Кәнфит түгел инде! — диде Рәфгать.— Укытучыларның ник сүз әйтмәгәнен беләсеңме? Барыбер унынчыны тутыра алмыйбыз, алалар безне. Ә тәмәке тартмаган солдат буламы!.. Эх, тизрәк китәсе иде!.. Әйдә, тәвәккәллик, ә?!.

Әгәр ул сугышка китү турында кайнарланып үгетләмәсә, мин аңа ул кичтә коедан чыккан бозым турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирә идем... Бозым Арзуга турыдан-туры бәйле булганга, аның исемен дә телгә алмый калмас идем... Ә аның исемен телгә алгач... Юк, юк, үз күңелемдә бөреләнеп кенә килгән уйларны Рәфгатькә сөйли алмас идем мин! Ходаем, яратам ич мин Арзуны! Үлеп, шашып яратам!..

## 5

Иртәгесен мин түзмәдем, бәрәңге басуына барырга булдым. Кичә көнозын аяк өстендә уралдым әле, тез төнлә бераз сызлаштырып торды торуын да, бүгеннән калмаска кирәк! Мәүлиха апа кызларына кушып минем исемне дә талкый башламасыннар!

Урамга чыксам, Гыйбадулла чулак белән Сирай кичә без аннан-моннан гына рәтләп куйган читәнне сүтеп ташлаганнар да, яңа баганалар утыртып, чыбыкларын өр-яңадан үреп маташалар. Сирай бишмәтен салып куйган, күлмәкчән генә, чыбыкларны биреп тора, Гыйбадулла тигез, шома итеп тезеп бара. Мине күргәч, икесе дә авыз чалшайттылар.

— Әнә, Аскы урам остасы чыкты! — диде Сирай, башын кагып.

— Әй,— дип кычкырды Гыйбадулла миңа.— Шәп нугыткансың икән син!

— Өстәл янында нугыта торгандыр! Анысына оста! — дип кушылды аңа Сирай.

— Кызлы йортта бер-бер өмете бардыр аның, шуңа тырышкан! — дип өстәде Гыйбадулла.

Кичә ашык-пошык бәйләгән мунчалам җилдә җилферди, телләре тик тормаганда кулларыда эшли тегеләрнең, күз ярмы...

Ни әйтим? «Эшләгәнегез үзегез өчен!» дигән булдым булуын, әмма җиңелүем, мәсхәрәгә калуым көн кебек ачык иде...

Сирайга моңарчы да ачулы идем, бүген тәмам җенем котырды. Тез капкачын куптарды, «хәлең ничек?» дип бер сорап куйсачы!

Басуда көн өйдәгедән тизрәк узды, казыдык, чүпләдек, тутырдык; буаз сыер корсагы хәтле капчыкларны Рәфгать белән Илһам кешелгә ташып торды. Мин дә ташыйсы идем дә, бүгенгә курыктым, йөгенеп китүең бар...

Кичен кайтсам, Мәүлиха апа балта тотып чыккан да мин кадаклаган такталарны каерып азаплана. Эш тотып өйрәнгән кул булса әллә кайчан алып ыргытыр иде, юк кына бит, алай итә, болай, балта йөзе белән кадак суырырга маташа, һич эш чыгара алмый. Ниятен белеп торсам да, башта, әдәп өчен, сәлам биргән булдым, аннары гына:

— Ударник чаклар искә төштеме әллә, Мәүлиха апа? — дидем. «Ташбакага атланып чапкан чаклар!» дип өстисем килгән иде дә, нигәдер тыелып калдым. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшергә ярамаганына күнегеп килә идем инде. Ул да сер бирмәскә булды, ярым көлемсерәп:

— Бер нәгъләт суккыры коены томалап куйган әле менә, ни ачуы булгандыр,— диде. Нугытыбрак суккан иде, балтасы ике такта арасында кысылып калды. Балтаны чыгарырга теләп ике арага бармагын тыкты, балта чыкты, бармак, шүрәленеке төсле, кысылып калды.

Азаплана торгач бармак та чыкты.

— Әлә-лә-лә! —дип чырылдады ул, бармагын суыра-суыра.
— Киселмәгәнме? — дидем мин, күлүемне көчкә тыеп.
— Кысылган киселгәннән яман ул. Менә син дә кысылырга бик яратасың!
Менә бусы инде Мәүлиха апача! Ак дип башлады, кара дип бетерде!
— Нигә алай дисең?
— Димичә! Кулың кычытканга яптың ич син бу коены! Атна буе ялкау симертеп ятканга эчең поша! Без тол хатыннарга мәшәкать ясыйсың килгән!.. Юньле булсаң, уңай эш эшләр идең, әнә Гыйбадулла... Кулы гарип, читәнне коеп куйды! Сирайны әйт тагын, ай-һай, егет икән! Эше өчен бер тиен алмады!..
Сүз озайту файдасыз иде, мин, кистереп:
— Коедан су алырга ярамый хәзер,— дидем.
— Мөгез чыгармасана! — диде ул, бармагын тач-тач суырып.— Нигә ярамасын?
— Анда песи төшеп үлгән. Коены башта нык кына тазартырга кирәк.
— Ә-ә? Песи?!
Үзе шапшак, юбалгы булса да, Мәүлиха апаның җирәнә торган гадәте барлыгын беләм, телемә беренче килгән ялганны ишетүгә аның чырае сытылды, куллары түш турына күтәрелеп, бармаклары белән куркынган хәрәкәтләр ясады, мин кое өстеннән балтаны алып, кузгатылган кадакларны яңадан каккалап куйдым.
— Песи шунда ятамы әле?
— Алуын алдык...
— Өч төсле песи идеме әллә?
— Анысы ни тагын?
— Шулдыр, ярабби, шулдыр!
Миңа кызык була башлады:
— Ничек була ул «өч төсле?» — дип сорадым.
Аның чиркануы да, җирәнүе дә күз алдымда эреп юкка чыкты, йөзе эшлекле, киеренке кыяфәткә керде.
— Атна чамасы булыр, шушы кое тирәсендә ят бер песи уралганын күрдем,— дип башлады ул, иреннәрен ялап.— Әнекәй генәм, карасам... Бел — песинең юньлесе ике генә төсле була аның. Ә бу хәерсез өч төстә иде: кара да, сары да! Шундук саф күңелемә шөбһәле уй инде бит: әһә, димен, мөгаен, юньле хәл түгел бу, казага булыр! Юраганым юш килгән икән, белми йөргәнмен!.. Шул төшеп үлгән инде, алайса!
Үз сөйләгәненә шундый ихлас ышанып, бирелеп сөйли бу апа, ышанмас җиреннән ышанырсың!.. Бер мәлгә күз алдыма әнә шул чирчор таратып йөрүче, бозымнар китереп чыгаручы өч төсле песи килеп китте...
Бер яктан, шүрли төшсәм дә, икенче яктан, җаным тыныч иде: хәзер безнең очның чыбыксыз телефоны бу хәбәрне тарата башлаячак! Югары очка песинең котсыз кәкре койрыгы, дилбегә буе мыегы барып ирешәчәк! Кое тирәсендәге сүзләр аны ябык килеш калдырачак!..
Мәүлиха апа сүздән-сүзгә камылдан йөгергән ут шикелле җинел күчә, ул хәзер бөтен дөньясын эттән-эткә салып сүгәргә кереште, сугыш ачкан фашистларга да эләкте, шулар аркасында авылны ташлап киткән ир-атларны да тетеп салды, монда калган «җебегән сарыклар»ны да тешләде, хатын-кыз өстенә өелгән кырыкмаса-кырык эштән зарланды:
— Тавык суярдай адәм табармын димә, үлсәң үл!.. Пычак үткеннәргә кемгә барыйм? Мал-туарым курмысыз калды... Утыным китерелмәгән!.. Килгәне киселмәгән... Түремдә җиде кыз... Җитмәсә, монда коега песи төшеп үлә! Идән юарга дигән суны да инештән төшеп алыйммыни? Үзе булса, чишмәсеннән ташып куяр иде дә... Үзе юк бит! Нишлим ди мин җиде кыз белән? Нишләде бу сәвит влачы?!

«Иөрисең шунда көянтә күк гәүдәңне сузып!» дип, мине ачуланды-ачуланды да тагын кызларын чәйнәргә тотынды. «Бүген бишесен тотып кияүгә бирер идем, кем алсын, ир заты корыды бит!» дип зарланды. Аннары үзенең ирсез үткән гомерен каргады... Кичә генә «аягың төзәләме, төзәлмәсә фәлән эшлә, күрәзәгә бар!» дип сөйләнгән апам бүген бөтенләй киресен сукаларга кереште: «Төзәлмәсен аягың, аксак булсаң, ичмасам, сугышка бармассың. Аскы урамда бер ир заты калыр. Тик юньсез хатын-кыздан сак бул. Хәзер хатын-кыз бик азынды, әнә Хәбибрахман тумасы да районда бер егет белән бик нык бутала икән» дип сөйләп һушымны алды.

Моңарчы ни сөйләсә дә көлемсерәп кенә тыңлаган идем, әмма Хәбибрахман тумасы дип кимсетеп Арзуның исемен яманлап телгә алгач, ачуым кабарды:

— Иөрмә жыен юк-барны жыеп, Мәүлиха апа! — дип кырт кистем.

Әнисенең озаграк лыгырдавын күзәтеп эче пошкан, ахры, Кәримә тәрәзә ачып кычкырды:

— Әнкәй, кайт инде!

Мин Мәүлиха апаның каныңа азрак тоз сибәргә булдым:

— Кәримә нигә бәрәңге алырга бармый? — дип сорадым.

Апам яшен ташы кебек шартлап ярылды:

— Әле син чүп башың белән минем кызлардан көләргә телисеңме, аксак тәре?! Ун класс гыйлемлеге белән Кәримә тиклем Кәримә синдәй каргалар белән бәрәңге ызанында чүпләнсенме? Үз бакчамны яллап алдырачакмын, беләсең килсә! Кызларыма сыер имчәге тоттырмам, сәнәк-көрәккә якын жибәрмәм! Ефәк кебек кызларны... Сәвит влачы хатын-кызга ирекне биргәнме? Биргән. Ун классны укыган кыз ул! Әлек хәреф таныганнар остабикә булып өйдән-өйгә бәлеш ашап йөргән. Хәзер сәвит влачы! Арзу укытучы булып калсын, ә минем Кәримәм... Сезнең ул Арзуыгыз минем Кәримәмнең кисеп ташлаган тырнагына да тормый! Менә күрерсең, барыбер Кәримә Арзудан уздырыр...

Кәримә тагын тәрәзәне ачты, әнкәсен чакырды, мин дә арыган идем, өйгә кереп аннан-моннан гына капкаладым да урынга аудым... Арзу кырдан туры мәктәпкә киткән иде... Ничек түзә икән ул? Миннән иртә кузгала, менә мин урын өстендә, ә аның кайтканы күренми...

Кое гаугасы моның белән генә бетмәде.

Берничә көн үткәч, бәрәнге басуына иртәрәк өлгерим дип караңгылы-яктылыда урамга чыксам,— өстемдә сырма, башта тула картуз,— көн кинәт суытып жибәргән, үзәккә үткеч вак яңгыр сибәли — карыйм, кое тирәли берәү йөри. Юлаучы икән, яңгырда шәбәргән аты да шунда ук туктаган. Чыбыркы сабы белән кое капкачын күтәреп карады да, мине абайлап (Арзу килеп чыкмасмы дип капка төбендә ышыкланып торам!):

— Киптеме әллә бу? — дип сорады.— Үткән атнада гына ат сугарып үзган идем.

— Суы качты, корыды,— дидем мин, ваемсыз гына.— Бала-чага төшмәсен дип кадакладык.

Кием-салымы чыланып, болай да өтеклэнгән юлчым кинәт иңеп кечерәеп калды, ачык зәңгәр күзләрен челт-челт йомгалады, кителгән вак тешләрен күрсәтеп сәер генә көлеп куйды. Көләрлек бер сәбәп тә юк иде, ачуым кузгалып мин аңа таба атладым, дегеткә манчылган иске бишмәтенә, эт талагандай алама колакчын бүрегенә, юештә чәбәләнеп иягенә ябышкан кызыл сакалына текәлебрәк карадым. Кызыл сакал да китәргә ашыкмады, чыбыркысын артына яшереп миңа таба атлады.

— Алай! — дип сузды ул мәгънәле генә итеп.— Бик аңлыйм... Әле менә теге яклардан килешем. Анда калхузда мал кырыла башлаган. Чутсыз үләләр ди. Сарыкларына әйләнчек булган. Пәтифун тәлинкәсе-

дәй зыр-зыр әйләнәләр ди менә. Ходай күрсәтмәсен. Көзлектә, юньле заманда мал кырыламы? Туклыкта дим? Тиешме кырылырга?

Абзый әллә көлә, әллә елый, бүрек колакчыннары дер-дер селкенә, төссез күзләреннән тонык яшь ага.

— Еласы урында, көләсез икән сез,— дидем мин.

— Кайгыдан көләм,— диде ул борынын сеңгереп.— Кайгыдан! Бу коеның суы нигә кипкән дисең син? Уйнама! Замана авырлыгы берьюлы килә торган була. Күктән алла хәсрәтне җир өстенә берьюлы җибәрә, табигать белән бергә безне дә тикшерә... Адәм баласын, киек җанварларны, мал-туарны бергә сыный. Тиктомалдан сарык муры тараламы? Күлләр кибә, коелар корый... Әнә, Түбән авыл күл ярына пар торна төшеп үлгән, ди...

Арзу китеп өлгергән булдымы шунда, капкалары һаман ачылмады, китәргә вакыт иде, әмма тигәнәктәй ябышкак бу кеше яныннан ычкынып китә алмыйм, ул кайсы ягы беләндер мине үзенә тарта, аның белән бәхәсләшәсем килә, бер үк вакытта аның каты, чуалчык сүзләре алдында үз дәлилләремнең йомшак, зәгыйфь булачагын да тоям. Көчсезлегемне сизү мине, гомумән, гарьләндерә, ярсыта. Кызып әллә ниләр әйтмәкче булам да зиһенем чуала, телем тотлыга. Бүген дә сүзсез-өнсез диярлек калдым. Ә кызыл сакал тигез, нәзек тавыш белән һаман үзенең агуын чәчә:

— Шыпионнар эше бу, шыпионнар кыландыра! Килә бит мимеч, килә... Ай килә!.. Шыпионнар җибәрми дисеңме әллә син аны? Мин, агайне, барын белеп, күреп торам... Кыяфәткә карама син минем!.. Заманында дөньясын авызлаган дәдәң булыр бу! Булгахтер ием мин...— Ул куш бармакларын аркылы-торкылыга куеп, рәшәткә ясады.— Читлеккә япмасалар, арыслан-киек идек тә без... Эх-хи-хи! Томана зирәкләр! Шыпионнар эшен аера белергә кирәк. Буага яисә коега бер-ике генә бөртек төрекөмеш салып кара әле менә син! И-и, вәссәләм! Суы җәһәннәмгә уба аның. Белми дисеңме мимеч шуны? Белә-ә, бик белә-ә-ә!

— Юкны һәм кирәкмәгәнне сөйлисез,— дидем мин. Ул миңа карамыйча гына:

— Әй, бу теге, ни, пружин Хәбибрахман өе буламы? — дип сорады.

— Белмим,— дидем мин, ачуымнан шартлардай булып.

Кызыл сакал камыт бауларын тарта-тыгызлый нидер мыгырдап калды, мин юлымда булдым.

Кичен мине Арзуның бабасы Хәбибрахман карт үзләренә чакырып кертте.

Янәшә күршеләр булсак та, без аның белән күзгә-күз сирәк очрашабыз, гадәттә очрашканда да сөйләшмибез. Мин һәрвакыт аны олылап, башымны иеп сәлам бирәм, ул исә сәламемне алган чакта ала, алмаганда, мунчала кебек чәбәләнгән ак кашлары астына кереп поскан яшькелт күзләренең кырые белән генә карап янымнан уза. Беләм, андый минутларында ул яныннан узучыларны бөтенләй күрми, мин генә түгел, өлкәнрәкләр дә аның сәламен сирәк ишетәләр, ул күбрәк вакытын без белмәгән, без аңламаган тирән, серле уйларына чумып уткәрә.

Мөнәсәбәтләребезне яхшы белгәнгә, чакыруының юньлегә түгел икәнлеген чамалап кердем.

— Песи төшеп үлгән диденме син коега?

Бу инде Мәүлиха түгел, колагыңны шаңкайтеп торсаң, бирер кирәгенне!

— Шулайрак иде шул,— дидем мин, мөмкин хәтле гөнаһсыз күренергә тырышып.

— Ул песине кемнәр күрде?

«Каптым!» дип уйлады күңелем, телем:

— Чиләк төшкән иде, шуңа иярел чыкты,— диде.

— Үләксәсен кая илттең инде син анын?
— Кая дип... күмдем...
— Үләксә базына бардыңмы?
— Юк ла, әнә тыкрык башына гына илттем.
— Песие ни төсле иде! — дип төпченде ул.
— Пычранып беткән иде, төсен аермадым,— диде ялганларга остарып барган телем.
Ул беравык миңа сынап карап торды да башын чайкады:
— Мөсафирны нигә алдадың, алайса? — диде.
— Кайчан? — дидем мин, ни әйтергә белмичә.
— Үзең беләсеңдер инде... Бездә, «фәлән авылларда мур чире таралган» дип китте... Ә күрше авылга барган да «Югары авылда коелар кибә» дип сөйләгән... Кем гаепле инде шуңа?.. Син аның кемлеген беләсеңме?
Тыңлап торганмы дисәм, урамда берәү дә юк иде бит, капкалары ачылмады, ишегалларыннан безнең сөйләшкән ишетелерлек түгел, әллә теге юньсез сакал күрше авылларда шундый гайбәт таратып йөри дә башлаганмы? Аны Хәбибрахман абзый каян белгән? Кем ишеттергән?
— Мин аның кемлеген белмим, мәгәр ул сезне белә! Өегезне сорады.
Хәбибрахман абзый усал гына көлемсерәде.
— МТСта бухгалтер булып эшли иде бер заман. Хөкүмәтне имеп кенә түгел, талап та караган бәндә ул! Ярканат!.. Ә син шуңа җыен юк-барны тоттырып җибәргәнсең... Алдарга осталыгың бар икән. Бусын көтмәгән идем. Бабаң андый түгел иде, атаң да... Шулар хөрмәтенә генә булса да соңгы соравыма дөресен әйт: нигә бу араларда Арзуны сагалап йөрисең син?!
Коелып индем! Кызыл сакалның «шпионнар эше» дигәне хәтергә төште. Хәбибрахман картның, төнге ябалакның, үз шпионнары бармы әллә? Барын да белеп, сынап, күңеленә төйнәп йөри икән! Шул төене белән минем җилкәгә хәзер шундый кундырды... Шыпан-шыпан гына чыгып сыздым...
Бабасы төшенгәнне Арзу үзе әллә кайчан төшенгәндер, шиксез! Әллә бабасына үзе сөйләп биргәнме? Икәүләшеп көлешә-көлешә аңлашканнармы әллә алар?!.
Соңгы көннәрдә бәрәңге басуында колхозчылар, укучылар белән бергә, Зәйдән килгән промкомбинат эшчеләре — кирпеч сугучылар, мунчала кабыгы төшерүчеләр, кап сугучылар да шактый тырыштылар, эш күзгә күренеп үрчеде, алга китте, укытучыларның күбесе яшьләр, тәҗрибәләре юк, методиканы белмиләр, «төшкә хәтле укытыйк та төштән соң кырга чыгарбыз» дип гозерләп идарәгә бардылар. Һәм без укый башладык, табигый буларак, Арзу да чын укытучы сыйфатында беренче дәресенә керде. Ничек барып чыгар икән, беренче тапкыр класска аягын ничек басар дип шактый борчылган идем, очрашу мин көткәнгә караганда шактый шома, ботаксыз-сатаксыз булды.
Каядыр очарга җыенгандай алга сөрлегебрәк, тиз-тиз атлап класска керде дә ишекне иплән кенә япты Арзу, тынлык урнашканын көтәргә дә сабыры җитте, елмайды. Арткы партадан кемдер тыенкы гына сызгырды, кызлар «тс-с!» дип пышылдап аны туктаттылар, яңа укытучыбыз каушавын сиздермичә генә һаман көлемсерәде, йомшак тавыш белән, нәкъ бүтән вакытларда сөйләшкән кебек, сүзен башлады:
— Укучылар, яшерене-мазары юк, немец телен үзем дә белмим мин. Чынчыны гына бетердем. Хәснимәрдән абый сугышка алынды... Тормыш шулай куша икән, телне бергәләп өйрәник. Сез шуңа риза булсагыз, мин районда — райкомолда да, РОНОда да ризалыгымны биреп кайттым...
Дәррәү «риза!» дип кычкырганыбызны сизми дә калдык...

Кичә педсовет утырышы булды. Директор бүлмәсендә ут сүнгәнче, бакчадагы иң зур чыршы астында мин басып тордым. Вак яңгыр сибәли. Көн дә тынмый хәзер, төн дә. Суык. Укытучылардан соңгы ир кеше — завучыбыз Хәнәфи абыйга чакыру кәгазе килгәнен беләм. Повестка. Анда, педсоветта, шулай озакка калып Хәнәфи абыйның физика дәресләрен бүлешәләр. Хәнәфи абыйның китәсен ишетеп, Мәүлиха апа бүген көне буе авыл буйлап чапты, безгә дә ике-өч тапкыр кереп чыккан...

— Кәримәдән кулайны таба алмаслар алар,— дип үгетли икән минем әнине.— Физиканы гына түгел, әллә нәмәрсәкәйләрне теттереп укытырлык бала... Шул Хәбибрахман җенлесе генә карышса инде... Шул аяк чалса... Гомергә Кәримәдән, аның матурлыгыннан көнләшеп яшәде... Кәримәм урнашса, ичмасам... Җаным тыныч булыр иде!

Соңгы керүендә мин дә бар идем, әни Арзуны яклап бер-ике сүз әйтте дә тынды, Мәүлиха апа белән телгә килгәнче, чалгы янавычын ялармын дип әйткәне бар аның. Шүрли.

Мәүлиха апа Хәнәфи абыйга, «юл күчтәнәче» дигән булып, тавык суеп китерде, директор янына өч-дүрт тапкыр кереп чыкты. Аның шулай эшлекле төстә ашыгып йөргәнен, бөтен кешегә ягымлы эндәшкәнен гомердә күргәнем юк иде...

Чыршы карт, ботаклары куе, көн яктысында, кояшта алар миңа тередер кебек тоелалар, куе ботаклар арасында яшертен сер бардыр дип уйлыйсың; өскә үк явып тормаса да, һава барыбер дымлы, черек, борын эчен кытыклый, туктаусыз төчкертә. Өс-баш та җиңелчәрәк, шуңамы, туңдыра башлады.

Мәктәп тәрәзәсендә күләгәләр йөри, менә кузгалдылар, утны сүндерделәр. Агач ышыгыннан чыгып, койма артынарак якынайдым. Моннан ишек ерак түгел, караңгыда да кемнең кем икәнен аерып була. Директор Зөләйха апа, Хәнәфи абый һәм Арзу иң артка калып чыктылар. Тирә-як тын. Башкалар, озак утырып ялыкканга, тиз-тиз таралыштылар, төн тынлыгын аяган яңгыр да мыштым гына сибәли, сөйләшкән сүзләренең дәвамы миңа да аермачык ишетелә, директор да, Хәнәфи абый да Арзуны кызып-кызып үгетлиләр, димәк, физикадан да өлеш чыгарганнар дигән сүз.

— Классыгызда беренче укучы идең, — диде Хәнәфи абый.

— Хәзер коллективта иң актыккы укытучы булачакмын. Шуны телисезме? — дип карулашты Арзу.— Болай да минем хакта юк-бар хәбәрләрне тараталар...

Мин сагайдым: ачармы серне, юкмы?

— Барыбыз да шулай курка-курка эшли башлаган,— диде Зөләйха апа.— Педучилищеның икенче курсыннан укытырга җибәрделәр, мине... Кадрлар җитми иде. Өс-баш, ташка үлчим... Белем — такыр. Авылның ындыр артыннан башка дөнья күрмәгән дә... Укытасы авылга кыш уртасында барып төштем, мәктәп мөдире бер олаучыга карый, бер миңа «Сезнең кайсыгыз укытучы соң?» дип сорый. Теләсәң ела, теләсәң көл... Әкренләп өйрәнерсең...

Арзу зәгыйфь тавыш белән:

— Әллә Кәримәне чакырып карыйбызмы? — дип сорады.

Хәнәфи абый хатын-кызларча кеткелдәп көлеп алды. Зөләйха апа Мәүлиха ападан тамчы да курыкмый икән, калын, ямьсез тавышы белән ишегалдын ярып:

— Үскәнем, сөйләмәсәнә җүләр сүзне! Кәримәне унынчыдан этеп-төртеп чыгардык. Ата ялкауны мәктәпкә китерәммe? — дип ачуланырга ук тотынды.

Алар таралыштылар. Мин Арзу артыннан үзебезнең очка кайтып барам. Куып кына җитәсе иде дә култыклап аласы иде! Әмма нишлим, ул укытучы... Мин аның укучысы... Бер караганда, бу киртәне сикереп

чыгу бик ансат кебек тоела... Әмма мин тыйнак, әдәпле идем шул, юаш идем, куркаграк идем...

Дөнья караңгы. Өйләрдә утлар байтактан сүнгән. Анда-санда гына саташып-ыңгырашып этләр өреп ала. Кайдадыр, тынлыкны сискәндереп, майламаган ишек шыгырдый, мыдыр-мыдыр укынган йокылы тавыш килә, комган шалтырый...

Арзу ялгызы курка, аның капка төпләреннән, тыкрык авызларыннан читтәрәк узарга тырышуы күренеп тора. Тыкрык турына килеп житә башлады исә, урамның икенче ягына каерыла, бераз атлый да туктап тыңлана, тагын китә. Бер урында мин ташка абындым, ул шып туктады...

Хәбибрахман картның иртә-кич капка бикләгәне юк. Арзу туп-туры өйгә кереп китте, ут кабызды. Китап-дәфтәрләрен таратып өстәл янына утырды. Җиңел суладым. Үзебезгә таба борылган гына идем, кое чыгыры артында кара күләгә кыймылдаган төсле булды. Күңелгә кара шик йөгерде. Үз турыбызда кайда-нәрсә ятканын беләм, иелеп саллы гына таш алдым да коега таба бер атладым, ике, тавыш-мазар ишетелми, йөрәгем тук та тук тибә. Юк, беркем юк, кем булсын... Шулай да җан ачуым белән ташны кое бурасы артына, шәүлә шәйләнгән урынга тондырдым. Беркем кыймылдамады, селкенмәде, шулай да бер читтә мышнаган тавыш ишетелгән кебек булды, ныклабрак карасам, кап-кара бер шәүлә йомылып кына чишмә тыкрыгына элдерә! Икенчесен дә тиз таптым табуын, бала башы хәтле ташны ике куллап тотып, лап-лоп баса-баса тыкрык авызына чабып кердем. Теге шәүләне куркытыр өчен юри катырак басам! Ташны тондырыйм гына дигән идем — абынып та киттем, барып та төштем. Ташым бер якка, үзем икенче якка, кычыткан арасына тәгәрәдем. Кычыткан арасыннан соңгы котны куып песи чыгып чапты.

Әллә бая да песи мәлгунь шәүләсен кеше дип уйладым инде?..

Ул арада булмады, мин куа барган шәүлә чын кеше кыяфәтенә кереп чишмә сукмагына таба йөгерде, мин, торып, әл-хәл алганчы караңгыга кереп югалды да... Борылып кайтып килә идем, каршы якта сузып кына капка шыгырдады... Ни булды бу? Әллә икәү булып берсе мине чалып екты инде?..

Ул төнне мин тиз генә йокыга китә алмадым.

Арзулар тәрәзәсендә дә ут озак кына сүнмәде.

Елан кабыгын, әкәм-төкәмнәрне күргәч тә күңелемә Мәүлиха апа килде. «Шулдыр, дип уйладым, аннан башка кеше «бозам!» дип йөрмәс». Мәүлиха апаның көнчелеген дә, көнче кешенең кулы әшәкелеккә барачагын да аңлый идем.

Инде бер дә көтмәгәндә теге кызыл сакал Хәбибрахманнар өен сорагач, мөсафирның «кыскача биографиясе» белән дә танышкач, Мәүлиха апа күңелдән читкәрәк китеп торды.

Хәзер менә кое янындагы шәүләләрдән соң ни уйларга да белмәдем. Мәүлиха апа йомыш белән лапаска да чыкмый, куян йөрәк диләр... Ярты төн җиткәндә чит авылның өлкән бер кешесе урамда буталырмы икән, ай-һай!.. Димәк, монда мин белмәгән, мин уйламаган өченче кеше булуы да ихтимал... Әгәр алар икәү булып чыкса?!

Нишләп йөриләр алар? Кемне сагалыйлар?

Күңелем төбендә шушы көзге, юеш төн кебек үк кап-караңгы иде...

## 6

Арзуга мин гади күрше кызы итеп кенә карый алмый идем. Минем кыюсызлыгымның төп сәбәбе бәлки аның укытучылыгында да булмагандыр... Сәер яшиләр иде алар, безнеңчә, авылча түгел, Хәбибрахман

карт үзе дә үтә чыккан гаҗәп бер кеше иде! Фамилиясе үк кызык — Ямашев! Безнең авылда гына түгел, тирә-күршеләрдә дә Ямашев фамилияле кеше юк. Онысына — улының кызына да агай-энедә очрамаган ят исем табып — Арзу дип ул куштырган.

Заманында үтә гаярь кеше булган диләр аны! Оренбург далаларында Дутовка каршы сугышып йөргән, яраланган, Блюхер отрядында да булган диләр, хәзер анысын дәшмиләр. Русча укырга-язарга да шунда отрядта өйрәнгән. Ел саен өенә «Правда» алдыра. Әле районнар волость булганда ук аны авыл активы итеп санап йөрткәннәр. Югары авылда «Икмәк контрактацияләү ширкәте»нең вәкиле итеп тә аны сайлаганнар. Ул чакларда кулаклар икмәкне совет властеннан яшерә торган булганнар, икмәккә мохтаҗ яшь республика икмәк контрактацияләү өчен ширкәтләр төзегән. Хәбибрахман абзый авыл байгураларыннан (ә алар безнең кара туфраклы, урманлы-сулы Югары авылда дистәләп саналган!) дәүләт файдасына икмәк җыя торган булган. Тирә-як авыллардан да шул җыйган, икмәкне байлардан алганнар да ярлыябагайга чәчүлек орлык биреп торганнар, кала эшчеләренә озатканнар, пычакка-пычак килгәннәр...

Мең тугыз йөз егерме тугызынчы елда авылыбызда колхоз оешкан. Хәбибрахман абзый беренчеләрдән булып колхозга кергән, аны Чистайга колхоз оештыручылар курсына укырга җибәргәннәр, ул шунда биш-алты ай укып кайткан. Хисапчы булып эшләгән, тора-бара председатель итеп сайлаганнар үзен. Ул рәис чакта авылдан кулакларны сөргәннәр, кулакларның каралты-кураларын сүтеп, һәркайдагыча, авыл Советы һәм идарә йорты салганнар. Мәчетләрнең берсендә клуб оештырганнар, манарасын кисеп ташлаганнар...

Боларында бер дә сәерлек юк әлегә, заман, тарих нәрсә кушса, шуны эшләгәннәр Хәбибрахман абзыйлар. Районда беренче сарык фермасы да безнең авылда салынган. Ферма төзегән көннәрне мин дә хәтерлим: эш тәмам булгач, бөтен авылны җыеп күмәк табын әзерләделәр, ике тана суеп, борчак ашы пешерделәр. Олылардан соң йомычка җыеп йөргән малай-шалайга да, ягъни безгә дә, сый әләкте, бүксәләр кап булганчы, шартлаганчы тәмле, өреле борчак эштие ашаган идек...

Утыз өченче елның унөченче маенда Казанның элекке цирк бинасында ударник колхозчыларның беренче республика съезды ачыла. Рәфгатьнең әнисе Миңсылу апа белән Хәбибрахман абый шул съездга делегат булып баралар. Хәбибрахман абзыйга бүләк итеп мех бүрек белән патефон, ә Миңсылу апага әйбәт күлмәклек биргәннәр. Безнең «Ленин юлы» колхозын дүрт лобогрейка белән бүләкләгәннәр.

Утыз бишнең башында бездән җиде генә чакрымдагы Ташлы МТСының нефть хуҗалыгы янып китте. Склад мөдире белән каравылчы «тычкан уты» фонаре тотып подвалга төшкәннәр, анда бензин газы җыйналган булган, янгын чыга... Кара буран, күз ачкысыз буран котырган көн була бу! Нефть хуҗалыгы төп корылмалардан чакрым ярым читтә утырганга, беркем берни белми дә, күрми дә кала... Мөдир дә, каравылчы да эзсез югалалар...

Безнең Хәбибрахман абзыйны политбүлек начальнигы чакырып ала. «Сынадык, кулыңнан эш килә, кыюлыгың да мәгълүм. Танышлыгың да бар. Нефть хуҗалыгын ашыгыч рәвештә аякка бастырырга кирәк! Тотын шуңа. Язгы чәчүгә хәтле эш тәмамланган булсын, иптәш Ямашев», ди.

Рәислеген тапшырып, Хәбибрахман абзый шул эшкә күчә һәм нефть хуҗалыгын өр-яңадан төзеп, рәткә керткәч, аны мөдир итеп шунда калдыралар.

Бусына инде бөтен авыл шаккатa!.. Ничек инде, колхоз шулай акрынлап чәчәк атканда, нефть хуҗалыгындагы өнгә кереп бикләнә!.. Якын кешеләре беләләр: Хәбибрахман абзыйның гомер буе йөрәген

ғалаган бер адәм була. Ул кеше — аның бердәнбер улы. Арзуның әтисе Мөлек Ямашев иде...

Яхшы хәтерлим мин ул кешене дә! Шалкан мае белән ялтыраткан чәчен ике якка тарап, итәге чигелгән алсу-кызыл күлмәген чалбардан чыгарып, зәңгәр чуклы ээәр белән буып йөрүче, шыгырдавыклы хром итекләрен иң эссе көннәрдә дә салмас бу шома, елгыр кешене, ничектер, мин дә яратып бетерми идем. Очраган саен я кызыл билле прәннек, я чуклы кәнфит биреп китсә дә, Мөлек абыйның төчелеген, сөрмәле читле оятсыз-зәңгәр күзләрен, тук мәче төсле мырлап, авызын бөрештереп сөйләшүен бала чактан ук сөйми идем. Мөлек абый узып киткәч, җилле көн булса да, Югары авыл урамында хушбуй исе озак вакытлар аңкып тора иде. Хатын-кыз балга ябышкан чебен кебек сырыша иде Мөлек абыйга! Әле өйләнгәч тә ул юньләп өендә тормый иде, аулак өйләргә йөри, кунак кызлары белән куна, яшьрәк тол хатыннарның сукмагына үлән үстерми...

Гомере буе эштән, хезмәттән башканы белмәгән Хәбибрахман картның күңелен аңлап була! Нәселенең тоткасы, бердәнбере игенче хезмәтенә хыянәт итсен әле!.. Үгетләгәндер ул аны, тик Мөлек абый атасының ай-вайларын җиргә салып, үзләренә итек басарга кергән Кужаш урысларына ияреп кәсепкә чыгып киткән. Ул чагында карчыгы күкрәк бакасыннан үлгән була. Хәбибрахман абзый тәмамысы бер ялгызы кала... Мөлекнең беренче хатыны бала тапмаган, озакламый аерылып китеп тә барган...

Аның итек басучы булып китүен дә, икенче хатынлыкка күрше Түбән авылдан вак сәүдәгәр, күкәйче Гариф кызы — бөдрә чәчле, ал иренле, хихай да михахай йөрүче кынҗыр Фатыйманы алып кайтуын Хәбибрахман карт бер дә, бер дә өнәмәгән! «Рәислеген ташламый иде ул, нефть базасына барып олакмый иде, әнә шул ала күзле суык аяк Фатыйма аркасында үз нигезен сөймәс булды», дип сөйлиләр иде безнең өй эчендә...

Мөлек читтә тагын да шомарган, көмешкә ярата башлаган, Фатыймасы ирен эзләп чыгып йөрергә гадәтләнгән. Мөлекне эзәрлекләп барып, көннәр буе бәрәңге ызанында сагалап утырып, Кужаш марҗалары яныннан якалап та алып кайткалаган... Инде марҗалар артыннан көпә-көндез сиптерә башлагач, кемнәрдер аның сырт сөяген каезлап, икеме-өчме кабыргасын да сындырып кайтардылар. Арт саны имгәнгән эт кебек сөйрәлеп кайтса да, атна-ун көн уздымы икән, Мөлек тагын шыгырдавык итекләрен киеп алды, хушбуй исе таратып Югары очка менеп китте һәм аны утырмага килгән кәнтәй Ләйсән яныннан чормадан тотып төштеләр...

Гомере озын булмады аның, эт кебек, чит кеше бусагасында, әллә кайда, ар ягында сукыр эчәгесе шартлап үлде. Аны агач табутка салып алып кайтып, зиратның бер читенә, аулак почмакка күмделәр. «Табутын да ачып карамадылар, чыраен күрергә теләгәннәр булмады», дип, тирә-юньдә бу хәлне могҗиза итеп сөйләделәр...

Күкәйче генә булса да, Гариф хәлле, атлы-түнлы кеше иде. Бай-кулакларның теш кортына әйләнгән кайнатасы Хәбибрахманны күкәйче Гариф кызы ирдәүкә Фатыйма, әлбәттә, яратмагандыр! Мөлек гүргә кергәч, ел ярым тордымы икән, Донбасстан сабан туена кайткан базык кына, тәбәнәк кенә бер керәшче татарга ияреп китеп тә барды. Хәзер шахтерларга сталовой пешерә икән, күргән-белгәннәр: «Килешкән күкәйче кызына казна камыры! Беләкләре кабартма-кабартма булган, арты тегермән ташы хәтле!» дип, ярым шаяртып, ярым җирәнеп кайтып сөйләделәр. Фатыйманы бай кызы булганы өчен дә түгел, кияүгә чыгып киткәне өчен дә түгел — бердәнбер баласы Арзуны үзе дә карауга мохтаҗ бабасында калдырып киткәне өчен әрләделәр.

Башта Арзуны алып китәргә яшь ире каршы торган. Инде ирне — шахтерны суык күлдә җебетеп, кояшта киптереп, талкыда кат-кат талкып, тәмам бау ишәрлек итеп йомшак хәлгә китереп житкергәч, Фатыйма Арзуны үз яннарына алдырырга теләгән, мәгәр ул чагында Хәбибрахман карт аяк терәп каршы килгән. «Нәсел-нәсәбе затсыз, бер кияү белән генә гомер уздырачак түгел Фатыйма, минем канымны кияү саен сөйрәп йөрми торсын әле, үз сөягем үзем!» дигән...

Кулында көч, беләгендә җегәр бар чак, район каршында да абруй җитәрлек, авылда да куәтле кеше, шуларга аркалангандырмы, бирмәде әнисенә Арзуны, янында алып калды. Теге базык шахтер да мәкерле булган, кызны бирмәүләрен үтенеп картка хат язган икән, дип тә сөйләделәр.

Бар иде Хәбибрахман абзыйның төп-төз буйлы, таза, нык жилкәле, җеп-җирән чаклары! Хәзер бөкрәйде, йөреш-торышы үзгәрде, нәтиҗәдә, аның тезен бөкләп, алга сөрлегеп, селлин-селлин атыпып йөрүен мәзәк иткән кешеләр «пружин» дигән кушамат тактылар. «Пружин» дигәннән тәм табып бетермәгән татар авызы бер заман аны «Быржин» дип җайлаштырды да куйды!

Заманында авылның иң абруйлы, иң мөгтәбәр адәмнәреннән берсе Хәбибрахманның ил агасы булып утырыр көннәрдә гап-гади «Быржин»га әйләнүенең ике сәбәбе бар иде. Бердән, игелексез улының башыннан кичкәннәре аны бик талады, икенчедән, ни сәбәптәндер, байтак гомер узгач, Ташлы МТСының януы тикшерү органнарына яңадан әйләнеп кайтты. Хәбибрахман абзыйны зурлап эшкә чакырган политбүлек начальнигын эшеннән очырдылар, моның кара күләгәсе аңа да килеп төште... Ташлыдан әйләнеп кайткач, аны яңадан председатель итмәделәр. Басу артындагы зур чүннеккә умартачы булып керде ул. Җәй буена авылга кайтмыйча, безнең күзгә-башка күренмичә шунда ятты. Көзен авылда: «Корт угы ярамый икән, Хәбибрахманның кан басымы бик нык күтәрелгән», дигән сүз таралды. Рас булды, ахры, агачлар шыбырдашып яфрак коеп утырганда, явымлы-юеш көндә кабык арбага Арзуны утыртып Хәбибрахман авылга кайтып керде, тәрәзәсенә аркылы-торкылы кадакланган такталарны каерып ташлады, көне буе ишегалдында уралды...

Арзу белән без бала чактан бергә уралып үскәнгә, аларның авылга кайтуларына мин бик сөенгән идем!..

Хәбибрахман карт ат караучы булып керде. Арзу белән без сугыша-татулаша мәктәпкә йөри башладык...

Арзу «бабаем, бабай!» дип өзелеп торса да, Хәбибрахман карт бер чакта да аңа «кызым, балам» дип эндәшми, иркәләми, бабасының Арзуның башыннан сыйпаганын, тегендә-монда барып күчтәнәч-мазар алып кайтканын хәтерләмим...

Түбән очта Арзу бер иде! Ике яктан ятим, аз сүзле, кырыс бабасы белән генә тора, кайсы йортка барып керсә дә, аның тамагын туйдырырга тырышалар, җылы сүз әйтеп юаталар. Сабан туе көннәрендә иң күп бүләк аңа эләгә!.. Үсә төшкәч, ул матур гына җырлый башлады, аны бик теләп, чакырып җырлаталар, ул җырлаганда карчык-корчыклар шыпырт кына балавыз сыгалар. «Ятим бала шул, моңлы бала!»

Беренче башлап Мәүлиха апа аны чит итте. Үз кызлары ишәйгән, үскән саен ул Арзуны күрәлмас булды. Аның сәхнәгә чыгып җырлавын «сансызлык» дип, кешеләргә ягымлылыгын «әрсезлек» дип бәяләде...

Без үсә төшкәч тә Арзу белән дус булдык, бергә уйнадык, көтү каршысына, җиләккә бергә йөрдек. Кинәт кенә безне аерган бер вакыйга булды... Мин Арзуның үземнән бер яшькә олы булуын, җиткән кыз икәнлеген шул чакта гына аңладым... Кәлимулла абый Арзуны клубтан озатып кайта башлады... Абыең кыз белән кайтканда аңа ияреп йөреп булмый ич инде? Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, мин Арзудан

читләштем... Кәлимулла абыйның Арзуга күзе төшкән дигән хәбәр әнигә дә килеп ишетелде, иртәләрнең берсендә ул пыр туздьі. «Шома Мөлек белән кәнтәй Фатыйма кызын озатып йөрмәсән, сиңа кыз беткәнме? Ул кызда да безнең халыкка хас тыйнаклык юк... Әтисе төсле койрыксыз булыр, җырлап көн уздырыр... Моннан болай аның янына атлыйсы булма, матри!» диде ул елый-елый... Әти дә Кәлимулла абыйны яклап бер сүз әйтмәде, киресенчә, күз кырые белән генә абыйга карап-карап утырды...

Әниләр сүзенә әллә ни карамаган да булыр иде, Арзу яратмады минем абыйны! Юашрак иде шул ул минем абый, сүзгә дә саран, котанрак та...

Менә минем эшләр шулайрак тора әле: Арзу минем укытучым. Бу бер. Икенчедән... Хәбибрахман абзый карт карчыга кебек аны сагалый!.. Өченчедән... әни!.. Әгәр белә калса, миңа якты көн күрсәтмәячәк... Шулар өстенә тагын серле шәүләләр, бозымнар, әллә нәрсәләр килеп чыкты... Мин тәмам аптырауда калдым... Нишләргә? Әйтергәме Арзуга берәр сүз?.. Ул үзе миңа ничек карар да, тирә-яктагы хәл тагын да ныграк болганып, барысы чәлпәрәмә килеп бетмәсме?

«Фронтка китик» ди Рәфгать... Әллә бөтенесен ташлап китеп барасы инде?

Ә Арзу?

Яратам ич мин аны! Бик яратам!..

## 7

Хәбибрахман абзый белән арамны якынайтырга булдым. Иң элек, нинди юллар белән булса да, аның күңелен күрергә кирәк! Беркөн сыртлап төяп утын алып кайткан иде, бушатышырга кердем. Очраганда ерактан ук сәлам бирәм, сүз катып карыйм...

Шушы көннәрдә генә мин аның ялгыз, бик ялгыз икәнлеген шәйләдем. Безнең Җиһангир бабай үлгәннән соң Хәбибрахман абзыйның бер генә якыны да калмады бугай? Авылда аларның кардәш-ырулары күп түгел, иң якын кешеләре Хәбибрахман абзыйның балдызы (ягъни Арзу әбисенең сеңелесе була инде) Гайникамал карчык та Кәҗә башы урамында. Ул да байтактан тол карчык.

Гайникамал карчыкның улы Мирзанур комбайнда эшли башлады да тиз ара тернәкләнеп китте, өен сиплэп яңартты, лапас-кура тергезде, Түбән авылдан фельдшер кыз Сәкинәне килен итеп төшерде. Сәкинә киленне Хәбибрахман абзый да бик ошатты, ахры, яшь бикәче белән Мирзанур Арзуларга чәй-коймакка килеп киткәли: аларның каладагы сыман көпә-көндез, якты күздә култыклашып йөрүләрен күреп безнең оч җиңгиләре гаҗәпләнәләр. Мәүлиха апа исә урамга чыгып, артларыннан бот чабып та кала торган иде...

Ике йорт арасындагы онытыла башлаган туганлыкны бөтенләй чит кеше — килен кеше яңартты. Килен мунча якса да, бәлеш салса да, олылап Хәбибрахман картны дәштерә, абзыебызның өс-башы да чистарак йөри башлады, рәис чакта киеп йөргән саргылт вельвет толстовкасын яңадан иненә салды. Сәкинә йорт эшенә дә искиткеч уңган, тегүчигүгә дә кулы йөгерек, Арзу аны әнкәсе урынына якын күрде. Аш-суга, кәлчә-мәлчә пешерергә, тегәргә, ямарга, түшәм-сайгак юарга, чигү тотарга җиңгәсеннән өйрәнде...

Сугыш Гайникамал карчыкның күз текәгәне Мирзанурны да аямады, аны да алдылар, Сәкинә килен дә иреннән калмады. «Мирзанурым белән китәм!» дигәч, Гайникамал карчык фатихасын бирде, военкоматта да каршы килмәделәр. «Медперсонал» дигәч, эш шома узды. Карчык улы белән киленен Бөгелмә станцасына хәтле озата барды...

Элек таза гына, чибәр генә йөргән Гайникамал карчык көтү каршысына кәҗәсен алырга барган да, карлы-бозлы яңгыр астында калып, чыланып кайткан. Иртәгесен янып-көеп егылган. «Үпкәсе шешкән» диделәр. Мәүлиха апа: «Бозым булган Гайникамалга, гөнаһысы күп икән»,— дигән хәбәр таратты.

Хәбибрахман абзый белән Арзу алмаш-тилмәш Кәҗә башына барып кайткаладылар. Бер көнне, һич уйламаганда, Арзу безгә килеп керде. Мин ялан аяк кына, чалбар балакларын сызганып идән юып маташа идем. Арзуны күргәч, нишләргә белмичә, тиле кеше сыман сүзсез катып калдым.

— Сездә урак өсте икән әле,— диде ул.

— Хәзер бетерәм,— дип мыгырдандым мин.

— Эшең беткәч, туп-туры безгә кер, алайса. Май әбине алып кайтырга булышырсың.

Май әби дигәне шул Гайникамал карчык була инде аның.

Миннән бигрәк аның сүзенә әни аптырады:

— И-и, Арзу, олы мәшәкать аласыз икән өстегезгә. Кайсыгыз карар соң аны? Бабаң кардадан кайтмый, үзең мәктәптә,— диде.

Арзуның җавабы әзер иде:

— Икебез дә тырышырбыз,— диде ул.— Бабай да «алып кайт» ди. Үзем дә Май әбине бик кызганам. Кәҗәсен сатарбыз. Безнең сыер бик сөтләч. Кайнар сөт эчертеп, җылыда тәрбияләргә кирәк Май әбине...

Кул арбасына мендәр-күпчеген салып, шулар өстенә кызыл чаршауга төрелгән тәене белән үзен дә утыртып Май әбине Кәҗә башы урамындагы суык өеннән Арзуларның җылы түренә күчереп тә куйдык. Карчык зәгыйфь куллары белән арбага ябышып, як-ягына каранып, оялып һәм читенсенеп кайтты, туктаусыз:

—Ниләр күрми безнең башлар, ниләр күрми! — дип кабатлады.

— Бергә күрә башлар, бергә! — диде Арзу.

Безнең турыга җитәрәк каршыга бер атлы очрады. Кожан башларын күзеннән күтәрә-күтәрә Гыйбадулла чулак килә икән, без Май әби утырган уф-алла арбасын бер читкәрәк чыгарып юл саптык. Гыйбадулла атын туктатты:

— Хи-хи, Гайникамал әби! Патша тәхетенә меңгергәннәр икән сине! — дип көлде. Май әби:

— Юлыңда бул, юлыңда, шөкәтсез! — дип караса да, Гыйбадулланың китәр исәбе күренми иде. Мин җирдән таза гына чыбык алдым да үшән алашаның җилкәсенә сыдырдым. Ат кушаяклап алга ыргылды, аны-моны сизенмәгән Гыйбадулла дыйк итеп арбага ауды, яман сүгенеп җибәрде, без көлә-көлә арбаны юлга чыгардык.

— Сеңелкәшне, мәрхүмә Миңлекамалны, кияүгә сораган иде бу сасы авыз,— дип аңлатты Май әби.— Әткәй ризалашыр күк тоелгач, мин елый-елый ялынган идем... Тәки әрәм итмәдек кызны шушы шөкәтсезгә!.. Шуны һаман оныта алмый йөри... Хәтер бар үзендә тагын!..

Әни, төче катлама пешереп, кич белән Гайникамал карчык янына кереп китте, чыккач озак кына офтанып утырды:

— Җәй башында орчык күк йөргән кеше коры сөяккә калган икән. Чир нишләтә адәм баласын, кимерә, кейдерә... Үзенең гомере дә бар сыман... Инде тынычланса да, елап калыр кешесе юк... Бер башы... Мирзануры кайчан кайтыр әле... Икәүләшеп елашып утырдык... Карыйм, мөлдер-мөлдер күз яше ага әле карчыкның... Күз яше җан тамырыннан чыга, күз яше корымаган кешенең ризыгы бетми аның. Яшәр әле, яшәр. Интегер, башкаларны да интектерер. Арзуга читенгә килер инде. Арзу дигәннән, булса да булыр икән уңган бала! Өйләрен гөл иткән, керсәң чыгасың килмәс, бар җирләреннән тәмле ис килеп кенә тора!

Арзу турында әйткәннәре күңелемә сары май булып ятса да, мин бүген әнигә карап бик аптырадым: кешенең тынуын ничек теләргә мөмкин? Әллә сугыш вакытында күңелләр катып китә микән? Юкса, әни ул сүзне кыеп әйтә алмас иде...

Ятим карчыкны үз янына сыендыргач, Хәбибрахман абзыйга карата күңелем йомшады. Дөресен генә әйткәндә, балдыз ул кадәр үк якын кардәш түгел, балдызларның баллы чагын — яшьлеген генә ярата җизниләр! Чирле сөякне үз янына сыендыру, хәзерге такы-токы заманда артык тамакны табынга алу ифрат зур шәфкатьлелек. Күрше-тирәдә Арзуның дәрәҗәсе бермә-бер үсеп китте, чөнки авыру карчыкны караунын мәшәкате күп дәрәҗәдә аңа төшәчәк, барыбыз да моны аңлый идек. Әмма Арзу исеме телгә алынуга эчләрен тырпайта торган бер бәндә бар иде безнең очта...

Һәм берәү генә идеме икән?!.

## 8

Кичкырын, Хәбибрахман абзый гадәтенчә атлар янына төшеп киткәч, Арзуларга кагылырга булдым. Урамга чыксам, коедан ерак та түгел, тагын атлы туктаган. Шалама бүреген кашына хәтле батырып кигән юлаучыны танымадым, әмма күңел шомланып китте. Арба янына килеп җитәрәк кенә аермачык таныдым — теге кызыл сакал! «Әһә,— димен эчтән генә,— хәзер ансат кына миннән котыла алмассың!» Ул да мине таныды.

— Нихәл? — дигән була.— Ат сугарып алырга иде исәп, коегызга су һаман кайтмаган икән.

— Абзый кеше,— дидем мин, яхшы ук усалланып.— Нишләп әле син чит авыл коеларын тикшереп йөрисең? Кем син? Кая барыш?

Ул, ике кулы белән дилбегәсен тартып тоткан килеш, бер дә кымшанмыйча арбасында бөкрәеп утыра иде, бүреген түбәсенә яшерә төшеп, сакалын селкетә-селкетә төксе генә итеп миңа карады:

— Ай-һай, япь-яшь башыңнан күкерт төсле кабына башлаган син!

— Бу яңгырда ат эчә димени? Ат сугарырга туктамаган син. Әйт, кая барасың?

Моннан ары һич көтелмәгән хәл булды, мин аптырап ярты сүздә өнсез калдым. Кызыл сакалның башы түшенә иңеп, иңбашлары калтыранды, ул шыңшып, яшенә буыла-буыла сөйләргә тотынды:

— Хәзерге заманда адәм кая юл тотсын, и надан?!. Нужа куа, нужа! Адәм нужаны куа бара, әйләнеп караса, нужа аның итәгенә аерылмаска ябышкан икән. Адәм белән нужа шайтан бөҗрасына кергәннәр дә бер-берсен куалар, бер-берсеннән аерыла алмыйлар.

— Төтенне куе җибәрәсең, абзый кеше,— дидем мин.— Нәрсә кирәк сиңа бу коедан?

— Коеда ни булсын анда, ходай кошы! — диде ул, чачакланган бишмәт җиңе белән күз кырыйларын тырышып сөртә-сөртә.

— Синең эше гайбәт капчыклары урамыңнан узса, коеда да әкәмәтләр була икән шул! Әйт, кая барышың?

Мин аның елавына да, туктаусыз аһ-зарларына да ышанмадым, нәзек тавышын ишеткән саен ачуым гына кабара төште. «Сарман ягына барам, кыз кияүдә шунда минем, кияүне солдатка алдылар да кыз биш бала белән торып калды, чирләшкә үзе, бала-чагасы да мантымый», дип, хәзерге көн өчен гадәти сүзләрне сөйли башлагач кына бераз йомшадым. Боларына ышанмый да мөмкин түгел иде.

Кызыл сакал минем шигемне арттырса да, әлегә кое буенда ызгышудан уза алмадым, кулымда төпле генә бер дәлилем дә юк иде. Арзуларга ярсып, ачуыма тулышып барып кердем, әмма аны-моны сиздермәскә тырыштым.

Арзу алдында моңарчы мин күрмәгән күн тышлы калын дәфтәр ята, ул бик бирелеп китаптан шул дәфтәргә шигырь күчерә иде. Өстендә — кыска җиңле, ачык якалы ак күлмәк, ялан баш. Өйләре жып-җылы, бишле лампа янганга шактый якты.

Мин аның муенының озын һәм гаҗәеп килешле, ничектер үзенә бер горур булуына игътибар иттем. Муен төбендә, сулда, нәни генә сөйкемле миңе дә бар. Чәчен ике калын толым итеп үргән дә толымнарын баш өстенә аркылы-торкылы күтәреп куйган, колак янында толымга сыймаган кап-кара йомшак бөтеркәләре сибелеп тора. Колак очларында кан кебек кызыл тамчы-тамчы алкалар җемелди. Ак күлмәк, алсу йөз, кап-кара чәчләр, кып-кызыл алкалар... Ул минем текәлеп, тын тартырга да куркып күзәтүемнән оялыпмы, озын, йомшак бармаклары белән дәфтәрне япты да күзләрен тутырып миңа карады... Аның гадәттә нур чәчеп торган кара күзләре бүген сер белән, мин моңарчы белмәгән, белергә дә тиеш булмаган ят моң белән туп-тулы иде. Минем каршымда тәмам җиткән, уйчан, моңлы чибәр кыз утыра иде... Арзумы бу?.. Үзе өйдә булса да, җаны читтә, моннан еракта вакытымы аның? Мин комачауладыммы? Сискәндердемме?..

Чыгып китәргә дә, аның янына якынрак барырга да көчем житмәде, шулай бер-беребезне сынап карап, сизелер-сизелмәс кенә елмаешып шактый тордык бугай. Юк, ул мине кумый, киресенчә, елмая, күзләрендә миңа таныш гадилек, дөреслек чагыла башлый, бу күзләр миңа да нидер сөйли, ымлый, ишарәли...

Кыюланып, дәфтәр янындагы китапны кулыма алдым: Есенин!

— Каян кулга төшердең моны?

Бишмәтемне, фуражкамны салып чөйгә элдем. Есенин! Без аны ишетеп кенә белә идек.

— Бабай алып кайтып бирде.

— Бабаң? Ул Есенинны беләме? Бу китап үзеңнеке булгач, нигә дәфтәргә күчерәсең?

Бер мизгелгә генә мин үземнең артык кыю, эрсез булуымны сизендем, теге кызыл сакал янындагы кызулык сүрелеп бетмәгән иде шул! Әмма Арзу үпкәләмәде, мин тартып алмасын дигән төсле, дәфтәрне үзенә табарак шудырды, битенә куе кызыллык йөгерде.

— Истәлек дәфтәре бу минем... Син бит егет кеше, көләрсең...

Арзу авызыннан «егет» сүзен ишеткәч, мин ирәеп тә киттем!

— Сиңа минем хисләр сәер дә тоелыр,— дип дәвам итте ул.— Шигырь күчерергә яратам! Күчергәндә, аңлатып булмый торган тойгы кичерәм. Шагыйрьнең иҗат газапларын күз алдыма китерәм: шушы хәрефләрне үз кулы белән тезеп барган бит ул дип уйлыйм... Шунда мин аның әйткәннәрен, шигырьгә салган йөрәк серләрен ачыграк аңлыйм. Хәтерем әйбәт, күчереп алганда берочтан яттан да өйрәнеп алам.

Дәфтәргә үрелдем, ул теләр-теләмәсрәк аны миңа бирде.

— Пушкин, Лермонтов? — дидем мин, битләрне тиз-тиз актарып. Тукай, Есенин, Такташ, Гейне исемнәре күренде.

— Боларның барын да яттан беләсеңме?

— Белмичә.

Беренче ачылган шигырьне бармагым белән төртеп күрсәттем.

— Яле, Арзу?!

Аның нечкә сызылган борын яфраклары тетрәнеп китте.

Край любимый! Сердцу снятся
Скирды солнца в водах лонных.
Я хотел бы затеряться
В зеленях твоих стозвонных...

Иң ахырдан: «Я пришел на эту землю, чтоб скорей ее покинуть», дип шыпырт тантана белән укып бетергәч, без икебез дә тынып калдык. Шигырьне моңарчы белми идем, ул миңа искиткеч ошады, аннан да бигрәк Арзуның күкрәк тавышы, укыган саен аның күңелендә үсә, яктыра барган гаҗәеп олы, ят бер хис, зурлык, тугрылык, әйтергә яраса — тиңдәшсез мәхәббәт гаҗәпләндерде. Юк, укымады Арзу, ул җырлап бирде, моңын чайпалдырып түкте, күңел тирәнлегенә мине дә чакырды...

«Лонных» дигән сүзне аңламадым, сорарга да базмадым. Сорасам, шигырьнең бөтенлеген, олылыгын киметермен төсле тоелды. Арзу авыл урамыннан, шушы яңгырлы караңгы кичтән, нигәдер өметсезлек сиздереп искән көзге җилдән, кызыл сакаллар, Сирайлар, Мәүлиха апалар арасыннан йолкып алып мине дә шигърият югарылыгына күтәрде, минем дә аннан ким буласым килми, ул кичергәнне тулаем кичерәсем килә иде.

— Хәтерлисеңме, Искәндәр, «Пионер каләме»нең актыккы битендә Тукайның «Күңелле сәхифәләр» исемле шигыре басылган иде? Менә шул шигырьдән башланды да хикмәт!.. Укыйм мин моны, укыйм, аңламыйм, ни булды? Юк, шигырьне аңлыйм, бик аңлыйм, үземнең хисләремне, күңелемне аңламыйм! Әллә ни булды миңа шул чак!.. Дөнья кинәт һәм берьюлы, тоташтан җире-күге белән үзгәрде! Мин аермачык итеп Тукайның аучысын, аның сытык чыраен, җыерылган кашларын, җитү сакалын һәм мәҗрух эшләпәсен күрдем! «Ха-ха-ха!» да «Хи-хи-хи!» дип аннан егыла-егыла көлеп калучы адәмнәрне күрдем, тавышлары колагымда яңгырады... Шунда, кешеләр арасында, мин уйчан-моңсу Тукайның үзен күрдем!.. Шигырьнең кодрәте мине үзе белән йотып, суырып алды, онытылдым. Миңа күңелле, ифрат рәхәт иде. Мин бай идем, юмарт идем, чиксез бәхетле идем! Беренче мәртәбә мин үземне кеше итеп, кыз кеше итеп һәм... чибәр, сылу кыз итеп тойдым!.. Шуннан соң башка шигырьләрне укый башладым... Шуннан китте дә китте. Хәзер исә, әгәр шигырь, матурлык булмаса, мин үксез, бәхетсез һәм гарип булыр идем. Тукай аша Пушкинны таптым, аннан Лермонтовны... Ниһаять, Есенинны. Рус халкын таптым... Хәзер Есенин белән Такташтан аерыла алмыйм.

— Бу дәфтәрне миңа да биреп торчы, Арзу.

— Бик күпне сорыйсың түгелме, Искәндәр.

— Ярамыймы?

— Ярамый дип... Хәер, берәр көнгә генә бирсәм инде. Тик бүген түгел, хәзер түгел! Яз җитсен әле, көннәр озайсын, кояш түргә менеп утырсын. Ул чакта мин ул кадәр үк ялгыз булмам... Яктылыкны яратам мин!.. Бер көнгә генә бирсәм, үпкәләмәссеңме?

Аның минем алда шулай уңайсызланып, ялгансыз кызарып утыруын ике төрле аңларга була иде: серен ачарга уңайсызланамы? Әллә берәрсенә гашыйкмы ул? Күрше кызы булса да, мин аны бөтенләй белмәгәнмен икән!.. Ул Зәйгә еш барып йөри. Комсомол райкомында пленум члены. Кунып та кайта. Хатлар да ала. Кемнәре юктыр дисең син аның?! Нигә ялгызлыктан зарланып куйды, алайса? Ялгызлык шул ук сагыну түгелмени?

Эре бизәкле, түшәмнән идәнгә хәтле төшкән чаршау артында Гайникамал карчык йөткерә башлады, Арзу йөгереп аның янына китте.

— Берәр нәрсә кирәкмиме, Май эби?

Ул озаклап әбидән нидер сораша, чаршау артындагы сөйләшү пышылдашуга күчә, нидер шылтырый, чыштырдый, ава... Икесе дә тыелып кына көләләр. Ә мин нишләргә белмим, бер минут, бер секунд Арзусыз тора алмам кебек, ишекле-түрле йөренәм...

Бәрәңгене алып бетердек диярга була. Ал-ялны белмичә тырышуы-быз бушка китмәде: «Ленин юлы» колхозы планны икеләтә үтәде. Колхозны, безнең мәктәпне, Арзуны, Рәфгатьне, тагын берничә кешене район Мактау тактасына керттеләр. Район газетасында аларның рәсемнәре басылып чыкты, җентекләп караганда һәрберсен танырга да була!..

Шуннан тоташ яңгырлар китте. Үзе суык, йогышсыз, тәнкәгә тия торган яңгыр. Көтү соң гына чыга да төш авышуга авылга кайтып та житә. Җомга көнне безнең сыер кайтмады. Мал-туарны барлап алып кайту сеңелем Нәсимәгә йөкләнгән булса да, бүген, шундый эт йөрмәс көндә, аны басуга чыгарасым килмәде, этинең кожанын кидем (таман гына, иңе генә бераз киңрәк!), билне каеш белән кысып будым, башлыкны күтәрдем дә урам сазын лачтыр-лочтыр яра башладым...

Авыл тирәли әйләнеп чыктым, арыдым, чыландым, коры җеп бөртегем калмады.

Сүгенеп, карганып өйгә кайтып керсәм, әни лапаста, коп-корыда сыерны савып утыра.

Арзулар капкасыннан җайдаклы берәү чыгып китте. Иске эшләпәсен кыңгыр салган, чүпрәк ияргә бөкрәеп утырган бу кеше Хәбибрахман абзый иде.

— Кая китте микән ул? — дип сорадым әнидән.

— Арзулар да сыерларын таба алмыйлар әле, күзеңә чалынмадымы? — диде әни.

Әнинең сыер савып бетереп өйгә кергәнен генә көтеп тордым да Арзуларга юнәлдем, ишегалларын уздым, өйалды ишегеннән башымны тыгып:

— Арзу, Арзу! — дип эндәштем. Өйдән Гайникамал карчыкның нидер аңлатырга теләп тамак кырганы, йөткергәне генә ишетелде, Арзу, мөгаен генә, өйдә юк иде.

«Нишләп ишекләрен элеп йөрмиләр икән болар? Кич бит инде?» дигән шикле уй күңелемә килде. Хәер, моңарчы да ишекләрендә йозак-мазар күргән булмады, анда-монда киткәндә дә бик тимеренә агач чөй генә тыгып куялар иде...

Төне буе яңгыр тынмады. Җил көчәйде, кузгатырга мөмкин булган бар нәрсәләргә кагылып, аһылдап, төн йокысын качырып туктаусыз усалланды...

Иртән Арзу мәктәп атын җигеп кайтып керде.

— Бүген минем дәресләргә башка кеше керер, Искәндәр,— диде ул.

— Ә син? — дидем мин күңелсезләнеп.

— Райком пленумы бүген. Ленинградтан эвакуация белән биш йөз бала килгән, шуларны урнаштырабыз.

— Яңа детдом ачалармы әллә?

— Анысы ишетелми...

— Сыерыгыз кайттымы? — дип сорадым мин, өй түбәләренә тияртимәс кенә шуышкан авыр, кара болытларга карап.

— Кайтыр,— диде ул, тезгенен капка баганасындагы боҗрага бәйләп. — Ярты авылның малы таралышкан кичә. Көтүчене күрдем, аптыраган үзе дә! «Әрәмәгә кергән маллар кигәвен вакытындагы кебек койрык чәнчеп чабып чыгалар! Әллә бүре-мазар шаярды инде?» дип торды...

Арзу булмагач, Зөләйха апа ике сәгать тарих укытты. Икенче дәресне тәмамларга өлгермәдек, аны чакырып чыгардылар. Укытучы чыгып китүгә, без дә кузгалыштык. Тәрәзәгә карасам, мәктәп капкасы төбендә Арзу җигеп киткән ат тора, Арзу да шунда. Ул арада бишмәтен кия-кия Зөләйха апа да аның янына чыгып житте, алар бер-ике сүз

алыштылар да, тарантаска менеп утырып, пычрак чәчә-чәчә юрттырып китеп тә бардылар.

Рәфгатьнең андый чакта елгырлыгы бар шул, белеп тә өлгергән, ишарәләп мине коридорга чакырып чыгарды.

— Кил әле.

— Нәрсә бар?

— Арзуларның сыерын үтергәннәр.

— Нәрсә-ә?!

— Сәнәк белән эченә кадаганнар!

— Кемнәр?

Рәфгать тә шуннан ары берни белми икән. Кичкә хәтле, Арзу районнан әйләнеп кайтканчы, чыбыксыз телефон ташыган имеш-мимешләр белән тукланып тордык.

Югары авыл белән Зәй арасында, урта юлга житәрәк, куе әрәмә бар. Әрәмә, юлны аркылы кискән елга агышына буйсынып, борыла-сарыла төньякка да, көньякка да сузыла, ике яктан да калын-калын урманнарга барып тоташа. Шул әрәмәгә житкәндә генә Арзуның алашасы чыгымчылый башлаган. Ул «тизлекне бераз арттыру өчен» сыек чыбык сындырып алырга уйлаган. Тарантастан төшеп юл кырыена керсә, нәкъ каршысында, ачыклыкта чуар сыерларының башы күренеп китә. «Монда төн уздырган икән, рәхмәт төшкере... Жилене ничек чыдый икән?» — дип, Арзу сыерга таба атлаган... Керсә... сыер үлеп бер читтәрәк ята икән, башын кемдер очлы каен казыгына кадап, юлдан күренерлек итеп кенә жиргә бастырып куйган. Ике мөгез арасына чабата киндерәсе белән язу дә бәйләгәннәр. «Сөте тәмле булсын, Быржин!»

Авылга тикшерүче килде. Байтак кешене чакырып сөйләште. Кичләрен, минем эчне пошырып, Арзуларга килеп утыргалады, эш чыгара алмады бугай, китеп барды. Ике-өч көн узгач, аларның икесен дә — Хәбибрахман абзыйны да, Арзуны да Зәйгә чакырып алдылар.

Районнан килгән тикшерүченең фамилиясе Асылов иде...

Егет кеше икән. Асыловны Арзу белән рәттән күргән саен күңелем тилмереп-тилереп алса да, беркемгә берни сиздермәдем. Шулай да Асылов хакында, аның килеш-килбәте, өстенә ятып торган форма киеме турында Рәфгать белән еш кына сөйләшә торган булып киттек. Рәфгать киек барын сизенгән ау эте кебек ярсып-кызып йөри башлады. Ни сөйләшсәк тә сүз сыер вакыйгасына килеп ялгана. Асыловның бер эш тә кыра алмый китеп баруын мин астыртын гына үз файдама борырга телим, сернең ачылмый калуын бары тик тикшерүченең булдыксызлыгыннан гына күрәм, Рәфгатькә эшнең нечкәлеген ачмыйча гына, үземчә, Асыловтан үч ала идем... Чынлап ук тикшерү әвәслегенә кереп киткән Рәфгать бер-бер нәрсә сизендеме, кичләрнең берсендә минем серне «алды». Сүз иярә сүз чыгып, үземнең шик-шөбһәләремне, Мәүлиха апа белән шикле кызыл сакал турындагы уйларымны аңа сөйләп ташладым. Рәфгатьнең кысык күзләре йомылдылар да ут булып миңа кадалдылар:

— Син нәрсә, син нәрсә? — диде ул, гомердә тотлыкмаганны бүген тотлыгып. — Акылыңдамы, юкмы?

— Соң мин...

— Күрәм, соскансың тилебәрән орлыгын! Нигә белгәнеңне Асыловка сөйләмәдең?

Ансат аңа Рәфгатькә! Сөйли аламмы мин боларны Асыловка?

— Нәрсәсен сөйлим? — дидем мин, ярсымаска тырышып.

— Миңа миңа бик шәп сөйләдең бит, шуларны сөйлә идең!.. Яшереп йөргән була бит, кара син аны!

— Нәрсә сөйләдем мин сиңа? Я, әйт!

— Күлмәкне таптыңмы? Таптың! Шикле юлаучыны күрдеңме? Күрдең.

— Күлмәкне Арзу тартып чыгарды. Ул тапты. Кирәк икән, үзе сөйләсен иде. Нигә үзе сөйләмәгән?.. Шул шул менә!

— Каян беләсең? Бәлки сөйләгәндер дә, — диде бераз юашланып Рәфгать.

— Юк дигәч юк инде. Сөйләми аны Арзу! Син дә телеңне теш артында тот.

— Нигә, Искәндәр?.. Җепнең очы бәлки шул коеда ятадыр?

— Анысы безнең эш түгел. Арзу синнән-миннән акыллырак...

— Ул хатын-кыз, син ир була бел, егет бул!..

Китте, китте, ике арадагы кызышуның гел яманга икәнен күңелләребез аңласа да, бер башлагач, тыела алмадык, байтак әрепләштек. Бер-беребезне ачыктан-ачык гаепләмәсәк тә, авыр сүзләр әйтештек. «Йоклап йөрисең син!» — диде Рәфгать. Сизәм: бәхәсебезнең төп сәбәбе — безнең көчсезлек иде. Гаепле кеше, җинаятьче шушында, үз арабызда гына йөри, ә без аны белә дә, таба да алмыйбыз.

Күңел дигәнең шундый икән ул, гаепне бер дә өскә аласы килми, ак эт баласен ягарга кара эт эзлисең! Мин:

— Асыловын әйтер идем, йөри шунда кукраеп... Аның урынында булсам, ярты авылны актарыр идем! — дип ычкындырдым.

Рәфгать сабырын җыярга өлгергән иде инде, «әйдә актарыйк!» дип әйтерен көткәндә, тыныч кына:

— Җае бардыр аның, тәртибе, — дип куйды. — Теләсә кем, теләсә ничек авылны актара башласа, беләсеңме, ул кая китә?

— Ә бер кеше теләсә ничек авылның котын алып торганда ничек була?

— Монда бер кеше кулы уйный, — дип дәвам итте Рәфгать. — Күлмәкне дә ул ташлаган, сыерны да ул чәнчегән!

— Кем?

— Дошман.

— Нинди дошман?

— Аяклы-куллы. Кара эчле. Әллә герман фашистын гына дошман дип саныйсыңмы син? Уяулык турында газеталарда язалармы? Күпме генә язалар әле.

Дошмандыр, анысына каршылыгым юк. Мәгәр Рәфгать бер нәрсәдә ялгыша: Арзуның күлмәген ташлау — вак мәсьәлә. Сыер үтерүгә килгәндә, бусы инде чын җинаять! Болар икесе ике кеше эше. Соңгысын, мөгаен, Хәбибрахман абзыйга үч итеп эшләгәннәрдер. Яшен яшәгән кеше, эшен дә эшләгән, дусы-дошманы юктыр дисеңме аның?!

Бер көнне Арзу безнең класска кереп, үткән дәрес материалларын кабатлата гына башлаган иде, класс ишеге ачылды, зур куян бүрек кигән Сирай килеп керде. Ишек катында таптанып торды да, алап авызын ерып, туп-туры арткы партадагы буш урынга юнәлде. Утырды. Без аптырашып бер Арзуга, бер Сирайга караштык.

— Берәр кешедә йомышың бармы, Хәбибов? — диде Арзу йомшак кына. — Безнең дәрес монда.

— Беләм,— диде Сирай, парта арасына җәйлабрак утырып.

— Белгәч, нигә килеп керәсең?

Сирайның җавабын ишетеп бөтен класс шаркылдап көлеп җибәрде. Кырык бернең июненнән бирле мондый тоташ, бердән көлүне ишеткәнебез юк иде әле.

— Бәй, укырга килдем лә, күрмисезмени? — диде Сирай һәм куанып, исе дә китмичә, безгә кушылып хихылдый башлады.

Күздән яшь чыкканчы, эчләрне кату алганчы көлдек. Яшь мөгаллимәбез, башта көләргә дә, көлмәскә дә белмичә, берсүзсез карап-карап торды да безгә ияреп көлә башлады.

— Нигә, ярамыймы әллә? — диде дә Сирай, гаярьләнеп, башын артка ташлады.

Арзуның тиз генә сер бирмәве безгә ошады.

— Нигә ярамасын, ярый, — диде ул. — Тик, уйла әле, син классларны бутагансың шикелле!

— Бутамадым. Минем монда укыйсым килә... Уку ягына килгәндә, куып җитәм мин аларны, күрерсең.

Безнең кызлар Сирайны күрсәтешеп нидер пышылдаштылар, көлештеләр, эшнең көлкедән узуын беренче булып Арзу сизенде:

— Булды. Күңелләрне ачтың, әмма син дәресне бүлеп торасың, Хәбибов, — диде ул.

— Соң син миңа карама, укыта бир... Мин дә тыңларга килдем.

Бусы инде оятсызлык иде.

— Кабатлап әйтәм: син безгә комачаулыйсың.

— Ничек алай? — Сирайның ирен читләре юешләнде. — Нигә комачаулыйм? Мин укырга килдем. Укыйсым килә... Юлда яткан ташмы әллә мин комачауларга?

— Ахыр чиктә, синең уку-укымау мәсьәләсен мин хәл кыла алмыйм, бар, директор янына кер. Зөләйха апа монда.

— Ярамый дисең инде? — Аның өстендә калын сары тун, муенында кәҗә мамыгыннан бәйләгән калын шарф. Тирли үк башлады егетең, маңгаена бөрчек-бөрчек тир сибелде. — Мине дурак дисең? Надан дисең? Шушы Дындыптан да наданракмы инде мин?

Класс тып-тын калды, чебен очканы ишетелерлек иде. Соңгы вакытларда никрутлар сафында военкоматларга йөри башлагач, кушаматын ишеткәндә Рәфгатьнең кәеф бик каты кырыла иде. Монда класс, кызлар алдында ничек түзеп утырырга кирәк? Шартлап ярылыр дип көткән идем, Рәфгать ярылмады, иреннәрен кысты, чыраена кара коелды. Аның каравы, Арзу кыза төште:

— Чык класстан, — диде ул нык итеп.

— Чыкмыйм, — диде Сирай, партага чытырдап ябышып. — Укырга килдем. Тыярга правагыз юк. Мин дә кеше.

Анда да, монда да ачулы сүзләр яңгырады:

— Өреп чыгарырга кирәк аны!

— Тапкан уен!

— Тинтәк!

— Тыймыйм, укы, — диде Арзу сабыр гына. — Тик укуның үз тәртибе бар... Алтынчыда туктадыңмы әле син?

— Хәзер сугыш заманасы. Нәрсәгә миңа алтынчы? Алтынчы бетләре белән утыртыр идеңме әллә мине оялмыйча? Миңа унынчы булсын. Аз да түгел, артыгы да кирәкми.

Ниһаять, Рәфгать дөрт итеп урыныннан купты, мин дә сикереп тордым.

— Яле, тай моннан, — диде Рәфгать, Сирай янына басып. Мин тун җиңеннән умырып тоткач, Сирай, тунын сала-сала, парта арасыннан чыкты.

— Я, сук! Сугып кара! Сук, сук! Мәктәпкә килгән өчен сугып кара. — Үзе безгә эндәшә, үзе каш астыннан гына сөзеп Арзуга карап тора. — Шкулдан очырырлар, укытучы җитми дип тормаслар...

Икәүләшеп йолкабыз, әмма тегермәнче малае җегәрле. Рәфгатьне кагып кына җибәрде. Без әүмәкләшә үк башладык. Арзуның класстан чыгып киткәнен дә сизми калганбыз. Төрле якта яңгыраган тавышка баш калкытып карасак, классташлар безне сырып алганнар, арада кызыкның дәвам итүен теләүчеләр дә табылды, алар ачыктан-ачык Сирайны котырталар, көләләр, күпләр Рәфгать белән миңа көч биреп тора.

— Ябышма диләр сиңа!

— Чыгып кит, тегермән күсесе!

— Ә-ә, күсеме? Нәрсәңне кимергән? Я, әйт!

Сирай минем касыкка китереп төртте, мин дә аңа берне ямадым. Ашыгып Зөләйха апа белән Арзу килеп керде, класс тынып калды. Зөләйха апа — усаллыкта ирләргә биргесез хатын, моны Сирай да белә, шуңа күрә, директор керүгә шиңеп, башын түбән иде. Зөләйха апа иплэп кенә килде, борчак күбәсе хәтле куян бүрекне идәннән партага алып куйды да Сирайның күзенә карап:

— Эчеп килдеңме әллә? — дип сорады. — Сала диләр сине, Хәбибов. Нәрсәгә тавыш чыгарасың?

— Минмени? Алар бит! — диде еламсырап Сирай.— Алар!..

«Алар» сүзен шундый тирән нәфрәт белән әйтте Сирай, бер мәлгә аптырашып бер-беребезгә карадык...

— Үртиләр, — дип дәвам итте Сирай. — Урамда очрасам да буш уздырмыйлар... Дындыбы да шул, Искәндәре дә... Аулак өйгә кертмиләр. Клубка менсәм, такмак чыгаралар. Нәрсә мин? Тиле Миннәхмәт артыннан таш атып калалар... Миңа да шул гына каламыни?!.. Мин андыймы?.. Алар унынчыда, янәсе... Булсалар ни?..

Зөләйха апа кызып кергән иде, Сирайның сүзләрен ишетеп, ул да бераз сабырланды, алай да дилбегәне кулыннан ычкындырмады:

— Укуны ташлагач, ничә тапкыр өегезгә бардым? Әтиеңне чакырттым. Оныттыңмы? — диде.

— Бәләкәй чакта бөтен кеше дурак була, — диде Сирай.

Ул кинәт юашланды, үзгәрде, тырышып-тырышып нидер аңлатырга, төшендерергә маташты, аннары, ниятенең өметсез икәнлеген аңлагандай, кулын селкеде, мышный-мышный тунын киде, күзен елтыратып бүлмәдәгеләрне карап чыкты, бүреген идәнгә тиярлек итеп селкә-селкә чыгып китте.

Дәреснең барыбер рәт-чираты булмады, Арзу да тәртип урнаштыра алмады, азакка таба Рәфгать миңа: «Җигәвен тешләгәнме әллә бу Сирайны? Нигә килеп керде икән?» — дип язып җибәрде. Шул турыда баш ватып утыра идем, Рәфгатьнең соравы борчулы уйларымны күбәйтеп җибәрде. Арзуның азсүзлелегенә, гадәттән тыш җитдилегенә карап, «Ул да шушы сорау белән газаплана түгелме?» дип уйладым.

Кич белән Сирайны мин тагын очраттым. Мәүлиха апалардан чыгып килә иде. Ул уң кулын иңбашыма салып мине үзенә табарак тартып китерде дә, сасы аракы исе куша-куша:

— Бик кирәге бар иде мәктәбегезнең... Надан булсам да, мин сездән акыллырак! Сугыш бит ул шундый нәмәрсә... яши белсәң яшәтә, яши белмәсәң... әйдә... фьют!.. Минем кебек берегез дә яши алмый!.. Берегез дә!.. — дип сөйләнде.

Мин көч белән аны читкә кактым һәм ашыга-ашыга кереп киттем. Болдырга менгәч, борылып карадым: Сирай урыныннан кузгалмаган, Арзулар тәрәзәсенә карап каткан да сагаеп нидер көтә иде...

## 10

Безнең елгыларны тагын военкоматка чакырдылар. Ишетүгә, әни балавыз сыга башлады. «Соңгысын алалармы? Соңгысынмы, ә?!»

Рәфгать безгә керде, иртән иртүк кардага төшеп киттек. Чаңгы белән генә элдермәкче идек, соңгы көннәрдә рәттән каты-каты бураннар булып торды, бөтен җир — урам-тыкрыклар, басу юллары ап-ак кар көртләре астында күмелеп калды... Уникe чакрым! Яңа кардан эз салып шул хәтле җирне узу алҗыткыч булачак, шуны уйладык та, никрутларча әрсезләнеп, председательдән ат сорадык...

Каравыл өе янындарак Рәфгатьнең кодалары тора, йомышы бар икән, ул аларга кереп китте, мин җилдән ышыкланып каравыл өе янында бер ялгызым басып калдым. Өйалдында ике ир кеше сөйләшәләр иде. Башта үз уйларым белән мавыгып мин аларга игътибар да итмәдем. Ирләрнең берсе Мәүлиха апа исемен атагач, сагаеп тыңлана башладым. Тавышларыннан таныдым, Гыйбадулла чулак белән Сирай сөйләшә иде.

— Май кап, май! — диде Гыйбадулла. — Май капсаң, озак яшәрсең!

— Майны кабам анысы, Гыйбадулла абый...

— Мин сине бер чакта да юньсезлеккә өйрәтмәдем, хәзер дә ялгыштырмам!.. Ак мамык кебек кыз, сиңа ни кирәк тагын? Син анда булсаң, миңа да җайлырак булачак... Барып йөрергә дим...

Гыйбадулланың сүзләрен аңлап булмый башлады, ул бик бирелеп, ышанып Сирайны үгетли, тегесе карышып маташкан була, шул ук вакытта риза икәнлеген дә сиздереп куя.

Рәфгать чыгып миңа кул болгады, теләр-теләмәсрәк атлап аның янына киттем. Сирай турында сүз башларга гына торганда, мышныймышный, үзе безне куып җитте.

— Мине дә утыртып барасызмы?

— Әллә сине дә чакырдылар?

Бер сүз әйтеп булмый башлады бу егеткә, шул сүзебезгә бәйләнә калды бит! «Юньсезләр сез», диде. «Кансызлар!» дип бетерде. Кәефләнеп кенә атлый башлаган идек, тәмам ачуны чыгарды, сөйләшмәс булдык. Җитмәсә, төшә-төшүгә, Хәбибрахман абзый Сирайга ябышты.

— Сиңа ат бирмим, — дип кырт кисте ул.

— Кем чыгарган закун әле бусы? — диде Сирай бүртенеп.

— Бирмим дигәч бирмим.

Болай да бүселеп, ачуланып төшкән Сирай кып-кызыл булды:

— Бирерсең, бирми кара, — дип янады.

— Янама, — диде Хәбибрахман абзый сабыр гына.

— Син Быржиннан сораган кеше дә юк. Мин никрут, хөкүмәт кешесе,— йөгерә-йөгерә җигәрсең!

Теле йогышсыз булса да, яшьтәш итепме, Рәфгать Сирайны жәлләп куйды:

— Я инде, Хәбибрахман абзый, куйчы шуны! — дип ялынып карады. Әмма картның йомшарыр исәбе күренми иде.

— Ат та бирмим, егетләргә дә утыртмаска кушам. Шәт, олы кешенең сүзен җиргә салмаслар. Утыртып бармагыз шул мөртәтне!

— Шулай укмыни? — дидем мин аптырап.

— Ул гыжлауны барыбер Кызыл Армиягә алмыйлар. Гыйбадулла чулак белән тәмәке суы чөмереп яталар бит алар! Ач карынга стаканы белән җибәрәләр. Нигә гыжлый дисең син аны?

«Бу Хәбибрахман картның белмәгәне юк!» дип уйладым мин. Сирай булып Сирай да бер мәлгә песиләнеп калды, аннары, тегермәндә төрле бәрелешләрдә чарланган икән, каһәр, ырлап Хәбибрахман абзыйның якасына ябышты:

— Каян күрдең? Каян! Падсуд җибәрәм мин син Быржинны! Өтермәндә черетәм!..

Хәбибрахман абзый Сирай янында — колга буе; озын куллары белән аны жиңел селтәп җибәрде дә безгә аңлатып бирде:

— Кансыз бәндә булыр бу! Узган атнада бер атны яндырып кайтты инде — Пигәшне. Кая барганын әйтми. Нишләп йөргәнен белгән кеше дә юк. Буш чана тартса яна торган атмы Пигәш?! Нишләп йөргән ул?

Ак-кара диярге өлгермәдек, Сирай атылып килеп тә җитте, Хәбибрахман абзыйның яңагына чалтыратып та җибәрде.

— Син... син!.. Фураж карагы! Бур син! Атларыңны юньләп туйдырмыйсың!.. Ат бирми кара, нигезеңне көл итәрмен!

Хәбибрахман абзый агач чөйдән дуга алып Сирайга кизәнде, сукмады, лач итеп төкерде дә аранга кереп китте, агач көрәк белән ат тизәкләрен идәндә тәгәрәтә башлады.

Сирайның тагын да ырлашырга нияте барлыгын сизеп, Рәфгать түзмәде, алагаемга берне китереп орды, чана урәчәсенә барып төште малаең. Мин дә җилкәсенә берне өстәгәч, ул бераз юашланып калды, торып тун итәген какты, әллә кая тәгәрәгән куян бүреген эзләп алды.

— Син нәрсә, атаң күк кешегә кул күтәрәсең?

— Атаң... атаң шундый булса... — диде ул, каш астыннан дөньясын сөзеп.

Барыбыз да чак тынычландык. Юлыбызның һич уйламаганда шундый гауга белән башлануы безнең кәефне бик нык кырды.

Өчәү чанада барабыз. Җирән бия, шактый көр булса да, чананы авыр тарта. Уйсу урыннарда гына түгел, кашлакта да тирән кар ята. Түбән авылның озын, тын урамын узганчы сөйләшми-нитми генә бардык. Билле сары тун, шап-шап куян бүрек кигән керәшен бабайлар куе кара сакаллары арасыннан чак күренеп торган челемнәрен авызларыннан алмыйча гына безгә сәлам биреп, хәерле юл теләп калалар. Рәфгать белән әллә ниләр гәпләшер идек, чанада Сирай бара, чанада минем ачу, нәфрәт бара.

— Озаталар бу юлы безне, егетләр, — диде Рәфгать калкынып. Аның ни уйлап баруын белү бер дә читен түгел иде.

Тегендә, карда ишегалдында, кыдрач этәч сыман кыланган Сирай, «озаталар» дигәнне ишеткәч, боегып калды.

— Алырлар дисеңме, малай? — дип сорады ул, чак өнен җыеп.

— Алалар дигәч алалар! — дип куәтләдем мин Рәфгатьне.

— Мужыт, язга тиклем ашыкмаслар?

— Алмасалар, үзем китәм, доброволь булып!

Рәфгатьнең чынны сөйләгәнен мин генә түгел, Сирай да сизә.

Җирән бия пошкырып-пошкырып куя. Тирә-ягыбызда күз камашырлык аклык. Офыктан чак кына аерылган кояш, үги кыз чырае кебек, моңсу.

— Ярый ла, син төз атасың, — дигән булды Сирай. — Биш патрунга кырык җидене җыйдыңмы әле?.. Минем кул кәкре, тигерә алмыйм!

— Күгәрченнәрне мелкашкадан кыеп кына төшерә диләр бит.

— Кулы дә кәкре дип өстиләр!..

— Кем әйтә? Күрсәт миңа шул йолкышны. Чыраен умырып алып, казык башына элеп киптерәм!

Тагын бераз гына шыгырдаганын тыңланып бардык. Сирай һич кенә дә тик ята алмый, боргалана-сыргалана, ютәлли, тамак кыра.

— Рәфгать яшьти, — диде ул, чыдары беткәч. — Унынчыларга брүн ди бит, алмыйлар ди аларны, укытып чыгарганчы тоталар, ди.

— Кем әйтә?

— Кем дип... Сөйлиләр инде. Гыйбадулла абый да шулайрак дип ишетеп кайткан.

— Чулак сөйләр ул. Тел сөяксез.

— Алай димә, яшьти. Районда әллә кемнәрне белә ул. Аны да беләләр. Пужар начальнигы аның первый әшнәсе...

— Көмешкә чөмергәндә әшнәдер...

— Көмешкә эчми ул, корсагына ярамый! Аңа чиста аракы булсын!

Сирай үзенең артыграк ычкындырганын сизеп туктап калды, озак кына уфылдап, әйләнгәләп ятты.

— Кемгә брүн кирәктер, миңа бирсәләр дә алмыйм, — диде Рәфгать.

Бүгенге чакыруның бушка гына түгеллеген барыбыз да дөрес чамалыйбыз. Рәфгатьнең шулай үҗәтләнеп Сирайны үртәп баруы да аңлашыла... Ирештерә торгач аз-маз ачылды малаең, Гыйбадулла белән сердәш икәнлеген дә таныды... Иш-ишен таба диләр бит... Никрут Сирай белән Гыйбадулла иш икән, нәрсә дуслаштырган аларны?..

Китүчеләр, калучылар турында сүз чыкты, искәрмәстән, кызлар турында сөйләшә башладык. Сирай, карап торуга бозау гына, Түбән авылның Кәбир кызы Мөгыйнә белән йөри икән. Авызыннан төкерекләрен чәчә-чәчә, дөньясын онытып, кинәнеп сөйли башлады. «Әткәсе белән тегермәнгә килгәннәр иде әле язлыкта, кеше мыж! Төнгә калдылар болар... Әткәсе келәт алдында агайне белән тәмәке пыскытып утыра, ә мин кызны шомырт агачына посырдым... Шунда агач арасында кочып үптем, малай... Имиләре, имиләре! Шалкан да шалкан, бу да шалкан...

Мактанырга, шапырынырга җай чыгуга Сирай бик шатлана иде, искәрмәстән, минем янтыкка нык кына төртте дә:

— Искәндәр яшьти, сиңа үч бар әле! — диде.

— Нинди үч?

— Бер тапкыр таш белән маңгайны яра язган идеңме?

— Кайчан? — дидем дә телемне тешләп тыелып калдым. «Ә-ә-ә!» дигән фикер күңелемдә яшен ташы булып сызылды.

— Кайчан икәнен үзең бел, — диде мактанган сыман Сирай.

— Хәтерләмим.

— Әй, хәшәп, шуны оныткан! Көзлектә, Арзу артыннан иснәнеп кайткан идеңме? Курмиләр ди бугай, әй, кайта инде бүлтерек бәрән күк терек-терек! Үзе курка тагын, биш чакрымга артта калган!..

Менә сиңа мыштым Сирай!

— Кое бурасы артында син идеңмени ул?

Ул канәгатьләнеп көлеп җибәрде:

— Мин булмыйча, койрыклы җен йөрсенмени анда?

Туңыбрак бара идем, кан тамырларыма кайнар кан йөгерде. Рәфгать тә сызгырып куйды: «Менә сиңа әбиеңнең кабармаган камыры!» — диде ул.

Сирайның сүз буасы тагын ерылды:

— Нәрсәкәй, әллә мине урамыгызда йөртмәс идеңме? Ким дисеңме? Арзу үземнеке дип уйлыйсыңмы?..

— Кемнеке соң? — дип ычкындыруымны абайламый да калдым.

— Кемнеке дип... Теге чакта алышкан идекме? Синең тез капкачың аерылганда?.. Уртага Арзуны куйган идем мин! Син җиңелдең!..

— Әллә Арзуга өметләнә инде бу кеше? — дип көлде Рәфгать. — Мөгыйнә җитмәгәнме аңа?!

— Миңа Арзу кирәк! — диде чатнатып Сирай. — Яратам мин аны. Белдегезме?.. Бабасы булмасамы?.. Бабасы аркылы төшә!.. Мине сугышка алмыйлар, үпкәдә бар минем. Сез китәсез... Арзуга кул салырлык нинди егет кала авылда? Кем миңа аркылы төшә ала?..

Ишетмәсәң ишет, Искәндәр!.. Менә эшләр кая таба китте!..

Арзуны үземнеке итеп санарга уйларымда, хыялларымда да кыймый идем мин. Кая ул телдән үк шундый йогышсыз сүз әйтү! Мин аны аяклы-куллы гади хатын-кыз итеп түгел, илаһи бер югары зат, тиңдәшсез олы итеп санап йөрим. Кичләрен, йокы алмый яткан газаплы мизгелләрдә, ул миңа таңгы нур көлтәсе, кичке шәфәкъ, күз явын алырлык кыңгырау чәчәк бәйләме, сары такыя булып, салават күпере төсле елкылдап кына күз алдыма килә иде. Шундый илаһи кешене, Есениннарны, Такташларны юлдаш иткән кешене, «синеке, минеке» дип ничек бүлешеп барырга мөмкин?!

Җитмәсә, «синеке түгел!» диләр бит әле... Кем әйтә диген!..

Ике бозауга кибәк аера белмәгән бер апара корсак...

Арзуның ал битләре, чем-кара күзләре күренеп киткәндәй булды... Сикереп тордым да Сирайга акырдым:

— Син маташтыңмы Арзуны бозарга?

— Ничек? Нишләп бозыйм ди мин аны?.. Бозым белән пычагымны кырырсың бик... Егете бар аның. Йөргән егете.

— Кем? — дидем мин, гаять гарьләнеп.

— Сары төймәле егет килгән идеме? Асылов. Мәскәүдә югары укуда булып кайткан, син-мин түгел, партийный. Арзуның егете шул. Әллә ничә тапкыр Зәйдә күрдем үзләрен. Берсендә ак чиркәүдән кинодан чыгып киләләр иде.

Сирай янында үземне бик олыга куеп барсам да, Асылов исемен ишеткәч, мин артка чигендем... Сирай белән без бик артта калдык, алгы планда Арзу янәшәсендә япа-ялгызы Асылов калды.

Озынча буйлы, ябыграк гәүдәле, зур, акыллы күзләрен тутырып карап, йомшак тавыш белән ашыкмый-кабаланмый сөйләшә торган, өр-яңа затлы киемнәр кигән Асылов янында мин үземне янымдагы Сирай рәвешендәрәк күрдем. Арзу янына Сирайны бастырып мин ниләр уйлый алсам, шундый ук эшне Асылов та эшли ала, бу юлы кызганыч кеше хәлендә мин үзем кала идем...

Мин тындым, Рәфгать кенә тынмады, ул Сирайны кат-кат кысып карады, юмалады, янады, әмма тегермәнче малае терәлеп каткан иде: «Юк! Бозымны-мазарны белмим. Батырмагыз мине, буямагыз! Ә Асылов турында әйткәнем хак! Тегермәндә анда информбюроң бер якта торсын! Барын беләләр! Быржиннарның сыерын суйганнан бирле шәп тәтелдиләр анда!»..

Рәфгатьнең юравы юш килмәде: безне әлегә алмадылар. Үзебез китәргә дәртсенеп, военком янына кердек. Елмайды майор, урыннан торып, аркадан какты. «Көне-сәгате житкәч чакырырбыз, әлегә тырышып укыгыз, Кызыл Армиягә белемле егетләр бик кирәк», — дип озатып жибәрде.

Эленке-салынкырак булса да тагын мәктәпкә йөрибез. Рәфгать белән көннәр буе бергә уралсак та, арабызда электәге татулык, эчкерсезлек калмады диярлек. Юк кына нәрсә өчен дә әләгешеп киткәлибез. Рәфгатьнең сүзе бер генә: ул мине ваемсызлыкта, боламыклыкта гаепли.

— Ак белән караны аера белмисең... Хәбиб малаен чанадан сугып та төшерә алмагач, егет булып йөрүең корсын! «Юк» дисә дә, бозымны ул салган! Бозымга, сихер-михергә ул наданнан башка кем ышансын?! Теге кызыл сакалыңны да авыл Советына тарттырырга иде. Үзе «шпион» түгел микән? Документларын тикшердеңме?

— Дәлилсез килеш закон каршына кешене ничек бастырасың! — дип карыйм, сүземне колагына да элми.

— Көт, алайса, дәлил! — дип кенә жибәрә.

Фронтка тизрәк жибәрүләрен сорап ялгызы гына райкомолга барып кайтуын Арзудан ишетеп белдем. Рәфгатькә: «Нигә миңа әйтми киттең?» — дигән идем, «Куркак ич син!» — дип авызымны йомды.

— Батыр булып син ни кырган? — дип мыгырдандым, дустыма хәтерем калды.

— Сөйгән кызы өчен бер тапкыр булса да канга-кан тузышмаган егет егетмени ул?

— Нинди сөйгән? Кем?

— Кара, кара! Чөгендер булды үзе! Куркак булу өстенә, шәп кенә ялганчы да икәнсең әле син, Искәндәр!

Рәфгатькә мине табаларга җай чыгып кына тора. Дүшәмбе көнне мәктәпкә барсак, кайсы явызыныңдыр безнең класс тәрәзәсеннән ике олы өлге пыяла урлап китүе мәгълүм булды. Ике көннән соң, тагын шулай төнлә өч зур өлгене алып киттеләр. Зөләйха апа директорыбыз

ашыгыч боерык чыгарып, укытучылардан һәм өлкән класс укучыларыннан мәктәптә даими төнге дежурлык билгеләде.

Бер караганда артык мәшәкать булса да, ул дежурлык дигәннәре яшь-җилкенчәккә мач та килде әле! Аулак өйләрдә буталып йөргәнне әнием яратып бетерми иде, хәзер, «дежурга барам!» дисең дә теләгән саен чыгып китәсең. Арзу анда чакта мәктәптән кайтып кермим, үзебезнең класс кызлары өчен дә калгалыйм, үз чиратымны да бирмим. Әни, шиккә төшеп, бер көнне дулап та алды:

— Бу ни бетмәгән жужур булды инде, тәмамысы язгы бизгәккә әверелде! Син анда, матри, Фатыйма кызы белән кыҗыр-быҗыр куерта күрмә... Абыең абына язды, синнән дә ерак йөрмәс, күзләрең бик елтырый. Алтынга мансалар да, Фатыйма кызы Фатыйма кызыдыр инде. Нәсел-нәсәпкә, тилчә тамырга... Алма агачыннан ерак тәгәрәмәс.

Әни кадәр әнидән шундый нахак сүзләр ишеткәч, үтә рәнҗедем, кычкыра башлавымны сизми дә калганмын:

— Әнисе өчен бала гаепләме?! Әгәр аның әнисе әшәкс булган икән, Арзу үз агачыннан ерак тәгәрәгән алма. Ул әнисен белми, аны бабасы карап үстергән!.. Ул... Ул...

Әни дә тәмам аптыраштa калды.

— Чү, чү, балам, ипләп! Кычкырма, — диде ул хафаланып. — Сугыш әллә нинди бәла-казалар чыгара торган була. Язгы ташкында бөтен чир-чор, чүп-чар купкан кебек, сугыш заманында юлдан читтә яткан таш та кыймылдый ди торган иде синең Җиһангир бабаң. Бу араларда бозым ише нәрсәләр турында еш ишетелә, бозмаганнардыр ич сине? Ул имансыз мәктәптә йоклый-йоклый авырмагансыңдыр бит? И-и, аллам...

Чуклы чүпрәк белән песи баласын ирештереп идәндә кайнашкан Нәсимә, купшакланган борынын тартып:

— Беләм инде, беләм! Арзу апа Искәндәр абыйга яулык чигеп биргән! — дип чәрелдәде.

Нәсимәнең борынына нык кына берне чирттем — теләсә кая сузмасын! Ул шыңшып калды, әнидән оялып ишегалдына чыгып киттем, ялан өс килеш әллә ни арада тау хәтле утын яргалап ташладым. Кызган шәпкә, Рәхимҗан бабайларга барып кердем, күздән бирле ишегалларын тарайтып, күзгә кереп яткан карама түмәрләрен ваклап, лапас астына ташып өйдем. Көзен пешеләнеп яткан карама түмәрләре балта белән берне оруга икегә аерылып әйләнеп кенә төшәләр! Хәтимә апаның да, Рәхимҗан бабайның да исе китте, чәйгә кер дип бик кыстаганнар иде, кермәдем. Аркам манма су булды, ә балтам, ышанасызмы, ут кебек кызган икән...

Авыл арасында «чиккән яулык» дигән сүз тараткаңнар икән... Нәсимә, юеш борын, берәрсеннән ишетеп сайрый аны. Мин чынлап торып халык теленә керерлек, Арзу исеме белән исемемне янәшә куеп йөртерлек егет булганмын икән! Ә Асылов? Ә Сирай?.. Ә мин белмәгән «бозучы?!» Алар бу мәсьәләгә ничек карарлар?..

Юк, Рәфгать ялгыша, аңламый мине. Тукмый ала идем мин Сирайны, нык ук бирә идем. Военкоматта «Тезе тотмый ич аның, шырт итә дә ычкына» дип мыскыллаганы өчен генә булса да, җир күмере ясый ала идем... Шулай да тимәдем: ни гаебе бар соң аның? Сөйләнә икән сөйләнсен!.. Арзу дип безне үчеклэп кенә барды ич ул!.. Кое янында без очраклы гына туры килешкәнбез! Алар Гыйбадулла белән Мәүлиха апалардан чыгып киләләр икән, мине абайлаганнар. Гыйбадулла аяк чалып мине тәгәрәткән, Сирай чишмә сукмагы буйлап элдерткән...

Ничек күрмәгәнмендер мин аларны, монысын һич тә аңлата алмый идем...

Юк, юк, Сирай Арзуга гыйшык тотадыр дип әйтергә телем бармый!

Юк, юк...

Димәк, гыйшык юк җирдә нәфрәт каян булсын?! Сирайга кул күтәрә алмадым, Рәфгать теләсә нәрсә әйтеп сүксен, кыйнамадым апара корсакны...

Минем шөбһәләремне ачыклагандай, нәкъ Яңа ел алдыннан, жомга кичендә, Мәүлиха түти көмешкә эчеп шактый мәлҗерәгән Сирайны үзләренә ияртеп кайтты. Кәримә белән икесенең туен да озак тотмадылар... Сирайның әнисе сәке йөзлегенә ябышып елый икән дип сөйләсәләр дә, Мәүлиха түти кияүдән бик канәгать иде.

— Аллага мең шөкер, ихлас күңелле төпле егеткә тап булдык. Кәримәнең аяк арты җиңел булсын, — дип, өй борынча шатлыгын уртаклашып йөрде.

Сирайның солдатка китәр алдыннан гына ишле гаиләгә йортка керүе акылга сыеп бетмәсә дә, без, Түбән очлар, аңлый идек. Мәүлиха апалар ир-атсыз яши алачак түгел, кыш уртасында суыкка ябышып катачаклар. Тик менә нигә Сирайны сайлады Мәүлиха апа? (Кәримә дип әйтергә һаман телем бармый!) Горур, үзенә күрә тәккәббер, һавалы Кәримә ничек аңа чыгарга ризалашты? Түбән очның «яшь әтәчләре» яшелле-мөшелле тавыш белән:

Чүке болынында оча
Аллы-гөлле күбәләк.
Кызы озын, егет кыска —
Үбешәләр чүгәләп.

— дип такмаклап узганда, ничек түзде?..

Озакламый, бу табышмакка да азмы-күпме ачыклык керде, Сирайны армиядән бөтенләйгә калдырып торалар икән, дигән хәбәр таралды. «Ындыр артыгызга фронт килеп житсә генә сине обозга алачаклар, егет», — дигәннәр, имеш...

Гыйбадулла чулак: «Сирайны солдаттан бер оя үрдәк алып калды. Үрдәкләрнең шулай көчле булуын беренче тапкыр күрүем»,— дип сөйләнгән, имеш.

Сирай безнең оч кияве булды. Иртән дә, кичен дә очрашабыз диярлек. Икәүләшеп коеның өстен ачып ташладык, ул аска төшеп чиләккә тутырып торды, мин түктем — коены күңел булганчы чистарттык. Ык эшли малай, мин аның жаена чак-чак өлгерәм...

Коедан чыккач, аның ниндидер яшерен сагыш белән Арзулар тәрәзәсенә карап торганын сиздем... Шушы мокыт Сирайда да никадәрле сер бар бит, уйлап карасаң!..

## 11

Төнге уннар чамасымы, әллә унберме? Беребездә дә сәгать юк, мәктәп ихатасы тирәли байтактан йөрибез. Алдан Арзу бара, аның артыннан тар сукмактан Рәфгать белән этешә-төртешә без атлыйбыз. Салкын. Чалт аяз төн. Купшы күк йөзе үзенең бар булган алтын-көмешләрен таккан, япанчасына энҗе-мәрҗәннәрен сипкән, бизәнгән. Офыклар гына көрәнсу-кара, тар гына ай урагы офыкларны яктырта алмый...

Йолдызлар ачыла. Без «әнә!» дип бер-беребезгә йолдызларны күрсәтергә ашыгабыз. Минем, нәкъ сабыйларча, йолдызларны күбрәк һәм Рәфгатьтән алданрак күрәсем килә...

Төнге дежурлык куелганнан бирле мәктәп тәрәзәләренә кагылмыйлар, утынын да урламыйлар...

Өченче көн әтидән хат килде, Калинин фронтында икән. «Безнең хәлләрне гәҗитләрдән укып беләсездер. Шул бер чама, сугышып ятабыз... Кышкы суык бик яман, ну, немецны да куыра. Үзегездә ни хәлләр? Искәндәрне алмадылармы әле? Безнең янга алар елгылар кила башлады. Хәере белән булсын азагы. Барыбер җиңеп кайтырбыз», дигән...

Бездә ни хәлләр? Яңалык шул икән, әтигә язасы булыр, атна элек кенә Гайникамал әбине җирләдек. Мантымады бичара, Арзу ни тырышты, җилкәсендә күтәреп алып барып эссе ләүкәдә мәтрүшкәле-бөтнекле себерке белән дә чабып карады, юкә чәчәгеннән ясалган төнәтмә парында сәгатьләп утыртты, авызыннан сары майда кетердәп пешкән коймак өзмәде, балдан-майдан мәхрүм итмәде, барыбер карчыкның җанын саклап кала алмады. Зурлап күмдек...

Хәлләр шул, агач мылтыкларны асабыз да чаңгыга басып Басу арты урманыннан әйләнеп кайтабыз. Авылга кергәндә, агач гранаталар ыргыта-ыргыта, «Ур-ра!» кычкырып чапкан булабыз... «Их» дип көрсенә Рәфгать...

— Керик, малайлар, — диде Арзу. — Суык та... Сез аз-маз йоклап алырсыз, минем бер кочак тикшермәгән дәфтәрем ята...

Кердек тә, аннан-моннан чишенеп, Рәфгать белән икебез укытучылар бүлмәсендәге күн диванга сузылыштык. Арзу, җиделе лампаны кысып кына куеп, директор кабинетында утырды. Ут яктысы урамга төшмәсен өчен тәрәзәләргә географик карталар эленгән... Ябылып бетмәгән ишектән, кылыч кебек кенә сызылып, безнең як идәнгә ак нур төшә, әнә шул нур миңа йокларга ирек бирми, әлләниләр уйлата, чыгардай җанымны тетрәтеп, ул якта ара-тирә кәгазь кыштырдап ала...

Мин йокламыйм, йоклый алмыйм, минем аның янына чыгасым, аның бирелеп дәфтәр тикшергәнен читтән генә булса да күзәтеп торасым килә. Мин уйларым белән әллә кайчан анда, аның янында, тик чыгарга ярамый. Әдәпме, оятмы, ниндидер бер хис мине тыеп тора, аның шунда якында гына икәнен тою, ул сулаган һаваны сулау, аяк тавышын ишетү үзе дә зур бәхет ич, тиңдәшсез бәхет! Минем тын тартырга да куркып ятуымны сизәдерме ул? Сизәдер, сизәдер!..

Мин бер мәлгә генә Асылов турында да, Сирай турында да онытып торам, хыялымда ул, бары тик ул гына кала...

Кай арада йокыга киткәнмендер, «малайлар, малайлар, торыгыз!» дигән тавышка чәчрәп уяндым. Рәфгать тә торып утырган, йодрыгы белән күзләрен уа.

— Торыгыз, тор, пожар!

— Ә?! Нәрсә?! Кайда?

Йокы куян булып качты.

— Әнә, карагыз.

Күрердән әвәл, урам яктан: «Пожар! Янабыз!» дип акырышканнарын ишеттек, җанны өшетеп чаң кага башладылар. Йөгерешеп тәрәзәгә сарылдык, берни белеп булмый, пыялаларга кунган абагалар алтын сары чәчкә атканнар! Куркыныч. Дәһшәтле куркыныч. Әллә салкыннан, әллә куркудан өчебез дә дер-дер киләбез, тешләр тешкә тими. Бишмәтләребезне кия-кия, ишегалдына атылып чыктык. Куркынычы монда икән әле аның. Моннан якында, йөз атлам чамасында гына, бәрәңге бакчасы мәктәп тәрәзәләре каршысына ук килеп җитә торган чат Нургалиләр өе дөрләп яна иде. Әрсез ут шактый үрләгән инде, салам түбәне эре-эре телләре белән ялмап маташа, ут яктысында әрле-бирле йөгерешкән кешеләр, август эссесендә аяк астыннан төрле якка сикерешкән чикерткәләр төсле, куркынган һәм кечкенә булып күренделәр. Мәктәп ишегалды, йортлар, тәрәзәләр, ак кар җан өшеткеч сәер ал төскә манылган, күк йөзе кап-кара, йолдызлар югалган. Без дә, «Пожар!

Пожар!» дип сөрән салып, Нургалиләргә таба чаба башладык. Безгә иярган Арзу кычкырып җибәрде:

— Малайлар! Ә мәктәп? Без бит постта!

— Мәктәп янмый ич!

— Җил кайсы яктан исә? Нәкъ мәктәп өстенә бит!

Кай арада җил чыккан диген, нәкъ менә мәктәп өстенә исә! Чат Нургалиләр түбәсеннән тубал-тубал очкыннар нәкъ мәктәп түбәсенә җитәрәк сибелешеп сүнәләр. Ә сүнми калсалар? Янгын көчәеп кенә бара ич, сүнми калсалар, рәттән салам белән ябылган биналар тоташтан ут азыгы булачак!

Арзу акылын җыеп өлгерде:

— Егетләр, түбәгә менегез! — дип кычкырды.

Карлы-бозлы авыр баскычны каз каурыен йөрткән кебек кенә очыртып пожар ягына чыгардык та түбәгә сөядек; балта, көрәк, багор, лом ише әйберләрне дә шул тирәгә ташыдык. Торабыз. Ул арада мәктәпне сакларга байтак кеше җыйналды. Түбә кары эреп безнең өскә су булып ага башлады, хәл минут саен хәтәрләшә бара иде. Рәфгать, мин, тагын бер-ике укучы түбәгә менеп киттек һәм сүрән генә төтәгән салам кисәкләрен кар белән томалый башладык. Эссе. Түбәдә янгын тагын да дәһшәтлерәк күренә иде. Сугыш кыры күз алдыма килеп китте. Анда да шушындый соры, үлек төс белән шәһәр-авыллар янадыр, тик як-ягында бомба, снаряд кыйпылчыклары гөжләп яуганда кешеләрдә янгын сүндерү кайгысы бар микән? Әле менә шушында, бөтен авыл җыелып сүндергәндә дә кешеләр һушларын җуеп, каушап калдылар. Җил күтәрелгәннән-күтәрелде, яман сызгырып, очкыннарны гына түгел, салам, вак чыбык кисәкләрен дә мәктәп түбәсенә яудыра башлады. Түбәләрнең утка караган ягында кар эреп агып бетте, җылы төшмәгән якның карын көрәкләр белән бу якка атып бетердек.

Нургали үзе балта остасы иде, ихаталары әйбәт нараттан салынган, берничә торык лапас өстенә, сыер абзары һәм таза гына келәте бар. Аларның олы малайлары безнең Нәсимә белән бишенчедә йөри, тагын өч баласы — кечкенәләр. Хәзер менә шул ихата утырып яна! Агачмы, нилэрдер шартлый, ата, көлтә-көлтә ялкын гүләп күтәрелә. Пожарның үз тавышы, дәһшәтле шомлы гүләве бардыр дип һич уйламаган идем! Әгәр бал кортлары урынына мең тилгән яки козгын куч булып оча башласа, нәкъ менә шушындый куркыныч, канны өшетә торган авазлар чыгара иде.

Әле анда, әле монда түбә көйри башлый, без, юеш, черек саламга балтыр тиңентен бата-бата, түбә буйлап чабабыз, кайбер урыннарда аяк бот төбеннән аска кереп китә, салам астындагы чыбык арасына өлгә, Рәфгать миңа кычкыра, мин аңа, арабызга Сирай килеп кергәнен тавышыннан гына абайладык.

— Нәрсә катып торасың, су менгер, су!..— дип, кемгәдер акыргач кына айнып киткәндәй булдык. Сирай баулы чиләк тотып менгән икән, астагылар көянтә-чиләк белән мәктәп коесыннан су ташыйлар, ул шул чиләкне түбәгә менгереп тора, имеш...

Сирай безгә дә кычкыра башлады:

— Катып тормагыз әле, тәре баганалары! Әнә ич, күзле бүкәннәр! Теге почмак көйрәп ята!

Без бата-чума «теге почмакка» ташланабыз, көйри башлаган түбәне толыкманы белән аска ишеп төшерәбез.

Сирай су да сибәргә өлгерә, көрәге уйнап кына тора, тыны гыжлый, маңгае, бите кап-кара булган. Мәүлиха апа да киявен күзәтергә килеп җиткән, учларыннан бүрәнкә ясап авызына китергән дә пожар тавышын басып чәрелди:

— Кияү, кияү, сак бул! Аягың таймасын дим... Ай, тырыш шул минем кияү балакаем!.. Сирай кияү дим, алай кырыйга килмә! Килмә!

Әллә киеменә ут капты инде. Искәндәр, дуңгыз малай, минем кияүне карачы!..

Мин Сирай өстенә кар сибәм, аннан тотен күтәрелә, ул яман итеп сүгенеп җибәрә.

Эш арасында Арзуга да күз салырга өлгерәм, алар Зөләйха апа белән укытучылар бүлмәсеннән әйберләрне акрын-акрын чыгара башладылар. Җил бик хәтәр өрә шул, шикләнәләр булса кирәк. Ул арада Түбән авыллар менеп житте, мәктәп янында халык ишәйде, кемне кемнән аерып булмый башлады. Ничек булгандыр, түбә белән мавыгып сизми дә, ишетми дә калдык, Сирай түбәдән туп-туры җиргә сикереп төшкәч, башкалар «ах» итеп куйгач кына аска карадык. Кемдер түбәдән бер кочак утлы салам ишеп төшергән: салам су күтәреп килүче Арзу өстенә туры килеп, аны аяктан еккан... Ут белән су арасында калган Арзу бер минутка гына һуштан язган, янындагы хатын-кызлар нишләргә белми югалып калган; Сирай, мокыт, каян чамалап өлгергәндер, түбәдән җиргә сикереп тә төшкән, ава-түнә Арзу янына килеп тә өлгергән, саламнан арчып аны уттан аралап алган. Мин дә, бик ярсып, төшәргә чамалап түбә кырыена килгәндә, Арзуны күтәреп мәктәп бүлмәсенә алып кереп киттеләр.

Өй янып бетеп килгәндә, акырып-сызгырып, пожар насосы тагып, Гыйбадулла килеп житте, ике-өч ир кулларын төкереклэп насос басарга тотындылар, көпшәдән нәзек кенә сызылып чыккан су ут өстенә барып төшкәнче күздән югала иде.

Шулай да ут акрынлап сүнде, биреште. Без дә лычма су булган итәкләребезне баскычның тайгак араталарына шап-шоп бәрә-бәрә түбәдән төштек. Мин беркемгә бер сүз әйтеп тормадым. Арзу янына йөгердем. Ул, бит-күзен юып, чистарынып, үзе минем каршыга чыгып килә иде. Кочагымны җәеп бер кысып алыймммы әллә дип торганда, Рәфгать килеп җитте, Арзу кырыйгарак тайпылып көлеп куйды һәм безгә карап:

— Йөгерегез, егетләр, югыйсә, салкын тияр сезгә. Өйләрегезгә чабыгыз,— диде.

Бияләем югалган иде, ул да ялан кул, безнең куллар бер-берсенә тиеп китте.

— Хәлең ничек? — дидем мин, китәргә теләмичә.

— Күрмисеңмени? — диде ул көлеп.

Урамда — шау-гөр, берәүләр өйләренә кайтып бара, берәүләр әле уянып «пожар карарга» килә, кемдер елый, кемдер көлә, галәмәт!..

Икенче көнне өйдә дә, мәктәптә дә сүз төнге ут турында гына булды. Кәҗә башы урамының кайбер кызлары янгын барын ишетмәгәннәр дә, йоклап калганнар. Алар, безнең дежурда булганны белгәч, көнләшеп сорашалар. Баш авырта, йокы килә, авыз минут саен ачылып-ачылып тора, ярминкәдә булмаган ич, аның нәрсәсен сөйлисең, утның?! Имеш-мимешләр утның үзеннән дә хәтәррәк дөрли башлады. «Нургали хатыны сыер бозауламадымы икән дип абзарга кергән дә шунда ширпы сызып ут төшереп калдырган» диючеләр булды. «Нургалинең Әнәсе, бишенчедә укучы ташбаш, качып тәмәке пыскыта икән, өй почмакларының мүген тартып бетергән, шул шайтан баласының эше генә бу!» дип тә сөйләделәр. Авыл гөж килде!

Имеш-мимешләр расланмады: Нургали хатыны төнлә чыгып йөрмәгән, Әнәсе дә тәмәке тартмый икән. Инде янгын чыккан җирдән ерак та түгел ят чиләк белән керосинга манчылган чүпрәк кисәге дә табып алгач, бөтен Югары авыл «ах!» итте. Милицияләр килде, эт китереп бата-чума эзләнеп йөрделәр. Асылов та килде.

Бу юлы беренче башлап Рәфгать белән мине чакырды, икебезне ике ягына утыртып, бергә дә сораштырды, аерым-аерым алып калып та сөйләште. «Сез ул төндә йокламагансыз... Арзу Ямашева сезне игътибарлы, күзәтүчән егетләр ди. Ниләр күрдегез? Урамда кемнәр йөрде?

Ят кеше күзегезгә чалынмадымы? Укытучылар кайчан китеп бетте, берәр кешенең үз-үзен тотышында үзгәреш сизмәдегезме? Өлкән класс укучыларыннан мәктәптә калучылар булдымы? Имеш-мимешләрне кем тарата? Сүз кемнән чыкканын белеп булмасмы?»

Белгәнне сөйләдек. Ләкин Асылов без белгәннәрне бик азсынып, сытык чырай белән баш чайкап утырды.

Икәүдән-икәү генә калгач, Асылов, уйларга вакыт биргән сыман, байтак кына дәшми утырды. Аннан көрсенеп тәрәзә янына барып басты, кинәт кенә миңа таба борылды да:

— Сирай Хәбибов турында ни уйлыйсың? — дип сорады.— Белгәнеңне яшермә!

— Ни уйлыйм дип... Уйлаган юк!

— Аны беләсеңдер бит?

— Беләм белүен... Беләм дип тә бетерә алмыйм, монда тормый ич Сирай. Тегермәндә. Быел гына ешрак күрәм... Безнең оч кияве бит...

— Чыгып йөргәлиме ул? Кемнәр белән аралаша?

— Мәүлиха ападан бик чыгып йөри алмассың...

Асылов миңа табарак иелде дә:

— Арзу Ямашева белән аларның мөнәсәбте ничек? — дип сорады.

— Каян белим ди анысын?..

Почмакта иске чүпрәк белән төреп куелган бер нәрсә бар иде, Асылов шуны сүтеп җибәрде. Карасам — янган чиләк.

— Бу чиләк сиңа таныш түгелме?

Тутык кисәкләре кубып-купшып торган янган чиләкне кулыма алып әйләндереп-әйләндереп карадым. Таныш дип, тукта әле, менә бу ике сызык... Көз көне багор белән без сызган идек түгелме соң боларны? Мәүлихалар чиләге түгелме соң бу?.. Түгел, түгел... Без сызганнар тирәнрәк тә, озынрак та иде... Юк, юк...

Әгәр мин бу чиләкне беләм дип әйтсәм?.. Арзу турында сүз кузгалачак... Сирай телгә керәчәк... Әнә ич, Асылов нидер сизенә, нәкъ менә шулар турында сүз алырга тели...

Әйтергәме? Әйтсәм... Мин кем булып саналырмын монда? Көнчелектән, көчсезлектән яла ягучы булып калмаммы? Ярый ла, әйткәнем раска чыкса? Ә чыкмаса? Мондый калшайган чиләкләр азмы әллә кешеләрдә?..

Чиләкне әйләндереп-әйләндереп карадым да кире суздым:

— Белмим, иптәш Асылов, күргәнем юк,— дидем.

Эт икән бу Асылов дигәннәре, минем күңелдәге каршылыклы уйларны сизенде бит:

— Тикшерүгә ярдәм итәргә теләмисез, алайса? — дип куйды.— Аңлагыз! Монда эш уеннан узган! Кемдер Нургали Исхаковларга ут салып мәктәпне яндырырга теләгән. Без ул кешене табарга тиеш!

Тик мин артыгын бер сүз дә әйтмәдем. Әгәр Асылов урынында башка берәү утырса, ихтимал, мин үземнең шикләремне сөйләп тә биргән булыр идем. Бу очракта мин аның җиңүен, тантана итүен теләмәдем, ахры. Ике арадагы сүздә Арзу исеме телгә алынуын теләми идем...

Әле мин ул кичне Асыловның Нәҗип атлы булуын да, аның, Арзу шикелле, комсомол пленумы члены икәнлеген дә, аларның төрле җыелышларда гел-гел бергә утыруларын да, егетнең кызда өмете барлыгын да белми идем.

Бездән соң Асылов янына Арзу керде, мин, бәбкә саклаган тилгән кебек, колхоз кәнсәләре тирәсендә уралсам да, ахыргача түзә алмадым, көн бик суык иде, аяклар тәмам боз булгач, өметемне өзеп, өйгә йөгердем...

Яңа ел килеп озак та тормады, колхоз председателебез Лотфулла агайны сугышка алдылар. Идарәдә баш булып партоешма секретаре,

ферма мөдире Нәгыймә чәтертән калды. Аны председатель дә иттеләр. Өлкәннәр арасында: «Тотарга да Хәбибрахман картны куярга кирәк!» дигән сүзләр йөргән иде дә, тыштан белдермәсә дә, аның нык ук сырхау икәнлеге мәгълүм булды. Авыру димәссең үзен, тынмый, гел өйдә тормый диярлек, атлар яныннан кайтты исә, чәчүлекләрне тикшерергә киләтләргә төшеп китә, алачыкта кул алмашлап күрек баса...

Мин элеккечә Арзуларга кереп утыргалыйм. «Аулак өйләр мөбарәк булсын!» дип, ике кесәсенә дә шыплап көнбагыш тутырып, кай арада Рәфгать тә килеп чыга. Керә дә, көнбагышын өстәлгә бушатып, ут төшми торган караңгырак почмакка урнаша, тезләрен кочаклап сүзсез генә тыңланып утыра. Күрше-күлән кызлары да кергәли, алар челтәр, пирчәткә бәйлиләр, көнбагыш яралар. Җырлап та алабыз. Арзу башлап җибәрә, Рәфгать караңгы почмактан аны күтәреп ала, без кушылабыз. Сугыш елы җырлары моңлы, сагышлы...

Бер кичне юк-барны сөйләшеп суган сатып утыра идек, ачу белән ишек дөбердәттеләр, дөп-дөп кагалар.

— Кем анда ишеккә сыймый, ачык ич! — дип эндәште Арзу, урыныннан кубып.

Озын куньчлы ак итек кигән, куян шарфын пинжәк якасы өстеннән ураган Сирай килеп керде, ялан өс.

Безнең авылда яшь кияүләр, бикәчләрен өйдә калдырып, бер-ике ел буе аулак өйләргә килгәлиләр, анысы гаеп саналмый, тик менә Сирайның шулай ялан өс, ялан баш килеп керүенә бераз гаҗәпсендек. Мәүлиха апа кияүен түгел, өй тулы кызларын да Арзуларга аяк бастырмый иде.

Сирай ишеген юньләп япмады, хуҗаларча эре-эре атлап түргә үк узды, сәкедә тезелешеп утырган кызларны чеметкәләде, кайсысына каш сикертте, утыргач, авызын бөреп хихылдап куйды.

— Көнбагыш чиртәсезме, аккошлар?

— Монда карчыгалар да бар,— диештеләр кызлар, челтәр энәләрен уйнатып.

— Искәндәрме? Ябалак диегез әле шуны.

Почмак яктан Рәфгатьнең тавышы чыкты:

— Сирай дус, көлүең матур матурын... Ичмасам, бер генә мәртәбә булса да нигә көлүеңне беликче?..

— Бәй, Рафа да монда икән! Күрми торам. Нихәл, парин... Шуны карчыга дидегезме әллә, аккошларым? Рәфгатьне әйтсәгез дә ярый. Егет, ичмасам!

Ул утырган җиреннән генә үрелеп өстәлдә өелеп торган көнбагышларны учына көрәп алды һәм учы белән авызына салды, чуар, юеш кабыклар аның иреннәре арасыннан бер-бер артлы идәнгә сибелә башлады.

Аның шулай оятсызланып, идән чүпләп, бөтен игътибарны үзенә җыярга омтылып утыруы Арзуга да, миңа да ошамады.

— Бар әле, Сирай яшьти,— дидем мин.— Кәримә тәтиеңне урламасыннар... Җилгә чыккан җирдән генә качып кергәнсең, көтәләрдер.

— Минеме? — диде ул, аска караган килеш.— Тышауда дип беләсеңме әллә мине?.. Көләргә яралган авыз син, парин.

Сирайның чыгарга исәбе күренми иде, безнең бәхеткә, урам ягыннан яман чәрелдәгән тавыш килде, шунда ук тәрәзә кага башладылар. Мәүлиха апаның тавышын иң әүвәл кияү таныды, көлгән булды, торып тагын кызларга кагылды, Рәфгать янына барып, аның аркасын какты, бусага янына барып житкәч, шарфын хәтәр генә җилкәсенә чөйде, тын гына чыгып югалды.

— Кулы артына житми, тагын ачык калдырды,— диде бер кыз, ярым ачык ишекне яба-яба.

— Фу кәҗә тәкәсе исе килә үзеннән, — диде икенчесе. — Сарымсак тыгынганмы?

Арзу гаепле кеше сыман миңа карады.

— Ни кирәктер бу әшем иясенә?! «Мин сине үлемнән коткардым» дип килә дә керә.

— Аягын кыскартырга кирәк, алайса, аның! — дидем мин.

Рәфгать мыскыллап:

— Кыскартучысы синме? — дип кычкырды.

Кызлар эшләрен куеп көлешеп алдылар, Арзу белән мин, башкаларга сиздермичә генә, бер-беребезгә караштык...

Кичләрнең берсендә Арзу белән икәү озак кына утырдык. Вакыт шактый соң булса да, ул мине чыгармый. «Утыр азрак, ялгызыма күңелсез!» — ди. Мин утырам да утырам, бер заман буран аша капка шапылдавы ишетелде.

Арзу сискәнеп:

— Бабай кайтты бугай,— диде.

Хәбибрахман карт белән болай соңгарып очрашасым килмәдеме, Арзуга ияреп өй алдына чыктым, бабасы өйгә узып киткәнче дип, чоланнарына кердем. Арзу этә-төртә мине кертеп җибәрде дә көлә-көлә өй алды ишеген ачты:

— Озак тордың, бабай. Бик туңмадыңмы?

— Озаккарак тартылды шул, нишлисең...

Алар керергә ашыкмыйлар, Хәбибрахман карт тырышып-тырышып итекләреннән кар себерде, тамагын кырып йөткеренде. Арзу туңмый микән анда?

Мин үз колакларыма үзем ышанмадым: колагыма шыпырт кына елаган тавыш ишетелде. Арзу дисәм, әле генә көлеп тора иде бит! Әйе, бу — Хәбибрахман карт үкси иде. Тәнем эсселе-суыклы булып китте. Нәрсә бар? Әллә фронтта берәр яман хәл булганмы?.. Ул озак кына, басынкы гына, үзәккә үтә торган итеп елады. Арзу аны кочаклады, ахры, тәмле теле, татлы сүзе белән юатырга тырышты:

— Я инде, бабай! Я! Елама, түз. Болары урынына башкалары булыр. Әнә нинди колыннарың бар бит! Миңа күрсәткәненә нинди исем куштың әле? «Озынъял»мы?.. Я инде, бабай...

— Юк,— диде карт яшь аралаш.— Унтугыз ат бит! Унтугыз җан! Берьюлы унтугызны... Иң шәпләре, иң акыллылары... Ул «Актояк»ны әйтәсеңме, «Корыч»нымы... Сабан туе юртаклары ич алар... Адәм акыллары бар иде бит аларда! Иптәшләрем, сердәшләрем иде...

— Сугыш бит, бабай...

— Белмәгән кая... сугыш... ир башы белән ат башы күрә, дигәннәр... Ирләр китәрләр дә хат язарлар... Ә минем бахбайларым?.. Улларым юк ич минем... Минем канатларым, ак канатым «Актояк!».. Әй, мөлдерәп карыйлар миңа... Әй, тояклары белән җир казыйлар... Военкомат каршындагы баганаы кимереп бетерделәр, иреннәреннән кан тама! Аерылганны сизенәләр, бахырлар... Минем балаларым... Унтугызын берьюлы... Ну, бу германны! Ну, бу фашистны!.. Югалалар алар шулай... Берәрсенең хәбәрен генә булса да ишетәсе иде... «Актояк»... Ак канатым!..

Арзу юату сүзләре әйтә-әйтә, ниһаять, бабасын өйгә алып кереп китте. Мин аяк очларыма басып кына чоланнан ишегалдына, аннан шыпырт кына урамга чыктым.

Ну, бу Арзуны! Бабасының атлар озатырга киткәнен әйтмәгән дә иде!.. Әллә миңа әйтер сүзе бармы дисәм... Бабасы өчен хафалануы гына булган икән!

## 12

Авылда вак-төяк бурлыклар гел булып тора башлады. Кибәнне кардан арчыйлар да бәләкәй чаналарга төяп печән алып китәләр. Ындыр табагыннан борчак, тары чәлдерүләр турында да озын колактан ишетелгәли. Ашлык сугу ярты кышта да бетмәде, болай булса, ындыр табагында эш язга хәтле сузылыр. Мәктәптә дежур торулар күңелле булып китте. Югары очта да, Түбән очта да төнге каравыллар бар хәзер, урамга кайчан чыксаң да, күңелне күтәреп шакылдавык тавышлары янгырый. Янгырый да безне сабый чакларга, кызлар киндер тукмаклаган кичләргә алып кайта...

Иген амбарлары, ферма биналары тирәсендә дә кеше аягы өзелми, авыл активлары, комсомоллар йөреп, тикшереп торалар, Чулак Гыйбадулла гына зарлангалап ала:

— Йөриләр... Йокыларын җәлләмичә, убыр күк йөргән булалар! Йөреп ни файда? Урлыйм дигән кешегә тишеге күп аның,— дип куя.

Кышкы каникуллар узгач, төнге дежурлыкка тагын Рәфгать белән туры килгәләдек, әмма хәзер төне буе сагалап йөрмибез, кичләрен ихатаны бер урап чыгабыз да суыктан качып классларга кереп утырабыз. Кыш гаҗәп суык килде, класслар да салкын, утын янга калсын дип, мичләргә җан сакларлык кына җылы биреп торалар...

Ул кичне мин, Рәфгать, биология укытучыбыз — алтын тешле, юантык Нәҗия апа дежурда идек. Нәҗия апа кызыллы-сарылы шакмаклы тастымалга төреп мичтә тәгәрәткән бәрәңге алып килгән, ак капкачлы буш кершән савытына эре-эре бөртекле тоз тутырган, шул бәрәңгесен, тозга мана-мана, бик тәмләп ашады да: «Кер юып бик ардым, укучылар, хәлем юк, ишәк тә ишәк, мин дә ишәк, үзегез караштырырсыз инде»,— дип, күн диванга менеп тә ятты.

Ихатаны тиз-тиз генә бер әйләндек тә укытучылар бүлмәсенә кайттык. Иртәгәгә дәресләр караштырасы да бар. Иртәгә физика. Немец теле. Икесеннән дә Арзу керә. Мин аның дәресләренә аерата тырышлык белән әзерләнеп барам.

Рәфгать белән кара-каршы утырып физикадан мәсьәлә чишәбез.

Маятникның тирбәнү вакыты Т фәләнгә тигез... Димәк... Шулай... Әгәр маятникны Җирдән Айга күчерсәк, аның тирбәнү вакыты күпмегә үзгәрер?.. Ай массасы Җирнекеннән 81 мәртәбә кечерәк... Ә Җир радиусы Айныкыннан 3,7 мәртәбә зуррак...

Җилле, суык февраль төне... Ертык-портык болытлар арасыннан тулган ай күренеп китә... Кулларымны артыма куеп, тәрәзә каршысында басып торам. Мәсьәлә чишелми... Маятник түгел, минем хыяллар еракка, болытлар арасына, офыклар артына күчәләр...

Өй алдында нидер шапылдады, сөйләшкән тавышлар ишетелде, ишек ачылды һәм, итекләрен бер-берсенә бәреп кар кага-кага, Асылов белән Зөләйха апа килеп керде. Нәҗия апаның йокысы сак икән, шундук торып утырды, итәген җыештырды. Асылов җитди һәм ачулы, Зөләйха апа куркынган, каушаган кешегә охшаган иде.

— Нихәл, егетләр? Сезгә гел мач килеп тора инде,— дип ияк кагып кына исәнләште дә күн пирчәткәләрен салып кесәсенә тыкты, күгәрчен тәпие төсле кып-кызыл бармакларына туктаусыз өрә башлады. Бераз җылынгач, укытучылар бүлмәсеннән коридорга чыга торган ишекне ачып карады, аскы иренен тешләп уйланып торды.

Зөләйха апа, башын чайкап:

— Моның булуы мөмкин түгел, Нәҗип иптәш. Юк,— диде.

Асыловның күз кабаклары йокысызлыктан кызарган, ул нәзек, матур кашларын җыерып безгә карады да:

— Эш болайрак тора, комсомол егетләр,— дип сүзен башлады.— Байтак колхозларда икмәккә кул сузу фактлары ачылды. Усал ниятле

кайберәүләр, ындыр табакларында эшнең сузылуыннан файдаланып, шактый гына ашлык урлаган булырга тиеш!.. Сезнең авылдан да житди генә сигналлар алынды.

— Барыбер ышанмыйм мин моңа! — диде Зөләйха апа.

— Сигналларның кайберләре раслану алдында тора,— диде көлемсерәп Асылов.— Кайберәүләрне тоттык без бүген. Төнгә алар белән юлга чыгып булмый, бер-икесен идарәдә калдырабыз. Анда участковый саклар. Ә бер-ике кешене монда китерербез...

Зөләйха апаның кулга алынганнарны мәктәпкә китерәсе килмәве күренеп тора иде, алар Асылов белән ачулы пышылдашып та алдылар.

— Таңнан алып китәбез аларны, Зөләйха апа! — диде, ниһаять, Асылов.— Укучылар белми дә калыр.

Беразга тынлык урнашты. Зөләйха апа:

— Нишләмәк кирәк, хәерле булсын!.. Эш укучыларда гына түгел бит, иптәш Асылов. Мәсьәләнең икенче кыен ягы да бар!.. Үзегез дә аңлыйсыздыр,— диде.

— Миңа жинел дип беләсезме? — диде Асылов, аннары безгә мөрәжәгать итте.— Күз-колак булырсыз, егетләр!

Алар чыгып киткәч китап-дәфтәрләрне жыештырып куйдык, физика онытылды, кемне эләктерделәр икән, кайда? дип баш вата башладык. Нажия апа сукранырга тотынды: «Аягым тартмаган иде бүген, шушыңа булган икән, күрәчәгемә!»

Жил көчәйдеме, әллә без тырышып тыңлаганга шулай тоеламы, тәрәзәләргә шапы-шопы бәрә, әллә кай жирләрдән, мүк араларыннан тишек-тошык табып эчкә үтә, аякларны туңдыра. Асыловлар итегеннән калган кар кисәкләре эреми ята... Рәфгать куян эзенә төшкән сунарчы сыман ярсыган, кычкырып көлеп тә жибәрә: «Менә күрерсең! Йомгак бер тәгәрәсәме, сүтелер!»

Ярты сәгать тә узмагандыр, бүлмәгә Хәбибрахман абзыйны, Кәжә башы урамыннан Сырур апаны, аның кызы Гөлбәдәрне ияртеп милиционер белән Асылов килеп керде. Асылов милиционерга китәргә рөхсәт итте, теге кабаланып чыгып та югалды.

Гөлбәдәр бездән оялды, әнисе артына посып, мышык-мышык еларга кереште. Сырур апа, бер дә исе китмәгән кыяфәттә борынын чөеп, түшәмгә карап тора иде. Аның зәһәрлек белән кысылган иреннәрен, ачу тулы жете кара тере күзләрен һәм бәреп чыгарга жыенгандай кабарган хәтәр түшләрен гомергә онытасым юк.

Гөлбәдәр мәктәптә безнең абыйлар белән укып йөрде, аннары Шатура ягына торф чыгарырга китте, шунда якташ кызларының күлмәккүнчекләрен урлап сатып, ызгышып, талашып кайтты дә хәзер колхозда эшли. Сырур апа чалгы пәкеседәй үткен, яшен ташыдай елгыр хатын; бакча артындагы мунчасында көмешкә пешерә, авылга милиция килеп төштеме, аның курасына кагылмый китмиләр, тикшеренәләр.

Хәбибрахман абзыйны, авыл активы буларак, пүнәтәй сыйфатында ияртеп кергәннәр дип уйладым. Аның дәү, бөкре күләгәсе мич аклыгына төшкән, ул олы, калын табанлы киез итекләренең үкчәсен солдатларча бергә кушып баскан да аска караган, тик кенә, тын да тартмыйча нәрсәдер көтеп тора, сагайган.

— Хәбибрахман абзый, утырыгыз монда,— дип, мин аңа урындык суздым. Ул миңа түгел, Асыловка карады...

Асылов та аны күзәтә иде. Хәбибрахман абзыйның түгел, киресенчә, Асыловның гөнаһ өстендә тотылган кебек уңайсызланып, газапланып, кыйналып басып торуын күргәч кенә миемә уй йөгерде, мин эсселесуыклы булып киттем.

— Тикшерү вакытына өчегез дә кулга алынасыз,— диде ул.

Без телсез калдык. Асыловның: «Өчесен өч класска ябып торы-

гыз»,— диган сүзләрен ишетмәдек. Апалар кузгалдылар, Асылов йомшак тавыш белән:

— Ә сез, гражданин Ямашев, калып торыгыз,— дип өстәде.— Утырыгыз.

Хәбибрахман карт мин куйган урындыкка авыр гына килеп утырды, күрсендә, каеры тунының агач төймәләрен ычкындырды, бүреген салды. Кыска гына калдырып алдырган җирән чәчләре сүрән ут яктысында да тоташ көмеш булып җемелдәде. Асылов та күрсендә, суыкта туңган сумкасын көч-хәл белән ачып, аннан язулы кәгазьләр чыгарды, таратып ташлады, аннары гына Нажия апага карады:

— Гафу итегез, фамилиягезне белмим,— диде.

— Раббаниева,— диде Нажия апа курка-курка.

— Кайтып ял итсәгез дә була сезгә. Иртәгә эшкәдер бит?.. Монда егетләр дә бик җиткән.

Нажия апа кат-кат рәхмәт укып җыена башлады, тастымал чишелеп китеп, идәнгә бәрәңге кабыклары, эре-эре тоз бөртекләре чәчелде. Апабыз, тезләнеп, тоз бөртекләрен берәмтекләп җыеп учына тутырды, аннары, Хәбибрахман абый ягына карамаска тырышып, юан аякларын көч-хәл белән сөйрәп чыгып китте.

Асылов башта «Гражданин Ямашев!» дип кырыс кына эндәште дә төзәтеп: «Хәбибрахман агай!» дип сүзен башлады.

— Болай итеп, мондый хәлдә очрашырбыз дип көтмәгән идем... Очрашканбыз икән, эшне тизләтергә тырышып карыйк. Икебезгә дә шулай кулайрак булыр. Дөресме?.. Без, пунәтәйләр Мөхәммәтшина һәм Баяновалар белән бергә, авыл Советы депутаты Әхияров катнашында, сезнең йортның чоланыннан потка якын, дөресрәк итеп әйтсәк, унбиш килограмм да өч йөз илле грамм борчак алып чыктык. Менә тенту акты. Менә үлчәү акты. Сезнең борчакмы ул?

Хәбибрахман абзый гайрәт белән бер кузгалып куйды да кире утырды, күкрәгендә кайнаган утны йотты, сабыр гына:

— Нинди борчак соң ул? — дип сорады.

— Быелгы уңыш борчагы. Сезнең агач кисмәккә тутырып куелган.

— Безнең колхоз быел борчак өләшмәде.

— Кисмәк сезнекеме?

— Почмактагы буш кисмәкне әйтсәгез — минеке. Анда бернинди дә борчак булырга тиеш түгел... Әллә кай гомердән буш тора ул кисмәк.

— Димәк, сез ул борчак минеке түгел дип барасыз.

— Дөресе шулай булгач, нәрсә әйтим?

— Яхшы! — Асыловның нидер эзләп түгел, болай гына, уеның очына чыгарга тырышып кына кәгазьләр актарганы безгә дә аңлашылып тора иде.— Яхшы! Мин дә шулай дип уйлыйм, ди. Ә бу — потка якын борчакны нишләтәбез? Хуҗасы кем аның? Чолан сезнеке. Кисмәк тә чит түгел икән. Борчагы кемнеке. Ачыклыйк шуны.

— Кем салган, шул ачыкласын.

Асылов эшнең уеннан узганлыгын, монда чамадан тыш җитди булырга кирәклеген искәртеп, сорауларын тагын бер тапкыр кабатлады. Бу эш белән маташу аның үзенә дә ифрат читен икәнлеге күренеп тора, мин, мөгаен, Асылов карт белән икәүдән-икәү генә калырга читенсенгәннән безне чыгарып җибәрмәгәндер, дип уйладым.

Хәбибрахман абзый эндәшмәгәч, ул аны үгетләргә үк тотынды.

— Бер сездә генә түгел, башка авылларда да икмәк белән шаяралар. Каракларга каршы көрәшне көчәйтәчәкбез. Сезне карак дип уйламыйм, алай уйларга хакым да юк. Гражданнар сугышы ветераны, колхоз төзешкән кеше... Унбиш кило борчакка кызыккансыз дип уйлый алмыйм, ышанмыйм. Аңлыйм... Әмма факт — аяусыз нәрсә! Бу очракта исә ул сезгә каршы.

— Минем сүзем бер — борчакны урламадым. Ант итә алам.

— Ул чагында чоланга борчакны Арзу Ямашева алып кайткан була.

Хәбибрахман абзый кыяр-кыймас кына урындыгыннан купты, калтыранды, урындыгы авып китте.

— Сез, Асылов иптәш, чамалап авыз ачыгыз! Арзуның нинди бала икәнен бик яхшы беләсез... Белмәсәгез, аны хатынлыкка сорап килмәс идегез... Мин бирмәдем аны сезгә! Мин! Мине гаепли аласыз, әйткәнегезчә, фактлар — аяусыз нәрсә... Гаепләгез, мәгәр балага тел тидермәгез... Мин икән, мин...

Асылов, бер ноктага карап бик озак сүзсез утыргач, өзек-өзек, ят тавыш белән Хәбибрахман абзыйга болай диде:

— Мин... гражданин Ямашев... элгәрге тикшерүне генә уздырачакмын... Сезнең эш... һичшиксез... башка хезмәткәргә тапшырылыр... Шуны өсти алам: бүгенге күңелсез хәлгә Арзу Ямашева белән булган мөнәсәбәтебез һич тә катнашмый!.. Чирткиле уйнамыйбыз, уголовный җинаять тикшерәбез!.. Сугыш заманасының иң каты законнары таләп иткәнне башкарабыз!.. Ә теге мәсьәләгә килгәндә, ялгышасыз, сез түгел... Арзу үзе мине кире какты...

— Ярый. Риза. Арзуның катнашы да юк, ди... Мәгәр борчакны урлаучы мин түгел! Түгел!

— Сигнал бар, Хәбибрахман абзый,— диде Асылов.— Сигнал, факт. Сораша-белешә торгач, шаһитлар да табылды.

— Нинди шаһит? Ни сөйлисез сез?.. Кайда?

— Хәзер китерерләр... Уйлап карагыз: сигнал алынды, борчак сездән чыкты, шаһитлар табылды... Мин нишли алам?

Җил сызгыра, бүлмәбез тып-тын. Рәфгать белән бер сүз эндәшергә дә куркып, бер-беребезгә сыенышып, күн диванда утырабыз. Аяк астына чәчелгән юка бәрәңге кабыклары бөтерелеп-бөтерелеп килгән әкәмтөкәмнәр булып күренәләр, озак карап торганга алар кыймылдыйлар, куркыталар...

Милиционер керде.

— Алып килдем,— диде ул бияләенә ютәлләп.

— Керсен монда,— диде Асылов.

Милиционер ишекне ачты, чуклы-чачаклы калын шәл бөркәнгән, мутон якалы яңа бишмәтен кигән Мәүлиха апаны үз яныннан уздырып җибәрде.

Хәбибрахман абзый да дүрт күз белән ишекне күзәтә иде, Мәүлиха апаны күргәч, түзмәде:

— Эх, эзләгән чучка... юлыгыр! — дип, ике кулы белән шап итеп тезләренә сукты.

Мәүлиха апа бүлмәгә ят ис — хушбуй исе таратып алгарак узды, шәл чукларын ычкындыра-ычкындыра, башын артка ташлап, рәхәт итеп елмайды. Асылов аңа урын тәкъдим итте:

— Утырыгыз, гражданка Мөрсәлимова.

— Утырып ук торыйм микәнни соң?

Мәүлиха апаның мондый да төче, иркә тавышын беренче тапкыр ишетә идем. Аңарда без бар дип берниндн ятсыну, читенсенү әсәре дә юк иде. Хәбибрахман абзыйны бик хаклы рәвештә эләккән дип санагандыр инде, үзен бик мөһим эш башкаручы кеше кебек хис итеп, Асыловның авызыннан нинди сүз чыгар икән дип, аңа таба авышкан. Урыныннан канәгатьләнмичә, урындыгын өстәлгә якынрак тартты да баягыдан да татлырак итеп җырлап:

— Утырсам да утырырмын шул! — дип куйды. Аның шулай шәбәеп, олы сымакланып утыруын күргәч, кылт итеп Мәүлиха апаның актив чаклары, президиумга менеп, ботын-чатын ерып утыруы хәтеремә төште. Һаман авыл активы буласы килеп йөри икән апаның, менә хәзер, җай чыккач, ул шатланган, аның күз алмалары рәхәтлек диңгезендә йөзә, чыраена, кыяфәтенә бәйрәм төсе кергән иде.

— Гражданин Ямашев, сез игътибар белән генә тыңлап торыгыз.— Асылов бердән корыланды, Мәүлиха апага да кырыс, ямьсез тавыш белән эндәште.— Менә сез, гражданка Мөрсәлимова, бүген кичке очрашу вакытында, «Яңа ел бәйрәме алдыннан, кичке эңгер-меңгердә күршебез Хәбибрахман Ямашевлар капкасыннан капчык күтәргән кеше кереп китте», дип күрсәттегез.

Апа чишмә челтерәгәндәй көлеп җибәрде.

— Бәй, кергәнне кермәде дип әйтмәм инде, апаем. Миндә ялганлау сыйфаты юк... Нәселебез белән...

— Ничәнче число иде ул? — диде Асылов, аны бүлдереп.

— Числосын-мислосын хәтерләмим, иптәш лачаннык, численник карарлык идеме соң?.. Кәримәмне, әле син ишетмәгәнсеңдер дә, кияүгә бирдем бит!.. Егетне йортка керттек. Егылыплар үндык инде кияүдән! Шәп егет икәнен белә идем, ул хәтле үк булыр дип башыма да килмәде. Юаштыр үзе, тел-теш күтәрмәс, сәвит өчен җаны фида, калхуз тегермәнендә көне-төне ята, йорт эшенә дә өлгерә, сөйләп биргесез!

— Сез... мәсьәләгә якынрак килсәгез иде!

— Киләм, бик киләм! Якын да килермен... Ни сөйли идем соң? Ә-ә, шул, кияү балакайны сөйли идем бит.— Бу урында Мәүлиха апа шәлен иңенә төшереп, күз яшьләрен сөртеп алды.— Ул туйлар... туйлары, мин сиңа әйтим... Тирә-якта бер булды инде! Кызым да уңган... Бер юньле эш кенә чыкмады үзенә... Менә, иптәш лачаннык, шуны сорарга онытмыйм дигән идем: сезнең кантур тирәсендә берәр күңелләрәк эш юкмы?

Мин Мәүлиха апаны куып чыгарырдай булып утырам, Асыловның түземлелегенә исең китәр, шул гайбәтчене сабыр гына тыңлый бит!

Ниһаять, ул да түзмәде:

— Капчык күтәргән кешене тәгаен күрдегезме? — дип кабатлады.

— Чат дөресен генә әйтәм! Икмәктер, валлаһи, ипинең чырае хәрәм булсын әгәр, берәү капчык күтәреп мыштым гына кереп китте.

— Кем икәнен танрдыгызмы?

— Кем дип.— Мәүлиха апаның тагын көләсе килде.— Кеше капкасыннан чит кеше йөри димени хәзер? Аннары, авылда ир-ат калдымыни? Хәзер менә бөтен эш үзебезгә өелде. Пычагың кайра — үзең, утынын яр — үзең, мунчага су ташы — үзең, әй!.. Ир-атсыз ничек гомер итмәк кирәк... Әле дә ярый, кияү бар... Син шуны да әйтеп кит, иптәш лачаннык, сугыш кайчан бетә дә, Биктимеремне кайчан кайтарырлар?

— Сез фикерне читкә алып киттегез.

— Бер дә читкә түгел, буразнасыннан гына барам. Сугыш булмаса, Хәбибрахман абзый дим, олы кеше дим, бер капчык икмәк күтәреп йөрер идеме? Борчак та булдымы ризык, тьфу, әйттем исә кайттым!.. Кызыл олаулар белән китереп аударалар иде безнең Югары авылда игенне, әргән уйнатып, кызыл әләмнәр элеп... Балын бүлерләр иде, кыярын-кәбестәсен... Үзең яратмасаң, энә малыңа ашат иде... Бар иде минем актив булып ударникларча җөргән заманалар! Зират тавы өстенә мәк чәчә торган идек... Каравылда Гыйбадулла кода торыр иде... Бай идек без!

— Гражданка Мөрсәлимова!

Мәүлиха апаның битенә ягылган иннеген ярып ике битеннән дә эре-эре яшь бөртекләре ага, кинәт кызарып киткән борыны өзлексез мышкылдый... Асылов каты гына дәшеп куйгач, ул бит алмаларын тиз-тиз ышкыды да тагын кояштай балкыды.

— Нәрсәкәй, тагын ялгышрак ычкындырдыммы?

— Аның капчыгында борчак икәнне каян белдегез?

— Бәй, үзең әйттең ич!

— Әйтмәдем.
— Кояштыр, әйттең. Әйтмәсәң дә, бөтен авыл белә аны: «Быржиннан бер капчык борчак чыккан»,— дип, эте-бете бытылдый.
— Ярый.— Асылов нидер язарга уйлады да язмады.— Капчык күтәреп кайтучы кеше Хәбибрахман Ямашев иде дип тагын бер кат раслыйсызмы?
Мәүлиха апа һич тайчанмыйча Хәбибрахман картның иелгән көмеш башына карап торды.
— Шул иде. Шул үзе иде, бер ходаем шаһит! Ул булмыйча, безнең очта кем буталып йөрсен? Быржин шикелле атына-атына кайтып килә иде. Кәмит инде, кәмит, чынкый уйласаң!..
Асылов Мәүлиха апа әйткәннәрне теркәп куйды, кул куйдырды. Шаһитны кайтарып җибәргәч, тагын гаепләнүчегә эндәште.
— Я, ни дисез?
— Ни әйтим? Әйтмим. Әйтерлеге юк.
— Шаһит Мөрсәлимованың сездә үче бармы, ачуы?
— Ачуланышкан юк. Каян булсын... Дус дип тә әйтә алмыйм. Күз алдыгызда икәү утырып тордык... Кайсыбызга ышанырга икәнен үзегез чамаларсыз тагын...
Хәбибрахман абзыйны класс бүлмәсенә озатып куйгач, Асылов безгә эндәшергә дә тиеш тапты:
— Шулай ул менә,— диде күңелсез генә.— Күрдегезме, егетләр?.. Сез мондагы сүзләрне ишетергә тиеш түгел идегез түгелен... Юри чыгармадым мин сезне! Бердән, шаһитның ныклыгын сыныйсым килде. Кайберәүләр кеше юкта әллә ниләр сөйләп бирәләр дә, халык күз алдына чыккач, киресен сукалый торган булалар. Бу апа андыйлардан түгел... Куркыныч шаһит!.. Менә шул... Районнан милиционер килеп җитсә, мин аны монда җибәрермен. Аңынчы болар янына берәүне дә кертмәгез!

13

— Нишлибез? — дидем мин Рәфгатькә.
— Нишли алабыз соң без?
— Урлагандыр дисеңме?
— Юктыр, әй. Булмас.
— Урламаган! Урлыймы соң! Беләм мин аны...
Хәбибрахман абзыйның атларны сугышка озатып кайткан кичен хәтеремә төшереп, тагын бер кат: «Урламаган!» — дип кабатладым.
Икебез дә тирән хәсрәткә төштек, мәктәп иминлеге өчен дә курка башладык. Асылов сүзләреннән соң тирә-якта караклар, әшәке кешеләр күптер кебек тоелды. Рәфгать сакта калды, мин йөгереп кенә мәктәп ихатасын әйләнеп чыктым. Тәрәзәләр салам маталар белән тырышып-тырышып капланган булса да, мин бер нәрсәне абайладым: байтак йортларда кешеләр йокламый иде. Димәк, теге яки бу дәрәҗәдә аларга да Асыловның килүе кагылган! Кемгә тентү кергән, кемне шаһит итеп чакырганнар, кемнең болай гына кайгысы тулып ташыган...
Кырык беренче-кырык икенче еллар!
Хәтәр еллар!
Рәфгать янына керәм дип торганда гына укытучылар бүлмәсенең ишек катында кара шәүлә күренде. Кемдер кармана-кармана нидер эзләнә иде. Утын урларга йөриме, әллә аннан да зуррак бурлыгы бармы? Күзәтә башладым. Таныш та, таныш түгел дә кебек бу кеше. Ишек эзли икән. Тапты да ача алмый маташа. Янына йөгереп килдем. Рәхимҗан бабай ич бу! Олы кешедән «Нишләп йөрисең монда?» дип сорап булмаганга, мин аның белән сәлам алыштым да сүзен көтеп калдым. Ул, әлбәттә, мине танымады.

— Караңгы,— диде ул.— Ишек таба алмыйм. Мөгаллимнәрнең кәнсәсенә керимме әллә дигән идем.
— Ишек мондарак, Рәхимҗан бабай.
— Шундамыни? Ай, рәхмәт төшкере... Син укучымы соң?
— Укучы, укучы... Искәндәр мин, Рәхимҗан бабай. Күршең.
— Бәрәкалла, шулаймыни? Алайса, син Хәбибрахман абзаңның кайдалыгын да беләсеңдер?
Рәхимҗан бабайны кочаклап үк аласым килде, ул миңа әкиятләрдәге яхшылык алып килгән фәрештә булып тоелды. Мин аны җитәкләдем, карманып эчкә уздык. Ишектән керүгә:
— Рәфгать! Хәбибрахман абзый янына килделәр,— дип кычкырдым.
Сөмсере коелып утыра иде, аның да авыз ерылып китте, тиз үк класс ишеген барып ачты да:
— Йокламыйсыңмы, Хәбибрахман абзый, монда сине күрергә килделәр,— дип эндәште.
Алар кочаклашып күрештеләр. Рәхимҗан бабай, озак сәфәрдән соң очрашкан кеше кебек, Хәбибрахман абзыйның аркасын озак кочып торды.
— Әһ-һә-һә,— дип кеткелдәде ул тешсез авызы белән.— Әһә-һә... Менә бит, агай... Күрәсең булса, күркә талап үтерер... Кем уйлаган иде дә... Әһә-һә!..
Еламсырады Рәхимҗан бабай, үзе һаман ирлегән итеп кеткелдәде.
Өчебез орынып торган күршеләр булып гомер итсәк тә, Рәхимҗан бабай белән Хәбибрахман абзый арасында шундый якынлык, ирләрчә кырыс дуслык бардыр дип уйламаганмын. Алар шулай, ике карт имән төсле, егылып китмәс өчен бер-берсенә тотынышып, сүзсез генә аяк кагышып байтак басып тордылар да күңелне ифрат нечкәрттеләр.
— Нихәлләрдә соң, Хәбибрахман?
— Күргәнеңчә, Рәхимҗан абзый, күргәнеңчә. Менә монда утыр... Утыр, утыр... Миңа урындык бирүеңме, Искәндәр? Рәхмәт, рәхмәт... Әйе, Рәхимҗан абзый... Менә ни, егетләр белән кадер киче уздырабыз, күк капусы ачылганны көтәбез.
— Очратмаммы дип, әүвәл өеңә кагылдым,— дип башлады Рәхимҗан бабай, җайлап кына урындыкка утыргач.— Карыйм, өеңдә юк икәнсең. «Алып киттеләр», диләр... Әһә-һә... Төштән соң безгә дә яшь кенә бер нәмәстә кагылып чыкты. Прокулол дидеме... Милиция ишедер дип калдым. Шул бик җентекләп сорашты. «Ямашевның борчак алып кайтканы сизелмәдеме?» — ди.
— Туп-туры Ямашев диме?
— Шулай ди шул, бәхете арткыры!
— Син ни-нәрсә дидең инде аңа? Прокурорга дим?..
Рәхимҗан бабай җавап бирергә ашыкмады, соңгы тапкыр карап калыймчы дигәндәй, төссез күзләре белән күршесенә текәлеп торды. Бүреген салып тезе өстенә куйды, сул кулы белән түбәтәен кузгатты.
— Нәрсә әйттем? Кирәген әйттем.
Картлар беравык икесе дә тын калдылар. Без, сүзгә катышырга кыймыйча, бер читтәрәк утырыштык.
— Гомер буе Ямашевка ышанып яшәдек без, дидем... Егерме тугызда атымны җитәклап беренче булып калхузга илттем, Ямашевка ышанганга илттем, дидем.
Хәбибрахман абзый учы белән иреннәрен сөртеп куйды, сүзсез генә Рәхимҗан бабайны куәтләде, ияген какты.
— Җан җегәремне биреп, тау-тау таш чыгарып алган атым иде... Минем чаптар алашаны, шәт, онытмагансыңдыр, ә? Карап торырга үшән төсле генә булса да, юртак иде бит, ботларны ничек каерып-каерып сала иде... Сырт өсте кара-көрән юл иде бит...

— Хәтерләмичә... Хәйриләр токымы иде... Затлы мал!..

— Әйе, димен, гомер буе Ямашевка ышандык, димен... Тик аны моңарчы бирәүгә дә әйтергә генә туры килмәде. Сораган кеше дә юк иде... Хаталык кыласыз, дидем... Хаталык! Үзе болай ару кешегә дә охшаган, нишләп прокулол булып йөридер... Иплэп тыңлады, бүлдермәде, дәфтәренә теркәп куйды. Табагач тамгамны салдым. Котылырсың, иншалла.

Күземнән яшь атылып чыгардай булды... Мин генә җибегән дисәм, Хәбибрахман абзый үзе дә йомшады, кул аркасы белән күз чокырын сыпыргалады.

— Авызыңа бал да май, Рәхимҗан абзый! Ярый ла, син уйлаганча барып чыкса!

— Үзең дә нык тор, Хәбибрахман. Нахак бәлане өстеңә алма. Син әле яшь кеше. Дөньялыктагы бурычларың үтәлеп бетмәгән. Кызыңны аякка бастырырга кирәк, урнаштырырга дигәндәй... Шуңа күрә әйтүем, кызуланып китә торган гадәтең бар. Үксезгә үгет бирергә килмәдем, дус итеп, күрше хакын хаклап килдем.

— Мәүлиха апа әкияте генә ич болар! — дидек без Рәфгать белән беравыздан.

— Шулаен шулай да,— диде шөбһәләнеп Рәхимҗан бабай.— Файдасызга, чаярак хатын булды шул... Иман юк ул хатынның авызында. Гыйбадулла чулак стрәпкәсе.

Картлар тагын тындылар, без дә дәшәргә кыймадык.

— Сүзең хагын хак, Рәхимҗан абзый... Син — ил агасы. Авылда иң өлкәнебез булсаң да, зиһенең күпләрнекеннән ачык. Ләкин үлчәү табасына тегеләй дә, болай да салып карагач, мондыйрак исәпкә киләм мин: хәтәр эшкә тарыдым!.. Хәтәр... Өскә күрсәтеп торучы да бар. Язып та җибәргәннәр... Сугыш заманында ил табынына кул сузучыга үзем дә рәхим-шәфкать күрсәтмәс идем... Һәм менә көтмәгәндә килеп явыз кеше казыган базга төштем. Сизенә күңелкәем, Рәхимҗан абзый, кадерлем, баздан үзем генә чыгып котыла торган түгел. Түгел!..

Хәбибрахман абзыйның ни уйлаганын белү кыен түгел. Ул да, Рәхимҗан бабай да, Рәфгать белән без дә: «Кем булыр? Кем шушы явызлыкны эшләр?» — дип туктаусыз баш ватабыз. Шушы шомлы сорау барыбызның да күңелен биләгән.

— Көчем дә бетенкерәп торган чак!.. Вакытын белеп чалдылар аякны!.. Гомеремне беләсең,— дип дәвам итте ул, ара-тирә Рәхимҗан бабайның йөзенә төбәп карап. — Бар да ил-күз алдында узды. Үзем канәгатьмен. Эшкә ашмас хыял белән үземне интектермәдем, булмастайга үрелмәдем. Бәхетне туя татыдым. Бер яктан алай да күңел китек булды: Зөлхәбирә мантымады, бер бөртек бала белән калдык... Инде менә юанычка кыз үстердем. Акыллы бала булып чыкты. Кеше арасына иртә керде. Кыз башы белән ил күзенә менде...

Рәхимҗан бабай аның сүзен куәтләп иреннәрен кыймылдата, ни әйткәне генә ишетелеп бетми: «Әйе, әйе... шулай, бик шулай» дигәннәре генә аңлашыла. Хәбибрахман абзый иелә төшеп утырган да бер җайга гына һаман сөйли бирә. Менә ул тезләренә учы белән таянып урыныннан кутәрелде, Рәхимҗан бабай каршысына барып басты.

— Гозерем шул сиңа, Рәхимҗан абзыкаем, васыятем итеп кабул итсәң дә риза, ил арасында сүзең үтә — берүк Арзуны кыерсытмасыннар! Бәлки мин дә югалмам, алай хөрт уйларга ниятләмим, дөреслек, мөгаен, бер ачылыр. Мәгәр дөнья хәлен белеп бетереп булмый, бәхилләшик. Кем бар, кем юк, дигәндәй, Рәхимҗан абзый, күз нурым, бәхилкәй бул! Кайсы кеше белән ашка-суга да эллә ни йөрешмисен, очраганда сүз дә ничектер үрчеми, иллә мәгәр шул кешенең җир йөзендә барлыгын белеп тору гына җан рәхәте була! Шундый якты кеше безнең өчен син булдың, Рәхимҗан абзый. Бәхил бул, гаебем-кыегым булса,

рәнжеш-каргышыңны төшермә, кичер. Авыр сүз әйткән булсам, йөрәгеңдә калдырма, ярармы?

Картларның бәхилләшкәнен күрүем беренче мәртәбә иде минем, алар кочаклашкач, түзмәдек, без дә аларга якынайдык, дүртәүләшеп басып торабыз, керфекләр чыланды.

Ни булса булган дидек тә, мәктәпне җил иркенә, тоткыннарны үз ихтыярларына куеп, өчәүләшеп Рәхимҗан бабайны өенә хәтле озата бардык. Хәбибрахман абзый үз өенә кереп чыгармы әллә дип уйлаган идем, караңгы тәрәзәләренә бер карап алды да сүзсез генә мәктәп ягына атлады.

Арзу бүген өйдә юк, ул Зәйдә иде. Өйдә юклыгын башта бәхет дип санасам (мондагы хәлләрне үз күзе белән күрми, ичмасам!), хәзер аны бик юксындым. Аны күрмичә бер минут түзәрлегем калмады.

Хәбибрахман абзыйны класска ябып куйгач, Рәфгатькә:

— Хәзер үк Зәйгә чыгып китәм,— дидем.

— Файдасы булырмы соң? — диде Рәфгать хафаланып.

— Арзу булмагач, әллә ничек...

— Иртәгә хәтле көт... Әнә, этәч кычкыра... Ярты төн авышкандыр инде.

Аптырашып, туңып байтак утырдык. Асылов вәгъдә иткән милиционер озакламый килеп тә житте. «Тәртипме?» дип, безгә бер сүз салды да класс ишекләрен ачып тоткыннарны барлады, аннан кыршылган ак туның салып, күн диванны мич буенарак тартып китерде, безгә күз кысты да мыегын сыпыра-сыпыра сузылып та ятты:

— Ни, егетләр, җеп өзәр хәл калмады. Өч көн, өч төн йокламаган. Сез алмашлап йокларсыз, яме, мин дә азрак черем итеп алыйм. Болар беркая да китә торганнар түгел.

Ятуга йоклый да башлады.

— Әйдә, әйләнгәләп керик, азрак җылынып булмасмы,— диде Рәфгать, туңган кулларын бер-берсенә ышкып.

Урамда җил. Йорт араларында буран котырына. Өй кыекларында кара өермәләр уйный. Күз ачкысыз әшәке, шыксыз төн. Җылынырга ниятләп биллэрдән алышып карыйбыз, булмый. Әчкә, күңелгә суык төшкән. Телләргә сүз килми... Буран битне чеметкәләсә дә, мин аны сизмим, карап торам...

Буран арасыннан чыгып яныбызга килеп баскач кына Арзуны абайладык.

— Арзу, син түгелме соң? — дип кычкырып җибәрдем.

— Кайтып җиткән!

— Тәмуг газаплары күрдем,— диде ул, битенә сарган карны пырчәткәсе белән кубарып.— Бураны яман. Юл беткән. Ярты юлда адашып сулга кереп киткәнмен, әле ярый, ат акыллы, текә яр өстенә җиткәч туктады...

Тындык. Кайсыбыз сүз башлар икән дип көтәбез. Арзуның сүзсезлегеннән мин барын да аңлап алдым:

— Белеп кайттыңмы? — дип сорадым.

— Монда кайткач сөйләделәр... Бабай ни хәлдә?

— Керик, күрерсең.

— Юк,— диде ул, минем аркага кагылып.— Иң әүвәл миңа синең белән сөйләшеп алырга кирәк.

Болай да аңгырайган башымнан хәвефле уй йөгереп узды, ис тигән кеше кебек чайкалып куйдым: Арзу атын тугармагандыр, хәзер бабасын алып качарга җыенадыр, мине шуңа үгетләргә телидер кебек тоелды. Курка-курка гына:

— Кая барабыз? — дип сорадым.

— Тындым мин, Искәндәр.

Рәфгать эчкә кереп китте, без ялгыз калдык.

— Арзу! — дидем мин, аңа таба омтылып.— Ни кушсаң да үтәрмен!
Ул мине култыклап алды:
— Әйдә безгә,— диде.
Аларга кайттык. Арзу өйгә кергәч тә пальтосын салырга ашыкмады, туңган бармакларына өрә-өрә, туктаусыз йөреп торды, гасабиланып нидер эзләнде, гүя ул үз өйләренә кайтмаган, яратмаган ят кешеләргә фатир кергән юлчы хәлендә иде. Баягы шигем тагын күңелгә килде: «Качыйк хәзер, алып кит!» дисә...
— Өе дә бит аның, җылы әсәре калмаган. Мичкә ягып җибәрим булмаса!..
Нидер эшләргә мөмкинлек булуына мин гаҗәп шат идем:
— Як, Арзу, як! — дип кычкырдым.
Көн буе кеше-мазар кереп йөргән, милициясе-мазары, пүнәтәе дисеңме, ишекне аннан-моннан ябып йөргәннәр, тәрәзә пыялаларында катлы-катлы боз. Арзу тиз-тиз чыра телде, пальто төймәләрен ычкындырды, шәле таралып иңенә төште, мин лапастан йөгереп кенә берничә каен яркасы алып кердем. Ут күңелле генә яна башлады, без артсыз кыска эскәмияне мич арасыннан тартып китереп, янәшә утырдык.
— Эчемә суык төшкән,— диде ул калтырап.— Җылына алмыйм.
— Ял итәргә кирәк сиңа, Арзу. Сәгать ничә икән?
— Туктаган,— диде ул, герләре идәнгә хәтле салынып төшкән сәгатькә карап. Ул да, мин дә урыннан кузгалмадык, сәгатьне җибәрәсе килмәде.
Мин аның кулларын учыма алдым, ул карышмады, ризалыгын белдергән кебек, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, миңа табарак тартылды. Аның шушы кыен төндә елмая алуы өчен әллә ниләренне бирерлек иде! Шушы буранлы кара төндә ул үзенә иптәшлеккә мине сайлады, елмаюын миңа бүләк итте...
Арзу бабасы белән булган хәлдән соң югалып калдымы әллә? Мин аның йомшаклыгыннан гына файдаланып утырмыйммы?..
Кадерле, бик кадерле бармакларын иреннәремә якын китереп җылы тыным белән өрә башладым. Ул елмаеп миңа карады, мин аңа. Юк, юк, Арзу җебеп төшә торган кыз түгел, мин дә аның егылганын түгел, калкынганын көтәм! Бу аулакта, бу мизгелдә мин аның саф күзләренә туйганчы карый алам...
Чак кына күпереп торган сусыл, алсу иреннәр пышылдадылар да минем исемемне әйттеләр:
— Искәндәр...
Бервакыт әнием аңа: «Шушы хәтле кызыл сөртмәсәң, Арзу, абау!» — дигән иде. Арзуның әнкәсенең иреннәре дә шулай кызыл, теп-тере булган дип бераз мәсхәрәләп сөйлиләр иде авылда, шуңамы, ул бик читенсенде, ак кульъяулык белән иреннәрен кат-кат сөртеп: «Үзе шундый ич, Фәгыйлә апа!» — дип өзгәләнде.
Минем өчен Арзудан да матуррак кыз юк хәзер дөньяда!.. Сүзе — җыр, карашы — моң, үзе аккош баласы... Тик ятим...
Чынлап уйласаң — үксез бала ич ул! Ата-ана назын күрми үскән ятим. Моңлы бала!.. Гәрчә ул бу турыда бер чакта да сүз кузгатмый, ятимлекне искә төшергәнне яратмый.
Ә менә бүген, шушы хәлдә, ятимлеген кискен тоядыр ул!
Нигә бабасы янына кермәде икән?
Нигә Рәфгатьнең барлыгын да онытты...
Мине чакырды, мине сайлады...
Нигә?
Дөрләп янган ап-ак каеннарга текәлгән кап-кара күзләрдә нинди уй?..
Ут шәүләсе аның күз алмаларында бии, битен тагын да алландырып, серле итеп күрсәтә. Колак бөтеркәләренә эленгән кызыл алкалар

ут яктысында әле күе шәмәхә, әле кан тамчысыдай дәһшәтле ал булып күренәләр...

Сүз башларга теләп ике-өч тапкыр талпынып карадым, ул бармаклары белән минем авызны томалады.

— Кирәкми, Искәндәр.

Сүз кирәкми икән, эш кирәк! Ә нәрсә эшләргә? Үпкәләргәме, сөенергәме — белмим. Арзу минем янда, минем янымда... Ләкин бабасы!.. Легендә, тоткынлыкта... Нигә дәшми ул? Ни уйлый?

Уйларында мин дә бардыр дип уйларга йөрәгем җитми. Төне ул түгел, вакыты ул түгел.

Нигә мин утырам соң, алайса, аның янында?!

Болай сүзсез, берни аңламыйча, берни белмичә күпме газапланырга мөмкин?!

Өй җылынмады, без кайнарландыкмы, бишмәтләребезне салып ташлап, тагын янәшә утырдык. Бу юлы мин аның тән кайнарлыгын ныграк, ачыграк тойдым, миңа бик рәхәт, ифрат рәхәт, бер үк вакытта чамасыз газаплы, сагышлы иде. Күңел бер кавымга онытылып иркәләнде дә тагын сызланды...

— Арзу!..

— Түз, Искәндәр...

Түзмәдем, сикереп тордым, сәгатьнең боздай салкын герен өскә күтәрдем. Буявы купшакланган сәгать келт тә келт йөри башлады, вакытны, чамалап кына, өч дип куйдым. Сәгать тавышыннан өй эчендә нидер үзгәрде, моны икебез дә ап-ачык сиздек.

Мичтә чатыр-чотыр каен утыны яна, мич казнасына сыймаган ялкын телләре ябырылып мич авызына тартылалар. Ялкын безнең тезләрне пешерә, тәнебезне җылыта. Эскәмияне чак кына арткарак күчерәбез...

Сәгать келт-келт йөри.

Сәгать ярты төн күптән авышканын, озакламый сүрән генә таң атачагын, шушы таңда Хәбибрахман картны алып китәчәкләрен секунд саен безнең хәтергә төшереп тора.

— Арзу!..

Ул минем авызны томалый, мин акрын гына, кыяр-кыймас кына аның хуш исле бармакларын үбәм. Чак кына калтыранган озынча, салкын бармаклар иреннәремнән аерылып минем битемне сыйпыйлар, каш-керфекләремне барып табалар, иркәлиләр, ул минем йөземне үзенә табарак китерә. Кыюланып аны кочып алам, ул карышусыз гына минем куенга инә, иреннәр бергә кушылалар.

— Искәндәр! — дип пышылдый ул, күзләрен ярым йомып.— Хәзер барысы да мин теләгәнчә булды.

Аһ, бу сәгать тавышы да булмаса! Нигә кузгаттым мин ул сәгатьне! Ямьсез тавышлы икән ул, каты тавышлы!..

Арзу!..

Мин куркып артка тайчынам, ул ычкындырмый, йотылып минем күзләремә карый. «Минем күзләремдә курку, шик кенә ич, карама, Арзу!»

Ләкин акыллы иптәшем күзләремнән башка нәрсә эзләп таба, ялгышмый да:

— Әйтмәсәң дә беләм, Искәндәр... Яратасың. Син дә миңа бик якын... Дөньяның бик кадерле бер кисәге син минем өчен! — ди...

Мич янып беткәнче, шау күмер төшкәнче, бер-беребезгә сыенып утырдык. Йокы килми, ул турыда без бөтенләй онытттык бүген.

— Искәндәр, исеңдәме? Миннән шигырь дәфтәре сораган идең.

— Әйе. Син бирмәгән идең.

— Бүген ал. Мә.

Дәфтәр минем кулда, тик мин куана алмыйм, аптырап Арзуның дымлы күзләренә карыйм. Көтелмәгән юмартлык мине сагайта, куанычымны киметә.

— Ни уйлыйсың син, Арзу? Нигә бабаң янына кермәдең? Нигә дәфтәрне хәзер бирәсең? Көндез ярамыймы?

Ул көлгәндәй итте, көлгәндә дә күзләреннән яшь китмәде.

— Иртәгәне кем белгән, Искәндәр... Бабай янына кермәдем, сәбәбен сизәсеңдер... Ялгызлыгы яман аның... Шул бетерде аны. Ишен таба алмады бичара... Адәм баласы ялгызлыкка түзми икән... Шуны белдем быел... Дәфтәрне ал син, курыкма... Сихерләмәм! Сихерем булсамы...

— Нишләр идең, Арзу?

Сәгать тавышы аны да борчып торган икән, ул тиз генә барып сәгатьне туктатып килде.

— Их, Искәндәр... Елан кабыклары салып берни эшләтә алмаганнар иде, бер пот борчак кертеп башны ашадылар. Сихерем булсамы, шул явызларны җыяять өстендә тотып алыр идем. Утлы күмергә ялан аяк бастырыр идем мин аларны...

Ни ялварып сорасам да, ул артыгын аңлатмады, сораганнарга җавап бирмәде, talәпчән йомшак тавыш белән кайтып китүемне үтенде...

Ул мине озата чыкты. Капка төбендә тездән карга батып без тагын кочаклаштык. Кайгы китердеме аны минем кочакка, ялгызлыгымы? Мәхәббәтме, нәфрәтме? Сөенергәме миңа, көенергәме?.. Гашыйклар да шундый хәлдә кала икән, и дөнья!..

Иртәгә бик озакка, бик күпкә аерылырга җыенган кешеләр төсле хушлаштык.

— Арзу!..

— Булды, Искәндәр. Хуш, тугры дустым. Бүгенгә дәфтәргә карамый тор, яме?

Тукайларны, Есениннарны салкын мәктәпкә, Хәбибрахман абзыйның бер төнлек төрмәсенә әйләнгән мәктәпкә алып барасым килмәде, үзебезнең ишегалдына кердем дә лапастагы печән арасына кыстырдым. Печәннән кояш исе, Арзуның чәч исе килә иде. Әллә мин кыштырдаганга уянып, әтәчебез кычкырып җибәрде, аны күрше әтәчләр күтәреп алды. Мәктәпкә йөгереп барып җиткәнче тынмады Югары авыл әтәчләре. Ни хәбәр итәсез сез бүгенге таңда?.. Ни сөйлисез? Буран басылса да, минем күңелдәге бураннар басылмаган бит әле!.. Әтәчләрдә һаман бер җыр инде — «кикри-күк» тә «кикри-күк!» Ә миңа хәбәр кирәк бит, әтәчләр, яңа сүз кирәк!..



## 14

Күзгә йокы кермәде. Күңелдә кайгы булганда, күз йокыны белми. Асыловның килеп җитүен сабырсызланып көтеп тордык. Ни булса да ачыклый алмадымы икән? Бөтен өмет аңарда иде.

Җыештыручы апалар килеп мичләргә ягып җибәргәч, милиционер да торып утырды, тоткыннарны барып карады, почмактагы су багыннан кружкага салкын су агызып, учы белән бер-ике тапкыр битенә сипте, канәгатьләнеп пошкырды, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып сөртенде, шуннан соң кәефләнеп тәмәке кабызды. Рәфгать белән без дә аннан берәр төрерлек сорадык. Өчәү диванда утырып төтәтәбез.

Йокысызлыктан йончыса да, чип-чиста итеп кырынган, кардай ак күлмәк кигән Асылов яктырыр-яктырмаста килеп житте. Килеп тә керде, Хәбибрахман абзый ябылган бүлмә ишеген ачып:

— Сез азат, Хәбибрахман абзый, өегезгә кайтыгыз, — диде.

Карт үз колакларына үзе ышанмады, ахры, беравык партага таянып торды, Асылов сүзен кабатлагач кына, иңенә элгән тунының

жиңнәрен киде, төймәләп тормады, саубуллашмады, селлин-селлин атлап чыгып китте.

— Бичара агай! — диде Асылов. — Шатланды шатлануын... Тик үзен нинди хәбәр көткәнен генә белми.

— Борчакны кем урлаган соң? — дидем мин түземсезләнеп.

Асылов җавап бирергә ашыкмады, бераздан тамак төбе тавышы белән:

— Арзу Ямашева, — дип куйды.

— Ничек? — дип кычкырып җибәрдем мин.

— Үзе килде. «Гаеп миндә», — диде.

— Ә Мәүлиха апа?

— Егет, егеткәй, — диде Асылов әрнеп. — Кичә шулай дигән иде, бүген иртән бөтенләй башкача... Арзу Ямашеваның идарәгә килеп, гаепне үз өстенә алуын каян ишетеп өлгергән диген! Җитмәсә, кызын да ияртkән.

— Кәриманеме?

— Әйе. Арзуның капчык күтәреп кайтканын күрдек дип икәүләшеп чатнатып торалар.

— Кияүләрен дә ияртмәгәннәрме? — дидем мин. — Ул да шуны сайрар иде.

Ачу белән әйткән сүзләремнән Асылов мәгънә тапты, җитди җавап бирде:

— Анысы өйдә юк. Тегермәндә куна калган, диләр.

Мин чәчрәп алгарак чыктым:

— Ямашева борчак урламаган, ул борчакны аларга кертеп куйганнар.

— Бәлки син моны исбат та итә алырсың?

Асылов шаярмый иде, күреп торабыз.

Мин:

— Тырышып карыйк! — дидем һәм көзлектә кое янында булган хәлләрне: күлмәк эченнән чыккан хәшәрәтләр турында, Арзуны бозарга теләүләре турында кабалана-кабалана сөйләп бирдем.

— Нигә моңарчы су кабып тордың? — диде Асылов кызып. — Күлмәк кайда?

— Күмгән урыннан казып алыйммы соң?

— Эзләп кара. Тиз бул.

Рәфгать йодрыгы белән миңа төртте:

— Сөйләгәч, барын да сөйлә! — диде.

— Мәүлихаападан чиләк сорагыз сез, иптәш Асылов. Көз көне коега төшкән чиләк, диегез. Яңгыннан соң миңа чиләк күрсәткән идегез бит, таныш кебек тоелды ул миңа.

Асылов бер агарынды, бер күгәренде:

— Малай! — дип кычкырып җибәрде. — Казы! Күлмәксез күземә күренәсе булма!..

Милиционер Сырур апа белән Гөлбәдәрне алып чыгып китте, без идарә янынннан йөгергәндә, җыелган кешеләр уртасында Арзуның ак шәлен күреп алдык. Янына барып торырга вакыт тар иде, тиз-тиз безгә чабып кайттык, әни болдырда борчылып кычкырып калды, без лом, кәйлә, агач көрәк, тимер чөй ише кирәк-яракларны алып тыкрык башына йөгердек. Бабайның таш чыгаргандагы коралларының кирәге чыкты!

Әле ярый, кычытканлыкка күмгән идем, хәзер дә курайлары җилдә сызгырып утыра, билгеле урын, арада уйдык-уйдык буш урыннар да шәйләнә, табарга ансат булыр. Беравык уйлап, чамалап тордым да:

— Менә шушында бугай, — дидем.

Рәфгать ачулы иде:

— Син «бугай» күмдеңме, әллә күлмәкме?.. Асылов сине чын исемең белән атады, ахры! Малай син!

— Шушында! — дидем мин дә кызып. — Шушында! Әнә теге botaklы казык төбеннән ат башы чаклы таш китереп салдым. Шушында!

Эшкә керештек. Агач көрәк белән карны арчып җиргә хәтле төштек, чал аю күк бәсәргән туң җир күренгәч, бишмәтләребезне салып ыргытып ломга тотындык. Казыйбыз, казыйбыз, кәйлә белән дә чокып карыйбыз, туңган җир суккан саен әчтерхан чикләвеге хәтле генә куба, йокысызлыктан арган күз төпләре сызлый, әмма бер тынга да туктамыйбыз. Рәфгатьнең җилкәсеннән сыек пар күтәрелә, мин дә күлмәк изүе турыннан корсак өсләп тир тамчыларының аска йөгерүен сизәм.

— Казыган җиргә охшамый бу бер дә, — диде Рәфгать, маңгайдан куе тир сыпырып. — Тоташ туң.

— Шушында булырга тиеш!

— Икеле-микеле сөйләшә торган әкәми булып чыктың син дә!.. Авызны тутырып сөйләшергә кирәк чагында, теш арасында камыр әвәлисең!..

Яктырды. Апалар, җиңгәләр суга төшә башлады, алар туктап кызыксыналар, «ни тилереп казырга тотындыгыз, хәзинә-мазармы әллә?» дип көлешәләр, без дә аларның сүзләрен уенга борып җибәрергә телибез, ләкин ярсудан күгәргән иреннәрдән шушы туң балчык төсле үк салкын, авыр сүзләр генә кысылып чыга.

Мәүлиха апа да күренде, кичәгечә ару шәлен бәйләгән, томырылып төшеп килә, авызы ачык:

— Бәрәкәт, алтын эзлисезме әллә сез? — дип көлде ул.

Сүзенә игътибар итмәдек, әмма аның хафаланып һаман китмичә торуы, көянтәсен бер иңеннән икенчесенә күчерә-күчерә, кечкенә күзләре белән тишеп-тишеп каравы безгә нидер сөйләгән төсле булды. Күзләреннән зәһәр ага, нәфрәт ага.

Нигә шул тиклем күрә алмый икән ул мине?

Юк кына бит, егылып үләсеңмени, күлмәк тә, өстенә бастырган таш та чыкмый.

— Дөмектергәнсең икән үзең дә! — диде Рәфгать карлыккан тавыш белән.

— Дускаем Дыңдып! — дидем мин әрнеп. — Егылыр урынымны белсәм, түшәк кабартып куяр идем дип әйтте ди берәү!.. Төшкә дә кермәгән хәлләргә дучар булдык. Кем уйлаган бит ул чагында... Җире йомшак, ачуым бик каты иде...

Арып, алҗып, эт булып, үзебез казыган чокырга аякларыбызны асылындырып утырдык та, көрәк сабы белән тирәнлекне үлчәп алдым.

— Юк. Монда түгел. Үпкәләмә. Болай ук тирәнгә китмәгән идем.

— Җире каты, ачу да катыракмы бүген? — дип көлемсерәде Рәфгать.

Киртә баганасыннан атлам белән үлчәп, икенче ачыклыкны чокый башладык. Мәүлиха апа икенче кат суга төште...

Җил кычыткан куралары арасында усал сызгыра, бүселеп чыккан күлмәк итәкләрен җилфердәтеп аркага кереп тула, өшетә. Бу юлы дөрес казыганбыз икән, аршын чамасы төшкәч тә, мин күмгән таш килеп чыкты, таш тирәли ныгытып-ныгытып казысак та, күлмәк тә, черек чүпрәк-фәлән дә, күлмәк эченә тутырылган хәшәрәтләр дә күренмәде.

— Тычкан ашап бетермәгәндер бит ләгънәтне?! — диде Рәфгать.

Ул бер төн эчендә сураеп, курачланып калган, кара шадралары чабата-чабата тирәнәйгән, уң күз астындагы җәрәхәт эзе кара-кучкылланган...

Мин нинди булдым икән?

Асылов, кулга алынганнарны районга озатырга җыенып, безне түземсезлек белән идарәдә көтеп утыра иде... Халык төркемен ерып мин

аның янына кердем, ишек яңагына сөялдем, сөялмәсәм идәнгә аварлык хәлгә житеп арган идем. Асылов күтәрелеп карады да барын аңлады...

Бүлмәдә бер ялгызы ул, янында Мәүлиха апаларның чиләге... Без коедан алган чиләк... Очлы багор белән сызылган ике сызыгы да исән. Чиләк исән, чиләккә няреп чыккан күлмәк кенә юк.

— Югалган... Юк, Нәҗип абый, — дидем мин, иреннәремне чак кыймылдатып...

Идарә алдына чыктым. Идарә алдында халык... Уртада милиционерның ак туны, Хәбибрахман абзыйның көмеш сибелгән башы һәм Арзуның кардай ак мамык шәле күренеп китте... Нишләргә?!

Мәүлиха апа, ыштыр бит, кызларын ияртеп чыккан, Кәримә белән чыш-пыш нидер сөйләшәләр, ызгышалар, ахры: Кәримәнең күз яшьләре менә тамам, менә тамам дип мөлдерәп тора.

Моңарчы Ялкаулык дисәләр, күз алдыма Мәүлиха апа килә иде.

Моңарчы Гайбәт дисәләр, Мәүлиха апаны уйлый идем.

Моннан соң Мәкер дисәләр, шул ук апаны исемдә тотармын.

Онытырлык итмәде...

Моннан соң Нәфрәт дисәләр, хәтеремә кара күләгә булып шул апа инәр... Их, чыраена берне төкерергә! Ләкин аннан ни файда?.. Мәхәббәтем Нәфрәт алдында көчсез бүген. Мәхәббәтем Мәкер алдында зәгыйфь...

Аптырагач, Рәфгать янына барып бастым. Беләм, ул мине дә гаепли. Әгәр көздән үк эшлеклерәк булсам... Бәлки, бәлки...

Күңелләрне шомландырып идарә алдында ике ат тора. Алларына карга салган коры печәнне ясканып ашыйлар. Шунда ук алама сакалына тигәнәк кисәкләре укмашып каткан арык кәҗә дә ялманып йөри, ике-өч малай трайлы уйныйлар, ат тизәге тибәләр...

Алама кәҗә, карак кәҗә...

Югары авыл урамнары, кешеләре дә, моржаларыннан чыгып җиргә төшәлгән аксыл төтене дә ят кебек бүген. Барысы да идарәдән Асыловның чыкканын, аның кузгалырга кушканын көтәләр.

Кәҗә башы урамы хатыннары — Сырур белән Гөлбәдәр тирәсендә. Сырур апаның теле монда да тик тормый, җыелганнарга нидер сөйли, көлешеп тә алалар. Гыйбадулла чулак та монда. Ул, кулларын җиңе эченә тыгып, бөкрәеп, төркемнән-төркемгә йөри, дәшми, тыңлана. Яхшырак ишетер өчен бер колакчынын өскә күтәреп куйган. Онытты Илдусны, килене Хәтимәне ияртеп, Рәхимҗан бабай да килеп җитте. Хәтимә апа ак тастымалга төреп күчтәнәч алып килгән, шуны Арзуга бирде, яулык чите белән күз яшьләрен сөртә башлады. Кара син, әнием дә монда икән бит, Арзу янында ук басып тора; Нәсимә дә шунда, әниенең бишмәт итәгенә тагылып борынын мышкылдата.

Кешеләргә күтәрелеп карарга читенсенеп кенә Арзу янына барып җиттем.

— Арзу...

— Менә Искәндәр дә озатырга килеп җиткән, — диде ул моңаеп кына.

— Нишләдең син, Арзу? — дип пышылдадым мин.

— Нәрсә бар?

— Нишләдең?

— Башкача җае юк иде, Искәндәр, — дип пышылдады ул.

Менә Асылов болдырга чыкты, халык төркеме чайкалып алды, гөҗелдәү тына төште, ул сүзсез генә кул изәде, милиционерлар кулга алынганнарны утырырга әйди башладылар.

Айлар буе фронтларга кеше озатып тордык-тордык та, мә сина, төрмәгә җибәрәбез! Югары авылдан алты кеше. Шул алтының берсе — Арзу!..

Алама кәҗә чанага ук менгән, куганны да белми, ашыгып-ашыгып печән чемченә. Бер чанадан куып төшергәннәр иде, икенчесенә барып ябышты. Һайт, мәлгунь!

Шул вакыт әллә ни булып алды: шау-шу купты, кемдер кычкырып елап җибәрде, дилбегәләр ат аягы арасына кереп буталды. Аннан кинәт тынлык урнашты. Кәҗә башы урамыннан, тегермән ягыннан кушаяклап атын чаптырып берәү килә иде. Ул чанасына аягүрә киерелеп баскан да дилбегәсен болгап атын туктаусыз чарлый, сызгыра, акыра, чана әле бер якка салулый, әле икенче якка кар сиптереп шуып китә. Кеше егылмый, атын җан-фәрманга һаман каулый.

— Туктагыз! Һай! Тукталыгыз! Көтегез!..

Борын тишекләре киңәйгән, манма су булган ат халык төркеме арасына ерып керде дә, тәртә башлары белән кемнәрнедер ега язып, шып туктады. Чанадан Сирай сикереп төште. Туны җилбәгәй, ялан кул, күлмәк изүенә хәтле ачык, изүеннән аксыл куе йон үскән таза күкрәге күренеп тора.

Моңарчы бу чуалышка һич катнашы, бер гаме юк кебек читтән-читтән генә йөргән Гыйбадулла кай арада Сирай янына барып җиткәндер, хәзергә хәтле аңламыйм!

Сирай ике сикерүдә тоткыннар төялешкән чана янына барып җитте дә:

— Арзу, сине виноват ясадылармы? Сине алып китәләрме? — дип акырып җибәрде.

— Күргәнеңчә,— диде Арзу, толып итәге белән аякларын төреп.— Нигә алай дидең, Хәбибов?

Милиционер иңе белән Сирайны бер читкәрәк какты да чанага тезләнде:

— На-на, кузгалдык, — дип, дилбегә какты.

— Тукталыгыз, — дип акырды Сирай, ике кулын да йодрыклап. — Тукта!

Асылов идарә ишеге төбенә барып җиткән иде инде, ул да тукталды, борылып чаналар янына килде.

Кызарынып-бүртенеп басып торган Сирай аңа таба борылды:

— Арзуның гаебе юк. Ул бур түгел, — диде.

— Кем гаепле соң? — диде Асылов тиз-тиз.

— Борчакны мин керттем. Чоланнарына керттем дә бушаттым. Кисмәккә...

Тирә-юньдәгеләр ахылдап куйдылар, төркем чаналар тирәсендә тагын да тыгызланды.

— Прокурор иптәш, — диде Гыйбадулла, Сирайның атын бора-бора, — күрмисезмени, исерек бит. Кеше таптата язды, юньсез!

— Әйдә, кияүкәем, кайтыйк, — дип, Мәүлиха апа да Сирайга килеп тотынды.

Сирай аларга күз дә салмады, Арзуга карап йотылган иде ул. Милиционер сорау белән Асыловка карады, Арзу чанадан төшеп толыбын салды, Сирай каршысына килеп басты.

— Я, я, Сирай...

Мәүлиха апа бер яктан, Гыйбадулла икенче яктан Сирайга асылынып чанага сөйри башладылар.

— Исерек ич, исерек! Чак басып тора, — дип чәрелдәде Мәүлиха апа.

— Мин алай булыр дип уйламаган идем, Арзу, ышан. Уен диебрәк санадым...

— Я, Хәбибов, әйтеп бетер, — диде Асылов аны кызулап.

Гаҗәп хәлнең бер башлануы гына кирәк икән, аннан үзеннән-үзе хут ала икән ул! Кәримә энисен бер якка кагып җибәрде дә иренең күкрәгенә килеп капланды, илереп елап:

— Әйт барын да! Әйт! Котыл, Сирай! — дип инәлде.

Сирай сыңар кулы белән Кәримәне үзенә тартты.

— Борчак минеке. Арзу бур түгел, — дип кабатлады.

Мәүлиха апаның теше ыржайды, ул әтәч шикелле очынып, кызына кунды, чәченә ябышты:

— Төнлә туган! Тилебәрән орлыгы ашаган исәр! Тинтәк!.. — дип чырылдады.

Кәримә, чәчен әнисенең кулыннан ычкындырырга теләп, төрле якка йолкынды, елак, әмма кеше аңларлык тавыш белән:

— Җитте. Ашадың башымны! Артыгы булмас... Сирай, җаныкаем, сөйлә. Түзәр әмәлем юк... Гомер буе Арзу белән тиңләп, аның белән чагыштырып җанымны таладылар. Аннан узар өчен яшьли кияүгә чыктым... Үзем үз була алмадым! Чулагын да әйт, башкасын да, аяма берсен дә!..

Без барыбыз да тетрәнеп сүзсез калдык.

## 15

Мәктәп янсын дип, утны Гыйбадулла чулак салган булып чыкты. Сыерны да ул чәнечкән... Мәүлиха апа Дөреш күрәзәсеннән алып кайткан бозымны коега салган. «Тәне тартышсын — җылан кабыгы кебек, йөзе саргайсын — тырнак кебек... Әкәм-төкәмдәй бөкрәйсен...»

Язга таба без түзмәдек, тагын военкоматка бардык. Бу юлы Рәфгатьне дә, мине дә алдылар.

Туганнар белән, авыл белән саубуллашып бер-ике көн никрут булып ду килеп йөрдек тә, Бөгелмәгә озаттылар, Арзу Бөгелмәгә хәтле озата да килде...

Бөгелмәдән частька киттек, аннан тагын юлга, кырык икенең җәендә без Сталинград янындагы далаларда идек инде...

Сталинградны белмәгән кеше дөньяда калмагандыр, андагы дәһшәт, Совет солдатының батырлыгы турында том-том китаплар язылган, мәгәр уртак язмыш кичерсәк тә, һәр солдатның юлы, үз көне бар иде. Бу турыда бер сөйләми калмам әле...

Әлеге хикәяттә исә иске дусларыма, иске танышларыма күчәм, шул сәбәпле турыдан-туры кырык бишенче елга, Җиңү елына сикерәм. Шулай кирәк... Чөнки минем язмыш юлын үзгәрткән мөһим вакыйгалар сугыш беткән көннәргә дә калган булып чыкты...

Сугышны мин бераз соңрак, май ахырларында Чехословакия тауларында тәмамлап нокта куйдым. Куанычым чиксез зур иде, бердән, этинең җиңел генә яраланып өйгә исән кайтканын беләм, үзем дә таза-сәламәтмен. Абый — юаш Кәлимулла гына — Төньяк фронтта Карелия сазлыкларында югалып калды...

Днестр буенда каты яраланган буларак, мин демобилизациягә яшьтәшләрдән бераз алдарак эләктем. Шул чагында полк командиры мине үз янына чакырып алды да:

— Укырга кирәк сиңа, Җиһангиров, — диде. — Укымыйча һич ярамый. Теләсәң, мин сине хәрби мәктәпләрнең берәрсенә тәкъдим итәм. Батырлыгың бар, башың эшли, тот та тәвәккәллә син!

Командир шулай дип торгач, бераз борын да күтәрелеп китте, тәкъдиме дә бик кызыккыч иде, мәгәр мин авылга кайтырга булдым... Арзу... Ул көтә иде мине!

— Рәхмәт, иптәш майор, — дидем. — Башта унынчыны тәмамлыйк инде! Әнә сеңел яза... Бармак башы хәтле генә кыз иде, хәзер унынчыны бергә тутырырга туры киләчәк.

— Хәрби хезмәтне яратмыйм дисең инде, Җиһангиров?

— Яратмыйм димим, күнегелде. Мәгәр авылда бик көтәләр.

Туганнарча саубуллаштык...

Туган илгә кайту шатлыгының зурлыгын канлы сугышны тәмамлаган солдат кына белсә беләдер! Китә-җыена башлагач табышасың бит ул, Татарстаннан өч егет җыелдык. Кичкә хәтле вакыт шактый иде, поезд төнге унберда гена китә, әйберләрне тапшырдык та үзебез азат иткән шәһәр белән танышырга чыгып киттек. Үзәк урамнарның берсендә, бомба һәм снаряд чокырлары белән чарланган мәйдан каршысында, бер йорттан музыка тавышы яңгырады, әсәренеп тукталып калдык. Тәрәзәләр фанер, такта белән кадакланган булса да, музыка тавышы безне үзенә чакырды. Якынрак барсак, күрәбез, ишек өстенә «Ресторан» дип язып куелган.

— Керәбезме?

— Керәбез!

— Малай, мондыйга акча җитәрме соң? — ди беребез.

— Бездәге акча, — ди икенчесе, кесәсенә сугып. — Рестораны-ние белән сатып алабыз!

Сиңа егерме бер-егерме ике яшь булсын, иңендә лейтенант погоннары, син чех шәһәрен фашистлардан азат итүче, син Европаның үзәгендә бул, җиңүче булып йөр, кесәңдә туган илгә хәтле билет кыштырдасын, көн матур, җәйге кояш синең орден-медальләреңә куныл балкысын — ничек бәйрәм итмисең ди инде?! Шәһәрне азат итү, урамнарны квадратлар, нокталар белән атап йөртү бер нәрсә, ә монда ресторан!.. Чын ресторан! Музыка уйнап тора, кергән-чыкканнарның авыз ерык!..

Башта этәчләнсәк тә, ишеккә тотынгач, каушап калдык, барыбыз да сала кабартмалары, ә ресторан ишегенең тоткасы арыслан башлары белән бизәп җиздән коелган, авыр, саллы ишек... Арада кыюрагы мин булып чыктым.

— Ни кыланса, шул килешә җиңеп чыккан егеткә! — дип, күкрәкне киердем дә арысланның танавыннан гына чеметеп авыр ишекне каерып ачтым...

Тып та тып басып кереп барабыз, малай, и-и, анда мыжылдаган халык, күбесе безнең офицерлар, солдатлар, тегендә дә, бу өстәл янында да русча сөйләшәләр, «Огонек»ны сузалар, сәхнә кебек эшләнгән, бәрхет белән өртелгән мәйданчыкта шәрә беләкле, озын күлмәк кигән арык кына хатын-кыз җырлый, карлыгач канаты кебек озын итәкле җилән кигән бер озын кеше скрипка уйный, галәмәт!..

Алай халык мыж килсә дә, кадерең юк дип, читкә какмыйлар икән монда, ап-ак яка куйган шома егет йөгереп килеп тә җиткән, «пан да пан!» дип өтәләнә бу! Какой-такой пан булыйк ди без сиңа, майлы күз, Татарстан егетләре без, Иделдән, фашист муенына элмәк булган елгадан, «товарищ» диген... Бетте моннан соң паннар! Дөньяда «товарищ»тан да кадерле сүз юк, белмисең икән, өйрәнә тор! Тегенең дә авыз колакка җитте, «Рәхим итегез, товарищ!» ди, бер кырыйдарак безгә язган буш өстәле дә бар икән. Малайлар батыраеп та китте: «Иң шәп шәрабләрне, иң әгъләә ризыкларыңны ташы!» — дип кенә торалар...

Әлбәттә, беренче чәркәне Җиңү өчен тоттык.

Җиңү дигәненә туган ил дә, әти-әниләр дә, сөйгән ярлар да, еллар буе күңелләрдә сүнәр-сүнмәс дөрләгән хыяллар да керә иде. Сүнәр-сүнмәс дим, чөнки сугыш сугыш ул! Идел ярыннан шушы бәләкәй шәһәргә килеп җиткәнче күпме яшьтәшләрне, никадәр иптәшләрне күмеп калдырдым мин!

Арадан без бәхетле булып чыктык...

Табындашым — зур авызлы, кыска кара мыеклы Шөгер егете Исмәгыйль:

— Әйдәгез, җанкай-җанашлар өчен берне күтәрик, — диде.

Арзу исәнлегенә берне эчәм дип торганда гына аркама шап иттереп бирәү сукты. Чәчәдем, борылып карадым һәм кычкырып җибәрдем: артымда кителенең өске төймәсен ычкындырган, киң җилкәле, чегән төсле кап-кара каралган, ялтыр куныч итекләрен ерып баскан өлкән лейтенант басып тора иде.

— Рәфгать! Дустым Дындып! Каян болай?

— Кая диген, өшегән! Өйгә!..

— Без дә өйгә!

Баксаң, алар ресторанның икенче почмагында утыралар икән, безнең татарча гөжләгәнне ишетеп килгәннәр. Ике егет. Шуларның берсе — Рәфгать!.. Официантны чакырып китереп өстәлләрне берләштердек, мәҗлес өр-яңадан башланып китте...

Без ул көнне, әлбәттә, поездга өлгермәдек, комендант янына кереп, мең бәхәс белән, билетларны иртәгәгә — Рәфгатьләр поездына төзәттереп чыктык. Рәфгать белән бергә кундык. Киев янында аерылганнан соң безнең башлардан шактый нәрсәләр кичкәнгә, сөйләшеп сүз бетмәде, таңны аттырдык, керфек тә какмыйча урамга чыгып киттек, әллә нинди шикле подвалларга төштек, барыбер таптык, баш төзәттек, җырладык, биедек...

Рәфгать миңа караганда егетрәк кеше шул! Өлкән лейтенант, түшкә йолдызлар да күбрәк сибелгән. Җитмәсә, менә диген күн пальто алып кайта, киеп тә күрсәтте, итәге үкчәсеннән. Шул пальтосын кигән иде, нәкъ менә Бөгелмәдәге абыйсына охшады да куйды! «Шушы пальтоны киеп Югары авылны биш әйләнәм әле, күрсеннәр кем икәнлекне!» — диде ул, мактануын һич тә яшермичә. Малай-шалайга бүләк җыйган: трофей зажигалкалар, кесә фонарьлары, пәкеләр, авыз гармуннары... Сизәм, авылны бөтенләй шаккатырмакчы була егетем!..

Икәү генә калгач, Арзуны телгә алдык.

— Язамы? — диде ул.

— Яза да, көтә дә! Шуңа күрә ашыгам да!..

Югары авыл... Хәбибрахман абзыйның үлгәненә ике ел... Сирай да штрафной батальонга эләгеп батырларча сугышып үлгән... Кәримә Сирайдан бәбәй табып Мәүлиха апалардан аерылып чыккан, хәзер Арзу белән бергә, бер йортта торалар... Гыйбадулла чулак төрмәдә эзсез югалган...

— Мин дә үземнең Арзуымны таба алырмын дип уйлыйм хәзер! — диде Рәфгать.

Ниһаять, без кайтып барабыз... Берәү дә купеда гына утыра алмый, коридорга чыгып бөялэбез, көн җылы, матур, тәрәзәләр шар ачык, вагоннарда трофей аккордеоннар белән Тула гармуннары ярышып-ярышып сайрашалар. Туган ил җиренә аяк баскач, дәррәү рәвештә «Ур-ра! кычкырдык...

Инде монда тынычлык, инде монда сугыш яраларын төзәтү бара, йортка түбә ябалар, станциядә водокачка тирәсендә нидер эшлиләр... Инде бездән дә бәхетле кеше юк хәзер — тыныч тормышны күрү бәхетенә дә ирештек!

Поезд Украина кырлары буйлап акрын гына чаба, вагоннарны кечкенә станцияләрдә дә зур-зур халык төркеме каршылый, кайгы яшьләре шатлык яшьләре белән аралашып ага...

— Болары Көнбатыш Украина авыллары, — ди Рәфгать, ап-ак тәбәнәк хаталарны күрсәтеп. Ихаталар зур түгел монда, киртә-куралар да юк, бәләкәй елга буена сырышкан йортлар алма, груша бакчалары арасында яшеллеккә күмелеп утыралар. Үзебезнең шулай ерак китүебезне, җирнең, илнең зурлыгын мин хәзер генә чынлап торып күз алдыма китерә алам. Һәм минем күңелгә гаҗәп бер уй килә: бар иде бит, шушы чиксез җирнең күкрәгендә ышыкланып, башны саклап торырлык урын тапмаган чаклар да бар иде бит!..

Татарстанга хәтле бик ерак, әле күрше республикалардан очраткан кешеләрне дә «якташ!» дип сөенеп каршылыйбыз, табын уртак, күнелләр хуш.

Шау-гөр килеп купеда чәй эчәбез. Каршымда Рәфгать... Ул бүген миңа ата-анамнан да, дөньядагы барлык кешеләрдән дә якынрак. Ул минем бала чак дустым гына түгел, ул аннан да мең тапкыр олырак: ул минем беренче окопташым... Беренче куркуымның, беренче мәхшәремнең шаһиты. Сталинград җәһәннәмендә булмаган кешегә сөйләп аңлату читен, күргән кешеләр үлем түшәкләрендә дә андагыларны онытмаслар. Кешеләрнең чакма ташыннан катырак икәнлеген без шунда күрдек. Әгәр без шуны күрмәсәк, шуңа инанмасак, Европа үзәгенә тикле барып җитә алган булыр идекме икән? Куркак күбрәк үлә сугышта...

Тәрәзәдән җәй җиле керә. Як-ягыбызда тыныч заманның тын өйләре кала. Юл буйларында чиккән түшле ак кофта кигән кызлар яулык болгап кала... Чәебез тәмле, сүзләребез сайланып кына чыга, уйларыбыз татлы... Рәхәт, чиксез рәхәт икән бу яшәү!..

— Мин юридическийга китмәкче булам, Искәндәр...

Мин Рәфгать өчен куанып баш кагам...

— Ә унынчыны?

— Анысын быел җәйдә үк җайларга кирәк!

— Арзу яшәсен! Кайтабыз да аңа егылабыз!

Кинәт әллә нәрсә булды: безнең купе тәрәзәсенә чарт иттереп нидер китереп сукты, яшен дияр идең, күк йөзе чалт аяз... Пыяла ярчыклары кулымдагы чәйле кружкага сибелде, берсе кул аркама кадалып сызылып кан агып чыкты. Рәфгатьнең кружкасы идәнгә үк тәгәрәде.

— Рәфгать, күрче, кан, — дидем мин. Коридорда тавыш, ыгы-зыгы купты, кемдер «аһ» дип куйды. Рәфгать өстәлгә иңеп төште, мин аның иңнәрен эләктереп алдым, кочагыма яткырдым... Аның чигәсеннән кан тибеп чыккач кына аһ дип өнсез калдым...

Коридорга атылып чыктык...

— Санитар! Врач! Ярдәмгә килегез!

— Бендеровчылар ата! Хыянәтчеләр! — дип кычкырды кемдер.

Атыш тавышларын мин дә ишеттем.

Поезд акрынлап туктады, офицерлар, солдатлар җиргә коелдылар, кайберәүләрнең кулында корал ялтырады.

— Бандитлар! Бендеровчылар!..

Минем алар турында юньләп ишеткәнем дә юк иде моңарчы, кылган явызлыкларын күреп шаккаттык. Безнең составка әллә ничә автоматтан атып калганнар икән...

«Саша» дип аталган бәләкәй генә станциядә Рәфгать белән тагын дүрт егетне тупыл агачы төбенә, туганнар каберлегендә күмеп калдырдык. Аның фуражкасын, балаларга җыйган бүләкләрен үзем белән алдым.

Тагын зур сынау алдында торып калдым. Алда юлым... Алда Татарстаным. Алда Арзуым... Янда Рәфгать... Янда яңа корбаннар...

Нишләргә?

Юк, мин электәге беркатлы малай түгел идем инде! Дус белән дошманны аерырга мине Сталинград далалары өйрәткән иде! Дусны иркәләргә хакым булган кебек, дошманны каты җәзаларга хакым бар иде минем. Мәхәббәт белән Нәфрәт уртасында бу юлы озак басып тормадым. Мәхәббәтем күңелем ярларына сыймыйча ташыса да, Нәфрәтем көчлерәк иде. Рәфгатьне җирләп, тыныч кына кызлар куенына кайтып китә торган егет идем мин, авызым тулы кара канны төкермәдем, Украинада калдым. Тернополь, Ровно өлкәләрендә армиядә хезмәт иттем. Ягымлы йөзле, җырга-моңга искиткеч бай, тәмле телле украин халкын гомерлеккә яраттым. Рус, украин егетләре белән бергә

илебез урманнарын милләтче бандитлардан арчыдык. Ел саен язын, агачлар ак чәчәккә төренгәч, Рәфгатьнең каберен зыярат иттем...

Шунда партиягә кердем, бандит пулясы муенымны шунда тишеп узды...

Шунда Кызыл Байрак ордены алдым...

Өйгә мин кырык җиденең көзендә генә кайтып элгәштем.

Әти өйдә иде, ул урам яктан йорт нигезен пычкы чүбе өеп җылытып йөри иде. Мин аттан төшеп калгач, әти танымый торды. Кочаклаштык.

— Бүген кайтырсың сыман күңелгә килгән иде, улым.

— Ә кичә?

— Кичә дә шулай... Һәр көн шулай иде.

Көлештек. Әтинең чал сакалы арасындагы җәрәхәт җөен кулым белән тотып карадым...

— Авыртмыймы, әти?

— Әлегә сизелми, улым...

Әни кибеткә төшеп киткән икән. Без урамда сөйләшеп торганда күрше капка ачылды һәм аннан җиңелчә пальто кигән, ыспай гына гәүдәле бер хатын-кыз килеп чыкты.

Әти янында хатын-кызга игътибар итү килешеп бетмәсә дә, мин аңа таба киттем, ул да бер мәлгә генә тукталып калды да туп-туры миңа таба атлады...

* * *

Кичкырын, бүләкләр, күчтәнәчләр алып, Арзу белән Рәфгатьнең әнисе Миңсылу апа янына киттек. Рәфгатьнең фуражкасын ак чүпрәк белән төреп Арзуга тоттырдым. Зажигалкалар, пәкеләрне Түбән оч малайларына өләштек. Кәримәнең малаена авыз гармуны һәм дүрт җәпле пәке эләкте...

Күз булса да, киче матур...

Җылы...

Торналар китә.

Берьюлы ике көянтә!

Без, тукталып, кызгылт-зәңгәр күктә очкан үзебезнең як кошларына сокланып карап торабыз. Ирләре, уллары сугыштан кайтмаганнар аларның моңсу тавышын ишетеп үкереп елыйлардыр...

Урамда, ишегалдында, бөтен җирдә коймак исе...

Печән исе. Тереклек исе.

Торналарны озаткач, икебез дә тәрәзәгә карадык: әти белән әни янәшә басканнар да үксеп-үксеп елыйлар. Алар чиксез шат. Әллә мин исән-сау кайтканга, әллә без Арзу белән кавышканга шатланалар, аңысын аера алмадык...

Июнь, 1972 — сентябрь, 1973.
Займище — Казан.

Фәнис Яруллин

## Ничек булыр?

Ничек булыр
Быелгы ел
икмәге?
Пешәрме ул
Болыт кебек
кабарып,
Торырмы ул
Табыныбыз
түрендә
Кискән саен
Бөтенәеп,
яңарып.
Ничек булыр
Быелгы ел
икмәге?
Ак булырмы
Игенченең
йөзедәй?
Никадәре
Сөенеч
һәм көенеч
Алып килер
Икән безгә
шушы җәй?

Ничек булыр
Быелгы ел
икмәге?
Соравыма
Җавап эзлим
кырлардан,
Уч төбемдә
Дымлы басу
туфрагы,
Ипи исе
Килә кебек
шуңардан...

## Рәшит Гәрәй

### Шигырь укыттылар

Сабан туйда шигырь укыттылар
Мәйдан уртасына чыгарып.
Ялганыңны монда тиз тоталар,
Һәр сүзеңдә булсын чынбарлык.

Тормыш үзе килсен күз алдына —
Бозылмыйча, матур көенчә.
Әйт, азмыни сине тыңлаганда
Хет бер кеше ихлас сөенсә?!

Курку басты шунда күңелемне:
Бу сынауны, димен, үтәлмәм.
Авылымның ел да мәйдан тоткан
Егетләре миңа текәлгән.

Сиздермичә генә елмаялар,
Карап карыйк әле, янәсе:
Авылыбызның сабан туйларына
Лаекмы син, хода бәндәсе.

Матур сүзләр сөйләп безне, имеш,
Шаккаттыра алмый беркем дә.
Кыяр-кыймас карыйм күтәрелеп
Мең карашлы чуар төркемгә.

Җиңел булыр кебек шул төркемдә
Дусларымны күпләп танысам.
Әйтерсең мин теге егетләрнең
Иң көчлесе белән алышам.

Шабыр тиргә батам... бу бәйгегә
Әзерлексез, ахры, килengән.
Сөлгем минем һаман өскә шуыша,
Кысып алыйм дисәм биленнән.

Тартышамын... егетеңнең, димен,
Кайнарлыгы бераз сүрелсен.
Җырың-ниең белән чалкан төшсәң,
Оятыңнан кая керерсең.

Үзен шулай интектергән өчен,
Изалаган өчен үртәлеп, —
Җирдән суырып ала да ул мине,
Кабат җиргә бәрә күтәреп.

Юк, ташлама ясамыйлар монда
Кунак итеп кенә булса да.
Бәйге тәмам... Халык миңа түгел,
Дәррәү кубып, аңа кул чаба.

Җиңелгәнне кем соң күккә чөйсен,
Башым минем түбән иелгән.
Сөялләнгән куллы аксакаллар
Килеп кага шунда иңемнән.

Якын итеп биргән киңәшләрен
Гомер буе юлдаш итәрлек:
— Җырларыңны өйрәт көрәшергә,
Сабан туйлар алда җитәрлек!

## Егор Уткин

### Әнкәй дә гел җыеп ала иде...

Болытларны күзләп яткан кырдан
Көзге сафлык тора бөркелеп,
Һәрбер орлык бик кадерләп җыя
Кояш нурын, яңгыр бөртеген.

Кем белә бит, ничек килер әле,
Кирәк булыр язгы чорларга...
Орлыклар бит җирдән шытып чыга
Үрелеп шул якты нурларга.

Еллар... еллар...
Кырлар ни күрмәгән,
Кадере зур нурның, тамчының...
Әрәм итми җыеп ала иде
Әнкәй дә гел ипи валчыгын.

## Нәҗип Мадьяров

●

Күзем текәп күксел офыкларга,
Шаулы басу өстен күзәтәм.
Кыр тутырып үскән игеннәрнең
Өлгерүен гүя тизләтәм.

Кырны иңләп чапкан дулкыннарда
Алтынаеп нурлар коена.
Авылыбызга алар менә-менә
Бәреп керер кебек тоела...

## Нур Әхмәдиев

●

Бодайларның керфек каккан чагы,
Карабодай кыры — ак күбек,
Арыш исә ил агасы сыман
Мыекларын тора бөтереп.

Арыш бит ул күпне күргән инде,
Кар астына качкан суыктан.
Яз җилләре белән көч сынашып,
Кыреуларда калып чыныккан.

Хәзер исә таңда чык эчә дә
Кояш нурларында коена.
Бөртегенә нурлар җыя-җыя,
Башаклары инде туена.

Басуларны урый ил картлары,
Чырайлары якты, мөлаем.
Алар инде уйда бу уңышны
Буралагра салган, мөгаен.

## Хәниф Хөснуллин

●

Сабан туе туган якларымда,
Кунаклар да килде еракта.
Мәйдан тулы халык, шау-гөр килеп,
Көч сынауны көтә ир-аттан.
Чыгып бас та мәйдан уртасына,
Еракларга ташла карашың.
Баш чыгарып килгән арышларда
Матурлык та, көч тә табарсың.
Әнә юллар. Тузан биеп кала,
Ярыш дәрте ташый атларда.
Игенче дә шулар шикелле бит
Урак өсте җиткән чакларда.

# Госман Садә

●

Иген кыры...
Уйный арыш диңгезендә
Кояш нуры.

Басу аша
Тар гына юл — сукмак уза
Офыккача.

Шул юл буйлап
Кайта кырдан ике гашыйк,
Көлеп-уйнап.

Уңган иген! —
Шатлыклары чиктән ашкан
Шуңа бүген.

Туйлар булыр!
Һәрбер өйдә шатлык җыры
Гөрләп торыр.

Ике гашыйк
Кайта юлдан. Бәхетләләр —
Кырлар шаһит.

Күпме өмет:
Учларында гәрәбәдәй
Алтын бөртек!

## Караидел — урман иле

Карлыганнар җыйыйм дисәң,
Караидел — урман иле.
Карлыгандай кара күзле
Кызларның туган иле.
Караидел — урман иле.

Карлыганга барган чакта,
Ялгызың барып кара.
Кайсы юлдан барсагыз да,
Урманга алып бара.
Ялгызың барып кара.

Кабып кара, татып кара
Кап-кара карлыганнар.
Гүя кызлар юри генә
Өзмичә калдырганнар.
Кап-кара карлыганнар.

Карлыганнар җыйыйм дисәң,
Караидел — урман иле.
Карлыгандай кара күзле
Кызларның туган иле.
Караидел — урман иле!

●

Гөлләрдән-гөлгә куныл,
Уйнады яз.
Чая кыз күңелендә
Уянды наз.

Ачылды наз күлендә
Нәни бөре —
Яшьлекнең иң самими,
Садә сере.

Үзгәрде кинәт төсләр,
Үзгәрде кыз.

Зәңгәрдән башка төсне
Күрмәде кыз.

Нурланды офык кашы —
Утлы балкыш.
Яфраклар телгә килде,
Култы алкыш.

Ә кояш барсын сизде,
Барсын күрде.
Салават күперенә
Кызны терде.

## Иршат Вергасов

# КЫРЫМ ПАРТИЗАННАРЫ

ХИКӘЯЛӘР

*Иршат Зәки улы Вергасов 1914 елда туган.*

*Бөек Ватан сугышы елларында Кырымдагы партизаннар хәрәкәтендә катнаша, зур гына партизаннар берләшмәсенең командиры була.*

*1948 елда яза башлый. 1949 елда «Таврия таулыгында» исемле беренче китабы чыга һәм соңыннан бу китабы рус телендә 12 тапкыр басыла. Аның шулай ук «Үткелдә», «Верхоречье юлы» исемле очерк һәм хикәя җыентыклары, «Җиребез бер генә» дигән романы, «Кырым сәхифәләре» исемле роман-хроникасы (3 тапкыр басылган), «Боз өстеннән үткән юл» дигән повесте бар.*

*Хәзерге вакытта «Полк командиры» исемле яңа романын төгәлләп килә.*

*Әдәби псевдонимы — Илья Вергасов. Әсәрләрен рус телендә яза.*

## «Без, бөтен җәмәгать белән...»



Сугыш илебезнең көньяк цитаделе — Севастополь янына ук килеп җиткән иде инде. Немец полклары, безнең оборонаны җимерергә тырышып, күп санлы танклары, самолетлары һәм сайлап алынган эсэс батальоннары ярдәмендә, бертуктаусыз һөҗүм итә һәм шәһәрне көчле артиллерия уты астында тота иде. Бөтен тирә-як сугыш гөрелтесеннән болай да калтырап тора иде...

Бары тик Севастопольдән көнчыгыштарак, утыз чакрым чамасы читтәрәк, таулар итәгендә ак йортлары белән җәелеп утырган Лаки авылында гына әлегә ул-бу сизелми кебек. Ерактагы зәңгәр тау сыртлары ягыннан әллә нигә бер ишетелеп куйган пулемет тырылдауларын исәпләмәгәндә (тауларга партизаннар хуҗа иде), авылда әүвәлгечә табигый тынлык хөкем сөрә. Анда немецлар ничектер кисәк кенә бер күренделәр дә, йорт саен аракы даулап, кош-корт атып мал җыйгач һәм колхоз клубы каршындагы мәйданда бераз исерешеп буталгач, Бакчасарай тарафына китеп бардылар. Алар киткәч, авыл янә әүвәлгечә яши башлаган кебек булган иде...

Әмма кышкы юеш-дымлы көннәрнең берсендә, иртәнге якта, табутны хәтерләткән озынча соры бер машина авылга ыжгырып килеп керде дә Лаки колхозы председателе Владимир Лелиның йорты кар-

шында шып туктады. Кабинадан юан гына бер фельдфебель сикереп төште.

— Синең Лакида партизан бар? — дип сорады ул, капкадан чыгып килгән председательгә эндәшеп.

Владимир Лели — аз сүзле, тыныч-сабыр холыклы кеше — чакырылмаган кунакка түбәнчелек белән күзләрен текәде дә:

— Каян килсен монда партизаннар, офицер әфәнде! Тын, аулак урын бу,— дип җавап бирде.

— Колхос гут, и партизан юк, э?

— Колхоз чынлап та яхшы,— анысын дөрес әйтәсез, офицер әфәнде, ә минә партизан дигәне юк, аллага шөкер,— диде Лели, башка нәрсә әйтергә белмәгән бер төс белән кулларын җәеп.

Фельдфебель тирә-ягын күздән кичерде, аннары күршедәге Кирмәнчек дигән авылның полицаен ияртеп, председатель йортының каралты-курасын, парникларын тикшерергә кереп китте. Шунда, бер уңайга, түтәлдән кыяр өзеп алып, шытыр-шытыр ашарга да тотынды. Терлек абзарына кергәч, белдекле бер кыяфәттә: «Якшы, гут, биик якшы»,— дип, үзалдына сөйләнеп торды: ниһаять, йөзе белән председательгә таба борылып, бармагын аның күкрәгенә терәде:

— Син кем була?

— Шушы авыл кешесе, колхозчы ягъни.

Кирмәнчек полицае, тешләрен ыржайтып, сүзгә катышты:

— Ник ялганлыйсың? Председатель икәнеңне бөтен кеше белә ич.

Фельдфебельнең күзе-кашы җимерелде:

— Бу дөрес, әйе?.. Күзләр акыллы, хуҗа кеше, әйе?

— Без барыбыз да хуҗалар.

— Юк! Син староста булыр. Син аңлый, әйе? Бургомистр, майн гут!

— Кая инде ул безгә андый начальник булу, офицер әфәнде! Аякларымның да рәте юк...

— Юк! Син немец командований кушкан староста! Саботаж — фьют! — диде фельдфебель, председательнең борыны төбендә бармагын шартлатып. Аннары, еракта ачылганнан-ачыла барган шәрә тауларга таба күрсәтеп: — Анда партизан бар? — дип сорады.

— Партизаннар әнә анда,— диде полицай, ялагайланып, һәм еракта караеп күренгән урманлы тауга таба кулы белән ишарәләде.

Шуннан соң алар машиналарына чыгып утырдылар да гүелдәп китеп бардылар. Лели исә бүреген күзләренә батырып киде, җиргә бер төкерде дә капкадан йортка керде.

Колхозның бухгалтеры — сирәк, уңган сакаллы, аксыл йөзле, өстенә кыршылып беткән вельвет куртка кигән Григорий Александрович — бу вакыт идарәдә калын-калын ниндидер контор кенәгәләре актарып, счеты белән нәрсәдер санап-исәпләп утыра иде. Гомумән, соңгы көннәрдә ул иртәдән кичкә хәтле идарәдән гел чыкмый иде диярлек. Әлеге фельдфебель белән полицайның председатель йорты каршындагы кыланышларын ул тузанлы тәрәзә пыяласы аша бик җентекләп күзәтеп торды, аннары, алар киткәч, тиз генә киенеп, култык астына счет һәм исәп-хисап кенәгәләрен кыстырды да идарәдән чыкты һәм туп-туры председательгә юнәлде.

Теге исә аны шактый коры каршылады. Авызыннан сүз алып булмас бу картлачны ул бик өнәп бетерми иде. Шуңа күрә хәзер: «Монысына тагы ни кирәк икән?» — дип, эченнән генә пошынып уйлап куйды.

Табынга утырып, йортта төнәтелгән йөзем шәрабеннән берәр стакан авыз иттеләр. Хисапчы карт, кулын колагы янына күтәреп, тыңлабрак торды да:

— Гули димме, ә? — дип сорап куйды.

— Гули,— диде Лели, әллә ни исе китмәгән бер тавыш белән.

— Севастопольне, әлеге «каты чикләвек» дигәнне, мәйтәм... ватмакчылар, ә?

— Ә сез шуңа шатланасызмы әллә?

— Нигә әле алай дисез?

— Ярар, Григорий Александрович, тел яшереп маташмыйк. Йомышыгыз нәрсә? Хәзер тәккә генә кунакка йөрмиләр — заманы андый түгел.

— Анысы дөрес. Мине менә нәрсә борчый: колхоз амбарларында күпме байлык ята бит безнең, беләсезме шуны? — дип, үртәлебрәк сорап куйды хисапчы.

— Шуннан нәрсә?

— Ничек «нәрсә»? Килерләр дә кырып-себереп китәрләр! Аулак урын дип безне ягалап үтәрләр дисезме әллә?

Шулай дип, бухгалтер председатель каршына счетны этәреп куйды да тәмәкедән саргаеп беткән бармаклары белән чалт-чолт китереп төймәләрне күчерә башлады:

— Дюбек тәмәкесе, ашлык, сарыклар, мөгезле эре терлек... Хәер, сез хуҗа кеше ләбаса, хәзинәдә ни барын үзегез дә беләсез! Менә шул байлык хакында җаныгыз бераз борчыламы дип соравым? — Бухгалтер, күзлеген маңгаена күтәреп, председательгә төбәлде.

— Сез нәрсә тәкъдим итмәкче буласыз соң? — диде Лели, әчке бер дулкынлану белән.

Карт, ябык-нәзек муенын суза төшеп, тәрәзә аша еракта караеп күренгән урманлы тауларга карап алды.

— Имеш-мимешләргә караганда, сезнең беренче ярдәмчегез Николай Константинович Спаи нәкъ әнә шунда, ягъни Македонский отрядында, сугышып йөри диләр. Дөресме шул, ә?

Лели гаҗәпләнүдән хәтта тетрәнеп куйды: гомере буе җәмәгать тормышыннан читтә булырга тырышкан, идарә утырышы булып идарә утырышларына да кыстата-кыстата гына килгән һәм анда беркайчан сүз алып сөйләмәгән, фәкать хисап эшләренең үзе куйган тәртибе бозылган очракларда гына холкын күрсәтә торган шушы мәхлук хәзер әллә кайдагы партизаннар турында хәбәрдар булсын, имеш!

— Николай Константинович хәзер кайда йөри торгандыр — анысын белмим, ә менә җәмәгать милкен кайгыртуыгыз өчен рәхмәт!..

Бухгалтер, өстәл өстеннән счетын тартып алып, аягүрә торып басты һәм председательгә таба очкынлы кысык күзләрен юнәлтте:

— Алайса, гафу итәсез: мин сезне әллә башлырак, йөрәклерәк кешеме дип уйлаган идем, ә баксаң — алай түгел икән. Хушыгыз!

— Туктагыз! Кичерегез, гаеп миндә. Сез хаклы: безнең Николай чыннан да Македонский отрядында. Тик менә соңгы вакытларда никтер күренми башлады — шунысы гына начар,— диде Лели, икърар итеп.

— Берәр бәла-каза булмагандыр бит?

— Үзегез дә күргәнсездер: теге чакны урманда зур янгын булды. Отряд шуннан качып берәр кая китеп бармадымы икән дим.

— Беркая да китмәс, әлегә шым гына яталардыр. Менә берәрсе килеп чыгар әле, кайгырма.

— Рәхмәт сезгә, Григорий Александрович.

— Болар белән нишлибез соң? — диде бухгалтер, кенәгәләрен айкап.

— Бүген җыелышып сөйләшербез. Кичен. Миндә. Сезнең дә килүегезне үтенәм.

— Килермен, һичшиксез килермен.

Кичен председатель өенең аулак, киң-иркен кунак бүлмәсендә дүрт кеше утыра иде. Өчесе — идарә члены, дүртенчесе — бухгалтер. Лели үзе авыл әйләнеп, аның тирәсендәге сукмакларга һәм ике олы юлга күзәтчеләр куеп йөргән арада, болары, үзара сүз куертып, бүгенге көн хәлләре һәм Севастополь тирәсендә барган каты сугышлар турында сөйләштеләр, безнең частьлар чигенгән чакта аларга һәм таулардагы партизаннарга колхоз милкеннән азык-төлек бирми җибәрүләре өчен үз-үзләрен шелтәләп тә алдылар.

Ниһаять, председатель кайтып керде. Ишектән керүгә үк, тирләгән маңгаен йонлач бүреге белән сөртте дә:

— Безнең Григорий Александрович фикерен тыңлап карыйк әле,— дип, сүзне шундук төп мәсьәләгә күчерде.

Карт та, буш сүзгә урын калдырмастан, фикерен төгәл итеп, санап ярдәмендә әйтеп бирде. Колхоз милкендә ике мең декалитр йөзем аракысы, фәлән-фәлән күләмдә алтындай кадерле дюбек дигән тәмәке чималы бар, диде. Аның соңында: колхоз көтүендә биш йөз баш сарык, күп санлы эре терлек бар. Күпме ашлык та күпме бәрәңге запасы! Һәммәсе күз алдында ята,— сизенсә, фашист шундук бөртегенәчә тазартып-чистартып китәчәк!

— Хәл менә шундый! — дип бетерде ул сүзен.

Аны һәммәсе дә зур кызыксыну белән тыңладылар. Әйтергә мөмкин, бу аның авылдашлары алдында беренче зур чыгыш ясавы иде.

Аннары кызу бәхәс башланды. Төрле тәкъдимнәр булды, иң соңында бөтен байлыкны яшерергә дигән уртак фикергә килделәр. Тәмәке чималын, тюкларга бәйләп, тау куышларына, йөзем, аракысын да — шунда илтергә. Тик алдан, икенче савытларга бушатып, савытларны күкерт белән төнәтергә кирәк булыр. Инде сарык, сыерлар көтүенә һәм бөртекле ашлык, бәрәңге запасына килсәк,— аларның һәммәсен урманга-тауларга җиткереп, партизаннарга тапшырырга.

Тик менә ул партизаннар дигәне генә кайда икән хәзер? Македонский үзенең сугышчан отрядларын нинди урманга, кайсы тау араларына күчерде икән? Николай Спаи белән юлчы-мастер Иван Иванович Суполкин ни сәбәптән элемтәне өзделәр соң әле? Әбит моңарчы авылга кемнәр генә килеп-китеп йөрми иде! Рядовой партизаннары да, командирлары да, хәтта элеккеге райком секретаре, хәзер партизаннар отряды комиссары Василий Ильич Черный үзе дә булгалый,— килеп, халык белән сөйләшеп, аны өметләндереп, сөендереп китә иде. Мәскәү янында немец гаскәрләрен тар-мар итү, Керчь, Феодосиягә безнең десантлар төшерелүе турындагы шатлыклы хәбәрләрне халык аңардан ишеткән иде бит!

Ә менә хәзер, партизаннарның ярдәме аеруча кирәк дигән бер вакытта,— һичберсе юк, җир упкандай, бөтенесе югалдылар да беттеләр!..

...Авылга Кырым кышы якынлашып килә. Иртәләрен тау сыртлары өстеннән түбәнгә катлам-катлам соры масса шуышып төшә дә бөтен тирә-якны куе томан каплап ала.

Колхоз сөрәнчесе иртә таңнан тәрәзә шакырга тотына:

— Һәй, эшкә чыгыгыз!

— Исәр баш, кем өчен эшләргә өндисең?

— Кем өчен булсын, Совет власте өчен!

Кичләрен исә тәбәнәк түшәмле идарә бүлмәсенә Лели керә. Ул арыган, йончылган. Гаҗәп түгел: көн эчендә ул күпме юл үткән — бригадаларда йөргән, тәмәке саклагыч сарайларда булган, тау куышлары белән авыл арасын ничәмә-ничә мәртәбә әйләнгән!

Идарәгә кергәч, ул бухгалтер картның кечкенә өстәле янына килеп утыра да, әкрен генә тәмәке пыскытып, Григорий Александровичның

тын-салмак тавышлы хисап сүзләрен тыңлый: ничә кап тәмәке озатылган, ничә мичкәне пешекләп, төнәтеп, күпме аракы салынган...

Атна эчендә төп эшне башкарып та чыктылар. Колхоз байлыгы тулысы белән озак вакыт саклау өчен җайлаштырылган тау куышына күчерелде. Анда барыр юл — чын лабиринт: белми кергәннең ары үтәр түгел, әйтергә мөмкин, кире чыгар әмәле дә юк.

Алгарак китеп, шунысын әйтик: 1944 елда Кырымны азат иткән Совет гаскәри частьлары Лаки колхозчыларының бу зур бүләген рәхмәт әйтеп кабул иттеләр. Дөрес, ул байлыкның яшерелгән урынын күрсәтеп бирүчеләр Лаки колхозчылары үзләре түгел иде түгелен...

Шул ук 1942 елның кышында Лели — «яңа гына пешеп чыккан бургомистр»— Бакчасарайдагы немец коменданты исеменнән: «Качи шоссе юлын төзәтү өчен унбиш крестьян җибәрергә!» дигән язма боерык алды. Бу боерыкны аңа сыңар погонлы кара шинель кигән фашистлар — эсэсчылар китереп бирде!

Нишләргә? Севастополь янында һаман каты сугышлар дәвам итә. Кая карама — анда «ягт-командалар» — партизан аулаучы фашист отрядлары тыкшынып йөри. Лаки өстенә һәлакәт якынлашканнан-якынлаша бара иде.

Берәүләр уенча, авылга ут төртеп, урманга партизанлыкка китәргә кирәк. Ләкин карт-корыны, бала-чага, хатын-кызны кая куярга? Икенче берәүләр, киресенчә, беркая аяк атламаска, күндәм генә, тын гына авылда яшәп ятарга һәм ни буласын көтәргә киңәш итәләр. Тик шундук шикләнеп тә куялар: нәрсә көтәргә? Аркаңа пулямы, әллә муенга элмәкме?!.

Шул чакны бухгалтер сүз сорады. Трибунага таба салмак адымнар белән атлап барган картка күп кенә колхозчылар хәтта ничектер гаҗәпсенеп карадылар шикелле.

Карт хисапчы болай диде:

— Безгә,— диде,— Крылов мәсәлендәге торна, кысла һәм чуртан кебек кылану һич килешми. Без бөтен җәмәгать белән бер сүзгә килергә, арбаны фәкать бер якка тартырга тиешле... Менә шулай, колхозчы гражданнар...

— Конкрет алганда нәрсә тәкъдим итәсез соң?

— Беренчедән, председателебезнең кушканын үтәргә.

— Бургомистрның ягъни, шулаймы?

— Кешенең! Рәсми яктан әйдә бургомистр була бирсен, ә гамәлдә — ул барыбер безнең председатель! Оккупантлар белән эшне хәйләгә корырга кирәк, аларны алдарга, сүздә вәгъдә биреп, гамәлдә үз файдабызны кайгыртырга кирәк. Хәзер иң мөһиме — партизаннарны табу, ягъни Македонский белән элемтә урнаштыру.

— Тотарсың кырдагы җилне!

Григорий Александрович кулын кискен генә югары күтәрде:

— Македонскийны мин күреп беләм, алар яшеренгән урманнар да миңа таныш. Ышанып тапшырсагыз — үзем эзләргә алынам!

Озакламый теге юан немец фельдфебеле тагы Лакига килеп чыкты. Бу юлы ул кыр жандармериясе отрядын һәм Кирмәнчек авылы полицайларын да ияrткән иде.

Председатель өенә кергәч, фельдфебель хуҗаларча эре бер кыяфәт белән түргә узды һәм аш өстәле янына килеп утырды.

Өстәл өстенә берничә шешә вино һәм салкын сарык ите китереп куйдылар. Лели хәтта кабыгы ләйсән бөртекләре кебек җемелдәп, чуарланып торган хуш исле розмарин алмаларын да чыгарып салды.

— Гут, молодец! — дип, кулларын уа-уа, көлеп сөйләнде фельдфебель, табындагы нигъмәтләргә карап. Шул ук вакытта астыртын гына гел хуҗаны күзәтте.

Солдатлар озаклап һәм бик тәмләп ашадылар. Фельдфебель, аракыны мактый-мактый, стаканын күтәрде:

— Севастополь капут! Солдат күп — ашау да күп кирәк. Немец командований хосусый милекне никс... алырга кушмый. Лаки колхози бай. Җәмәгать фонди зурмы?

— Байлык зурын зур иде дә, эвакуацияләделәр, Кызыл Армиягә биреп җибәрделәр. Хәзер колхозның бөртек тә байлыгы юк, офицер әфәнде.

— Ник юк? — дип, фельдфебель кинәт йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты һәм урыныннан сикереп торды.— Без белергә кирәк... Сарик, сыир, шнапс, э-э... ничек? Дюбек, дюбек... Алар бар, әйе?

— Бар иде, хәзер юк шул инде. Юкка суд та юк — шулай диләр бездә,— диде Лели, кулларын җәеп.

Фельдфебель аның өстенә килә башлады:

— Ник юк?

Алар шулай бер-беренә бик озак карашып тордылар. Солдатлар хәтта чәйнәүләреннән туктады, ишек төбендәге полицайлар да афәт көткәндәй катып калдылар.

— Син — коммунист... Партизан. Сине — фьют!..

Фельдфебель, үз солдатларына һәм полицайларга таба борылып, нәрсәдер немецчалап әйтте. Тегеләр шундук корал-мылтыкларын эләктереп ишегалдына атылдылар. Берәве, автоматын әзер тотып, бусага төбенә барып басты.

Шулай унбишме-егермеме минут вакыт үтте. Лели, берни булмагандай, урындыгына тын гына утырды, фельдфебель исә күзен алмый һаман аны күзәтте.

Ниһаять, солдатлар кире әйләнеп кайттылар һәм колхоз амбарларында, сарайларда тузаннан башка берни дә булмавын сөйләп бирделәр. Фельдфебель янә Лели янына атылып килде һәм ике бармагын тырпайтып күрсәтте дә:

— Ике тәүлек, ике көн, ике төн — егерме биш сыир, ике йөз сарик, йөз декалитр шнапс булсын!..— диде.— Юкса...

Һәм ул, кулы белән һавада элмәк сурәте ясап, күзләрен өскә таба чөеп алды.

— Берни дә юк бит, немец әфәнде.

— Дәшмә! — дип җикерде фельдфебель, йодрыгы белән Лелинең яңагына төртеп.

Лели хәтта артка чайкалып китте. Күзләрендә шундый нәфрәт очкыны кабынды ки, фельдфебель, үзе дә аңышмастан, кобурасындагы пистолетына сузылды.

Председатель, ачуын ничек кирәк алай басып, түбәнчелекле гадәти тавышы белән әйтеп куйды:

— Мин кулдан килгәннең бөтенесен эшләргә әзер, офицер әфәнде, тик алыр җире юк бит. Шулай да ни дә булса җыйнаштырып карармын.

Урман эченнән иске юл сузылып киткән. Ян-якларында куе әрәмәлек. Карала башлаган җепшек кар өстендә бернинди эз юк. Тынлык. Тик кайдадыр якында чылтырап гөрләвек акканы гына ишетелеп китә.

Як-ягына карангалап, юлдан карсак-ябык гәүдәле, кулына кызыл агачыннан кисеп алынган таяк тоткан бер карт бара. Ул бик арыган булса кирәк, аякларын көч-хәл белән генә атлый.

Куаклык эченә яшеренгән сакчы исә юлчыны күзен дә алмый күзәтә, әмма тавыш биреп туктатырга әле ашыкмый: партизаннар оясына көтмәгәндә килеп чыккан бу сәер картлачның юл максатын чамаларга тели, ахрысы.

Менә, ниһаять, карт юлны аркылы кисеп үткән һәм аяк эзләре белән чуарланган сукмак чатына килеп җитте. Килеп җитте дә, туктап, иелә-иелә, сукмактагы эзләрне карарга керешге. Һәм нәкъ шул мизгелдә колагы төбендә:

— Тукта! Кулыңны күтәр, атакай! — дигән кискен тавыш ишетте.

Күтәрелеп караса — каршында өстенә сырма кигән автоматлы бер егет басып тора.

— Бу нәмәстәкәеңне читкәрәк ал,— диде карт, арыган тавыш белән, аннары егетнең күзләренә туры карады да: — Әйт әле, син партизанмы әллә, улым? — дип сорады.

Картны әлеге тапталган сукмактан бик озак алып бардылар. Сукмак әле шарлап аккан елга үзәненә барып төшә, әле текә ярдан тау өстенә күтәрелә иде. Ахырда ул, тигез җиргә чыгып, дөм-караңгы урман агачлары астыннан бара башлады.

Тоткынны штаб урнашкан шалаш янында туктатып, командирга хәбәр белән кереп киттеләр.

Шалаштан таза-тыгыз гәүдәле, кыска муенлы, урта яшьләрдәге бер ир кеше чыкты. Тоткынга бер күз төшереп алгач та, ул гаҗәпләнүдән кычкырып ук җибәрде:

— Карале, Григорий Александрович түгелме соң? Йа аллам, шул! Менә бу кунак дисәң дә кунак, егетләр!

Карт аягында көчкә басып тора иде.

— Македонский, иптәш Македонский! — диде ул, командирны кочаклап.— Әйе, бу мин, мин!..— Аның хәтта күзләре яшьләнде.

— Ни булды, Григорий Александрович, нинди бәла китерде сезне монда?

— Сезне таба алмыйм икән дип, инде бөтенләй хафага төшкән идем...

Бакчасарай төбәгенең сугышчан отряды командиры Михаил Андреевич Македонский үзенең элеккеге укытучысын бик хөрмәтләп чәй табынына утыртты. Карт чәен дә эчте, хуҗаны мактый-мактый, җимеш төнәтмәсеннән дә авыз итте һәм, сөеп-яратып, әледән-әле элеккеге шәкертенең көч-гайрәт ташып торган кара-кучкыл йөзенә күтәрелеп карады.

— Мәктәп хәтереңдәме? Ул чакта ук мин сиңа: «Синнән җүнле бухгалтер чыкмас!» — дигән идем.

— Эшләп карадым ич,— дип җавап бирде Македонский елмаеп.

— Ә ничек эшләдең, хөрмәтлем? Күңел бирмичә, тәмен тапмыйча эшләдең.

— Болар һәммәсе узган эшләр. Ә менә сезне монда, урманда очрату — чыннан да көтелмәгән хәл. Сез бит Бакчасарайда төнлә урамга чыгарга да курка торган идегез.

— Курыкмыйча, куркырсың да... Мине бит бармак белән чиртеп тә аяктан түндереп була... Мин, мәсәлән, хәзер дә бик куркам. Биш тәүлек буе тауларда адашып йөри-йөри котым тәмам ботыма төште,— ахырга таба нәрсәдән куркырга, нәрсәдән курыкмаска кирәген дә аңышмый башладым. Әзегезне һич табарлык түгел.

— Безгә эз калдырырга ярамый шул.

— Аягым кая таба атласа, шунда бардым да бардым. Сезнең ярдәмнән башка хәзер безгә һич мөмкинлек калмады, Мишенька. Без, бөтен җәмәгать белән, менә нинди фикергә килдек, тыңла. Бу бик мөһим эш, халык эше...

Караңгы кышкы төннәрнең берсендә партизаннар отряды, Дәү урмандагы оясыннан бөтен составы белән кубарылып, Бишуй-Бакчасарай юлын сиздермичә генә кисеп чыкты да, тау сыртындагы бормалы сукмакларны тәмам бутап-саташтырып бара торгач, таң вакытын-

да Лаки авылыннан ике чакрым гына ераклыкта яткан кечкенә, ләкин куе бер урманчыкка кереп яшеренде...

Лаки председателе Лели, бик каты тәрәзә шакуга уянып, урыныннан сикереп торды да җылы пинжәген атлаган уңайга кия-кия ишеккә юнәлде.

— Кем бар анда?

— Үз кешеләр. Бу мин — Григорий Александрович!..

— Ниһаять, кайтып җиткәнсең икән!

— Кунакларны кабул ит! — диде бухгалтер һәм плащ-палаткага төренгән киң җилкәле бер кешене үзеннән алда эчкә уздырып җибәрде.

Тегесе, кердә-керешли үк, шат һәм калын тавыш белән хуҗага эндәште:

— Лаки колхозы председателе ничек яшәп ята соң, иптәш Лели!

Председательнең йөзенә шатлык нуры җәелде:

— Македонский! Һай, молодец!..

Ул да булмады, өйгә өстенә сыланып торган командир шинеле һәм аягына шундый ук ыспай итек кигән икенче берәү килеп керде. Йөзгә шактый яшь күренә, мыеклы, күз карашында исә ниндидер мутлык, шаянлык очкыны ялтырый...

— Василий Ильич, иптәш Черный! — дип ах итте Лели.

— Партия райкомы секретарен мене ничек кабул итәсең икән син, иптәш председатель! — диде Василий Ильич, шаркылдап көлә-көлә.

Алар бер-берен инде күптән беләләр, район үзәгендә оештырылган җыелышларда, райком утырышларында еш кына очраштыргалыйлар, бергәләп тәмәке плантацияләрендә булалар, хәтта телефон аша кычкырышкалап та алалар иде. Ләкин хәзерге минуттагы кебек рухи якынлыкны моңарчы алар, белмим, кайчан да булса бер хис иттеләр микән?!.

Зур эшләр гадәттә аз сүз белән башкарыла.

Кыска гына киңәштән соң, уртак нәтиҗәгә килделәр: терлекне хәзер үк Басман-тау арьятына — партизаннарның үзәк төбәгенә куалый башларга, киптерелгән җиләк-җимеш, калдык тәмәке, берничә мичкә вионы — отрядка тапшырырга. Фельдфебельнең исә күзен буарга: арыграк сыерларны сайлап, шуңа беркадәр вино һәм бер-ике дистә сарык та өстәп, тамагын тыгылдырырга — әйдә, дөмексен шул малы белән!

Аннары кемне нинди исемлеккә теркәү мәсьәләсе кузгалды. Лаки ирләреннән аерым партизаннар группасы төзергәдер бәлки?

Шул чак комиссар Черный әйтеп куйды:

— Сабыр итегез, сүзне хатын-кыз, карт-коры һәм бала-чагадан башларга кирәк. Аларны кая куябыз?

— Бәлкем бу мәсьәлә белән ашыкмаскадыр? Соңыннан күз күрер әле. Аларның һәммәсен отрядка алып булмый бит инде,— диде Македонский.

Григорий Александрович комиссар фикерен куәтләде:

— Халыкны кая кую мәсьәләсен, минемчә, хәзер үк хәл итәргә кирәк. Минем тәкъдим — иртәгәдән эвакуацияли башларга. Картларны, хатын-кыз, бала-чаганы далага, Тарханкутка — туганнары, кардәшләре янына озатырга, анда немец бөтенләй булмый диярлек.

Иртәгесен эвакуация башланды. Лели, бургомистрлык вазифасыннан файдаланып, китүчеләр өчен пропусклар табып бирде. Дөрес, эвакуация барышында ара-тирә каршылыклар да килеп чыккалады. Кайберәүләр: «Шушында тудым, шушында үләмен!» — дип карышып маташтылар, елаштылар. Ләкин шартлар авыл халкын эвакуацияләүне таләп итә иде.

Озак та үтми, бу эшнең бик вакытлы эшләнгәнлеге расланды.

Лакига тагы әлеге фельдфебель килеп төште. Янында ике офицер да бар. Берсе — яшь, аксыл чырайлы, кулына камчы тоткан немец, ә икенчесе — шактый юан гәүдәле, башына биек козыреклы фуражка кигән акшарлы румын капитаны. Алар шулай өчәүләп авылны тикшерергә керештеләр. Лели аларга ияреп, аңлатмалар биреп йөрде. Янәшәләреннән култык астына амбар кенәгәләрен кыстырган Григорий Александрович тыраклады. Бу кенәгәләрне яңа килгән яшь немец офицеры соратып алган иде.

— Бөтенесен дә күрсәтегез! — дип боерды ул саф рус телендә.

— Бездә яшерердәй нәрсә юк, әфәнделәр.— диде Лели.— Терлек эвакуацияләнде, аракыны да эвакуацияләделәр. Башка җирдә ничек, бездә дә шулай. Өстәвенә, колхоз үзе дә зур түгел, хуҗалык саны белән әйтсәк, нибары...

Немец офицеры председательнең каршысына ук килеп басты.

— Юкны сөйләмәгез, бургомистр әфәнде. Колхозыгызны яхшы беләм мин. Сүз уңаеннан: Мәскәү авыл хуҗалыгы күргәзмәсендәге сезнең колхоз стендына элентән портретыгызда сез күпкә яшьрәк күренәсез. Аңлашылмаучылык бетсен өчен алдан ук кисәтеп куям: мин Фрайдорфтан килгән агроном. Кырымның төньягындагы ул немец колониясе турында сезнең ишеткәнегез бардыр дип уйлыйм? Кыскасы, шул: миңа чын дөреслек кирәк!

Лели, «кунакларны» лабаз янына алып килеп, аларга фельдфебель өчен дип җыелган аяклы малны күрсәтте:

— Менә, бөтен булганы шул, әфәнделәр!

Фрайдорфтан килгән офицер председатель күрсәткән якка, ичмасам, башын гына да борып карамады. Идарә янында туктап, авызын ерып елмаеп торган румын капитанына:

— Подразделениегезне бөтен кирәк-ярак белән шушы авыл тәэмин итәр. Сез монда күченергә ризамы? — диде.

Тегесе, ризалыгын белдереп, башын иде, ләкин эченнән ул мондый мөмкинлеккә һич тә ышанмый иде булса кирәк.

Аннары немец офицеры Лелига таба борылды:

— Һәммәсе җитәрлек булсын: ипи дә, аракысы да, ит тә, тәмәке һәм башка нәрсәләр дә.

— Ләкин бит, офицер әфәнде...

— Бернинди «ләкин» юк! Сезнең коммунист икәнегез миңа мәгълүм, шулай ук бәрәкәтле хуҗа булуыгыз да билгеле. Аннары, бераз уйланып торгач, болай диде: — Сез бауга асылыр дәрәҗәдә үк ахмак түгелсездер дип уйлыйм. Большевиклар сезнең колхоз милкеннән бер нәрсә дә алып китмәделәр — мин моны бик яхшы беләм. Сүзем бетте, бургомистр әфәнде!

Немецлар китеп барды.

Авыл халкының шактый өлеше эвакуацияләнеп беткән иде инде. Македонский үзенең отрядын авылга тагы да якынрак күчерде. Көндезләрен алар әрәмәлектә яшеренеп яталар, ә кичләрен...

Җылы түбә астында төн куну — Кырым партизаны өчен бөтенләй эшкә ашмас бер хыял кебек нәрсә. Ә монда...

Иртә таңнан партизаннар группа-группа булып операциягә китеп баралар. Әле монда, әле тегендә күперләр шартлый, немец машиналары күккә оча...

Немецлар тәмам аптыраштa калдылар: ул партизан дигәннәре каян килеп чыга да операциядән соң кая китеп югала соң? Дәү урманга бара торган сукмакларның һәммәсен алар көн-төн күзәтеп торалар бит, югыйсә! Ул сукмакларда бер генә җан иясенең дә күренгәне юк, шул ук вакытта — машиналар шартлый бирә, солдатлар, старосталар, полицайларны юк итә торалар...

Лаки авылында унтер-офицер җитәкчелегендәге кечерәк бер ру-

мын командасы урнашкан иде. Солдатлары — йончылып, арып, керләнеп-бетләп беткәннәр. Алар фашистларны һәм үз «фюрерлары» — Антонескуны бертуктаусыз сүгә. Ашыйлар-эчәләр, әмма авыл буенча үз өйләрендәге кебек иркенләп йөргән кораллы партизаннарны әллә күрмиләр, әллә күреп тә күрмәмешкә салышалар иде.

Ниһаять, авылга теге акшарлы капитан җитәкчелегендә, тоташ румыннардан торган бер рота килеп төште. Йорт саен тентү башланды, тик бу тентүләрдән нәтиҗә генә булмады. Капитан атасы-анасы белән сүгенә, солдатларны кыйный иде. Бигрәк тә әлеге унтерга каныкты. Аны айнымаган һәм кыйналып һушыннан язган килеш каядыр хөкемгә озаттылар.

Бер иртәне отрядтан Николай Спаи чабып килде дә:

— Качыгыз тизрәк — эсэсчылар якынлаша! Тизрәк китегез! — диде.

Йорт саен йөреп, авылда булганнарның һәммәсен кисәтеп чыктылар. Берәүләр китеп өлгерде, икенче берәүләр өлгерә алмый калды. Карательләр авылга берьюлы өч машина белән килеп керде. Аларга теге яшь чырайлы офицер — Фрайдорф колониясенең элеккеге агрономы җитәкчелек итә иде.

Кулга алынганнарны, клубка җыеп, ак стена буена тезеп бастырдылар. Офицер саф буенча бер баштан икенче башка әйләнеп узды да уң флангта басып торган Лели каршысына килеп туктады:

— Терлекне кая куйдыгыз? Амбарлар нигә буш? Ниһаять, авыл халкы кайда?

Лели гадәттәгечә тыныч тавыш белән җавап бирде:

— Халык таралышып бетте. Аларны тотып торып буламыни!

Офицер беравык Лелиның күзләренә текәлеп карап торды һәм камчысы белән селтәнеп:

— Кулга алырга! — дип боерды.

Аннары кара мыеклы Спаи каршына килеп басты:

— Партизанмы? Кулга алырга... Монысын да,— диде, камчысының очы белән Григорий Александровичның иңбашын куырып алып. Аннан соң, артка чигенеп, тын гына басып торган кешеләр сафын тагын бер кат күзеннән кичерде дә: — Боларын — атарга! — дип сүзен тәмамлады.

Кулга алынганнарны урман аша сузылган иске юл белән Кирмәнчек авылына таба куаладылар. Алар артында, авылда, автоматлар тыкылдавы, ачыргаланып кычкырган әче тавышлар яңгырап калды... Лаки ягыннан тау сыртларына таба куе төтен болыты күтәрелде, тирә-юньгә көйгән исе таралды...

Карсак, нәзек гәүдәле бухгалтер баһадирларча таза, озын Лели һәм Спаиның уртасында салмак кына атлап бара иде. Бераздан юл кырт уңга — Кирмәнчеккә таба борылды... Анда — комендатура, гестапо, полиция. Әнә, авылның көмеш айлы мәчет манарасы да күренә инде.

Карт, пышылдап, юлдашларына әйтте:

— Сезгә качарга кирәк, дуслар. Мин сакчыларның игътибарын үземә тартам, алар өчен үзенә күрә бер хушлашу концерты ачып җибәрәм, ә сез урманга, агачлар ышыгына китегез, ярыймы?..

— Ә сез Григорий Александрович? — дип пышылдады Лели, картның кулын кысып.

— Мин сездән күпкә өлкәнрәк; утеначемне кире какмагыз... Ахыр чиктә, мин моны сездән таләп итәм!

Юл түбән төшә башлады. Кинәт карт, алга ыргылып, җиргә ташланды да ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Ай, зинһар үтермәгез, үтермәгез мине... Үләсем килми, килми... Яшисем килә, яшисем...

Карт тәмам шашкан кешедәй җирдә ауный иде.

Конвойчылар, аптырап, туктадылар да картны аяклары белән типкәли башладылар. Спаи янәшәсендә нибары бер генә солдат торып калган, анысы да бөтен игътибарын җирдә чапаланып яткан бухгалтерга юнәлткән иде. Спаи солдатның корсагына берне тондырды да түбәнгә, агачлар арасына сикерде, ә Лели, ярдәмгә ашыккан икенче бер солдатны бәреп егып, Спаи артыннан ташланды.

Беренче пуля председательне яралады, икенче — Николайның кулын яндырып узды, ләкин алар, җәрәхәтләреннән шарлап кан агуына да карамыйча, һаман алга йөгерделәр. Ниһаять, шулай чабачаба Татар-ялга дигән тау итәгенә барып җителәр. Анда партизаннар посты тора иде.

Качакларны Македонский үзе каршы алды.

— Эшләр харап, командир...— диде Спаи, хәлне аңлатып.— Авылны яндырдылар, кулга эләккәннәрнең һәммәсен кырып салдылар, Григорий Александровичны да үтерделәр...

— Юк, аны үтермәделәр, алып киттеләр, дөресрәге — өстерәп киттеләр,— диде Лели, әчетеп сызлаган җәрәхәтен учы белән басып.

— Аны коткарырга кирәк, Михаил Андреевич,— дип ялынды Спаи.

— Дуся, яраларын бәйлә әле,— дип боерды Македонский.

Ул арада Спаи алга ыргылды.

— Ничек булса да коткарырга кирәк Григорий Александровичны!

Ләкин Македонский аны туктатып калды.

— Әлегә монда мин командир. Дуся, бәйлә яраларын. Суполкин, Бережной, Николайны тотып торыгыз!

Дуся — отрядта бер үк вакытта разведчик та, медсестра да, аш пешерүче дә, диверсантка да. Кайнар канлы кызый, шуның аркасында еш кына бәла-казага да эләккәли. Комиссар Черный семьясының немецлар тарафыннан юк ителүе турындагы хәбәр отрядка ишетелгәннән соң, Дусяның кайнарлануы бөтенләй чиктән аша башлаган иде. Әйтик, аны гади бер задание белән разведкага җибәрәләр. Ул анда бик күп нәрсә күреп-күзәтеп кайта. Ләкин кайтышлый нинди дә булса башбаштаклык эшләми калмый,— мәсәлән, берәр немецны сагалап тора да аның өстенә граната ташлап китә. Шуннан соң инде бөтен төбәктә ыгы-зыгы башлана!

Бу эшләре өчен комиссар аны берничә мәртәбә гафу итте, ләкин бик еш кабатлана башлагач, боерык бирде:

— Кухняга күчерергә, акылына утырганчы шунда эшләсен! — диде.

Кухняда Дуся әллә ни эш майтара алмады: әле боткасы көя, әле пешергәне кирәгеннән артык тозлы яки борычлы була,— нәтиҗәдә авызга да алмас бер нәрсәгә әйләнә...

Дусяның кухняда эшләвенә бигрәк тә разведчик Иван Иванович Суполкин — Бакчасарайдагы яшьлек дусты бик әрни иде. Булышырга вәгъдә итеп, ул бер мәртәбә комиссарның үзенә дә барды:

— Батыр кызый, бик сагышлана бит, җибәрегез инде шуны, Василий Ильич! — дип ялынды ул.

Ләкин комиссар: «Юк!» дип кырт кисте.

Дуся елады-елады да көннәрдән бер көнне кухнядагы бөтен савытны кырып ташлады:

— Әйдә, зур казаннан ашасыннар әле! — диде.

Дуся табигате белән гомере буе кемне дә булса багып-кызганып яшәргә яратылган кыз иде. Хәлсезрәк кешеләргә ул һәр вакыт ярдәм итәргә ашыга: «Кая, бераз үзем күтәреп барыйм»,— дип, аларның сумкаларын, автоматларын, пулемет дискыларын күтәрешә һәм бер вакытта да бу эшенә зарланмый иде.

Григорий Александрович отрядта нибары өч тәүлек булды. Шул вакыт эчендә Дуся аны бөтенләе белән үз канаты астына алып өлгерде. Елга-инешләр аша чыгарга кирәк булганда, ул хәлсез картны кочагына күтәреп ала да шундук икенче ярга чыгарып куя, үзе сукрана: «Шундый әйбәт кешеләрне харап итәләр бит, кабахәтләр!» — ди. «Кабахәтләр» дигәне кемдер — алла белсен!

Лели белән Спаиның җәрәхәтләрен бәйләгәч, Дуся, яшьле күзләрен сөртә-сөртә, Македонский каршына килеп басты.

— Ни кирәк?

— Рөхсәт ит, командир. Кирмәнчеккә барасы иде. Карт бик кызганыч.

— Ыгы-зыгы гына чыгарачаксың бит!

— Рөхсәт ит — башкача булдыра алмыйм!

— Анда сине таныйлармы?

— Берсе-бер танымый, ант менә!

— Тик кара аны! Белешеп кенә кайт, аңладыңмы?

— «Әһ» дигәнче кайтып та җитәм!

Кирмәнчек авылы Качи һәм Бельбек үзәнлеген аерып торган ике тау тезмәсенең бергә кушылган сыртлыгына утырган. Һәр ягы урман. Авылдан урманга таба әллә ничә юл сузылган. Офык читендә — мәһабәт Чатыр-даг. Борынгы крепость хәрабәләре — ярым җимерек таш стена — буеннан ул бигрәк тә ачык һәм матур булып күренә.

Шул стена буенда куллары бәйле өч кеше басып тора; болар — Лаки авылы крестьяннары, арадан берсе — Григорий Александрович.

Аларның кулларын чишеп, төрткәли-төрткәли, стенага тагы да якынрак китереп бастыралар.

Иртәнге дымлы һаваны ярып, залп яңгырый.

Дуся борынгы крепость хәрабәләренә таба җан-фәрманга чаба, әмма өлгерә алмый. Ул килеп җиткәндә инде жандармнар кире борылалар иде.

Дуся, куаклык арасына яшеренеп, жандармнарны уздырып җибәрә дә җимерек стенага якынлаша. Караса: анда карабинлы бер полицай йөренә. Дусяның күзләрендә усал очкыннар кабынып китә.

Әрле-бирле күпмедер вакыт йөренгәннән соң, полицай йокысы килгән кеше сыман авызын ачып иснәнә дә мәетләр яткан җирдән бер читтәрәк таш өстенә килеп утыра.

Дуся, күп уйлап тормастан, аңа таба шуыша. Арттан сиздермичә генә килеп, полицайның башына таш белән суга, аннары карабин түтәсе белән эшен бетерә...

Мәетләрнең икесен дә ул шунда күмә, ә Григорий Александровичның гәүдәсен җилкәсенә күтәреп отрядка алып кайта.

Лаки авылының иң аз сүзле, иң тыйнак кешесен — карт бухгалтер Григорий Александровичны партизаннар зурлап соңгы юлга озаттылар.

Македонский отряды Олы урманга кире кайтты. Ике ай буе партизаннар Лаки колхозыннан алган азык-төлек исәбенә яшәп сугыштылар. Николай Спаи үз җитәкчелегендә Лаки колхозчыларыннан сугышчан дружина оештырды. Озакламый бу дружинага, Спаиның булышлыгы белән, Дуся да күчерелде.

Спаи дружинасы сугышчан операцияләрне башлыча туган авыллары — немецлар тарафыннан яндырылган Лаки тирәсендә алып барды. Дуся разведкага йөрде. Аның бөтен уе карт бухгалтерны һәм аның иптәшләрен үтергән фашист җинаятьчеләренең эзенә төшү һәм алардан үч алу иде.

Кышкы салкын көннәрнең берендә Спаи үзенең кешеләрен Акбур тарлавыгы янындагы юл буена цепькә яткызды да, тагын бер кат ышану өчен, Дусядан сорады:

— Ялгышмадыңмы?

— Валлаһи минә — юк! Алар анда, Фоти-Салада, юлчы-мастерны үтергәннәр.

Шактый озак көттеләр. Юлдан бер-бер артлы машиналар, җигүле атлар уза. Салкын сөякләргә хәтле үткән — һәммәсенең теше-тешкә тими.

Ниһаять, Дуся, үрелә төшеп, еракта караеп күренгән һәм торган саен якыная-зурая барган кара ноктага текәлеп катты:

— Киләләр!..

Амфибия тибындагы машина иде бу.

— Шулар «кнехты», валлаһи!

— Акрынрак! — диде Спаи һәм гранаталар бәйләмен тотып, юлга тагы да якынрак шуышты.

Зур тизлек белән килгән машина борылыш ясыйм дигәндә генә граната шартлавыннан шып туктады һәм таркала башлады. Кузовыннан исә автомат тыкылдавы ишетелде.

— Кабахәтләр!.. Җиргә ятыгыз, туганнар! — дип кычкырды Дуся һәм кулындагы гранатасын машинага ыргытты, аннары, шуның артыннан ук, Шмейссер маркалы трофей автоматыннан тырылдатып алды.

Документларны, коралларны җыйнаштырып, тикшереп карагач, шулар ачыкланды: үлүчеләр арасында хәрби җинаятьчеләрдән фельдфебель Фестер һәм Фрайдорф агрономы офицер Клорнер фамилиясе дә бар иде.

## «Туариш[1] Тома»

Лаки колхозыннан алынган азык-төлек бетте. Трофей ат итенең дә соңгы калҗасына хәтле ашалды. Салкыннан тау агачлары бәскә төренде. Ачлык өстенә, Севастополь белән элемтә дә өзелде. Ашау җитмәү һәм дымлы салкыннан күп кеше авырып, яшерен лазарет-землянкаларга озатылды.

Дошман хәзер үзенең азык-төлек олауларын фронтка таулар аша түгел, бәлки әйләнгеч юллардан, самолет, танклар сагы астында күчерә иде.

Чын мәгънәсендә ачлык блокадасы!

Яралылар үлә бара. Сәламәт дигәннәре, язмышларыннан гаҗиз бер хәлдә, салкын шалашларда тилмереп утыралар. Иртәгә ни көтә аларны?

Әйе, иртәгә ни көтә? Партизаннарның Көньяк районы берләшмәсе командиры мин дә бу турыда уйлыйм.

Мин тәмам арыганмын. Коточкыч арыганмын. Салкын плащ-палатка эчендә, ничек җылынырга белмичә, газапланып ятам. Буыннар үтереп сызлый, аннан да бигрәк шомлы уйлар борчый... Кырым тулы немец полклары, румын хәрби бригадалары, төрле-төрле штаблар. Шәһәр базарларында шаулатып-гөрләтеп сәүдә итәләр, кофеханәләрдә көн-төн кәеф чигәләр. Кырымның көньяк яр буйларында инде кайнар кояш балкый — дошманнар шунда нәҗес тәннәрен кыздыралар...

Севастопольдә дә хәлләр кыен. Немецлар анда иң сугышчан гаскәрләрен туплаганнар, Германиядән никадәр гигант туплар китерт-

[1] Туариш (товарищ) — иптәш.

кәннәр. «Дәү Густав» дип аталган мондый тупның бер снаряды биш катлы таш йортны кузы чикләвегедәй шундук урталай яра, имеш.

Әйе, хәл бик кыен. Ләкин без тере, исән әле. Немецлар: «Кырым җирендә ике аякка да нык басып торабыз»,— дип шапырынсалар да, барыбер як-якларына каранып яшәргә мәҗбүрләр,— төнлә генә түгел, көндезен дә шулай! Без көрәшне дәвам иттерәбез. Хәтта үлгәндә дә аларны кыйнап үләбез. Минем кесәмдә Кызыл Армиянең партизаннар отряды командиры, элеккеге райком секретаре Әбләм Айдиновның рапорты ята. Менә нәрсә язган ул: «Егерме беренче март көне лейтенант Столяров җитәкчелегендәге группа Коуш-Бакчасарай юлында дошманның җиде тонналы хәрби машинасын шартлатты. Бер фашист офицеры һәм унбер солдат юк ителде, түбәндәге трофейлар кулга төште: өч автомат, бер пистолет һәм биш плащ-палатка. Отрядка кире кайту юлында ачыгудан сержант Коваленко үлде».

Уйлар эчендә әкрен генә йокымсырый башлаганмын...

Азмы, күпме йоклаганмындыр — белмим, кинәт мине кемдер төрткәләп уята.

— Македонскийдан элемтәчеләр килде,— ди вестовоем Семенов.

— Чакыр.

Мин Македонский янына чыгып киттем. Бер түбән төшәсең, бер югары менәсең — юл буе шулай. Сукмакның очы-кырые юк кебек. Үткән көзне мин бу сукмактан күп йөрдем, ул чакта миңа тигезрәк һәм кыскарак булып тоелган иде ул.

Семенов минем күзгә карап-карап куя.

— Туктап ял итик, иптәш командир,— ди.

— Туктасак, бөтән кузгала алмаячакмын. Әйдә атла! — дим.

Бу кадәр дә текә булыр икән! Мин суламыйм, ә һаваны ялкынсынган үпкәм белән ничектер эләктереп-йотып алам кебек.

Семенов гәүдәгә чандыр, җиңел сөякле. Ару дигәнне беләме, юкмы — аңламассың. Ачмы, тукмы ул, алдында текә таумы яки текә яр астымы — аңа барыбер, бөтенесен бертөрле кичерә. Үзе миңа ярдәм итәргә тырыша, ләкин бәйләнчекләнеп түгел,— ничектер, әдәп белән, җай белән тырыша.

Ниһаять, сукмак тигезләнә төште. Аннары көн ничектер караңгыланып киткәндәй булды — димәк, Олы урманга кергәнбез. Актык көчебезне биреп тагы бер мәртәбә талпынуга, без Македонский отрядына барып җиттек.

Мин иягемне капшап карыйм,— әйе, кырынмаганмын икән. Ярар инде, артык игътибар итмәсләр әле...

Македонский безне шат чырай белән каршылады:

— Здравия желаю, иптәш район командиры!

— Нәрсәгә шулай бик шатсың? — дим.

— Куанычлы хәбәрем бар.

— Алайса, тизрәк сөйлә, мине дә куандыр.

— Хәбәрем төгәлрәк булсын өчен, разведкадан Иван Иванович кайтканын көтик инде.

Македонскийны ачлык та сындыра алмаган шикелле — шул ук киң җилкә. Хәер, нидер бар: яңаклары суырылган, күз төпләренә авыру җыерчыклар чыккан.

— Ут капкандай, нәрсә шулай ашыгыч чакырдың? — дип ачуланган булам.

— Кырынып алырга иде сиңа, ә? — ди ул, ихлас бер теләктәшлек белән.

— Кайда, ничек? Чәчтараш ачмагансың бит?

— Тома Апостолны кая куясың?.. Чын тылсым иясе. Пәкесе дә шәп — Эккер пәкесе.

— Теге румынны әйтәсеңме?

— Әйе.

Тома — бик терчән, җитез хәрәкәтле, ярым румын, ярым грек егет — минем бит тиресен әйтерсең лә киергедә тарттыргандай тигезләде. Аның сумала исе аңкып торган бармаклары минем бит өстендә күз иярмәс тизлек белән йөри, суырылган яңакларны барабан суккандай массажлый иде. Сакалны сабынсыз кырса да, мин бернинди авырту сизмәдем,— киресенчә, рәхәтләнеп ярым йоклап утырдым.

Кырынып, юынып алгач һәм бераз ял иткәч, партизаннарның аерым-аерым группалары белән танышырга чыгып киттек.

Ачлык блокадасы монда да үзен нык сиздерә. Бакчасарайлылар менә икенче көн инде юкә бөресе һәм кычыткан белән генә җан асрыйлар икән. Яңаклары эчкә суырылган, күз төпләре шешенгән, әмма күз карашларында өметсезлек дип әйтердәй нәрсә юк. Македонский һәм комиссар Черный ачлык афәтен төрле юллар белән җиңәргә тырышканнар.

Ничек дисезме?

Иң мөһиме — тик ятмау... һәркем хәрәкәттә, эштә. Берәве разведкага җибәрелә, икенчесенә патруль хезмәте йөкләнә, өченчесе Мулга буена чирек бәрәңге җыярга чыгып китә. Дүртенчесе урманда ау белән кош-корт тота яки елгада балык каптыра. Бишенчесе исә болында кыргый сарымсак җыя...

Юкә бөресеннән пешерелгән ашны мин дә ашап карадым. Аңагы нәрсә өстәгән булганнардыр — белмим, әмма ул нинди дер крахмаллы ябышкак бер сыекчаны хәтерләтә иде.

Македонский мине шулай лагерь буенча йөртә-йөртә бүтән отрядлардагы хәлләр турында да сорашты: тагын күпме кешене партизанлык юлына тартырга мөмкин? Безнең күрше — Георгий Северский, мохтаҗлык туган очракта, үзенең сугышчан отрядлары белән ярдәмгә килә аламы, юкмы? Һәм башка шундый сораулар бирер йөдәтте.

— Сорауларыңа караганда, сине Бакчасарайны штурмларга җыена дип уйларсың,— дип төрттереп куйдым мин.

Македонский елтыр күзләрен яшерергә тырышты. Шул чакны ул Иван Суполкинны күреп алды да, эре-эре атлап, аңа таба китте; үзе артыннан мине дә ияртте.

— Я ничек, Иван?

— Әлегә шәп, он булырга тиеш.

— Тиешме, әллә бармы?

— Бар, бар, тик менә солдатларны гына күчерделәр.

— Шурагамы?

— Ауджикойга.

— Тьфү, котны алдың, шайтан. Тагын ниләр бар?

— Үзең белгәннән артык яңалык юк.

— Алайса, бар, ял ит.

Македонский үзалдына беравык уйланыбрак торды.

— Инде миңа сөйләсәң дә ярыйдыр, шәт,— дидем мин, түземсезләнеп.

— Бер четерекле эш уйлап йөрим әле мин.

— Я, сөйлә.

— Румыннар киеменә киенүгә бәйле эш...

— Нәрсә? — дидем мин каты итеп, үз колагыма үзем ышанмыйча.

Ул елларда без андый романтик кыланулардан бик ерак кешеләр идек... Немецның үз киеменә киенеп, алар арасында ниләрдер башкару — юк, монысы безнең кулдан килердәй эш түгел...

Македонский да минем шигемне сизенде булса кирәк:

— Авантюра дигән нәрсә юк, бөтенесе һәр яктан уйланган,— дип куйды.

— Нәрсәсе уйланган, ачыграк итеп сөйлә, юкса, сүзеңнең рәте юк!

— Безнең үз румыннарыбыз бар — бу бер! Тома Апостол үзе — ике! Инде взвод чамасы партизанны румын формасына киендерсәң — монысы өч була!

— Нинди үз румыннарыгыз ул? Тома Апостол нindирәк бәндә соң ул?

Тома Апостолның безнең отрядка килеп эләгүе шактый гыйбрәтле иде.

1942 елның кышында румын дивизияләре Севастопольгә һәм безгә — партизаннарга каршы, әйтергә мөмкин, көчләрен аямыйча сугыштылар. Бу вакытта румын офицерлары гына түгел, гади солдатлары да әле немецка ышана, аны үзенең «союзнигы» итеп саный иде. Газеталарда нindидер «Трансднестрия» дигән «румын территориясе» турында мәкаләләр басыла. Мәркәзе Одесса булган бу өлкәне «союзниклар», ягъни немецлар, бөтенләйгә «бөек юлбашчы Антонеску» хакимлегенә бирә икән дигән уйдырмалар нык таралган иде.

Шулай да, аерым алып караганда, румын солдаты безнең өчен немец солдатыннан күп өлеш куркынычсызрак дошман иде. Румын солдаты сугышта да, тормыш-көнкүрештә дә немец солдатыннан күпмедер дәрәҗәдә кыенрак хәлгә куелган: аны немецның үзенә ошамаган йортларга фатир кертәләр. Таланган байлыкның аңа нибары калдык-постыгы гына эләгә — кыскасы, барлык мәсьәләләрдә ул үги бала хәлендә иде. Ни өчен сугыша, нәрсә өчен чит-ят илдә үзенең гомерен корбан итәргә тиеш — ул моны рәтләп белми дә.

Румын офицерлары исә эчүгә сабышкан; бар белгәннәре — солдатларны кыйнау да җирле халыкны талау. Шуңа күрә гади солдат күбрәк үз-үзе белән мәшгуль: яшәү шартлары турында да, ашау турында да ул үзе кайгырта, җайлаша, алдаша, нинди дә булса берәр кәсеп белән шөгыльләнә иде.

Ефрейтор Тома Апостол да шундый солдатларның берсе була. Гомере буе ул чәч алып, сакал кырып яши. Дөньяның күпчелек парикмахерлары кебек, тәмләп-озаклап сөйләшергә ярата, хәтта үзенчә фәлсәфә сатарга да оста. Сугыш аның өчен бөтенләй чит-ят нәрсә. Карабин асып йөрсә дә, бу үлем коралына ул җирәнеп карый һәм аны гамәлдә кулланмас өчен үзендә булган бөтен тапкырлыгын эшкә җигә.

Лаки авылына ул румын квартирьерларының берсе сыйфатында килеп эләгә. Авыл белән танышуны тел камаштыргыч «сухой» аракыдан — кабернедан башлый һәм теге акшарлы капитан бөтен халык алдында Томаның турыдан-туры начальнигын — унтерны кыйнап ташлаганчыга хәтле туктаусыз эчә дә эчә. Капитаннан аның үзенә дә өлеш чыга, әлбәттә.

Шуннан соң ул капитанның күзенә эләкмәскә һәм тыштан тәртипле булып яшәргә тырыша. Күрәсең, очраклы бер туры килү булгандыр,— аны колхоз председателе Владимир Лелиның өенә фатир кертәләр.

Күзәтүчән, сизгер хуҗа үз фатирчысының нindирәк кеше икәнлеген шундук аңлап ала һәм аңардан файдалану әмәлләрен эзли башлый.

Лели аны ашата, эчертә, тәмам үз канаты астына сыендыра. Җитмәсә, Тома грек телен — Лелиның туган телен дә яхшы белә икән. Алар шулай икәүләшеп төннәр буе сөйләшергә гадәтләнеп киттеләр. Тома, тел бистәсе буларак, үзенең бөтен күргән-белгәннәрен сөйли. Ә ул Кырымның күп җирләрендә булган — Симферопольдә, Феодо-

сиядә, Ялтада, Бакчасарайда... Хәтере дә әйбәт. Бу мәгълүматларның партизаннар штабы өчен дә ярап куюы бар дип уйлый Лели...

Лели дөрес фикер йөрткән. Чыннан да, без бу вакыт Севастополь белән ашыгыч элемтә урнаштыруны кайгыртып йөри идек. Бу эштә исә дошман турында беренче кулдан мәгълүмат алу гаять кыйммәтле. Безне бигрәк тә Беренче румын корпусы, аның дислокациясе, тылы, кыр хезмәте кызыксындыра иде...

Көннәрдән бер көнне безнең штабка Македонскийдан пакет килеп төште. Пакетта Тома Апостол турында язма доклад ята иде. Без шундук: румынны кичекмәстән кулга төшерергә һәм район штабына китерергә дигән приказ җибәрдек.

Македонский, Лаки халкына шик төшмәсен өчен, бу эшне авылдан мөмкин кадәр читтәрәк башкарырга карар бирә. Операцияне үтәүчеләр итеп разведка башлыгы Михаил Самойленко һәм партизан Николай Спаи билгеләнә.

Бер көнне Лели, сүз ара сүз чыгарып, Апостолдан үзен Кирмәнчек авылына кадәр озатып куюын үтенә. Кунакчыл хуҗасына ихтирам йөзеннән, Тома бу үтенечкә риза да була.

Алар шулай икәүләп юлга чыгалар. Тома, гадәтенчә, юл буе такылдап бара...

Кинәт каршыга кара мыеклы бер кеше килгәне күренә. Тома, шикләнә калып, сүздән туктый, ләкин шундук тагын тынычлана: таныш кеше икән — авылда ул аны инде берничә мәртәбә күргәне бар. Өстәвенә, күз карашы да ничектер ягымлы, дустанә...

Кара мыек, туктап, Лели белән исәнләшә дә, күзләрен аяз, зәңгәр күккә төбәп:

— Шәп! — дип куя.

— Сулавы рәхәт,— ди Лели, узгынчының сүзен җепләп.

— Крим — во! — ди Тома да, баш бармагын күрсәтеп.

Спаи кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгара:

Тартып алабызмы әллә, солдат?

— Яхшы! — ди Тома һәм, карабинын Лелига тоттырып, үзе бик канәгать төстә тәмәке төрә башлый.

Төреп бетереп, кабызырга да өлгерми, агач арасыннан кораллы Михаил Самойленко килеп чыга.

Тома агарынып китә, шулай да, өйрәнелгән хәрби гадәтенә буйсынып, карабинын алырга ташлана.

Лели исә бирми, мылтыкны күкрәгенә кысып:

— Сиңа хәзер аның кирәге юк, солдат,— ди.

Тома тораташтай катып кала һәм тотлыгып:

— Ппарти...заан? — дип сорый.

— Шаулама,— дип җавап бирә аңа Самойленко. Томаның кесәләрен тенти, аннары Лелиның кулыннан карабинны ала да хушлаша башлый: — Эш бетте, Володя! Бар, өеңә кайт, ә безнең юл ерак әле,— ди.

Тәмам аптырашта калган Тома, ни эшләгәнен үзе дә аңламыйча, Лели артыннан ташланмакчы була, ләкин Самойленконың:

— Тукта! — дигән авазы аны янәдән җиргә кадаклап куйгандай итә. Куркудан ул хәтта телсез кала.

Николай Спаи юл буе ефрейторны тынычландырырга тырыша: сине бернишләтмәсләр, исән калырсың, ди, әмма Тома юатудан ашкан — хәтта грекчалап әйткәнне дә аңламый, фәкать куркудан акайган күзләре белән Самойленкога гына карангалап ала икән.

Берничә чакрым җир узгач, ул тәмам арый, мәлҗерәп төшә, шулай да арыганлыгын сиздермәскә тырыша — «домнуле» ачулана башлар дип шикләнә. Усал, кырыс кыяфәте Самойленконы (чынлыкта ул андый түгел, ифрат йомшак күңелле, миһербанлы бер кеше.

Моның шулай икәнен Самойленко белән күп аралашкан һәммә кеше белә иде) ул шулай «домнуле» — партизаннарның зур офицеры итеп кабул иткән була.

Үрмәли-үрмәли Кирмән-тауга күтәреләләр. Самойленко иңбашыннан карабинын сала да:

— Тамак ялгап алыйк булмаса,— ди.

Николай учак ягып җибәрә, котелокка салып ит җылыта, бер кирпеч ипине тигезләп өчкә бүлә.

— Әйдә утыр,— дип, Самойленко румынны да учак янына чакыра.

Тома аптыраган кыяфәттә баскан урынында таптанып тора.

— Я, кемгә әйтәм! — дип кабатлый Самойленко.

— Домнуле... офицер... Тома — сольдат...

— Бик телисең икән, бел, алайса: мин дә офицер түгел, ә иптәш командир. Чакырганда утыр әйдә, бер әйттем бит инде... Әллә ун тапкыр кабатлаганны көтәсеңме?!.

Тома, Самойленконың тавышында ниндидер йомшаклык сизеп, бераз тынычлана төшкәндәй була. Учак янына ятсынып кына килеп утыра да, елмаеп:

— Туариш... Тома — туариш...— ди.

— Кара син аны, тагын бер «иптәшкә» арттык лабаса,— дип, үз-алдына көлемсерәп куя Самойленко һәм румынга кашык суза:— Әйдә сыпырт, аша дим, ягъни!

...Алга таба киткән саен сукмак тарая бара. Арган юлчыларны яннан салкын җил камчылый. Тома Апостолның өстендә күксел соры җиңел куртка да башында юка берет кына була — ул тәмам күгәреп чыга, теше-тешкә бәрелеп шакылдый башлый.

— Безнең «тел» җан тәслим кылмагае,— дип борчылып куя Спаи.

Самойленко җилкәсеннән плащ-палаткасын сала да.

— Мә, киеп җибәр! — дип, Томага тоттыра.

Гаҗәпләнүдән Томаның күзләре шар була: «домнуле» өс киемен әсир солдатка биреп, үзе бер кат фуфайкадан калсын, имеш!

Сукмак Качага килеп җитә дә өзелә. Җәен Кача — чыпчык тәпиен дә чылата алмаслык дигәндәй сай бер инеш сыман. Аның каравы, кышын — ургылып, шаулап, күбекләр чәчрәтеп ага. Елга кичү тәҗрибәң булмаса, сине аяктан егып, агызып китәсен көт тә тор!

Бернинди басма-фәлән юк. Томаның коты алына. «Домнуле» Самойленконың шундый салкын җилдә өстен салып, анадан тума шәрә калуын күргәч, ул бөтенләй акылдан шаша. Ул да булмый, Самойленко румынга да:

— Чишен! — дип боера.

Тома, инде берни аңышмыйча, кулларын машиналь төстә хәрәкәтләндереп, өс-башын чишенә. Үзе шундый кечкенә, арык, ди, бары тик күзләре генә кыргый бер курку белдереп, зураеп карый икән.

Ташкынга аны Спаи төртеп төшерә. Бозлы су аның тәнен куырып ала. Томаның гәүдәсе, бөрешеп, тагы да кечерәеп калган сыман була.

Спаи аны, үзе артыннан өстерәп, теге як ярга күтәреп дигәндәй чыгарып куя. Аннары киемен алырга тагы кире йөзеп китә.

Самойленко исә, судан чыгуга, аяк бармакларыннан алып колак яфракларына кадәр бөтен тәнен учы белән ышкырга тотына һәм шуны ук Томага да эшләргә куша. Әмма тегенең кымшанырлык хәле дә юк икән: һәммәсенә бөтенләй дөньядан ваз кичкән кыяфәттә карап тик басып тора, ди...

Самойленко, ниһаять, хәлне төшенеп, кар өстенә плащ-палаткасын җәя дә румын ефрейторын шуңа сузып сала һәм аның суына башлаган тәнен үзе ышкырга керешә.

Әкренләп-әкренләп тәнгә җан керә. Тома бөтен гәүдәсе буйлап ниндидер рәхәт бер җылылык таралуын тоя һәм күзләрен ачып җи-

бэрэ. Каршында — «домнуле». Аның күз карашында бернинди куркыныч нәрсә юк. Һәм шул минутта румын парикмахерь күңел төбендә моңарчы беркайчан да кичермәгән яңа бер хис күтәрелүен ачык сизә.

Хәтеренә ни рәвешледер сеңеп калган барлы-юклы рус сүзләрен җыеп ул ихлас күңеле белән әйтеп куя:

— Гитлер — сволош, Антонеску — гав, гав!.. Я — туариш Тома Апостол[1].

Аңа бер-ике йотым спирт эчерәләр, тагы бер мәртәбә ашаталар.

— Ә хәзер марш! — дип боера Самойленко.

— Марш-марш, туариш Тома! — дип такылдый Апостол, «домнуле» белән бердәй атларга тырышып.

Ул инде «домнуле»дан бөтенләй курыкмый башлый.

Тома, күзәтүчән-сизгер кеше буларак, безнең штабка күп нәрсәләр сөйләп бирердәй «тел» иде. Чынлап та, аның сөйләгәннәре партизаннар хәрәкәте өчен генә түгел, гомумән бөтен Севастополь оборонасы өчен әһәмиятле булды.

«Ләкин аның үзе белән нишләргә?» — безнең башка менә шул кайгы төште. Ахырда, уйлый торгач, Бакчасарай отрядында калдырырга булдык. Николай Спаи аны яшертен генә күзәтеп торырга тиеш булды. Хәер, Спаи үзе аңардан һич шикләнми, аны безнең уртак эшебезгә турылыклы кеше итеп саный иде.

Бер вакыйга Апостолның бакчасарайлылар каршындагы абруен бигрәк тә күтәреп җибәрде.

Аучылар бер болан аталар. Итен алып кайту өчен ике кеше җибәрергә кирәк. Уйлыйлар, уйлыйлар да, комиссар Черныйның тәкъдимен хуплап, өлкән яшьтәге партизан Шмелев белән Апостолны җибәрәләр.

Болар, аучылар янына барып, итне җилкәләренә салалар да отрядка кайтырга чыгалар. Юлда Апостол, арып, иптәшеннән артта кала һәм урманда адаша. Шмелев отрядка ялгызы кайтып керә.

Димәк, качкан?

Комиссарның һич килешәсе килми:

— Кая китсен ул? Минемчә, ул безнең арада гына үзен чын кеше итеп сизә башлады.

— Анысын инде бер шайтан үзе генә белә торгандыр,— ди Михаил Самойленко. Ул, гомумән, һәр нәрсәгә шулай шикләнеп карарга гадәтләнгән.

Румынны бик озак эзлиләр. Николай Спаи тәмам борчылып бетә...

Ниһаять, икенче көнне кичкә таба ул бөтен отрядка ишетелерлек итеп сөрән сала:

— Томабыз кайтып килә, исән-имин!

Тома елап беткән. Җилкәсендәге болан боты аны бөтенләй хәлдән тайдырган. Шулай да йөкне ташламаган, тауларда үрмәли-үрмәли барырга туры килсә дә, кыйммәтле табышны отрядка алып кайтып җиткергән.

Кайткач, үзен аклап, һаман кабатлый:

— Туариш Тома качарга теләмәде,— ди икән.

1942 елның мартында ачлыкның иң кыен бер чорында, Севастопольне камаган дошман гаскәре сафларында кайбер үзгәрешләр сизелә башлады. Ахыры күренмәгән сугыш, ару, ачлыктан туган һәм әлегә румын частьларында гына ачык сизелгән бу үзгәрешләрне таркалу хәрәкәте дип исемләргә булыр иде.

[1] Гитлер — кабахәт, Антонеску — эт!.. Мин — иптәш Тома Апостол.

Фронт сызыгына якын авылларда румыннардан торган ниндидер вак-вак «командалар» ишәйде. Алар, төрле дәлилләр табып, авыл старосталарыннан азык-төлек, аракы, тәмәке таләп итәләр, кунарга сорыйлар иде. Баштарак аларны румын частьларының рәсми вәкилләре сымаграк кабул иттеләр, ләкин соңга таба һәммәсенең дә сукбай «командалар» икәнлеге ачыкланды. Немецлар аларны эзәрлекләү турында хәтта махсус приказ таратырга мәҗбүр булдылар.

Бервакыт Самойленко, нәүбәттәге разведкадан кайтышлый, партизаннар сукмагында бер төркем коралсыз румыннарны күреп ала.

— Болар яки бөтенләй акылдан язганнар, яки срогыннан элек тәңре каршына басарга телиләр,— дип пышылдап куя ул янәшәсендә атлаган Суполкинга.

Җайлы һәм ышык урын сайлап урнашалар да, тегеләр килеп җиткәч, Самойленко сукмак уртасына чыгып баса һәм:

— Руки вверх! — дип команда бирә.

Ә бу ике сүзне безнең ил туфрагына аяк баскан һәркем аңлый. Һәрхәлдә, румыннар карышып маташмыйлар — шундук кулларын күтәрәләр.

Кесәләрен тентеп, чалбар төймәләрен кисеп алалар да үзләренә тапшыралар (әсирнең чалбар төймәсен кисүне Иван Суполкин уйлап чыгарган).

— Кирәге чыккач тагарсыз! — янәсе.

Тома Апостол, якташларын күреп, чиксез шатлана, билгеле. Җитмәсә, алар аның полкташлары булып чыга. Ул шундук аларны, сакалларын кырып, кеше рәтенә кертә, үзе бертуктаусыз көлә, сөйләшә. Күрәсең, туган телен бик сагынган булгандыр.

Румыннарның партизаннарга юл эзләп барулары икән. Менә шул рәвешчә, бакчасарайлылар отрядында үзенә бер румын «берләшмәсе» барлыкка килде.

— Безнең кунаклар урман тирәли урнашкан гарнизоннар турында бик хәбәрдар булып чыктылар. Моның өстенә, алар башка нәрсәләр турында да шактый кызыклы мәгълүматлар бирделәр,— диде Македонский, сөйләвендә дәвам итеп.

Мәсәлән, Кача үзәнендәге Гура дигән авылда тегермән бар икән. Ул икенче румын дивизиясе частьларына он тарта, ди. Тегермән һичбер вакыт буш тормый, хәтта тартылган он да берничә көн алынмыйча ятарга мөмкин, ди. Дөрес, ул якларда румын солдатларының исәбе-чуты юк. Сак ягы да начардан түгел — һәрбер юлга, сукмакка пулемет көпшәсе карап тора, ди. Һәрхәлдә, штурмлап алып булмаячак!

— Алайса, ничек эшләмәкче буласың — уеңны әйтеп кара! — дидем мин, мәсьәләне кабыргасы белән куеп.

«Румын» ротасы төзеп, Шурага хәйлә белән, сугышсыз үтеп кермәкче булам. Шул рәвешчә тегермән янына үтәргә, аннары анда нишлисен күз күрер.

— Бөтенегезне кырып салырлар — шул булыр эшегез.

— Ни генә булса да, ачка үлүдән хәерлерәк,— диде Михаил Андреевич, ачуы килеп.

Мин уйга калдым. Моңарчы Македонскийның юкны бушка аударып маташканы юк иде әле. Ул җиде кат үлчәп эш йөртә торган кеше...

Шулай да тагы бер мәртәбә разведка ясап алырга булдык. Тегермәндә хәзерге көндә он яки тартылмаган бодай запасы бармы, юкмы? — моны һичшиксез ачыкларга кирәк иде.

Шурадагы тегермәнче хатыны янына хәлне белешеп кайтырга

киткән Дусяны ике тәүлек көттек. Тегермәнче хатыны Дусяның авыл мәктәбендә бергә укыган сабакташы булган.

Ниһаять, Дуся кайтып житте. Он бар икән. Румыннар үзләре вакытлыча җыелган терлек көтүе кебек: тирә-юньдәге бернәрсәгә дә гамьнәре юк, ди. Киләләр, китәләр. Отряд-отряд булып та, ялгыз да. Беркем бернинди документ тикшерми, ди. Дөрес, төнен сакчылар куела икән куелуын, ләкин артык уяулык күрсәтмиләр, ди.

— Ярар, башкар эшеңне, Македонский,— дидем мин, ризалык биреп.

Операциянең планын бергәләп эшләдек. Мин, отряд саен йөреп, унбиш-егерме чакрым җирне «эһ» тә итми үтәрдәй кыю егетләрне сайлап алдым. Северский белән очрашып, ярдәмгә Евпатория отрядыннан партизаннар китерту мәсьәләсен сөйләштем.

Хәзерлек эшен тиз, әмма җиренә җиткереп эшләргә тырыштык. Шура авылын өзлексез күзәтү астында тоттык. Әлбәттә, «румын подразделениесе» беркадәр борчу тудыра иде тудыруын. Аңа иң көчле дигәннәрне генә сайладык, ләкин партизаннар тышкы кыяфәтләре белән тылдагы тук румыннарны бик аз хәтерләтәләр иде, билгеле.

«Румыннар» белән җитәкчелек итү эше Тома Апостолга тапшырылды. Ләкин бу аның рәсми вазифасы гына иде. Асылда исә төп җаваплылык Иван Иванович җилкәсенә йөкләнде. Румыннар өчен дә, румын булып киенгән партизаннар өчен дә (бу киемнәрне без үзебездән һәм Северскийдан җыеп алган идек) бары ул гына җаваплы. Аның ярдәмчесе итеп Николай Спаи билгеләнде. Бер үк вакытта ул Тома Апостолның тәрҗемәчесе булып та йөрергә тиеш иде.

Ә Македонский белән Черный партизаннарның төп массасын әйләнеч юлдан тегермән урнашкан Кача елгасының аргы ягына — нарат урманына алып барырга тиешләр.

Шулай итеп, отрядлар юлга чыкты. Хәерле сәгатьтә!

Урман юлларын яхшы белүче Иван Иванович «румын» ротасын кыска юл белән Бишуй-Бакчасарай шоссесы кырыена китереп җиткерде дә, Спаи аша Апостолга: «Командалыкны үз кулыңа ал, безне шоссега алып чык!» — дип боерык бирде.

Шоссега чыктылар да атлап киттеләр — бер... ике, бер... ике! Алда, күзләрен очкынландырып, тәбәнәк буйлы «фельдфебель» Тома Апостол бара. Ролен менә дигән итеп башкара, румын телендә шартлатып командалар бирә.

Асфальт коры. Ара-тирә йөк төягән машиналар узып китә. Хәтта солдат төягәннәре дә очрый.

Каршыдан килгән бер машина «рота» алдында туктады да, кабинадан румын офицерының йөзе күренде. Тома гаскәриләрчә нык, төгәл адымнар белән машина янына килде һәм офицерга устав кушканча рапорт бирде.

— Кая юл тотасыз? — дип сорады офицер.

— Шурага, господин капитан.

— Нинди дурак җибәрде сезне анда?

— Полкның штаб начальнигы подполковник Видражку, господин капитан.

— Тинтәк баш! — дип сүгенеп куйды капитан һәм сәгатенә карады.— Ярый, барыгыз. Шурада төн кунарсыз, ә иртән бездән яңа боерык көтегез.

— Мин кем белән сөйләшәм, господин капитан?

— Дивизия командирының адъютанты белән.

— Баш өсте, господин капитан!

Машина китеп барды. Дулкынланудан маңгаена салкын тир бәреп чыккан Апостол офицер белән сөйләшкән сүзләрен Николай Спаи өчен грекчага тәрҗемә итте, ә Спаи шул ук сүзләрне Иван Иванович-

ка тылмач кылды. Суполкин куркаклардан түгел иде, хәлбуки, бу юлы ул да аркасы буйлап салкын кымырҗык йөгереп узуын сизде — аны операциянең өзелү ихтималы куркытты.

Кояш борынгы Чуфут-Кала хәрабәләре артына кереп яшеренде. Таулардан язгы кар һәм нарат исе сеңгән дымлы җил исеп куйды.

Бу инде партизаннар «көне» якынлашып килә дигән сүз иде. Эңгер-меңгер куеруга, Апостол командасы тагы да кыюрак атлап китте.

Менә авыл. Патрульләр соңга калып кайтып килгән якташларын дәшми генә уздырып җибәрделәр. Аның каравы, Тома командалар биргәндә юри җикеренеп-җикеренеп куйды — шуның белән ул әйтерсең үзенең тәмам арып, дөньясыннан туеп кайтып килгәнлеген һәм тыныч урында туйганчы бер йокларга ашыкканлыгын сиздерергә тели иде.

Менә шарлап төшкән су тавышы ишетелде, ут җемелдәде,— димәк, тегермән. «Рота» шул якка таба борылды. Кинәт караңгылык эченнән патруль командасы калкып чыкты. Папахалы озын румын Томадан нидер сораштыра башлады. Тегесе аңа кулын гына селкү һәм үз эшен дәвам иттерә: җикеренә-җикеренә, колоннадан арта калган «солдатларны» куалый иде.

Озын румынның сабыры төкәнде, ахрысы: автоматын күтәрә төште дә бер читтә басып торган солдатларына нидер боерып әйтте. Ул да булмады, Томаның карлыккан тавышы яңгырады:

— Кыйна!!!

Румын патрулен күз ачып йомган арада автоматтан кыеп салдылар.

«Рота» белән җитәкчелекне Иван Суполкин үз кулына алды.

— Сигнал бир! Тегермәнгә таба һөҗүмгә ташлан! — дип кычкырды ул.

Ыгы-зыгы, тәртипсез атыш башланды; еракта хәвефле командалар ишетелде. Үзәнлекнең һәр тарафында күккә сигнал ракеталары чөелде.

Македонский:

— Черный, һәммәсен минем арттан куала! — дип боерык бирде дә үзе кичүгә таба ташланды.

Аяклар тая, кешеләр йөгереп барган уңайга ташкын суга барып төшәләр, тончыгалар, пошкыралар, әмма алга барудан туктамыйлар иде. Кыска гына вакыт эчендә туксан кеше, елганы кичеп, кирәкле ярга чыгып өлгерде.

Тегермән эчендәге атыш тавышлары кинәт тынып калды,— анда инде Иван Суполкин хакимлек итә иде. Он тузаны каплаган идәндә исә мәетләр аунап ята...

Тегермәнче, әлеге Дусяга таныш хатынның ире, тыраклый-тыраклый, Иван Иванович тирәсендә бөтерелә һәм аңа нәрсәдер аңлатырга азаплана:

— Син, туң баш, аңлыйсыңмы: мин бит үз кеше ләбаса! — ди.— Ә син, тьфү! Шул хәтле куркыттың... Чак кына җанны алмадылар бит. Моны ничек аңларга, синеңчә?

— Үз кеше димсең? Ә кемнәргә тыкшынып йөрисең? Кемгә хезмәт итәсең, сатлык җан?!.— дип, җен ачуы белән аңа җикереп куйды Суполкин.

— Кемгә хезмәт итәсең, имеш... Ашарыңа булмаса, хезмәт тә итәрсең, җаныкаем...— дип мыгырданды да тегермәнче бер читкә юнәлде. Шул чакны ул Василий Ильич Черныйны күреп алды: — Иптәш райком секретаре! Нишләргә соң миңа хәзер? Фрицлар тереләй эчәкләремне тураклаячак бит, валлаһи менә, тураклаячак...

— Белмим инде, нишләтергәдер сине...

— Үзегезгә алыгыз, урманга. Юкса, мин кая барыйм?

— Ярар, ә хәзергә әйдә мондагы механизмнарыңны бозып ташла.

— Анысын мин аның бик тиз эшлим,— дияргә ашыкты тегермәнче.

Тегермәнгә зур бер төркем партизаннар белән Македонский атылып керде.

— Эшләр ничек, Ванюша?

— Он бар, Михаил Андреевич... Тик менә ике егетне генә югалттык.

— Үзебезгә алып кайтып күмәрбез,— диде Македонский, аннары, боерык көтеп басып торган партизаннарга таба борылып, әмер бирде:— Төянегез дә, тиз генә ычкынабыз: бер аягыгыз монда, икенчесе елга аръягында булсын! Ә син, Иван, кара аны, операциянең тыныч узуын тәэмин ит.

— Тырышырмын, иптәш командир!

Партизаннар елга аша бер саф булып янәшә тезелешеп бастылар. Иң көчле дигәннәре уртага, су эченә басты. Шушы җанлы чылбыр буенча он капчыклары кыска вакыт эчендә елганың теге ягына күчереләп бетте...

Шул чак авыл чатыннан бер машина атылып чыкты, аның артыннан — икенчесе... Фаралары белән тегермән бинасын яктыртып, солдатлар цепькә яттылар да ут ачтылар.

— Ванюша! — дип эндәште Македонский, Суполкинны кочагына алып.— Дошманны тоткарларга кирәк. Операциянең финалы синең кулда... Иң әйбәт егетләрне ал да эшкә тотын. Кимендә биш минут тоткарлап тор, аннары маневрлар ясый-ясый чигә башла һәм карательләрне үз артыңнан ияртеп кит.

— Булды, шулай эшләрмен!

Бу эш Суполкинга да, аның командасына да бик кыенга туры килде. Һөҗүмне кире кайтара-кайтара, алар елга ярыннан Бакчасарайга таба чигенә бардылар. Ара-тирә дошман белән йөзгә-йөз килеп тә якалаштылар. Әлбәттә, корбансыз булмады. «Төймәсез» румыннар командасыннан шактый кеше үлде, бакчасарайлылардан да икәве сугыш кырында ятып калды. Иван Суполкин фәкать таң атканда гына карательләр эзәрлекләвеннән котылды. Партизаннар төбәгенә ул әйләнгеч юллар белән, бик соң кайтып җитте. Араларында дүрт партизан каты яраланган иде.

Македонский исә, сугыш кырыннан ишетелгән тавышларга борчулы бер төстә колак салып, авыр йөк күтәргән егетләре белән бергә тауларга карап юл тотты.

Ончылар эзе Олы урманга илтә иде. Иртәгесен карательләр шул эз белән партизаннарның оясына барып чыкмакчы булып карадылар. Әмма урман эченә кергәч тә, юл сукмакларга тармаклана, ә ончылар эзе, шул сукмаклар буенча таралып, юкка чыга бара иде.

Трофей он барлык партизан отрядларына озатылды... Кырым урманнарында бу «он операциясен» әле бик озак хәтергә төшереп сөйләделәр. Тома Апостол шушы операция аркасында легендар бер шәхескә әверелде. Отрядта ул, менә мин кем! дигән сыман, күкрәген киереп йөри башлады. Күңелендәге шатлык хисләрен кая куярга белмичә, хәтта Дусяга гашыйк булды. Дуся аңардан бер башка озын, җилкәләре дә анықыннан бермә-бер киңрәк иде. Шулай булса да, Тома кызны ихлас күңелдән ярата, көн саен диярлек аңа беренче язгы чәчәкләр — миләүшәләр ташый иде.

*(Дәвамы бар.)*

**Р. ДАУТОВ тәрҗемәсе.**

------------

# Роберт Әхмәтҗанов

## Чал платан төбендә

Чал платан төбендә дә — кояш.

Искә төшә
иген кырлары,
иртәнге җырлар,
яшел таулардагы җил,
ак карлар!

Су кебек шаулап ага җил
яфрак арасыннан,
яфраклары — яшел карлыгачлар.
Ишетелә сыман тормыш агышы,
алтын башаклар шавы,
җигүле атлар...

Шау кояшта утыра агачлар!
Чал платан төбендә дә — көз.
Утыра шунда бер карт — нәкъ Мәрҗани!
Бирелә гүя гыйлем мәгарәсе...

Чал платан — манма кояш!
Җиһан каршысында
алтын таҗын киеп шаулап тора,
һәр яфрагы —
гомер шәҗәрәсе!

Чал платан төбендә дә — җил...
чал платан төбендә дә — туфрак.

Чал платан төбендә дә — Ил!

●

(«ЯКТЫ ЮРАУЛАР» ЦИКЛЫННАН)

— Төштә бүген ак ат чапты.
— Ә мин төштә су күрдем.

1

Еллар аязуга булсын, —
ап-ак балык сикерде!

2

Сугыш алдыннан төшендә
ниләр күргән икән ул?

Офыккача су күргәндер,
юл төшедер,
су ул — юл.

Очкан кошлар күрде микән,
суга төшкән кошлармы?
Төшенә җил керде микән,
иеп агач башларын?

Кошлар күрсәң — кавышуга, ди, —
әллә юрый белмәдең, —
күк тулы кошлар күрсәм дә,
юравым юш килмәде,
юравым юш килмәде!..
Юраганың юш килмәгәч,
инде нигә юрасын?
Кызыл елга, кызыл дәрья —
Офыккача су да су!..

3

...43 — күмелде суга,
44 — күмелде суга...
дошман сугыш ачуга,
суга китте — балалар,
суга китте — еллар...
тирәнгә китте — яралар,
төпкә китте — алар!..

Бары бер кояш калды.
Бер кояш һәм ул —
Ана!

Түшәгендә уяна,
уфтана да куана...
Чал кояшка карый-карый,
төшләр юрап
юана...

●

Сине нинди җилләрдән сакларга,
араларга давыллардан,
якларга нинди кайгылардан,
ут-күздән, кыен сүздән?

Бу ояда
синә да канат чыгар тиздән.

Ничек сине сакларга,
тидермичә ятлардан?
Китәсең кереп күк асларына —
тере нокта!
Ничек сине сакларга
шушы олы дөньяда?

Син — бөҗәк түгел
керергә яфрак астына.
Син — балык түгел
посарга
дулкын арасына.
Син — киек түгел
күмелергә урманнарга.

Син — кояш астында!

Заманага — туры!
Ничек кенә сакларга
җырлы йөрәгеңне
кыраулардан,
нәни кешем!

## Җәяүле күбәләк

Безнең сагыну шундый —
ашкынабыз җир үзәге булган төбәккә
йөрәгебез
болытларга тигәләп!

Ә түбәндә,
таулар, урманнар артына
чакрымнар аша
җилне җиңеп, җилфер-җилфер килеп,
кайта
бер күбәләк!
Кайта! Болытлар астыннан,
давыл сукмагыннан,
каршысына урманнардан
сибелә сары яфрак —
сары күбәләкләр күч-күч
ятып кала кырда.
Ә бу кайта! —
җанлы сары яфрак төсле
җил-җил килеп,
калтырап!

Колакларда саубуллашу җыры.
Әллә инде кыска җәен эзләп,
ашыккан кешедәй, очына-талпына
кайта!
Җәйге болыннарның җаны —
җәяүле күбәләк.

●

Улым, көзнең бу китабын
саклап кына актар.
Чаганнардан сибелә яфрак —
сары көздән хатлар...

Эчтән балкып янып тора
безнең якты чатлар!..

Улым,
минем ерак җәемдә
күбәләкләр очып йөри,
сикерә агач атлар!..

## Иделгә ялвару

1

Җанымны җыр итә
ягымлы җилләрең!
Күңелле көннәрем —
Иделле көннәрем!

Тугайлы таңнарым,
дулкынлы чакларым,
бирегез күңелгә
хисләрнең сафларын;

уйларга — яктылык,
күңелгә — тирәнлек, —
яшәеш ярында
шул безнең берәмлек.

Кыен ла бу үсеш —
сабырлык бир, Идел.
Гүя мин мәҗүси:
табынам — бер Идел!..

Бер, Идел, бир, Идел,
син моны аңларлык:
хыялга — иркенлек,
җырларга — кайнарлык!

Шигырьгә — җегәрлек,
җаныма — җылылык,
таңыма — зәңгәрлек,
аңыма — олылык;

каныма — кыюлык,
өметемә — хәрәкәт,
илемә — иминлек,
җиремә — бәрәкәт!

Ярыңда бер минме —
бөгелгән дәү ирләр.
Фатиха сораган —
баш игән дәверләр!

Биралсаң, бир идең
аз гына... сабырлык,
офыктан-офыкка
тын гына агарлык!

Көннәрне-көннәргә,
хыялны-хыялга,
өметне-өметкә
бер җепкә ялгарлык!

Бер, Идел,
бир, Идел!
Син, кинәт чалланып,
«Коткар!» дип, күземә
карыйсың ялварып...

2

Син — кеше, телең бар,
син — көчле, арала.
Ярларым агара,
суларым карала!

Сезгә дип ачтым бит
сандыгым, серләрем...
Туганнан юам мин
илемнең керләрен...

Ярасын юам мин,
күтәрәм йөкләрен...
Тик нигә аталар
йөземә чүпләрен?

Мин агам, мин китәм,
кай ярда каласың,
кай ярда каласың,
табигать баласы?

Син җавап эзлисең,
суларда карашың.
Үзеңдә үзең тап
коткару чарасын.

Ярларым агара,
суларым карала.
Син — кеше, син көчле, —
язмыштан
арала!..

## Машук итәгендә уйлану

Күксел төтен Машук иңнәрендә —
болытларның тузгый төркеме...
Яңа гына әле таралгандай
пистолетның аксыл төтене.

Кайның урман яшел диңгез сыман,
ак болытлар сарыла Машукка...
Атылмаган янар таулар тора —
шигырь диеп, каләм, ашыкма!

Атылмаган янар таулар тора,
әйтелмәгән нәфрәт сыманнар.
Секундантлар, әйтегез, — күк астына
кешеләр түгел, таулар сыйганнар!

Даһилардан калган шушы таулар!
Болытларның тузгый төркеме,
Яңа гына әле таралгандай
пистолетның аксыл төтене!

Секундантлар, заман үзгә дә бит —
туры килә кайчак авырга:
Дуслар кайда? Ачык дошман да юк —
дуслар микән бәрә бавырга?

Пистолет юк. Йодрык бетә бара —
матурлыкка күңел күнеккән!
Машук итәгенә терәр дошман
әллә кайчан инде дөмеккән!
Ә нәфрәт бар!
Лермонтовлар заманында туган,
ә нәфрәт бар —
килә электән!

Бүген дә бит әле яшәп була
почмакларда гайбәт сатышып.
Вак интриган күзгә карап көлә —
ак перчаткаң! —
булмый атышып...

Бар да дуслар!
Җыелып шул тауларга
су эчәбез кайнар чишмәдән.
Бер кояшка карап төчкерәбез
түгелергә торган хисләрдән...
Юынабыз таулар суы белән, —
таулар суы йөзне пакьласын.
Тик намусны гына булмый юып,
булмый юып —
Тик бер таплансын...

Сыеп була, әйе, күк астына
кешеләр түгел, таулар сыйганнар...
Атылмаган янар таулар тора —
әйтелмәгән нәфрәт сыманнар!

## Хисап көннәре

Хисап көнене
вакыт җиткәнен
тоярга вакыт!
Көннәрне туктек,
елларны чәчтек, —
җыярга вакыт!

Кояш кыекта —
иркә чак үткән,
торырга вакыт.
Хисләрне иктек
антларны чәчтек, —
урырга вакыт!

Төпкә җигелеп,
сабанда күптән
сайрарга вакыт.
Сүзләрне әллә
җилгәме сиптек,
нинди моң үсә —
сайларга вакыт!

## Кабатлануларга мәдхия

Көннәрнең — көннәрдә,
гөлләрнең — гөлләрдә,
җилләрнең — җилләрдә
кабатлануы!

Хисләрнең — хисләрдә, кичләрнең — кичләрдә,
яшьлекнең — яшьлектә
кабат януы!
Кояшның — офыкта, яңгырның — болытта,
минутның — минутта
кабатлануы!

Күңелнең — күңелдә, язларның — язларда,
назларның — назларда
канатлануы!

Таңнарның — таңнарда, эңгернең — эңгердә,
гомернең — гомердә
кабатлануы!

Елларның — елларга, елганың — елгага,
тармакның — тармакка тармаклануы!
Тормышның — тормышта, сулышның — сулышта
тумыштан-тумышка
канатлануы!

1974—75.

# САЛИХ БАТТАЛГА 70 ЯШЬ



Хөрмәтле Салих ага!

1924 елда «Эшче» газетасында басылган беренче шигырегез белән башлап җибәргән иҗат юлыгыз бай һәм күпьяклы булды. Сез әдәбиятның төрле жанрларында 50 елдан артык эшләп, шигырь, драма, комедия, роман, повесть һәм очерклар, балалар өчен әсәрләр яздыгыз.

20 нче еллар уртасында завод-фабрикаларда, совхоз кырларында эшләдегез. Гади эш кешеләре белән якыннан аралашу, аларның эчке дөньяларын якыннан белү Сезне иҗат дөньясына килергә дәртләндерде. Иҗатыгызның беренче чорында күп кенә шигырьләр язып, гади хезмәт кешесенә дан җырладыгыз.

1927 елда үз теләгегез белән РККАның Хәрби-һава көчләре сафларына киттегез һәм, очучылар хәзерли торган курсларны тәмамлап, курку белмәс очучы булып хезмәт иттегез. Илебезнең зәңгәр күкләрен иңләп очу Сезнең иҗат дәртегезне илһамландырды, үзегезнең күп кенә шигырьләрегездә очучыларның ялкынлы хисләрен җырладыгыз һәм очучы-шагыйрь булып танылдыгыз. 1934 елда Сез СССР Язучылар союзы членлыгына алындыгыз. Шул елларда тамашачылар тарафыннан җылы каршыланган «Язулы яулык», «Сынау» исемле пьесаларыгыз Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды.

1935—36 елларда проза жанрында актив эшләп, күп кенә хикәяләр, очерклар, «Очучылар» исемле роман яздыгыз.

Бөек Ватан сугышы елларында Тын океан Хәрби-һава көчләре частьларында хезмәт иттегез.

Авыр сугыш елларында халкыбыз күрсәткән батырлыклар турында күп кенә шигъри әсәрләр иҗат иттегез. «Капитан Гастелло» исемендәге поэмагызда Сез совет кешеләренең Ватанга бирелгәнлекләрен, зур каһарманлыклар күрсәтергә сәләтле икәнлеген тасвирладыгыз.

Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, Сез яңа дәрт белән иҗат эшегезне дәвам иттегез, «Олы юл буйлап» исемле зур күләмле әсәрегезне яздыгыз. Шигырь белән язылган бу повесть Сезнең иҗатыгызда үзенә бер урын алып тора. Бу әсәрдә Газзә кебек матур образлар, колхоз авылындагы күркәм кешеләрнең җанлы портретлары бар. Авыл хезмәт ияләренең совет җәмгыяте шартларында тормыш, көнкүреш һәм

әхлаклары тамырыннан үзгәрүгә багышланган әсәр рус телендә дә басылып чыкты.

«Чирмешән якларында» исемле шигъри романыгызны да укучылар яратып кабул иттеләр.

Күптән түгел Мәскәүдә «Советская Россия» нәшриятында «Сигезенчесе кем?» исемле повестегыз рус телендә басылып чыкты.

Хөрмәтле Салих ага! Җитмеш яшегез тулу уңае белән, Сезне кайнар котлыйбыз, озын гомер, ныклы сәламәтлек, бәхет телибез. Иҗатыгызның беренче чорында язылган шигырьләрегезнең берсендә:

Тибә генә түгел, җырлый йөрәк,
Җырлыймын мин кушылып моторга,
Очам кебек күктән җирем сөеп,
Матур җырлар алып кайтырга,

— дип дулкынланып җырлаган әдипнең әдәбият сөюче дусларыбызга тирән эчтәлекле, югары идея-художестволы яңа әсәрләр бүләк итүенә өметләнәбез!..

Татарстан язучылар союзы идарәсе,
«Казан утлары» журналы редколлегиясе.

## Салих Баттал

### Яшәү мәгънәсе

Яшәү ни ул? Бу турыда
Ни әйткән әле Тукай? —
«Ялыкмый һәм ял итмичә
Тырышмак...» дигән бугай.

Гете әйтә — син ия, ди, —
Гомер итү хакына,
Әгәр аның һәрбер көнен
Сугышып алсаң гына.

Яшәү ни ул? — Үз бәясен
Бирә моңа һәр күңел.
Һәрхәлдә, яшәү — борынгы,
Модалы нәрсә түгел.

Нидә мәгънәсе яшәүнең?
Җавап бар минем дә бер —
Һәркемнең тоткан урнында
Һәм туган илендәдер...

Әйе, уен түгел яшәү.
Шушындый чаклар була —
Күз йомасың — йокы алмый,
Ачасың — кошмар була.

Җебеми совет кешесе
Тик читен хәлгә калып,
Суга әврелдереп булмый
Утны чиләккә салып.

Чакма чаккан саен ничек
Чаткы бөркелеп тора,
Йөрәк типкән саен шулай
Җырларым көлеп туа.

Туктамый гөрләп үсә ил! —
Тамырларында аның
Бәхете өчен минем дә
Саркытып биргән каным...

●

Бөек Ватан сугышында
елгалап кан акканда,
ә без Ерак Көнчыгышта
резервта чакларда

борчак кадәрле бер төер
чыккан иде башыма,
ярдылар чәчемне кырып,
китереп бар шартына.

Врачның осталыгын мин
шунда мактаган идем,
ул да телгә алып үтте
зур чыдамлыкны минем.

Бик әдәпле сөйләшсәк тә,
саф булса да күңелебез,
мыскыллаган кебек сиздек
беребезне беребез.

# САФА САБИРОВКА 60 ЯШЬ



Язучының биографиясендә һәр вакыт иҗатына баштанаяк юнәлеш салган бер чоры була. Сафа Сабировның бу чоры бик үзенчәлекле елгачылык хезмәтенә бәйләнгән. Башта Казан елга техникумында уку, аннары Тын океан Хәрби-диңгез флотында хезмәт итү, 1946 нчы елны демобилизацияләнгәч, Идел йөк пароходчылыгында эшләү — 60 яшьнең нәкъ егерме елы шунда торып калган. Ләкин бу заяга үткән еллар түгел. Киресенчә, Сафа Сабировка ул дөнья материалы бирә. Язучы шул материалы белән әдәбиятка килә, елгачылык эшеннән аерылса да, Иделеннән аерылмый. Чыккан китапларының исеменә генә күз ташлыйк: «Яшь моряклар», «Дүрт елга буйлап», «Зур Идел туганда», «Идел чакыра», «Идел таңнары», «Су естендә акчарлак», «Кайнар агым» һ. б.

Сафа Сабиров бу бөек елганың бөтен холкын белеп яза. Идел әле ул матурлыгы белән күзне иркәләп, карап торыр өчен генә яралмаган; аның өстендә һәлакәтле давыл уйнаган чаклар да еш була. Шуның кебек, Иделдә яшәгән һәм эшләгән кешеләр дә гел романтиклар гына түгел, алар — кырыс та, авыр да хезмәт кешеләре. Капитанмы ул, лоцманмы, маякчымы, кранчымы — һәркайсының катлаулы холкы бар; күңелләре Иделдәй киң булса да, кирәк чакны кырыслыклары да җитәрлек. Сафа Сабиров аларның холкын, тормышын яхшы белә. Шуңа күрә хикәяләрендәге геройлар ышандыра да.

Сафа Сабиров — баштанаяк хикәяче. Хикәяләренең һәркайсы кыска, композицион төзек. Минемчә, моның сәбәбе төп профессиягә барып бәйләнә. Диңгез дә, Идел дә сүлпәнлекне яратмый — анда төгәл кул, тәвәккәл йөрәк, тиз хәл итә торган баш кирәк. Шуңа күрә Сафа Сабировның хикәяләре, елгачылар турында язылуы өстенә, шуларга хас төгәллек белән эшләнә дә. Гомумән, шундый хакыйкать бар: язу эшенә кадәр башка бер һөнәрне камил белгән язучы үз әсәрләрен дә шул камиллек белән язарга омтыла, чөнки камиллек тойгысы инде аның зиһенenә кергән була.

Әлбәттә, тавыштан башка көй, буяудан башка сурәт булмаган кебек, сүздән башка әдәбият та юк. Сафа Сабиров сүзгә саран: ул чуклы-чачаклы җөмләләр язмас, берәр матур сүз я тәгъбир табып, аны чееп-иркәләп уйнамас; аның теле төгәл һәм саллы. Бу урында әдәби тел остасы, хикәяче Әмирхан Еники менә нәрсә диган иде:

«Аның үз материалы, үз теле, үз стиле бар. Гомумән, Саба Сабиров иҗатына яхшы мәгънәдәге гадилек, табигыйлек, сүзнең кадерен белеп язу, кешеләрне һәм вакыйгаларны ничек тә тормышчан, ышандырырлык итәргә тырышу бик хас нәрсә», ди ул («Казан утлары», 1969, № 6).

60 яшь ул йөгереп кенә үтәр гомер түгел. Бу инде ирләрнең дә күбесе өчен «эшлисен эшләдем» дигән сүз. Ләкин язучы алтмышка җитү белән: «Җитте!» дип каләмен куя алмый — аның җитмештә дә, сиксәндә дә йөрәгендә ут, кулында каләм булыр. Сафа Сабиров үзенең юбилеен Кәмада гравий чыгаручылар тормышын сурәтләгән «Яз юлдашлары» дигән әсәрен язып каршылады. Андый әсәрләр моннан соң да язылыр дип өметләнәбез, каләмдәшебезгә иҗат шатлыклары телибез.

**Татарстан язучылар союзы идарәсе,**
**«Казан утлары» журналы.**

## Сафа Сабиров

# КАР АСТЫНДА КАЛГАН ЭЗЛӘР

ХИКӘЯ



Автобустан төшеп чаңгыларын кигәч, Шакир Рәхимович үзен кинәт җиңеләеп, егетләрчә яшәреп киткән кебек хис итте, базык гәүдәсен турайтыбрак басты, рәхәтләнеп салкынча саф һава сулады. Аннары, үзеннән бераз арттарак әле һаман чаңгыларын ныгытып бетермәгән Хәдичә ханымга борылып карамыйча гына:

— Нәрсә син анда, буласыңмы инде?.. Ярый, мин атлый торам, куып җитәрсең,— дип китеп барды.

Озакламый ул куе урман эченә барып керде. Ботакларын кар баскан наратлар, урман авазларын тыңлаган сыман, тынып калганнар. Төнге кырпак кар төшкән йомшак чаңгы эзе, бәхет вәгъдә иткәндәй, алга ашыктыра, күңелне җилкетә һәм әллә кайда басылып яткан хисләрне уята иде...

Наратлар арасыннан бара торгач, Шакир Рәхимович ачыклыкка килеп чыкты һәм түгәрәк алан уртасында матур булып үсеп утырган пар каенны күреп, якын танышын очраткандай, кинәт гаҗәпкә калды. Башта ничектер ышанмады, ул түгелдер, шулай күренә генәдер дип уйлады. Әмма үзе баскан җирендә бер мәл тын да алмыйча хәйран калып карап тора бирде һәм үзәк өзгеч әрнүле дә, шатлыклы да тавыш белән:

— Шул ич, безнең алан, безнең пар каен ич...— дип әйтеп куйды.— Кара син аны, танырлык та түгел, нинди матур булып үсеп җиткән...

Түгәрәк алан уртасында бер-берсенә сыенып үскән бу пар каен чынлап та искиткеч матур иде. Шәм кебек төз кәүсәләре аяз күккә таба үрелгән. Як-якка салынып-салынып торган тармакларында бәс энҗеләре җемелди. Бу минутта алар, үзләре генә белгән истәлекләргә талган кебек, тып-тын торалар иде.

Шакир Рәхимович бу түгәрәк аланны, бу пар каенны бик яхшы хәтерли. Монда беренче тапкыр килгән көн аның күңелендә онытылмас истәлек булып саклана.

...Гәрчә ул чакны хәзерге кебек салкын кыш түгел иде. Матур җәй уртасы, эштән бушагач шәһәр халкы урманга, су буйларына агылган вакыт иде. Шундый матур ял көннәренең берсендә затон яшьләре автобуска утырып Идел буена Аргы тугайга чыктылар. Барысы да бәйрәмчә киенгән. Күңелләр күтәренке. Берсеннән-берсе тапкыр сүзләр явып тора. Автобус кузгалып китү белән, берсе баян сыздырып җибәрде, башкалары дәррәү кушылып җырлый башладылар.

Шакир Рәхимовичның күптән түгел генә баш инженер булып күтәрелгән, кар кебек ап-ак китель җиңнәренә әлерәк кенә сары ука тасма тагып йөри башлаган чагы иде. Начальник кешегә килешмәс дип, үзе шундук җырга кушылырга арусынмады, авыз эченнән генә көйләп барды. Ул күбрәк бүтәннәр җырлаганны, бигрәк тә үзе белән янәшә утырган кызның җырлавын тыңлады һәм беренче тапкыр күргәндәй гаҗәпкә калды... Узган җыелышта яшьләргә юл бирелми дип Шакир Рәхимовичка иң нык бәйләнүче шушы кыз булды бит. Ул чакны аңа Зөлфия бер дә ошамаган, усал кайнана кебек, бик тә сөйкемсез күренгән иде.

Кара син аны, нинди моңлы җырлый икән! Шакир аның пешкән чия төсле алсу иреннәренә, зур кара күзләренә онытылып карап барды. «Бу кыз бездә конструкторлар бюросында эшли бит. Моңарчы мин аның шундый гүзәллеген ничек күрмәдем икән?!» — дип бик гаҗәпләнде һәм аңар ияреп, ирексездән үзе дә җырлый башлады.

Алар юл буе үз моңнарына үзләре дулкынланып җырлап бардылар. Шул уртак җыр, уртак моң аларның күңелләрен берберсенә тоташтырган җеп кебек булды, араларын якынайткан кебек итте.

Аргы тугайда алар су керделәр, кояшта кызындылар, урманга кереп бөрлегән җыйдылар. Шакир белән Зөлфия гел бер тирәдә булдылар һәм, шулай бергә йөри торгач, менә шушы түгәрәк аланга килеп юлыктылар.

Куе урман эченнән чыккангамы, яшел алан аларга бигрәк тә якты булып күренде. Бөтен тирә-юньне соклангыч тавышлары белән тутырып кошлар сайрый. Чәчәктән-чәчәккә кунып умарта кортлары бал җыя. Иң уртада әйләнә-тирәгә ямь биреп зифа куш каен үсеп тора иде. Зөлфия аларны күрү белән:

— Карагыз әле бу пар каенны!.. Нинди матурлар... Әйдәгез, кайсыбыз шунда тизрәк барып җитә...— дип, куе үлән ерып, алан уртасына таба йөгерде.

Шакир да бар көченә шунда чапты һәм каен төбендә күтмәгәндә нәрсәгәдер абынган Зөлфияне, егылмасын дип, ихтыярсыз иңеннән кочаклап алды. Кызның бит урталары алсуланган, йомры күкрәкләре сулыш алган саен калкып-калкып куя, маңгаена таралган чәчләре арасыннан зур кара күзләре ничектер сәер карый иде. Үпкәләдеме ул, әллә үз итеп иркәләп карадымы,— бу мизгелдә Шакир аны сын белмәде,— нишләгәнен уйлап та тормастан, кочагындагы кызның кайнар иреннәреннән үбеп алды.

Моның ничек килеп чыкканын Зөлфия абайламыйчарак калды бугай, бер мәлгә шаккатып хәрәкәтсез торды. Абайлап алгач, бар көченә талпынып, Шакир кулыннан ычкынды да рәнҗүле тавыш белән:

— Шакир Рәхимович, нәрсә бу — көлүегезме? Шулай ярыймыни? — дип бик үпкәләде.

Кисәктән генә җилбәзәкләрчә кыланып ташлаганын Шакир үзе дә аңлады, уфтанудан нишләргә белмичә:

— Бетте, бетте, зинһар, кичер мине, Зөлфия...— дип, ихлас күңелдән гафу үтенде.

Ярый әле, аның бәхетенә нәкъ шул чакны урман эченнән иптәшләре чыгып, куш каен янында күз бәйләш уены башлап җибәрделәр. Барысы да кулга-кул тотынышып тезелеп беткәч, Шакирны түгәрәк эченә чыгарып бастырдылар. Элек мондый уенны күргәнебелгәне булмаганга, ул башта бераз уңайсызланып калган иде. Әмма аның ык-мык итүенә карап тормадылар. Берсенең косынкасы белән күзләрен бәйләделәр, каршысына кызлардан кемнедер китереп бастырдылар да такмаклап җырлый башладылар:

Чибәр егет, ныклап уйла
Алдыңда кем торганын:
Ялгышмыйча әйтеп кара
Исеме кем булганын.
Зирәк булсаң, танырсың.
Танымасаң, җәза алырсың.

Моңарчы якыннан аралашмаганга, Шакир аларны белеп бетерми иде. Каршысындагы кызның исемен дөрес әйтмәгән өчен җәза биреп, мәзәк сөйләттеләр. Аннары күзен бәйләп, каршысына башка берәүне чыгардылар, тагын җыр әйттеләр. Бу юлы ул Зөлфияне аяк тавышыннан, хушбуй исеннән танып, исемен һич икеләнмичә әйтте.

Күңелле уен арасында Зөлфиянең үпкә-рәнҗеше эреп югалды бугай, һәрхәлдә, ул һич тә читенсенмичә берничә тапкыр Шакирга дустанә карап елмайды. Шакир исә башта ничектер кыяр-кыймас кына тотынса да, бер башлагач, рәхәтләнеп уйнады, һәр уенда Зөлфиягә якын булырга тырышты...

Шуннан бирле алар бу түгәрәк аланга икәү генә килә, күп вакытларын шушы пар каен янында бергә үткәрә торган булып киттеләр. Җитен чәче өстеннән яшел косынкасын бәйләп, өстенә кыска җиңле ак күлмәген киеп каен янына килгән чакларда зифа буйлы Зөлфия үзе дә ак каенга охшап кала. Шакир аңа гашыйк күзләре белән сокланып карап тора да:

— Гүзәл ак каеным, нәфисем...— дип иркәли иде аны.

Хәер, Шакир гөнаһсыз яшүсмер түгел, азмы-күпме дөнья күргән сазау егет инде. Ара-тирә берәр чибәр белән мавыгып киткәләгән чаклары булса да, ул беркайчан да башын югалтмый, үзен бик тиз кулга ала һәм акрынлап суына торган иде. Зөлфия аның тормышына һич тә уйламаган-көтмәгән яктан, йолдыздай атылып килеп керде. Гадәттә караңгы чырайлы, йомыкый табигатьле Шакир ничектер ачыла төште, кешеләр белән ешрак аралаша башлады. Һәр вакыт ниндидер планнар белән мәш килгән тынгысыз Зөлфия янында ул үзе дә канатланып, яктырып китә торган булды. Зөлфияне ул көннәнкөн якынрак күрә, аның белән бергә үзен ничектер үсеп киткән кебек хис итә иде.

Нинди күңелле, бәхетле көннәре бар иде аның. Тормыш һәр вакыт шулай якты, матур булыр кебек иде бит. Ничек болай килеп чыкты соң әле?..

Шакир Рәхимович, дөньясын онытып, кайчандыр бу аланда үткән бәхетле көннәрен хәтерләп торганда, авыр мышный-мышный Хәдичә ханым да килеп җитте һәм гадәтенчә дорфарак бер кайгыртучанлык белән:

— Ни булды? Тагын биленне кузгаттыңмы әллә? — диде.

Шакир уңайсызланып калды, йокыдан кинәт сискәнеп уянган кеше кебек, беравык зиһенен җыя алмыйча торды.

— Юк, берни дә булмады... Болай гына...— диде дә чаңгы таяклары белән этенеп китеп барды.

Чаңгы эзе аны урман эченә алып кереп китте. Шакир Рәхимович тагын истәлекләр дөньясына чумды. Ул үзе чаңгы эзеннән бара, күз алдына тагын җәйге урман, тагын Зөлфия килеп басты, аның белән бергә утрауга чыккан бер җәйге төнне хәтерләде.

...Зөлфиянең туган көне иде бугай. Катерда, алардан тыш, тагын рулевой Җәүдәт һәм квартир хуҗасының кияүдән кайткан кызы кибетче Хәдичә дә бар иде. Дөресен генә әйткәндә, бу Хәдичә Шакир өчен үлеп, һәрчак кайгыртып тора: пикникка кирәкле бөтен аш-сыйның хәстәрен дә шул күргән иде.

Ул көнне алар эштән соң, кичкырын гына юлга кузгалдылар. Әйләнмәле утрауга ничек тә тизрәк барып җитәргә, караңгы төшкәнче ухалык балык тотып калырга кирәк иде. Затон тамагын үтеп, Иделгә чыгу белән Җәүдәт катерны бар куәтенә җибәрде. Шакирның һәр теләген күз карашыннан ук аңлый белгән Хәдичә аңа шешәдән бер стакан салкын сыра салып бирде, авып-китеп китмәсеннәр дип, сумкаларны, рюкзакларны рәтләп куйды.

Зөлфиянең больницадан сукыр эчәгесен кистереп чыкканнан соң яңарак кына хәлләнеп килгән чагы. Шулай да күңеле күтәренке, зур кара күзләренең карашы еракларга төбәлгән, борылыш артыннан яңа бер күренеш ачылган саен сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куя иде. Менә ул кечкенә тын елгага сокланып карап барган җиреннән кинәт әсәрләнеп кычкырып җибәрде:

— Күрегез әле, су өстен күрегез!.. Комач җәйгән төсле кып-кызыл...

— Әйе, әйе, мин дә шуны әйтмәкче идем, чынлап та исләрең китәрлек...— дип, Җәүдәт тә сүзгә кушылды.— Төптән яктырткан кебек, алсуланып балкый, балык уйнаганда су тамчылары ялкын телләредәй сикереп-сикереп куя.

Койрык якта кармакларны рәтләп утырган Шакир түзмәде:

— Әй, син, сакаллы студент, берсекөнгә механикадан имтихан тотасың барын онытма,— диде.— Дөньяңны онытып буш хыялга чумып утырганчы, әнә шул хакта кайгыртсаң, файдалырак булыр.

Бу сүзләрне ул ачуланып түгел, болай гына, хыялый студентның кызлар алдында төчеләнүен бераз тыяр өчен генә әйтте.

Кармакларны рәтләп бетергәннән соң, ул үзе рульгә утырды. Катер тагын да катырак бара башлады һәм баржалар этеп баручы буксир пароходны якыннан гына узып китте. Тиздән ул елганы кыйгачка кистереп тугайлар ягына чыкты һәм наратлы утраулар арасына кереп китте. Вак утраулар эченнән борыла-сарыла аккан елга тармагы буйлап байтак үткәннән соң, катер барышын акрынайтты һәм озакламый сөзәк ярлы утрауга борыны белән килеп төртелде.

— Иң яхшысы менә шушы наратлы утрау булыр, — диде Шакир.

— Монда чебен-черки дә изаламас. Әнә теге камышлар буенда балык та әйбәт эләгә иде.

Элек, Идел суы күтәрелгәнче, монда куе урман булган, мәһабәт наратлар чайкалган. Хәзер алар урынында колач җитмәслек юан агач төпләре генә каралып тора һәм, тереклекнең мәңгелеген раслагандай, матур булып яшь наратлар үсеп килә.

Утрауда туктап калырга булып, катерны яртылаш комга тартып чыгардылар, әйберләрне бушаттылар. Хатын-кыз чыбык-чабык җыеп учак якты, котелок белән су кайнатырга куйды. Егетләр, учактан читкәрәк китеп, камышлы култыкта балык тотарга керештеләр.

Шакир, кармак салгач, иплэп утырып папирос кабызырга да өлгермәде, шундук ярты кило чамасы корбан балыгы тартып чыгарды һәм,

балаларча шатланып: «Әй, сакаллы студент, күрмәсәң күр, балыкны менә шулай тоталар аны!» дип мактанып та алды. Әмма ашыгып мактануын соңрак, бүтән бер балык та эләкмәгәч кенә аңлап алды. Җәүдәт исә, уңышсыз тотынган кебек булса да, тиздән менә дигән ике кызыл канатны бер-бер артлы чирәм өстенә ыргытты. Зөлфия белән Хәдичә шуларны чистарткан арада тагын да зуррак бер корбан балыгы тотты да:

— Бүгенгә шул җиткән...— дип, кармагын комга ташлады.— Иртәгә таңнан торып тотарбыз. Хәзер әйдәгез, уха өлгергәнче, су кереп алыйк...

Алар су коенып, табын янына утырганда көнбатышта кичке шәфәкъ акрынлап сүнә башлаган, әңгер-меңгер куера төшкән иде инде. Күрше утраудагы әрәмә артыннан тулган ай ашыкмый гына күтәрелеп килә. Көндезге әлсерәткеч кызудан соң кичке тын атауның салкынча-дымсу һавасы рәхәт җиңеллек бирә иде.

Хәдичәнең әллә ниләр салып пешергән ухасы искиткеч тәмле булып чыкты. Яңа тотылган балыкның шулпасын да, итен дә мактыймактый ашадылар. Зөлфияне туган көне белән котлап тостлар күтәрделәр.

Шакирның, бераз төшереп алгач, күңеле түгәрәкләнде. Берсеннән-берсе көлке мәзәкләр сөйли башлады. Ниһаять, ул якындагы төп башына менеп басты да, кулларын карау торбасыдай итеп, бөтен әйләнә-тирәне ашыкмый гына күздән кичерде. Аннары, трибунадан мәйдан тулы халыкка бик мөһим хәбәр әйткәндәй, үтә җитди кыяфәт белән:

— Әй, адәмнәр, тыңлагыз, тыңлагыз!.. Барыгыз да белеп торыгыз һәм күрше мәмләкәтләргә дә җиткерегез... — дип мөрәҗәгать итте. — Моңарчы кеше аяк басмаган һәм бүген без ачкан менә бу Мәхәббәт утравын Зөлфиягә бүләк итәм, утрауның хөкемдары дип Зөлфия игълан ителә. Менә бу төп башы аның «тәхете» булсын...

Шакирдан соң патшаларча тантаналы, сабыр адымнар белән «тәхеткә» Зөлфия үзе менеп басты.

— Әһә, шулаймы?!. Алайса, минем беренче фәрманым менә шул... — дип белдерде ул. — Бу урманнарны, суларны, тугайларны — барысын да сезгә, илем улларына, кызларына, мәңгегә бүләк бирәм. Барысына да хуҗа булыгыз, киек-җәнлек аулагыз, балык тотыгыз, терлек асрагыз, иген игегез, тырыш хезмәтегез белән илебезне баетыгыз...

Уйламаган-көтмәгән бу шаяру, эзәрлексез-нисез үзеннән-үзе килеп чыккан импровизация һәммәсенә дә ошады. Барыннан күбрәк Зөлфия үзе рәхәтләнеп көлде һәм бу күңелле шаяру өчен башкаларга сиздермичә генә Шакирны иркәләп, кулыннан кысты.

Шул чак караңгы су өстеннән леп-леп итеп ишкәк ишкән тавыш һәм вак дулкыннар чайпалганы ишетелгән кебек булды. Шакир, беравык колак салып тыңлап торганнан соң:

— Тәгаен браконьерлар бу... — дип әйтеп куйды. — Алар гел шулай йөриләр. Гадәттә җикеренүчән, нахал булсалар да, ауга чыксалар, ерткыч бүре кебек, кеше-карага күренмичә, мыштым гына йөриләр...

Ярты сәгать узмагандыр, утрауның түбәнге очында кинәт нәрсәдер бик каты гөрселдәде һәм тын әрәмәләр өстеннән тирә-юньгә яңгырап үтте. Шундук төнге йокыдан куркышып уянган кош-корт чыр-чу килеп шаулашып алды.

Аннары, акрынлап бу тавышлар басылгач, тынлыкта моторлы көймәләр шаулаганы, кемнәрнеңдер талаш-тиргәше ишетелде, һәм

шунда берсе җан ачысы белән каравыл кычкырып, ярдәмгә чакыра башлады.

Бу шомлы талаш-кычкырышны тын да алмыйча тыңлап утырган Җәүдәт:

— Ишетәсезме, браконьерлар котырына бугай, — дип сикереп торды. — Харап итмәгәйләре, әйдәгез барып күрик әле...

Зөлфия дә шундук кузгалды, туфлиларын алып тиз генә аягына киде. Шакир исә бу минутта, бик мөһим эш белән шөгыльләнгәндәй, учак тирәсендәге кисәү башларын, янып бетмәгән чыбык очларын утка ташлап утыра иде:

— Әйтегез әле, анда безгә ни пычагым калган? Җәнҗал күргәнегез юкмы әллә? — диде ул.

— Шулай ярыймыни?!.. Анда бәлкем кешене харап итәләрдер, ә без монда кул кушырып утырыйкмы?

Зөлфиянең бу сүзләренә Шакир чыраен сытып куйды. Әйтер сүзен эзләгән сыман, кулындагы таяк очы белән учакны актара бирде.

— Анысын гына мин дә аңлыйм анын, — диде ул, ниһаять. — Әмма, бәла-казадан башаяк дигәндәй, белмәгән-күрмәгән кешеләрнең ызгышына тыгылуның ниге кирәге бар?..

Җәүдәт белән Зөлфия аны бүтән үгетләп тормадылар. Сүз куешкандай, бер-берсенә карашып алдылар да яр буйлап түбән очка йөгерделәр...

Җәүдәтнең шикләнүе юкка булмаган икән: җинаять өстендә тотылган браконьерлар рыбнадзор инспекторын каты кыйнап чак харап итмәгәннәр. Иртән иртүк Шакир белән Хәдичә катерга утырып, утрауның түбәнге очына белешергә төшеп җиткәндә, төнге фаҗига булган урында ике милиционер тикшеренеп йөри, Җәүдәт белән Зөлфия каты яраланган инспекторны анын үз көймәсенә салып, аргы яктагы район үзәгенә, больницага илтә киткәннәр иде.

Озакламый Шакир белән Хәдичә дә аргы яктагы зур поселок каршына килеп туктадылар. Яр буенда кармак салып утыручылар тегеләрне күргән булган икән. Сораштыра башлау белән: «Әйе, килделәр. Инспекторның хәле бик авыр иде. Больницага үзебез күтәреп менгезештек»,— дип, тау өстендәге ике катлы кирпеч йортны күрсәттеләр.

Хәдичәне яр буенда катерда калдырып, Шакир тау өстенә күтәрелде һәм барып керү белән больницада ниндидер киеренкелек хөкем сөргәнен шәйләп алды. Вакыт әле бик иртә булса да, вестибюльгә кемнәрдер җыелган, барысы да пышылдап кына сөйләшәләр, кереп-чыгып йөргән ак халатлы медсестралардан нидер белешергә тырышалар иде.

Берничә кешедән сораштыргач, Шакирның белә алганы шул булды: яралы инспекторга врач инде операция ясап бетергән. Зөлфия авыруга кан биргән икән.

Кем икәнен әйтеп бик ялварып үтенгәч, Шакирга берничә минутка кереп, тегеләрнең хәлен белергә рөхсәт биргәннәр иде. Әмма аңа палатага керергә туры килмәде. Медсестралардан берәрсе хәбәр иткән булса кирәк, вестибюльгә Зөлфия чыкты һәм эскәмиягә утыру белән каядыр читкә карап:

— Бераз башым әйләнә, — диде, — ятып торырга кушканнар иде. Бер генә минутка чыгуым...

Ул өстенә ак халат кигән, калын чәчен арттан бәйләп куйган; әлерәк кенә кан биргәнгәме, бераз талчыккан, йөзе агарып калган иде. Шакир аны якын итеп хәлен сорашты, операциядән соң әле рәтләп хәлләнеп җитмәгән килеш кан биргән өчен борчылуын да әйтте.

Моңарчы сүзсез генә тыңлап утырган Зөлфия кинәт талпынып куйды, колакларына ышанмагандай, Шакирга сынаучан текәп карады. Аннары көтелмәгән ят тавыш белән:

— Борчылмагыз... хушыгыз... — диде. Ишектән кереп китәр алдыннан әйләнеп карады, каты сүзләрен йомшартырга теләгәндәй:

— Гафу итегез, бераз башым әйләнә, мин керим инде, — дип өстәп куйды.

— Алайса, болай сөйләшик, — диде Шакир, аны туктатып. — Бераз хәл җыеп алгач, чыгарсыз. Без сезне яр буенда катерда көтеп торырбыз...

Зөлфия, ни әйтергә белмәгәндәй, беравык сүзсез торды да һаман баягыча читкә караган хәлдә:

— Юк, юк, көтмәгез... Авыруның хәле бик кыен, хатыны килеп җитмичә, без барыбер аны калдырып китә алмыйбыз,— дип, эчкә кереп китте...

Моннан соң да Зөлфия очрашкан саен һаман читкә карап сөйләшә, ашыгып китеп бара торган булды. Аннары ул, Җәүдәт белән бергә институтка укырга китеп, бөтенләй күздән югалды... Зөлфия белән бергә үткән бәхетле, якты көннәр, кабатланмас матур төш кебек, Шакир күңелендә гомер онытылмаслык якты истәлек булып уелып калды.

Бу югалтуны Шакир бик авыр кичерсә дә, еллар үтү белән ул инде акрынлап оныткан, күңеле тынычланган кебек иде. Бактың исә, юк икән, бер дә онытылмаган, салкын кар астында яшьлек эзләре югалмаган кебек, ул көннәр дә күңел түрендә һаман сакланган икән...

1974

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**АВГУСТ, 1974 ел**

Луцк шәһәреннән Чаллыга кадәр ике мең километр чамасы булса да, Украинадагы бу шәһәр янында төзелә башлаган подшипниклар заводын КамАЗ иярчене диләр.

Бу индустрия гигантының (аның куәте Харьков подшипниклар заводына караганда өч мәртәбә артыграк булачак) технологик проектын Куйбышев шәһәрендәге галимнәр һәм инженерлар башкарды. Алар барлык производство процессларын автоматлаштыруны күздә тотканнар. Программа белән идарә итүгә корылган агым линияләре, барлык технологик яңалыклар яңа заводның характерлы үзенчәлеге булачак. Бу завод чыгарган продукция Кама буенда төзелә торган автогигантка китәчәк.

**«Советская Россия», Мәскәү.**

Брно шәһәрендәге машина төзү заводы Кама елгасы буенда салына торган автогигант өчен зур, җаваплы заказны гамәлгә ашыра... Бу завод бер мең, мең алты йөз, ике мең биш йөз, дүрт мең тонналы пресслар эшләп чыгарырга тиеш. Бу прессларның кайберләренең зурлыгы ике катлы йорт кадәрле. Ждарнад-Сазавадагы машина төзү заводында ясала торган тагын биш прессны кушсаң, КамАЗның бөтен тимерчелек-пресс заводы Чехословакиядә ясалган җиһазлар белән тәэмин ителәчәк дигән сүз.

Тольятти шәһәрендәге Волга автомобиль заводы заказларын уңышлы башкарганы өчен Брно шәһәрендәге машина төзү предприятиесе СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләнгән иде. Бу югары бүләк завод эшчеләрендә, инженер-техник хезмәткәрләрендә зур шатлык һәм хезмәт күтәренкелеге тудырды. Хәзер алар Советлар Союзы өчен яңа заказны срогында һәм югары сыйфатлы итеп үтәргә омтылалар.

— КамАЗ заказлары, — ди орденлы Брно заводының директор урынбасары Э. Козак, — безнең предприятие тарихында иң зур контракт. Ул технологияне камилләштерергә этәрә, иң алдынгы техника белән җиһазландырыла торган КамАЗ алдында Чехословакия маркасын төшермәскә әйди.

**АПН, Прага.**

Казан янындагы «Волга» дуслык лагеренда ял итүче бер төркем француз яшьләре Чаллыга килде.

Кунаклар автомобиль комплексының төзелеш мәйданнарында булдылар, ремонт-инструменталь заводының төп корпусын карадылар.

Төзелеш мәйданында алар «Автозаводстрой»дан Николай Шмоткин җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасының эше белән таныштылар, ә «Энергетик» культура сараенда шәһәрнең комсомол активы белән очраштылар.

КамАЗ төзелеше, Чаллы яшьләренең тормышы һәм хезмәте Франциядән килгән кунакларда зур кызыксыну тудырды.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Батуми шәһәрендәге ботаника бакчасының өлкән фәнни хезмәткәре, биология фәннәре кандидаты Т. Л. Самхарадзе унжиде ел дәвамында роза чәчәкләре селекциясе һәм генетикасы белән шөгыльләнә. Шушы вакыт эчендә ул утыздан артык яңа сортлар чыгарды.

Ул чыгарган өр-яңа сортларның әлегә исеме юк. Һәм менә күптән түгел гаять хуш исле, куе кызыл төстәге роза чәчәгенә «КамАЗ» исеме бирелде.

Яңа сортның беренче сабаклары Чаллы шәһәренә җибәреләчәк: бу гүзәл чәчәкләр автогигант төзүчеләр шәһәренең урамнарын һәм мәйданнарын бизәсен!

«Известия», Мәскәү.

«Знамя труда» производство берләшмәсе коллективы Чаллы өчен күп төрле арматуралар җитештерә. Ленинград шәһәрендәге башка предприятиеләрдәге кебек үк, биредә дә Кама автомобиль төзүчеләрнең чакыруына зур теләк белән кушылдылар һәм КамАЗ заказларын махсус график буенча үтәргә булдылар. Бу заказларның бер өлеше срогыннан алда ясалды һәм җибәрелде. 223 нче һәм 227 нче цех эшчеләре бу эшләрне уңышлы башкарып чыгу өчен күп көч куйдылар. «Полимерстрой» заводы Чаллы шәһәре өчен менә дигән итеп юыла торган, ефәк төсле поливинилхлорид обойлар эшләп чыгара.

Иҗат коллективлары да читтә калмады. «Гипроавтотранс»ның Ленинград филиалы белгечләре зур энергия белән мең данә авыр йөк машиналары өчен гараж проектлауга керештеләр. Ә Калинин шәһәре проектчылары куәтле прокат станы сызымнарын эшлиләр... Аларның девизы — сызымнарны вакытыннан элек югары сыйфатлы итеп тәгәлләү.

ТАСС, Ленинград.

Кама автомобиль комплексының ремонт-инструменталь заводында токарьлар конкурсы үткәрелде. Аңа Идел буендагы 11 республика һәм өлкә вәкилләре — завод, район, өлкә һәм республика конкурслары лауреатлары катнашты.

Беренче урынга Казан моторлар төзү заводы токаре Д. Ерошин чыкты.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Иксез-чиксез илебез киңлекләре буйлап тугызынчы бишьеллык атлый. Аның һәр елы махсус максатка юнәлдерелгән, һәр елының үз исеме бар: өченче-хәлиткеч, дүртенче-билгеләүче... Ул нык адымнар белән атлый... Аның адымнары — Красноярск ГЭСы, яңа җылылык һәм атом станцияләре, яңа газ магистральләре, КамАЗ, БАМ...

Мәскәү шәһәренең Бауман сайлау округы сайлаучылары белән очрашуда ясаган чыгышында, яңа эре халык хуҗалыгы комплекслары төзү эшләрен җәелдерү эшләре турында сөйләгәндә, Л. И. Брежнев: «Кама буенда автомобиль гиганты төзелә», — дип әйтеп узган иде.

Үзенең масштабы белән дә, иҗади фикерләү кыюлыгы белән дә, илебез тормышындагы әһәмияте белән дә бу төзелеш чын-чынлап гигант.

Төзелеш кызу темплар белән бара... Бирегә илебезнең барлык районнарыннан яшьләр килә. Эшләргә, торырга килә. Бүген дә килә, яңа отрядлар иртәгә дә киләчәк. КамАЗ шундый ул — яшьләрнең йөрәген магнит кебек үзенә тарта.

«Советская культура», Мәскәү.

Кама автомобиль комплексы төзелеше һәм «КамАЗ» автомобиле белән бәйләнешле заданиеләрне башкарып чыгу срогын кыскарту буенча социалистик йөкләмәләрне уңышлы үтәве өчен Ярославль моторлар төзү заводы коллективы ВЦСПС дипломы белән бүләкләнде.

Ярославльлеләр яңа йөк машинасы, дөресрәге, аның унөч модификациясе өчен менә дигән дизель двигательләре, шулай ук биш һәм ун баскычлы тизләкне үзгәртү коробкалары ясадылар. Моторларны һәм тизләк коробкаларын тагы да камилләштерү эше дәвам итә. Коллектив КамАЗ өчен кадрлар әзерләү буенча да зур

эш алып бара. Дизельләр ясау буенча күп кенә тәҗрибәле осталар Кама буена китте.

ТАСС, Ярославль.

Татарстан китап нәшрияты «Без КамАЗ төзибез» дигән җыентык бастырып чыгарды. Аңа Кама автогигантын төзүдә катнашучы бетончылар, ташчылар һәм башка һөнәр кешеләре язган материаллар тупланган.

«Строительная газета», Мәскәү.

Белоруссия башкаласы белән Кама буе арасы үзенә күрә бер маршрутка әверелде. Тугызынчы бишьеллыкның гигант төзелешенә Минскидан һәм Белоруссиядәге башка автозаводлардан күп кенә йөк машиналары җибәрелде. Кама буенда төзеләчәк үзбушаткыч машиналарның беренче үрнәкләре биредә җыелды. Алар хәзер илебез юлларында сынау үтә. Күп кенә предприятиеләрдә КамАЗ өчен квалификацияле эшче кадрлары әзерләнә, инженерлар стажировка үтә.

Октябрь революциясе исемендәге заводта ясалган буйга кыру һәм буйга фрезерлау өчен ике авыр станокны Чаллыга җибәргәндә, аның детальләрен тояргә ун вагон кирәк булды. Алар срогыннан бер айга элегрәк җибәрелде. Киров исемендәге станок төзү заводы, автомат линияләр заводы һәм Витебск, Молодечно шәһәрләрендәге станок төзү предприятиеләре коллективлары да КамАЗ заказларын уңышлы үтиләр.

ТАСС, Минск.

5 августта, дүшәмбе көнне, Чаллыда Энергетика һәм электрофикация министрлыгы коллегиясенең күчмә утырышы булды. Утырышны министр П. С. Непорожный алып барды.

Коллегия «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе начальнигы В. А. Фоменконың беренче ярты еллыкта эшләнгән эшләр йомгагы турында докладын тыңлады.

Коллегия утырышына КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеев, КПСС Үзәк Комитетының машина төзү бүлеге мөдире урынбасары М. В. Борисов, Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Т. Троицкий, КПСС Үзәк Комитетының машина төзү бүлеге инструкторы Д. Ф. Проценко, КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляев, Минмонтажстройның КамАЗ төзү буенча Главка начальнигы З. С. Садаринов, СССР Энергетика министрлыгының Главка һәм идарә җитәкчеләре, СССР Госстрое, Госснабы вәкилләре катнашты.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

«Елга-диңгез» тибындагы суднолар Ильичевск портыннан чыгып Чаллыга юнәлделәр. Алар ике атна эчендә, диңгез һәм елга трассаларын үтеп, бишьеллыкның удар төзелешенә автомат пресс линияләрен илтәчәк.

Бу йөкне тимер юл белән йөртү мөмкин түгел: аның детальләре 200—300 тонна авырлыкта. Җиһазларны төяү һәм алып бару планын «Союзвнештранс» конторасы һәм Ак диңгез — Онега елга пароходчылыгы хезмәткәрләре белән берлектә Ильичевск портчылары эшләде. «Суджа» исемле Кара диңгез теплоходы Япониядән Ильичевскига линия комплектын алып кайтты, ә А. Барановский, А. Корзюк, Н. Гарагаш һ. б. лар җитәкчелегендәге докерлар бригадалары, куәтле «Богатырь» краны ярдәмендә, биш тәүлек эчендә авыр агрегатларны «Суджа» бортыннан «Волга-Балт» бортына күчерделәр.

ТАСС, Ильичевск.

Танылган «Березка» ансамбленең музыкаль җитәкчесе, композитор В. И. Темнов Чаллыда булып китте. Двигательләр заводы матбугат үзәге мәйданында ул төзүчеләр алдында, баянга кушылып, үзенең әсәрләрен һәм рус халык җырларын башкарды...

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

# Марсель Зарипов

# КИҢЛЕКЛӘР

**Юлны башлап киту генә кыен.**
**А. Твардовский.**

## Юл башы



Безнең Идел-Кама яклары тарихи истәлекләргә бай. Һәркайда әледән-әле иске манаралар, борынгы шәһәр хәрабәләре белән бергә яңа гына салынган калалар, авыллар синең игътибарны үзенә тарта. Кайчан барлыкка килгәннәр алар? Үзләрендә кайсы заманнарның эзләрен һәм истәлекләрен саклыйлар? Ул шәһәрләрне һәм авылларны күргәч, күңелдә бер-бер артлы әнә шундый сораулар туа.

Ә менә Иделнең үзе турында, аның кайсы дәвердә үзенә юл яруы турында мондый сораулар бервакытта да уйга килми. Идел-ана кешеләргә дөнья яралган көннән бирле хезмәт итәдер кебек тоела.

Элеккеге Тверь, хәзерге Калинин җирендә, Идел үзенең суларын илтеп коячак Әстерхан тамагыннан бик-бик еракта, җир куеныннан кечкенә генә бер кизләү агып чыга. Шул тирәдәге искиткеч матур Селигер күле, биек һәм төз наратлар, усаклык һәм каенлыклар сине һәр вакыт кызыктырып, үзләренә дәшеп тора.

Баш очында зур-зур түгәрәкләр ясап, тилгәннәр әйләнә. Якындагы авыл буенда балалар уйнап йөри. Үләннәр арасыннан ниндидер кошчык тавыш бирә. Шуларның бөтенесенә илаһи ямь өстәп, һәркайсыбыз өчен чиксез кадерле чишмә челтери. Аның тавышында сүз белән аңлатып бирә алмаслык ниндидер тирән мәгънә барлыгын тоясың. Русның күренекле шагыйре Александр Твардовский әйткәнчә, туган җирнең уртасы саналган Иделнең чыннан да шулай бик гади һәм күзгә күренер-күренмәс кенә башланып китүенә һич кенә дә ышанасы килми.

Менә ул, юлын дәвам итеп, бер чакрым, биш... ун чакрым җир уза. Бер караганда тирә-якта әлегә бернинди дә үзгәреш сизелми. Кая карама, һаман шул ук яшел урманнар, шул ук тирән упкыннар... Ә инеш исә кыска гына ара эчендә үзгәреп тә өлгерде. Әйтерсең лә әле менә хәзер генә уйнап-сикергәләп йөргән шаян кызчык безнең күз алдыбызда үсеп буйга җитте, уйчанланды, басынкыланды.

Һәм менә инешнең киңәйгәннән-киңәя, тирәнәйгәннән-тирәнәя барып, елгага әверелүен раслаучы беренче билгеләр күренә башлады. Ярдан ерак та түгел кызыл маяклар тирбәлә. Кечкенә катер, моторын барлык көченә эшләтеп, каядыр ашыга. Аның артыннан як-якка таралган дулкыннар ярга килеп бәреләләр. Палубадагы кешеләр арасында зур җанлылык.

Алда — бу елга ярына салынган агач дебаркадерлы беренче пристань. Яшелгә буялган будкага, зур пристаньнардагы шикелле, «ОМ»нарның, «Ракета»ларның килүкиту вакытлары язып куелган. Шунда ук малайлар кармак салып мәш киләләр, өлкән

яшьтәге балыкчылар пассажирларга үзләре киптергән тәмле испе балык саталар. Авыллардан килгән апа-җиңгиләрнең чиләкләрендә — кып-кызыл булып пешкән алмалар, чия һәм башка төрле җиләк-җимешләр.

Хәзер инде син бу елганың Иделнең нәкъ үзе икәнлегенә чын-чынлап ышанасың...

**Бу дулкынга карап, мөмкин түгел**
**Ышанмаска, димәк, шушыңа:**
**Көнбатыш һәм Көнчыгышны Идел**
**берләштерә, алар кушыла**
**Идел аша мәңге аерылмаска,**
**Бер ил булып изге зур юлда.**
**Туган җиребезнең уртасы ул —**
**Боек Идел... Җиде мең елга!**

Күпме илләр һәм халыклар елгаларны чик сызыклары иткәннәр?! Нил, Рейн, Иордан, Миссисипи кебек олы суларның бер як ярлары теге яки бу илнең үзенеке, икенче як ярлары исә читләрнеке, мәңгелек ызгыш, тынычсызлыкның шаһиты алар.

Ә безнең Иделебез — планетаның иң-иң тыныч елгасы. Үзенең кочагына ул, кайгыртучан ана шикелле, русларны, татарларны, чувашларны, мариларны, калмыкларны җыйган. һәм шагыйрь, Иделнең Көнбатыш белән Көнчыгышны берләштерүе турында язганда, географияне түгел, бүгенге тормышның үзен күз алдында тота. Кешеләр, халыклар, тамырлары төрле якка тармакланган агачны хәтерләтеп, Идел буена урнашканнар һәм кулга-кул тотынып яшиләр, эшлиләр, үзләренең киләчәк тормышларын төзиләр.

Тарихка син бернәрсә дә өсти дә, аны киметә дә алмыйсың. Шуңа күрә узган тарихның бүгенге көн өчен файдалы сабакларын һәр вакыт истә тотарга кирәк.

Идел буенда яшәгән ырулар һәм халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр җиңел генә көйләнеп китмәгән. Үзара ызгыш-талашлар, төрле низаглар, бер-берсенә ышанмаудан килеп чыккан кан дошманлыгы тарих битләренә кайгы һәм газап булып язылган, хәтерләргә мәңгелеккә сеңеп калган.

Калька елгасы янындагы сугышларда Киев князьларының таркау дружиналарын тар-мар иткәннән соң Чыңгыз ханның мәрхәмәтсез баскыннары Идел буе җирләренә һөҗүм иткәннәр, Болгар дәүләте өстенә ташланганнар. Куркусыз болгарлар яулап алучыларга каршы өч тапкыр күтәрелгән һәм монголлар үзләренең явыз теләкләренә ирешә алмыйча өч тапкыр кире киткәннәр. Әмма барлык варварларның варвары саналган кансыз Батый Болгар дәүләтен җимергән, аның шәһәрләрен һәм авылларын җир белән тигезләгән. Шулай итеп чират аерым-аерым, Козельскига, Мәскәүгә килеп җиткән. һәм еллар, гасырлар буена, Куликов кырындагы сугышка кадәр, Идел буе шәһәрләрендә һәм җирләрендә басып алучыларның гаскәрләре торган.

Мамай урдасы тар-мар ителгәннән соң да татар ханнары Суздальга, Владимирга, рус князьларының дружиналары исә Идел буе җирләренә яу белән барганнар. Ләкин моннан соң килгән буыннар үткәннең җан тетрәткеч вакыйгаларыннан акрынлап сабак ала башлаганнар. Бергәләшеп, дуслашып, кулга-кул тотынышып яшәргә тырышканнар. Милләтләр, халыклар арасындагы кыргый мөнәсәбәтләргә, ызгыш-талашларга алмашка аңлы сыйнфый көрәш хисе килгән. Руслар, татарлар, чувашлар, башкортлар, марилар иң кирәкле минутта, бер кешедәй булып, үзләренең уртак изүчеләренә каршы көрәшкә күтәрелгәннәр. Ярлы-ябагайларны байларга каршы яуга дәшкән Степан Тимофеевич Разинның чакыру хатын бөтен Идел буе хуплаган. Арзамас, Муром янындагы рус авылларында Дон атаманын татарлар, башкортлар, чувашлар, мордвалар түземсезлек белән көткәннәр, отрядлар оештырып, аны каршыларга чыкканнар. Камап алынган Семберне коткарырга ашыккан князь Борятинский юлдан патшага язган махсус хатында Казанка елгасы тамагында казаклар, татарлар, чувашлар, мордвалар белән дүрт тапкыр каты сугыш алып баруы турында хәбәр иткән.

Добролюбов, Карамзин, Гончаров, Некрасов, Короленко, Мельников-Печорский, Чернышевский, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һ. б. бик күпләрнең исеме Идел белән аерылгысыз бәйләнгән. Идел аларны куркусыз көрәшчеләр итеп үстергән, талантларына канат өстәп, бөек иҗатка рухландырган.

Безнең сәнгатебезне Идел пейзажының кабатланмас буяуларыннан, Репинның

Левитан, Куинджи, Нестеров, Кустодиевның социаль һәм бай жанрлы портретларыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Идел дөньяга Бутлеров, Лобачевский, Зинин, Арбузов, Камай һ. б. лар кебек атаклы галимнәрне бирде. Аларның һәркайсы Ватаныбызның данын үстерделәр, халкыбызның, фәнебезнең горурлыгы булып әверелделәр.

Без пролетар, революцион Идел турында аерата горурлык хисе белән сөйлибез. Әле бөтенләй яшь-яшь Николай Федосеев, Россиядә беренче булып, марксистик түгәрәкне Идел буена урнашкан Казанда оештыра. Патшага кул күтәргән Николай Осипанов, Дмитрий Каракозов, Вера Фигнер — Казанда укыган студентлар. Бөек революциянең давыл хәбәрчесе Алексей Максимович Горький берьюлы ике шәһәрне — Нижний Новгородны һәм Казанны үзенең туган җире дип атаган.

Кешелекнең бөек улы Володя Ульянов Идел туфрагында — Семберда дөньяга килгән. Ә инде революция һәм көрәш юлына ул Казанда баскан.

Тагын шунысын кабатлап әйтергә кирәк: Петроградтан соң Октябрь байраклары иң элек Идел буе шәһәрләре өстендә җилферди башлаган. Ак чехларның аяусыз яулары Иделдә туктатылган. Иделдә һәм аның бертуган сеңелесе Камада кызыл комиссар Маркин флотилиясе ак адмирал Старкның эскадрасын тар-мар иткән.

Мең тугыз йөз кырык икенче елда күп милләтле совет дивизияләре Сталинград янындагы Мамай курганында, трактор заводы диварлары буенда, Иделнең текә ярында немец илбасарлары белән бугазга-бугаз килделәр һәм расизм идеяләренең өстенлеген бөтен дөньяга күрсәтү өчен Россия киңлекләренә ябырылган фашистик армияләрен кол-талкан китерделәр.

Библиядә шундый бер әкият — сөйләк бар. Кешеләр алла каршында бик зур гөнаһ эшлиләр. Ут урлыйлар, тәңре әйткәнчә түгел, үзләренчә яшәргә тырышалар. Ачулана алла боларга һәм коточкыч җәза уйлап чыгара — бер-берләрен аңлый алмасыннар өчен кешеләрне төрле телләрдә сөйләшергә мәҗбүр итә.

Әйе, җирдә һәр халыкның үз теле, үз культурасы, үз гореф-гадәтләре, традицияләре бар. Әмма без барыбыз да бер-беребезне аңлыйбыз. Чөнки без барлык совет халыклары өчен уртак телдә — туганлык телендә аңлашабыз.

Ана теленнән тыш үзләштерелгән төп телнең рус теле икәнлеге үзеннән-үзе аңлашыла. Бөек туганлык телендә — Ленин, Пушкин, Толстой, Маяковский телендә Идел буенда яшәүче халыклар иркен сөйләшәләр һәм бер-берләрен бик һәйбәт аңлыйлар.

Волгоградта, Горькийда, Ленинградта, Мәскәүдә чыгарылган һәм Идел буе шәһәрләрендә, авылларында эшләүче тракторларның, машиналарның, станокларның паспортлары рус телендә язылган. Милли мәктәпләрнең һәркайсында балалар «ана», «Ватан», «партия» сүзләрен үз ана телләрендә дә, русча да язарга өйрәнәләр. Куйбышев өлкәсе, Татарстан, Мари, Чуваш, Мордва республикалары һәм Ярославль, Горький, Иваново, Калинин, Саратов һәм Волгоград... Сулъяк һәм уңъяк ярлар хезмәттә яңа уңышларга ирешү өчен көрәшәләр, аларның һәркайсы күбрәк, әйбәтрәк эшләргә, дәүләтебезнең көчен, куәтен арттырырга тырыша.

Үз юлында сеңелкәшләре Ока, Ветлуга, Каманың суларын кабул итә-итә, кечкенә кизләүдән башланып киткән бөек елга Әстерхан дельтасына кадәр ага. Аның юлы озын һәм катлаулы. Иделнең нәкъ уртасында Куйбышев диңгезе кайвакытта дәһшәтле дулкыннары белән корабларга ябырыла. Сизгер бул, зирәк капитан! Ашыкма, тәҗрибәле сал агызучы!..

Иделнең иң киң урынын узганда башка менә нинди уйлар килә: аерым-аерым гына агып ятсак, кечкенә инешләр кебек без дә зур елгага әверелә алмыйбыз. Ә көчебезне бергә кушсак, юлында бернинди киртәләр белән хисаплашмаган Иделгә әвереләбез. Монда, Идел белән Кама кушылган урында, Тукайның тирән фәлсәфи фикерле шигъри юлларын тагын бер тапкыр күңелеңнән үткәрәсең:

**Һич бетәрме бу тарихи бергәлек! —**
**Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.**

...Кызыксынганыгыз бармы икән, Россия елгаларының уртак әнкәсе булган Иделне аның ярларында яшәүче халыклар ничек дип атыйлар? Руслар аңа «Волга», татарлар, башкортлар «Идел», марилар «Юл», чувашлар «Атель» диләр. Төрлечә атасалар да, һәр халык аңа үзенең тирән мәхәббәтен белдереп, назлап-сөеп дәшә.

Кешеләр Идел табигатенең матурлыгын яраталар. Ләкин Иделгә карата булган ихтирам һәм соклану аның табигатенең кабатланмас матурлыгы белән генә түгел, барыннан да элек, бу елганың эшчән булуы, борын-борын заманнарда ук төрле кешеләргә карышмый хезмәт итүе белән аңлатыла. Әйе, Идел ул олы су гына түгел, туендыручы һәм киендерүче эшчән ана да.

Революциянең беренче елларында, ярлы һәм бөлгенлеккә төшкән ил әйтеп бетергесез кыенлыклар кичергән чагында, Идел өстендә электр утының әсәре дә булмаган. Мәскәү тирәсендә бары тик илдә беренче төзелгән Кашира электр станциясе утлары гына күренер-күренмәс җемелдәгән. Хәзерге масштаблар белән чагыштырганда, аның көче бик аз булган, энергиясе хәтта Мәскәүне дә яктыртырга җитмәгән. Ләкин без электр елгаларының ташкыны Кашира станциясе генераторларыннан башлануын онытырга тиеш түгелбез.

Хәзер илебездә торф, күмер, газ, мазут яки атом энергиясенең куәтле киловаттлары, су көче белән эшләүче зур һәм кечкенә электр станцияләре исәп-хисапсыз. Аларның һәркайсы илебез экономикасында, халкыбыз язмышында, чорыбызның техник прогрессында билгеле бер адым булып тора. Моннан дүрт дистә ел элек Иделдә беренче гидроэлектростанция — Иваньков станциясе утлары кабынды. Утыз мең киловатт — ул чакта бу сан моңарчы күрелмәгән зур уңыш һәм шатлык иде. Бүгенге көндә Конаково станциясенең үзенең генә дә һәр турбинасы Иваньков станциясенекенә караганда ун тапкыр артыграк энергия бирә.

Җырларда җырланган Конаково Калинин өлкәсендә урнашкан. Суны ул Иделнең беренче шифалы зур диңгезе булган Мәскәү бассейныннан ала. Монда Мәскәү исемендәге каналның куәтле транспорт системасындагы беренче шлюз, поселок һәм станция Порфирий Конаков исеме белән аталган. Порфирий Конаков шушындагы заводта карап-сокланып туймаслык сервизлар бизәкләүче булган. Еу савыт-сабаларны Париж, Амстердам, Лондон күргәзмәләрендә бәяләп бетерә алмаганнар. Оста инде үзе исән түгел, Порфирий Конаков революция өчен башын салган, әмма аның традицияләрен якташлары дәвам итә. Хәзер дөньяны Конаково энергетиклары таңга калдыра. Биредәге блоклар өчәр йөз мең киловатт, трансформаторлары үткәргечләргә токны 750 киловольт белән бирәләр. Бу станция үзенең куәте белән Братск гидроузеленың энергетик потенциалына тигез.

Әмма Братск станциясе үзе нинди дә булса башка берәр төзелешнең энергетик зурлыгын үлчәп-чагыштырып карау өчен без куллана торган гадәти эталон гына. Әйтик, бу сүзне без метр, килограмм, ампер сүзләре кебек үк еш кабатлыйбыз.

Инде хәзер үзенең моторлары, акыллы полиграфик машиналары, диңгезе һәм энергетикларының фидакарь эшләре белән атаклы Рыбинскига төшик.

Рыбинск диңгезенә суны сугыш алдыннан тутыра башлаганнар. Су проектта билгеләнгән урынга күтәрелеп тә өлгерми, сугыш башланып китә. Фашист фельдмаршалларының танк армияләре сугышның беренче көзендә башкалабызның капка төбенә диярлек килеп җиткәнләр. Бәхеткә каршы, Мәскәү янында ук аның энергетик йөрәге тибүен немецлар сизенми алмыйча калалар. Зур әһәмияткә ия булган экономик үзәкләрне бомбага тотарга очкан һава пиратларының планшетларында Рыбинск станциясе билгеләнмәгән була. Станция агрегатлары сугышның дүрт елы эчендә дүрт миллион киловатт-сәгать энергия бирә.

Әйе, һәрнәрсәнең үз үлчәве була. Елларның да, эшләрнең дә. Кайчандыр Казан сәүдәгәрләре бертуган Крестовниковлар шәм сатып ифрат зур капитал җыйганнар. Соңгы тиеннәргә сатып алынган ул шәмнәрне, үлгәннәрне искә алып яки тәңредән үзләренең гөнаһларын кичерүне сорап, чиркәүләрдә яндыралар. Ул шәмнәр губернаторларның кунак йортларын яктырталар һәм ачлы-туклы яшәгән крестьяннарның җимерелеп-ишелеп беткән өйләрендә, әле тормыш барлыгын белдереп, сүнәр-сүнмәс пыскыйлар.

Хәзер Татарстанның бай нефть промыселлары, Түбән Кама комбинаты, КамАЗ корпуслары белән берраттән, үзенең куәтле Братск ГЭСы кадәр энергия бирә торган электр станцияләре бар.

Бер уйлаганда, Идел бер дә ашыкмый-кабаланмый гына ага кебек. Анда Кавказ елгаларының ярсуы-ашкынуы юк. Ә карыйсың, күпме эшләр аның түзем җилкәсенә төшә. Шул хакта фикер йөртсәң, борын-борыннан килә торган зирәк әйтемнең мәгъ-

нәсенә тагын да ныграк төшенгәндәй буласың: «Ашыккан үзен, ашыкмаган эшен бетерер».

Әстерхан тирәләренә барып җиткәнче Идел Волгоград, Волжск, Саратов... кебек гидростанцияләрнең турбиннарын әйләндерергә өлгерә. Утыз ике миллиард киловатт-сәгать — алны-ялны белмичә һаман эшләүче Идел шәһәр һәм авылларга әнә шул кадәр энергия бирә.

Ә энергетика — Иделнең әле телгә алынган бер генә тармагы ул. Илне бөтен дөньяга билгеле булган Калинин шәһәрендәге «Пролетарка», Кинешма, Иваново, Камышин, Чебоксар фабрикаларының данлы тукучылары киендерә. Агымдагы бишьеллыкта икенче Баку — Башкортстан, Татарстан, Куйбышев промыселлары бер миллиард тонна кара алтын бирәчәк. Бүгенге көнебезгә карап сөенгәндә, узганнарны искә төшереп үтүне беркем дә гаепкә алмас.

Бу уңайдан безгә ни өчен бөек елгабызның иң борынгы һөнәре — бурлаклар эшен телгә алмаска?! Әйе, энергетика шәһәре булып үскәнче байтак заманнар элек Рыбинск шәһәрен «бурлаклар башкаласы» дип йөрткәннәр. Яз башлануга, бирегә төрле артельләр җыелып килгәннәр һәм җәй буена пароходларны агымга каршы сөйрәгәннәр.

1851 елда хәзерге «Красное Сормово»да беренче пароход — ике торбалы «Астрахань» судносы суга төшерелә.

Буксирлар һәм земснарядлар, танкерлар һәм теплоходлар, җитез «Ракета»лар һәм өчәр палубалы дизель-электроходлар — легендар заводның осталары бүген әнә шундый суднолар ясыйлар. Һәрбер судно илебезнең көчен, куәтен арттыра. Һәр ел саен 50 миллион пассажир, 65 миллион тонна йөк — бу саннар үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Моннан тыш Иделнең әле тагын 10 миллион тонна йөк күтәрергә мөмкинчелеге барлыгы турында да төгәл исәпләүләргә нигезләнгән фикерләр әйтелә. Моны нәрсә хисабына эшләргә мөмкин соң? Барыннан да элек дөрес планлаштыру, эштә төгәллек, һәр судноны тулы көчкә эшләтү хисабына. Бүгенге көндә исә Иделдәге йөк суднoларының биштән бер өлеше теге яки бу якка буш йөри икән. Борчылырлык, уйланырлык нәрсәләр күп монда?

Көчле, эшчән елганың тагын бер зур бурычы—шәһәрләрне һәм авылларны яхшы су белән тәэмин итү. Кешеләрнең борын-борын заманнардан ук суга якынрак урнашырга омтылулары тикмәгә генә түгел. Мәскәү һәм Киев, Новосибирск һәм Хабаровск, Варшава һәм Будапешт, Лондон һәм Париж — бу шәһәрләрнең тормышын, язмышларын елгалардан башка күз алдына да китерү мөмкин түгел.

Иделнең башланып киткән һәм койган җиренә кадәр булган араның уртача һәр биш чакрымына бер авыл яки шәһәр туры килә. Аның ярларының һәр метры кешеләргә карышусыз хезмәт итә.

Исәпләп чыгаруларга караганда, илгә елына уртача 200 миллиард кубометр чиста су кирәк. Халыкта телдән-телгә күчеп йөргән борынгы әкиятләрнең күбесе су турында булуы бер дә гаҗәп түгел. Су нефть чыгара, металл эретә, тукымалар тукый, химик реакторларны шаулата, җирләрне сугара. Бүгенге көндә Идел кешеләргә елына 25—30 миллиард кубометр су бирә. Озакламый су 10 миллиард кубометрга күбрәк кирәк булачак.

Беренче карашка, Иделне син бик-бик яхшы беләсең кебек. Ләкин аны берәр җәй яки берәр ел күрми торсаң, андагы үзгәрешләр сине шунда ук таңга калдыра. Әнә бер урында яңа гидростанция калкып чыккан, икенче бер урында төзелеп үзенә дәшеп торган өр-яңа шәһәр күзгә ташлана. Иртәгәсе көнгә караш ташласаң, бу төзелешләрнең тагын да киңрәк колач җәячәген күрәсең...

## Өч тапкыр туган шәһәр

Иделдәге Ставрополь...

Шундый риваятьләр йөри. Имеш, беренче булып монда калмык ханнарының чыбык очы саналган Тайшин килеп утырган. Үз диненнән ваз кичеп, христиан динен кабул иткән Тайшин, әлбәттә, ялгыз булмый. Бу якларга ул үзенең ырудашлары белән

күчеп килә. Ләкин урыннан-урынга күчеп йөрергә күнеккән калмыклар утрак тормышка ияләшеп китә алмыйлар. Алар яңадан иркен далаларга китеп баралар.

Аның каравы, калмыклар сайлап алган урын ялкаулыклары, эшсезлекләре аркасында бөлгенлеккә төшкән Тула, Смоленск, Рязань дворяннарының күңеленә бик хуш килә. Күрәсең, алар яңа урында һәр нәрсә үзеннән-үзе, Манилов фикер йөрткәнчә, бик җиңел эшләнер, дип уйлыйлар. Әмма тормышны оҗмах итеп кору турындагы буш хыяллары чынбарлык нырыслыгына бәрелеп челпәрәмә килә.

Йөз елдан артык вакыт узгач та Ставрополь Россиянең моңсу йокыга талган хәрәкәтсез, ташландык шәһәрчекләреннән берсе булып кала. Әйтерсең тормыш үзләреннән соң ярда нәрсә калачагын уйлап та карамаган Идел дулкыннарына ияреп, каядыр качып китә. Хәр фикерле, чиксез кыю Софья Перовская бу урыннарда халыкка «йөреп», тып-тын яткан шәһәрчекне йокысыннан уятмакчы була. Ләкин мондагы чын хәлне күргәч, аның исе-акылы китә. «Һәр җирдә тирән үлем тынлыгы хөкем сөрә, — дип яза ул Ставропольдан, — һичбер кайда фикерләүгә нигезләнгән аңлы эшчәнлек һәм тормыш күрмәссең».

Кин Россия империясенең монархы Николай I «төзелеш эшләренең казнаны зур чыгымнар тотарга дучар итүен» күреп, шәһәр комендантлыгын һәм канцеляриясен ябарга әмер бирә.

Идел буйлап сәяхәт кылучылар өчен 1911 елда бастырып чыгарылган махсус белешмәдә Ставропольга үз эшләре яки бөтенләйгә урнашып калу теләге белән килгән кешеләрне алдан ук кисәтеп куйган менә мондый юллар бар: «Бу өяз шәһәре бернәрсәсе белән дә кызыклы түгел. Пристань буларак та аның әллә ни әһәмияте юк».

Ләкин белешмә авторлары, теләпме, теләмичәме, бик зур бер хәйләкәрлек эшлиләр — бу яклар белән кызыксыну артканнан-арта. Россия энергетикасының патриархы, соңыннан ГОЭЛРО планын эшләүчеләрнең берсе Глеб Максимилианович Кржижановский нәкъ менә шул вакытта, унынчы елларда, Самара Лук гидростанциясен төзү турында хыяллана. Аның бу хыялы бәлки тормышка да ашкан булыр иде, ләкин Самара һәм Ставрополь архиепископы Симеон «алла кодрәтеннән башка» эшләнәчәк бу эшкә каршы чыга, мондый нәрсәләргә юл куймауны сорап хәтта граф Орлов-Давыдовның үзенә кадәр барып җитә. Ул чакта Ставропольга әле үзе турында ныклап белдерергә иртәрәк булган, күрәсең. Аңа бары тик бер генә нәрсә — үзенең алдагы матур язмышын — күгендә бәхетле йолдыз балкыячак көнне көтәргә кала. Һәм көтеп алынган ул сәгать сукты.

Мең тугыз йөз илле беренче елның язында Ставропольга гидротөзүчеләр штабы килеп урнашты. Бөтен тирә-як бөек төзелеш гөрелтесе белән күмелде. Хәзер, мазут, газ белән эшләүче Конаково, Кармановск, Зәй җылылык станцияләре, миллион киловаттан артык егәрлеккә ия булган турбиналы Красноярск, Саян-Шушенск станцияләре эшли башлагач, Волжск станциясенә карата «бөек» эпитетын куллану ничектер уңайсызрак шикелле. Ләкин ул вакытта, моннан чирек гасыр элек, Жигулидагы төзелеш, дөрестән дә, илебез өчен дә, Европа өчен дә моңарчы күрелмәгән зур эш иде. Ике миллион киловатт егәрлекле агрегатларның сафка басачагы тиз арада бик күпләр игътибарын үзенә җәлеп итте.

Бөтенесе дә безнең күз алдыбызда эшләнде. Башта котлованнар казылды, аннан гигант плотина күтәрелде, монтажчылар искитмәле турбиналарны җыйдылар. Озак та үтмәде, киң колачлы диңгез хасил булды һәм иске Ставрополь су астына күмелде. Яңа урынга күчерергә мөмкин булган нәрсәләрне ватмый-җимерми ташырга тырыштылар, әмма шәһәрнең үзәк өлеше ор-яңадан төзелде.

Мең тугыз йөз алтмыш дүртенче елда карт Ставрополь үзенә башка исем алды — Тольятти шәһәре дип йөртелә башлады. Тольяттига популярлыкны энергетиклар китергәнлеген оныту, әлбәттә, гаделсезлек булыр иде. Әмма анда яшәүчеләр өченче тапкыр алышынганнан соң, хәзер ул искиткеч кыска вакыт эчендә үсеп чыккан һәм тагын бер шәһәргә тормыш биргән автогигант буларак билгеле. Элеккеге кварталлары белән бутамас өчен хәзер аны «Зур Тольятти» дип йөртәләр.

Зур Тольятти әле үзенең сабыйлык чорын кичерә. Идел автогигантын төзергә килүчеләрнең балалары мәктәпкә былтыр гына йөри башладылар. Яшь шәһәр вакытның һәр сәгатен исәпкә алып, бүгенге көн графигы белән яши һәм эшли. Әйтерсең ул узган еллар һәм гасырлардан калган эшләрне дә эшләп бетерергә ашыга. Моңар-

чы беркем белмәгән, беркем ишетмәгән кечкенә бер шәһәрчекнең кинәт шулай бөтен илгә, дөньяга танылуы гаҗәп түгелмени!

Шахталар, мартеннар төзү, дөньяда тиңе булмаган уникаль станоклар, приборлар эшләү, дәүләтнең экономик, политик бәйсезлегенең, көч һәм куәтенең нигезе булган «А» группасын үстерү өчен илебез беркайчан да акча кызганмады. Халыкка киң куллану әйберләре, товарлар җитештерүгә килгәндә исә кешеләрнең көндәлек тормышында иң-иң кирәкле нәрсәләр генә эшләп чыгарылды. Һәммәсенә берьюлы тотынырга безнең әле көчебез җитәрлек түгел иде. Гражданнар сугышы җимерекләреннән арынып беренче бишьеллыклар дәвамында илне тагын да үстерергә, ныгытырга тотынганда гына ил өстенә фашист ордалары ябырылдылар. Сугыштан соң бөтенесен өр-яңадан башларга туры килде.

Елларны еллар алыштыра торды. Илебез яңа үрләргә күтәрелде. «Б» группасында җитештерелгән продукциянең күләме «А» группасы белән тигезләнү ягына авышты. Моны раслау өчен ике бишьеллыкны — җиденче һәм сигезенче бишьеллыкларны чагыштырып карау да җитә. Җиденче бишьелыкта «А» группасының продукциясе — 151, «Б» группасының 136 процентка үсте. Ә сигезенче бишьеллыкта бу чагыштырма 151 һәм 149 процент булды.

Һәр ике группаның, гомумән, безнең бөтен экономикабызның шундый үсеш закончалыгына туктталып, партиянең XXIV съездында КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев халыкка киң куллану товарлары җитештерүне тагын да арттыруның зарури икәнлеген басым ясап әйтте. «Без, иптәшләр, озак еллар героик тарих үттек, ул чакта миллионнарча коммунистлар һәм партиясезләр аңлы рәвештә корбаннарга һәм мәхрүмлекләргә бардылар, иң кирәкле нәрсәләр белән генә канәгатьләнергә риза булдылар, үзләрен тормыш өчен аерым уңайлыклар таләп итәргә хаклы дип санамадылар, — диде Л. И. Брежнев. — Бу исә киң куллану товарлары җитештерүгә, аларның сыйфатына һәм ассортиментына мөнәсәбәткә дә тәэсир итмичә калмады. Ләкин элек беренче планда башка бурычлар, башка эшләр торганда аңлашылырлык һәм табигый булган нәрсә хәзерге шартлар өчен яраклы түгел...»

Процентлар һәр вакыт процент булып кала. Әгәр кеше үзенең табигате белән уйларга, гомуми саннарның, математик категорияләрнең асылына, мәгънәсенә төшенергә сәләтле булмаса, процентларга аның артык исе китми. Ә бит шул процентлар безгә сигезенче бишьеллыкта төзелгән Тольятти автомобиль заводы тугызынчы бишьеллыкта җиңел машиналар эшләп чыгаруны 3,8 тапкырга арттыруга нигез булды.

Завод беренче көннән үк илебездәге иң әһәмиятле төзелешләрнең берсе дип игълан ителде. 1967 елның 14 январенда экскаваторчы коммунист Илья Шевелев автозавод төзеләчәк мәйданга беренче булып эз салды. Исәпсез-хисапсыз техника, әле кичә генә Жигули таулары буенда Идел аша плотина торгызган белгечләр, тәҗрибәле осталар тагын бер биеклекне штурмлый башладылар.

Автомобиль баранкасыннан илебездәге беренче автомобиль заводы руле артына утырган атаклы практик һәм хыялый күңелле Иван Алексеевич Лихачев мең тугыз йөз егерме җиденче елда аз җегәрле АМОны реконструкцияләү һәм елына дүрт мең урынына 25 мең автомобиль эшләп чыгару хакында янып йөргән. Аның исәпләвенчә, конвейердан һәр дүрт минут 12 секунд саен бер машина төшәргә тиеш булган. Тольятти автомобиль заводы башта ук елына 660 мең автомобиль чыгаруны күздә тотып проектлаштырылды һәм төзелде. Бу — аның конвейер линияләреннән һәр 28 секунд саен бер машина төшеп тора дигән сүз.

1930 елда Ока белән Идел кушылган җирдә берәр катлы такта бараклар салына. Аякларына чабата киеп, авыллардан килгән ун мең мужик Нижнийда автомобиль конвейерының чираттагы звеносын төзергә керешә. Җир казыйлар, атлар һәм носилкалар белән балчык-ком ташыйлар. Озак та үтми, булачак заводның нигезе салына, аңа төрле зурлыктагы станоклар кайтарыла. Көн буена эшләп арыган-алҗыган кешеләр кичләрен китап-дәфтәр битләре өстенә иеләләр. Юк, аларның кулларында әле геометрия яки физика дәреслекләре булмый. Укырга-язарга өйрәнер өчен гап-гади әлифба китабы күтәреп, алар әле ликбезларга гына йөриләр.

Ун мең... Бу түгәрәк сан Зур Тольятти биографиясендә дә кабатлана. Ун мең кран, экскаватор, бульдозер һәм скрепер... Автозаводны беренче булып төзи башлаган «Куйбышевгидрострой» тресты эшкә әнә шундый техника белән керешә.

Кеше гомеренең нибары яртысына тигез булган бу өч дистә ел вакыт арасында нинди зур аерма, нинди зур алга китеш! Әйе, чоры башка, илнең көч-куәте, җәйгән колачы башка. Тольятти гиганты завод корпуслары белән генә түгел, урамнары, кварталлары, үзенең микрорайоннары белән бергә күтәрелде. Зур Тольяттиның беренче яңа йортларына 1969 елның язында күченделәр. Хәзер бу районда 160 мең кеше яши. Ә шәһәрнең барлык халкы 350 мең кешедән артып китте.

Шәһәр һәм автозавод икесе берьюлы үсте. Төзүчеләр тугызар, уникешәр катлы йортлар, культура сарайлары, мәктәпләр, балалар бакчалары салдылар, «Фиат» фирмасыннан килгән ашыгучан итальяннар, алдан төзелгән договорда каралганча, совет белгечләренә беренче технологик линияне тапшырдылар, конвейерны ходка җибәрергә булыштылар.

1970 елның апрель төнендә конвейрда беренче алты автомобиль җыелды. Ничек шулай туры килгәндер, анысын әйтүе кыен: АМО заводында да беренче машина төнлә җыела. Ләкин бу вакыйга яз көне түгел, көзен, октябрь аенда була. Директор Лихачев кабинага үзе кереп утыра һәм, артык дулкынланудандыр, күрәсең, башта машинаны кабыза алмый азаплана. Ниһаять, автомобиль гөрләп кабына һәм көчле алкышлар астында кузгалып китә.

Югарыда әйтелгәнчә, ВАЗда беренче машиналарны җыю төнлә тәмамланды. Ул чагында менә хәзер, шушы минутта илебезнең автомобиль төзелеше тарихына тагын бер данлы сәхифә язылыр дип беркем дә уйламагандыр, мөгаен. Конвейердагылар машинаны нинди төскә буяу хакында озак бәхәс алып бардылар. Бер караганда, бөтенләй вак нәрсә турындагы бәхәс иде бу. Ләкин анда бик күп төрле фикерләр әйтелде. Ахырда, Россия Федерациясенең Дәүләт флагы төсенә туры китереп машиналарның дүртесен кызылга, икесен зәңгәргә буярга булдылар.

Кайвакытта без олылар да һаман бала булып калабыз. Безнең һәркайсыбызның яңа машинаның ниндирәк икәнлеген башкаларга караганда бер генә көнгә, бер генә сәгатькә булса да алданрак күрәсебез килде. Без шатландык, бәйрәм иттек. Әмма беренче автомобильдән сериялап чыгара башлауга кадәр авыр һәм озын юл үтәсе бар иде әле. Бөтенесе конвейерны җиренә җиткереп көйләүгә бәйләнгән иде.

Революция алдыннан Россиядә автомобиль кытлыгын бетерергә ниятләгән промышленникларның һәм АМО кампаниясенә нигез салучыларның берсе Сергей Павлович Рябушинский, хәрби ведомство машиналар таләп итә башлагач, Италиядән детальләр сатып ала һәм шулардан машиналар корып заказчыга тәкъдим итә. Дөрес, бик үк табышлы эш булмый бу. Детальләр сатып алу кампаниягә 11 мең сумга төшә, аларны кайтартуга зур чыгым тотыла. Әмма Рябушинский акыл белән эш итә, тотылган капиталның иртәме-соңмы артыгы белән кире кайтачагын ул бик яхшы аңлый. Башлысын башлы була Рябушинский, ләкин ул үзенең капиталыннан файдалана алмый кала. Россиядә революция башлана һәм Рябушинский чит илгә чыгып китә.

ВАЗның баш инженеры Евгений Артемьевич Башинджагян һәм конвейерда аның белән бергә төн уздырган башка кешеләр беренче машиналарның әле сынап карау, конвейерны камилләштерү юнәлешендә нәрсәләр эшләргә кирәклеген белү өчен генә ясалганлыкларын бик яхшы аңлап тордылар. Конвейере тулы көчкә һәм төгәл эшли башлаганчы күпме вакыт узар — бер елмы, икеме, әллә аннан да артыгракмы— моны тәгаен генә әйтүе кыен иде әле.

Конвейерны ахырынача көйләп бетерү өчен унбер ай вакыт кирәк булды. Үзәк линиягә синхроник төгәллек белән меңнәрчә детальләр бирел торучы йөз илле километр озынлыктагы зур һәм кечкенә конвейер системалары энә күзеннән үткәргәндәй кат-кат тикшерелде.

Конвейерның төп тармагы 1 километр 800 метр озынлыкта. Ә аңа йөзләрчә гектар мәйданда корылган башка системалар хезмәт күрсәтәләр. Гомум системадагы ун меңнән артык кечкенә «винтикның» берсенең генә дә бөтен эшне тоткарларга мөмкин икәнлеген искә алсак, хезмәт күрсәтүче системаларның нинди синхроник төгәллек белән эшләргә тиешлеген күз алдына китереп бастыру кыен түгел.

1972 елның январенда ВАЗның икенче, шул ук елда өченче тармаклары эшли башлады. 1973 елның октябренда экспертлар машинага «Сыйфат билгесе» бирделәр,

ә бер айдан соң Тольятти һәм бөтен илебез ВАЗда миллионынчы автомобиль чыгуны бәйрәм итте. Шул ук көнне автомобиль төзүчеләрнең данлы коллективы байрагына Ватаныбызның олы бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены беркетелде.

## Җил тула җилкәннәргә

Моннан күп гасырлар элек ничек булган булса, хәзер дә шулай ук һәм шулай ук түгел дә. Киләчәктә дә һаман шул ук су башы булыр. Кечкенә инеш елгага әверелер. Ә елга, үз юлында болыннарны һәм иген кырларын сугара-сугара, шәһәрләргә, авылларга яшәү көче биреп, диңгезгә ашыгыр.

Шул ук су юлы буйлап авыр йөк төягән баржалар, танкерлар, берничәшәр катлы теплоходлар йөзәр, су эченә күмелгән канатлары белән ап-ак күбекләр кайнатып, тиз йөрешле катерлар узар.

Шуның белән бергә, тормыш бер генә урында тукталып тормый, туктаусыз алга бара. Иксез-чиксез Идел киңлекләрендә яңа эз салынмаган, куәтле ташкынга буйсынып турбиналар гөрләмәгән, конвейер линияләре хәрәкәткә килмәгән бер генә көн дә юк.

Тугызынчы бишьеллыкта Иделдә нинди эшләр эшләнүен, аның бассейнындагы республикаларның, өлкәләрнең экономикасы, культурасы ни дәрәҗәдә үсүен без инде күреп торабыз. Партиябезнең XXIV съезды карарларында боларның барысы да ачык әйтелгән иде. Барыннан да элек, Иделнең энергетик куәте моңарчы күрелмәгәнчә үсә. Сүз хәзер аерым корылмалар гына түгел, илебез, һәр республика һәм өлкә тормышында зур әһәмияткә ия булачак эре-эре комплекслар төзү турында бара.

Әйе, географик яктан элеккечә калса да, Идел үз юлында зур үзгәрешләр кичерә. Аңа икенче тормыш китерәчәк эшләрнең күбесе безнең планнарыбызда ачык һәм төгәл билгеләнгән.

Бездәге кебек елгалар, елгачыклар һәм инешләр муллыгы башка беркайда да юк. Аларның гомуми саны өч миллионга җитә. Әллә азмы бу?! Ләкин бәла шунда: аларның һәркайсы кире холыклы — кая телиләр, шунда агалар. Илебезнең халык аз яши торган төньяк һәм көнчыгыш өлкәләренә бар булган суларның 85 проценты туры килә. Ә тормыш өчен, яшәү өчен уңайлы, уңдырышлы һәм халык тыгыз урнашкан көньяк районнарга, индустриаль үзәкләргә калганы гына тия. Менә шуны искә алып, Иделнең куәтен моңарчы бер файдасызга агып яткан төньяк елгалары хисабына арттыру күздә тотыла. Ул елгаларның суын Иделгә кушу буенча уннарча проектлар төзелгән. Ул проектларның берсе Печора елгасын Каманың югары агымы белән тоташтырудан һәм Камага ел саен 30 куб/километр су өстәүдән гыйбарәт. Ә Кама ул шул ук Иделгә кушылачак су дигән сүз.

Галимнәр Иделгә булышуның башка төр мөмкинлекләрен дә эзлиләр. Кубенск-Шекснинск проекты аңа, мәсәлән, Кубенск, Леча, Вохе күлләренең Сухона һәм аның кушылдыгы Юг елгаларының суын өстәүне күздә тота. Иделгә Төньяк Двина, Вычегда, Пинега, Мезень елгаларын тоташтыру буенча да гипотезалар бара. Ә Идел үзе, тагын да зуррак куәткә ия булып, Дон, Урал, Терек һәм көньяктагы башка елгаларга ярдәмгә киләчәк.

Идел арты далаларында Идел — Урал каналын төзү эшләре башланды. Бу канал Саратовтан көньяк-көнчыгыштагы корылыклы далаларны сугару, Уралның түбәнге агымында, Каспийның төньяк-көнчыгыш өлешендә нормаль гидрологик режим булдыру өчен хезмәт итәчәк...

Киләчәктә эшләнәчәк кайбер эшләрнең планы әнә шундый. Бу эшләрне тормышка ашыру юлында без алда торган авырлыклардан курыкмыйбыз. Без туар көннәр каршына ышанычлы, кыю адымнар белән барабыз.

Хәтерлисезме Александр Твардовскийның шигъри юлларын:

**Юл арты юл, ел арты ел килә,**
**Чик артыннан чикне ил үтә.**
**Юллар авыр, ләкин гасыр җиле**
**Безнең җилкәннәрне киертә.**

# СЕРГЕЙ ЕСЕНИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

●

Аерым тамга белән тамгалана
Бала чактан һәр җан иясе.
Әгәр дә мин шагыйрь булалмасам,
Миңа карак булып китәсе...

Тәбәнәк буй, ябык гәүдәм белән
Урамнарны батыр айкадым.
Ул чак һәр көн борынымны җимереп,
Мышный-мышный өйгә кайта идем.

Шунда куркып каршы чыга әнкәм,
Мин кан аша сүзләр сөзәмен:
«Ташка гына мин абындым, әнкәй,
Иртәгәчә бар да төзәлер».

Менә хәзер суынып үткәннән соң
Кайнар оетмалы ул көннәр,
Бер тынгысыз, кыю-дуамал көч
Поэмаларыма бөркелә.

Мин сүзләрнең алтын өемнәрен
Һәм һәр юлны тезгән чагымда,
Элеккеге усал башкисәрнең
Чаялыгы хәзер чагыла.

Шул чактагы горур һәм батыр мин,
Тик яктырак күренә йөргәнем.
Элек танавымны кыйнасалар,
Инде канга туза йөрәгем.

Һәм әнкәмә түгел, шаркылдаучы
Ятлар төркеменә әйтәм мин:
«Ташка гына абындым ла бары,
Иртәгәчә төзәлер әле!» — дим.
1922

## Качаловның этенә

Бирче, Джим, йомшак тәпиеңне,
Бәхет теләп миңа тормышта.
Айга карап икәү өрик әле:
Көннәр китсен ямьгә, тынычка.
Бирче, Джим, йомшак тәпиеңне.

Зинһар боргаланма, күгәрченем,
Тыңла мине бераз булса да.
Син белмисең тормыш ни икәнен,
Яшәү кирәклеген дөньяда.

Хуҗаң синең мәшһүр һәм мөлаем,
Кунаклары аның күп була.
Һәм һәрберсе синең хәтфә йоныңа
Кулын тидерергә омтыла.

Син этләрчә шундый матур үзең
Һәм карыйсың матур иттереп.
Бер тамчы да сорап тормыйсың син,
Үбешәсең исерек дус кебек.

Их, Джим җаным, синең кунакларың
Арасында була төрлеләр.
Барсыннан да тынрак, моңсурак кыз
Кереп чыкмадымы соң берәр?

Мин ышанам, бер керер ул кичен,
Мин юкта син аңа карап ал,
Бар да, юк та гаепләрем өчен
Гафу сорап кулын ялап ал.

1925.

Әнвәр Давыдов тәрҗемәләре.

●

Кызганмыйм да, дәшмим, еламыйм да,
Чәчкәләрем коелыр көн җитте.
Алтын сарың инде миндә, көзем,
Яшәрмәм мин, яшәрмәм инде.

Син дә инде, суына төшкән йөрәк,
Ашкынмассың кызып китәргә.
Дәшми инде мине зәңгәр кырлар
Ялан тәпи генә гизәргә.

Илгизәр җан, кайда инде синең
Элеккеге рухи ашкыннар...
И кайда сез, минем егет мәлләр,
Утлы күзләр, хисси ташкыннар?

Теләкләр дә сүрән. И тормышым,
Гүяки син төш кенә идең,
Әйтерсең мин чыңлап торган таңда
Алсу атта үттем дә киттем.

Барыбыз да безнең — бер бетәсе.
Яфрак коя чаган тын гына...
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, гел яшәреп,
Гел искереп торган бу дөнья!

1922

## «Фарсы моңнары»ннан

И Шаганэ, шаһинәм син, шаһинәм лә!
Мин төньяктан килгәнгәдер микән әллә,
Сиңа менә сөйләргә мин әзер бүген
Ай нурында арыш ничек тирбәлүен.
И син минем Шаганэм лә, Шаганэм лә.

Мин төньякта тугангадыр микән әллә,
Ямьле дә бу Шираз, әмма бездәге ай
Сездәгедән йөз мәртәбә зуррак бугай,
Ни җитә соң Рязаньдагы киңлекләргә,
Мин төньякта тугангадыр микән әллә.

Сиңа менә сөйләргә мин әзер бүген:
Бу чәчләрне алтын арыш бирде миңа,
Телисең икән — ура әйдә бармагыңа —
Андый гына авыртуга түзә күңел.
Сиңа менә сөйләргә мин әзер бүген.

Ай нурында арыш ничек тирбәлешен
Күз алдыңа китер минем бөдрәләрдән.
Телисең икән — елмай, шаяр һәм иркәлән.
Искә генә төшермә тик зинһар өчен
Ай нурында арыш ничек тирбәлешен.

И Шаганэ, шаһинәм син, шаһинәм лә!
Төньягында — бер кыз бала яши анда.
Һай, сиңа ул исләр киткеч охшаган ла.
Ул да мине уйлый микән бүген әллә...
И Шаганэ, шаһинәм, шаһинәм лә!

1924

⊖

Син әйттең: «Сәгъди, диден син,
Үпкән тик түштән бары».
Белермен, алла боерса,
Бераздан мин дә аны!

Җырладың: «Ефрат ягында:
Гөл-кыздан әйбәт», — дидең.
Маллырак булсам әгәр мин,
Бүтән җыр җырлар идем.

Гөлләрне тапар идем мин! —
Шыр калсын әйдә түтәл:
Булмасын илдә, Шаганэм,
Шәбрәкләр синнән бүтән.

Борчыма инде мине син
Тик серле вәгъдә белән.
Мин шагыйрь булып туганмын,
Бәс, шагыйрь булып үбәм.

1924

●

Фирдәүсинең зәңгәр иле, син
Уйчан күзле гади урысны,
Искә алган сыман чын дусны,
Хәтерләрсең бәлки мине син,
Фирдәүсинең зәңгәр иле, син.

Яхшы ил син, Иран, мин беләм.
Алгөлләрең балкып утыра,
Сөйләп ерак илем турында,
Сафлык бөркеп торган тел белән...
Яхшы ил син, Иран, мин беләм.

Ә бүген мин соңгы мәртәбә
Хуш исләрен эчәм гөлләрнең.
Килеп җитте китәр көннәрем.
Җырларыңны синең, Шаганэ,
Тыңлыймдыр мин соңгы мәртәбә.

Ә син мине онытыр дисеңме?
Сөйләп илгә синең хакыңда,
Еллар аша кичкән чагымда
Хәтерләрмен мәңге мин сине,
Ә син мине онытыр дисеңме?

Истәлеккә илем турында,
Русь турында бер җыр калдырам.
Җырла шуны мине сагынсаң,
Мин кайтырмын сиңа җырымда,
Уйлаганда минем турымда.

1925.

Хәсән Туфан тәрҗемәләре.

●

Тиле йөрәк, бәргәләнмә!
Алдандык без бәхетләрдән,
Хәерче тик сорый ярдәм...
Тиле йөрәк, бәргәләнмә!

Айның сары моңы яшел
Каштаннарны чылатты,
Мин Ләйләнең пәранҗәсе
Астында ышык таптым.
Тиле йөрәк, бәргәләнмә!

Без күп чакта сабый сыман
Елыйбыз да көләбез,
Якты бәхетләр соңыннан
Кайгы килә, беләбез.
Тиле йөрәк, бәргәләнмә!

Күп илләргә юлым төште,
Бәхет эзләдем күптән.
Өлешкә тигән көмешне
Эзләмим инде бүтән.
Тиле йөрәк, бәргәләнмә!

Гел алдамас бу дөнья,
Яңа көч сулар күкрәк,
Сөекле кызның алдында
Йокласаң иде, йөрәк.
Гел алдамас бу дөнья.

Бәлки безне дә бер күрер
Язмыш, акса да ерак:
Мәхәббәткә җавап бирер
Былбыллар булып сайрап.
Тиле йөрәк, бәргәләнмә!

1925

●

Басылгандай булды иске яра,
Исерек уйлар суырмый җанны.
Чәйханәдә мине савыктыра
Зәңгәр чәчәкләре Таһранның.

Чәйханәче чәйнең хуш исенә
Соклансын, дип, урыс кунагы,
Аракы һәм шәрабләрсез генә
Кып-кызыл чәй белән сыйлады.

Сыйла хуҗа, тик бел дәрәҗәсен,
Роза гөлләр бик күп багыңда.
Юккамыни, ачып пәрәнҗәсен
Кара күзләр карый тагын да.

Ә Россиядә зәңгәр язлар кызын
Эттәй сакламыйбыз бәйдә без,
Кулланмыйча хәнҗәр явызлыгын,
Түләмичә генә үбәбез.

Бер карасын бу кыз күтәрелеп,
Фарсистанның зифа баласы,
Һарсан шәлен бүләк итәрмен мин
Һәм Ширазның йомшак паласын.

Катырак чәй, хуҗа, сал касәмә,
Мин алдамам сине гомергә.
Синең өчен җавап бирмәсәм дә,
Үзем өчен әзер бирергә.

Ишек ягын артык күзләмә син,
Арт капка бар синең багыңда...
Юккамыни, ачып пәрәнҗәсен
Кара күзләр карый тагын да.

1924

Зөлфәт тәрҗемәләре.

Рәшит Ахунов

# ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘДӘ КОМПЕНСАЦИЯ МЕТОДЫ

Тәрҗемә теориясе безнең илдә шул кадәр алга китте ки, кайсы илнең генә филология фәне һәм әдәбият белеме бу өлкәдә безнең белән ярыша алыр икән. Әгәр рус телендә басылган хезмәтләрне генә алып карасак та, тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган дистәләгән махсус китап күрербез. (Бу исәпкә әле брошюраларны, әдәби журналларда, махсус җыентыкларда чыккан күп санлы мәкаләләрне кертмибез, аларда да тәрҗемә проблемалары бик җитди рәвештә тикшерелә.) 1959 елдан башлап «Тәрҗемәдә осталык» дигән 9 җыентык, филология фәннәре докторы Л. С. Бархударов редакциясендә «Тәрҗемәче дәфтәрләре» дигән 7 җыентык һәм башкалар басылып чыкты.

Бу хезмәтләр белән танышканда бер үзенчәлек күзгә ташлана: әгәр кырыгынчы елларда тәрҗемәдә төгәлсезлек калу ихтималы табигый бер нәрсә итеп күрсәтелсә, безнең ил галимнәренең соңгы еллардагы хезмәтләрендә теләсә кайсы әсәрнең бер телдән икенчесенә тулы канлы итеп, сәнгатьчә югарылыкта тәрҗемә ителә алу мөмкинлеге расланды. Тәрҗемә теориясенең нигез ташы булган бу билгеләмә ел саен йөзләгән тәрҗемә китабы басылып килә торган күп милләтле совет әдәбиятында тәрҗемәчеләргә ныклы ышаныч белән эшләргә, тәрҗемә практикасын өзлексез яхшыртырга, туктаусыз эзләнергә мөмкинлек тудыра.

Кайбер тәрҗемәчеләр әдәби әсәрне яхшы тәрҗемә итү өчен телне практик белү, аның нечкәлекләрен сиземләү җитә дип уйлыйлар. Сүз дә юк, тәрҗемәченең телне яхшы белүе кирәк, аның сиземләве дә башкаларга караганда көчлерәк булырга тиеш, ләкин ул сыйфатлар гына җитми. Телне яхшы белү, сиземләү — ул караңгыда барган кеше кулындагы шәм яктысы кебек кенә әле. Адашып китмәс, юлдан читкә чыкмас өчен, әлбәттә, шәм яктысы ярап куя, ә инде нык адымнар белән, абынмый-сөртенми барыр өчен көчле прожектор белән яктыртылган юл кирәк. Прожектор яктысы дип без тәрҗемә теориясен әйтәбез. «Ике тел мөнәсәбәтендәге закончалыкларны белү кирәк, закончалыкларны белү тел чараларын аңлы рәвештә файдаланырга, иң кирәклесен сайлап алырга, оригиналның үзенчәлекләрен тәрҗемәдә дә саклап калырга ярдәм итә»,— ди А. В. Федоров «Тәрҗемә теориясенә кереш» [1] исемле хезмәтендә.

Теорияне белү тәрҗемәче кулындагы зәгыйфь утны, сүнәр-сүнмәс янган шәмне якты нурга әйләндерә, әнә шул нур ярдәмендә тәрҗемәче катлаулы һәм кыен юлның караңгы, билгесез борылмаларын яктыртып бара ала.

Тәрҗемә практикасында гомум тәрҗемә теориясе һәм хосусый тәрҗемә теориясе бар. Я. И. Рецкер «Тәрҗемә теориясе һәм тәрҗемә практикасы» [2] дигән хез-

---

[1] А. В. Федоров. Введение в теорию перевода. М., 1958.
[2] Я. И. Рецкер. Теория перевода и переводческая практика. М., 1974.

мәтендә: «Хосусый тәрҗемә теориясе ул ике телнең тәрҗемәдә парлашуына карый торган теория», дип билгеләмә бирә. Бу очракта без рус теле белән татар теленең парлашу практикасын алып өйрәнәбез.

Тәрҗемә эше белән шөгыльләнә башлаганга бик күп вакыт узуга карамастан, бездә әле һаман да уңышсыз тәрҗемәләр очрый. Бу бездә тәрҗемә эшенә сәләтсез кешеләр тотынудан гына түгел, хосусый тәрҗемә теориясе эшләнмәгән булудан да килә. Дөрес, 1917 елдан алып төрле газета-журналларда тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган йөзләрчә мәкалә басылып чыккан, әмма шуларның теориягә караганнары бармак белән санарлык кына. Аларның да тик берсе китапка кертелгән. (1930 елда басылган «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» дигән җыентыкта Г. Кутуйның «Тәрҗемә әдәбият турында» дигән мәкаләсе бар.) Тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган аерым брошюра 1964 елны гына дөнья күрә. Бу — В. И. Ленин хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итүе белән танылган С. Фәйзуллинның «Ике тел хәзинәсе» исемле брошюрасы. Тагын ун ел чамасы узганнан соң, Г. Хантемированың һәм Р. Юсуповның тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган брошюралары басылып чыкты[1]. Татарстанда тәрҗемә теориясенә караган бүтән китап юк дисәк, ялгыш булмас. Көндәлек матбугатта мәкаләләр күп басылуын әйткән идек, ләкин алар барысы да аз-маз гына үзгәртүләр белән бер-берсен кабатлап баралар, тәрҗемә теориясенә төгәллек, ачыклык кертмиләр. Ул мәкаләләрдә кайсы тәрҗемәнең яхшы, кайсысының начар булуы турында сүз әйтелә, әмма яхшы тәрҗемәгә нинди алымнар, нинди чаралар белән ирешеп була, алары күрсәтелми. Ул мәкаләләрдә теоретик фикерләр дә, тәрҗемә практикасыннан чыгып нәтиҗә ясаулар да юк диярлек.

Тәрҗемәнең төрле формаларын табып, аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен билгеләргә беренче мәртәбә Хәбиб Гали тырышып карый: 1926 елны «Безнең юл» журналының 5—6 саннарында аның «Тәрҗемә әдәбиятны яхшырту юлында» исемле мәкаләсе басыла. Хәзерге заманның «адекват» тәрҗемә төшенчәсенә якынрак төшенчәне язучы Ибраһим Гази әйтеп бирә[2].

Тәрҗемәгә багышланган мәкаләләрне Л. Җәләй, М. Әмир, А. Шамов, С. Әдһәмова, М. Зәкиев, К. Сабиров, Г. Ахунҗанов, Р. Башкуров, А. Гомәр, А. Әхмәт, З. Мансур, Г. Ахунов, Ф. Хатипов, М. Тутаев, Р. Сибгатов, В. Ганиев кебек тел галимнәре, язучылар, тәрҗемәче-практиклар язалар. Бу хезмәтләр тәрҗемә теориясен гыйльми яктан эшли башлауга беренче адым булдылар, әмма теориянең үзенә үк барып җитмәделәр.

1962 елны Казанда тәрҗемәчеләрнең бөтен Россия киңәшмәсе үткәрелде, киңәшмә татар тәрҗемәчеләренә гаять зур кызыксыну уятты. «Казан утлары» журналы С. Липкин һәм М. Тутаев мәкаләләрен бастырып чыгарды, Татарстан китап нәшрияты киңәшмә материалларын туплап, «От знакомства к родству» исемле русча җыентык бастырды. Киңәшмәдән соң «Социалистик Татарстан» газетасында тәрҗемәгә багышланган зур гына дискуссия үткәрелде.

1970 елны Р. Сибгатов «Тәрҗемәгә ике төрле караш» исемле мәкалә бастырды. Автор мәкаләсенең ахырында татар тетендә тәрҗемә теориясенең инде төп контурлары сызылган булуын, тиз арада аның аерым бүлекләрен җентекләп эшләү башланачагын әйтте. Шуңа җавап төсендә дип әйтерлек, 1970 елны Р. Юсуповның «Билингвизмның бер төре буларак тәрҗемә» дигән мәкаләсе русча җыентыкта[3] басылды. Автор тәрҗемәнең аерым проблемаларын теоретик нигезли. Бу чыннан да гыйльмилекне дәгъва кылырлык хезмәт, әмма кайбер төгәлсезлекләре бар. Р. Юсупов тәрҗемәдә лингвистлык теориясен яклый, әдәбилек теориясен кире кага. А. В. Федоров алга сөргән лингвистлык теориясенең кайбер аспектларына аеруча басым ясавы сәбәпле, Р. Юсупов башка теорияләрне игътибарсыз калдыра, лингвистлык теориясе дә бер яклырак аңлатыла. Тәрҗемәгә әдәбилек теориясе таләп иткән нәрсәләрне — оригиналның рухын саклау, аһәңлелек, ритм, хис-тойгыларга тәэсир итүне Р. Юсупов икенче дәрәҗәдәге нәрсәләр дип карый. Ул, әсәр пунктуаль

[1] Г. Хантемирова. Национальное своеобразие оригинала и проблемы перевода. Казань, 1974; Р. А. Юсупов. Тәрҗемә теориясенә кереш. Казан, 1972.

[2] И. Гази. Уңышлы бер адым. «Совет әдәбияты», 1935, № 8; Тәрҗемә принциплары турында. «С. Ә.», 1936, № 3; Тәрҗемәдә формализмга каршы. «С. Ә.», 1952, № 9.

[3] Ученые записки КГПИ. 74 нче чыгарылыш. Казан, 1970, 56—73 битләр.

тәгәллек белән, җөмлә артыннан җөмлә, сүз артыннан сүз эшләнүе хәерлерәк, дип саный.

Менә Р. Юсуповның «Күтәрелгән чирәм» романы тәрҗемәсеннән уңышлы дип алган мисалы:

« — Я, товарищи, сам — рабочий Краснопутиловского завода. Меня послала к вам коммунистическая партия и рабочий класс, чтобы помочь вам организовать колхоз и уничтожить кулака как общего нашего кровососа. Я буду говорить коротко. Вы должны все соединиться в колхоз, обобществить землю, весь свой инструмент и скот. А зачем в колхоз? Затем, что жить так дальше, ну невозможно же. С хлебом трудности оттого, что кулак его гноит в земле, у него с боем хлеб приходится брать! А вы рады сдать, да у самих маловато. Середняцко-бедняцким хлебом Советский Союз не прокормишь! Надо больше сеять...»

« — Иптәшләр, мин үзем Кызыл Путиловчы заводы эшчесе. Мине монда колхоз оештыру өчен һәм барыбызның да канын суыручы кулакны бетерешүдә ярдәм итү өчен безнең коммунистлар партиясе һәм эшчеләр сыйныфы җибәрде. Мин сүзне озынга сузмыйм. Сез барыгыз да колхозга кереп җирләрегезне, бөтен эш кораллагыгызны һәм терлекләрегезне берләштерергә тиешсез. Колхозга керү ни өчен кирәк соң? Киләчәктә болай яшәү мөмкин булмаганга кирәк! Ни өчен икмәк мәсьәләсе шундый кыен: чөнки кулак икмәкне җиргә күмеп черетә, икмәкне аннан тартып-талап алырга туры килә. Сез менә бик бирер идегез дә, икмәгегез үзегезгә дә аз. Советлар Союзын урта хәлле һәм ярлылар икмәге белән генә туендырып булмый. Моның өчен игенне күбрәк чәчәргә кирәк...» [1].

Шушы өзекне китергәннән соң Р. Юсупов менә нәрсә ди: «Бу өзектән күренгәнчә, хәтта әдәби текстта да, «әдәбилек теориясен» яклаучыларга капма-каршы буларак, сүзләр тәңгәллеге, эквивалент тәңгәллек өстенлек ала. Шул ук вакытта бу өзекнең тәрҗемәсен берничек тә хәрефкә-хәреф дип әйтеп булмый, чөнки анда тел нормаларын бозу юк, Давыдовның кайнар тойгылы ялкынлы рече татарчада да тулысынча сакланган» [2].

Чыннан да, тәрҗемә тәңгәл, тәрҗемә хәрефкә-хәреф тә түгел, татар теленең нормалары да бозылмаган, ләкин Давыдовның «кайнар тойгылы ялкынлы рече» сакланып җиткәнме монда?

Беренче җөмләне тикшереп карыйк. «Я, товарищи, сам — рабочий»,— ди Давыдов. Ягъни логик басым — эшче сүзенә төшә, аннан соң гына **Кызыл Путиловчы заводы** эшчесе икәне өстәмә рәвештә аңлатыла. Болай куюның хикмәте нәрсәдә? Мин, иптәшләр, үзем эшче кеше, Кызыл Путиловчыдан мин, дип әйтергә тели Давыдов,— анда да эшем муеннан, ләкин менә сезнең хәлегез бик кыен бит, икмәксез яшисез, шуңа күрә коммунистлар партиясе һәм эшчеләр сыйныфы мине сезгә ярдәм итешергә җибәрә, дип әйтергә нияте.

Ә менә лингвистлык теориясе тарафдары Р. Юсупов яклап чыккан тел нормаларын (әдәби тел нормаларын дип әйтү дөресрәк булыр иде) бозмаган тәрҗемә: «Мин, иптәшләр, үзем Кызыл Путиловчы заводы эшчесе». Бердән, моңа подтекст (эчке мәгънә) салып булмый, бары тик фактны констатацияләү генә булып кала. Икенчедән, тартым кушымчаларының рәттән тезелеп килүе җөмләне сүлпәнләндерә. Димәк, Давыдовның рухы, ихласлыгы, халык вәкиле, эшче сыйныфы вәкиле булуы югала, ул бик дөрес әдәби формада сөйләүче коры кеше булыбрак күз алдына килеп баса [3].

Без Р. Юсуповның лингвистлык теориясе тарафдары икәнен әйткән идек, әлеге теориянең авторы Андрей Венедиктович Федоров үзе дә «Тәрҗемә теориясенә кереш» исемле хезмәтендә оригиналның әнә шул аспектларын, ягъни «рухын»,

---

[1] М. Шолохов. Күтәрелгән чирәм. I китап, Казан, 1966. Я. Халитов тәрҗемәсе.

[2] Күрсәтелгән җыентык, 61—62 битләр.

[3] Әлеге өзек Яхъя Халитовның тәрҗемәче буларак осталыгын билгели торган өзек түгел. «Тын Дон», «Күтәрелгән чирәм», «Яңа тормышка», «Уленшпигель турында хикәят» китапларында Я. Халитов үзен талантлы тәрҗемәче, тел остасы итеп танытты, ул китаплар инде татар халкының үз культура хәзинәсенә әверелделәр. Шундый ук сүзне К. Миңлебаев, Р. Даутов, Т. Нурмөхәммәтов тәрҗемәләренә карата да әйтергә була. Мин монда Я. Халитов тәрҗемәсеннән бигүк уңышлы булмаган бер өзекне алганмын икән, лингвистлык теориясе тарафдары Р. Юсупов ул өзекне һәр җәһәттән җитлеккән, әдәби тәрҗемәнең иң югары үрнәге дип күрсәткәнгә күрә генә алдым.

«музыкасын», «ритмын», «ассоциативлыгын» сакларга кирәклеген кат-кат әйтә, алардан башка тәрҗемә оригиналның тәссез бер шәүләсе булып кына кала, ди.

Утызынчы-кырыгынчы елларда тәрҗемәдә формализм көчле булган. Әдәби практикада моның күп төрле мисалларын күрергә була; хәтта Шәриф Камал кебек күренекле зур язучы да «Күтәрелгән чирәм»нең беренче китабын тәрҗемә иткәндә күбесенчә формаль алымнар белән эш иткән. Шунлыктан нәшрият бу әсәрне соңгы елларда кабат тәрҗемә иттерергә мәҗбүр булды.

Сугыштан соң әдәби тәрҗемәдә формализмга каршы кискен көрәш ачыла. Формализм мәктәбен яклаучылар инде беткән булырга тиеш иде кебек. Әмма Р. Юсупов мәкаләсе кебек формализмны яклаучы хезмәтләр тагын калкып чыга. Лингвистлык принцибына корылган тәрҗемәләрдә тышкы яктан һәммә нәрсә үз урынында — оригиналның мәгънәсе дә идентик дөрес, татар теленең грамматик-синтаксик формалары да саклланган, ләкин тәрҗемә үзе күңелдә канәгатьсезлек тойгысы калдыра. Безнең карашка, моның сәбәбе, беренчедән, гомум тәрҗемә теориясенең төп принципларын белмәүдән һәм Татарстанда хосусый тәрҗемә теориясе эшләнмәгәннән килә.

Тәрҗемә практикасыннан тагын бер мисалга тукталыйк. Михаил Бубеновның «Ак каен» романы «Шел листопад» дигән җөмлә белән башланып китә. Тәрҗемәче Шәйхи Маннур аны гаҗәеп төгәл һәм образлы тәрҗемә итә: «Шаулап яфрак коелган чак иде», ди. Бер карасаң, оригиналдан ерак җөмлә килеп чыкты кебек. Ләкин шул ук вакытта оригиналның «рухы», «музыкасы» «ассоциативлыгы» бик дөрес бирелгән: «Ш-ш-шел... Ш-ш-шаулап...» Без моны иҗади тәрҗемәнең матур бер үрнәге дип саный алабыз. Шәйхи Маннур моны хосусый тәрҗемә теориясен белеп эшләгән дип ялгышмыйк, бу очракта әдипнең телгә булган сизгерлеге, интуициясе ярдәм иткән.

Көн тәртибенә хосусый тәрҗемә теориясен эшләү мәсьәләсе килеп басты. Безгә тәрҗемә методларын шундый итеп эшләргә кирәк ки, тәрҗемәчеләребез аларны ныклы ышаныч белән куллана алсыннар. Моның өчен оригиналь әсәрдә сурәтләнгән тормышны аңлы рәвештә өйрәнү, шул ук вакытта оригиналны аңа тәңгәл килердәй чаралар белән икенче бер телдә яңгырата алу кирәк. А. В. Федоров сүзләре белән әйткәндә: «...ике телнең дә структурасында булган аермалыкны тирәнтен аңлау гына тәрҗемәчене теләсә нинди әдәби әсәрне мәгънәви ялгыш тәрҗемә итүдән һәм хәрефкә-хәреф аударып куюдан коткарып кала ала».

Гомумән тәрҗемә теориясен, димәк ки, «әдәбилек» белән «лингвистлык» теорияләренең синтезын тирәнтен аңлау кирәк. Шундый синтезның конкрет, реаль чагылышын, безнеңчә, тәрҗемәдә сәнгатьчә компенсация методы бирә ала.

Компенсация методы турында Максим Рыльский язып чыкты: «Бу метод, күрәсең, кирәк нәрсә: компенсация ясау, теш үтми торган детальне икенче бер деталь, тәрҗемә ителә торган телгә хас деталь белән көчәйтү. Кайвакыт компенсациянең янәшә булмавы, ерактарак булуы да ихтимал, чөнки... биредә хәлиткеч фактор — гомуми колорит, үзәк тон, аһәңлелек. Әйтик, геройның культурасызлыгын, шаянлыгын, аңгыралыгын, тапкырлыгын яки башка шундый сыйфатларын фразадагы җиденче яки унынчы сүз түгел, бишенче сүз характерлавы ул кадәр үк мөһиммени?»[1]

Ләкин М. Рыльский компенсация турында сөйләгәндә бу төшенчәне таррак мәгънәдә, «саф» компенсация мәгънәсендә, анда да аерым сүзне компенсацияләү мәгънәсендә генә алган. «Саф» компенсация безнең тәрҗемәчеләр практикасында гадәттән тыш аз очрый. Күрәсең, тәрҗемәчеләр аның тышкы кыяфәте ирекле тәрҗемәгә тартым булудан курка торганнардыр. Компенсациянең икенче бер төре, гомуми тәрҗемә теориясендә «опосредствованная» дип йөртелә торганы күбрәк очрый, татарчада без аны «әйләнмәле компенсация» дип алырга булдык.

Әйләнмәле компенсациядән без тәрҗемәдәге шундый методны аңлыйбыз: тәрҗемәче оригинал бирәмлегенең татар телендә шундый ук идентик бирәмлеген таба алмаганга күрә, безнең телдәге икенче бер сүзләр белән алыштыра. Бу сүзләр төгәл тәрҗемәне бирмиләр, оригиналның рухын бирәләр.

---

[1] М. Рыльский. Чехов в украинском переводе. Кара: «Мастерство перевода», М., 1970.

**Әйләнмәле компенсация** шактый киң төшенчәне эченә ала, шуңа күрә без бу методны дүрт төргә бүлеп карыйбыз: локаль компенсация, ялгызак компенсация, фраза компенсациясе, контекст компенсациясе.

Компенсация методы турында сөйләгәндә без оригиналь әсәрнең тәрҗемәгә бирешми торган өлешләрен истә тотабыз. Мәгънәви һәм сәнгатьчә әһәмияте ягыннан оригиналга адекват итеп тәрҗемә итү мөмкинлеге булганда компенсация методы куллану үз-үзен акламый, кулланган очракта да бу ирекле тәрҗемә булып кына саналырга тиеш. Оригиналдан тәрҗемә итеп булмый торган өлкәләргә без рус телендәге лексик катлаулардан сөйләү деффектын (чит ил кешесенең сүзе, акцент белән сөйләү, тотлыгу, сакаулану һ. б. ш.), неологизм, эффеизм, оксиморон, историзм, архаизм, фразеологизм, диалектизм, жаргон, термин, гади катлам халык сөйләшен алабыз. Мондый очракларда компенсация методы бик әйбәт нәтиҗәләр бирә.

**Локаль компенсация.** Бу төр компенсация бер сүз эчендә бара, ягъни тәрҗемә итәргә кыен булган сүзнең фонемалары, морфемалары татар теле чаралары белән бирелә.

«Мочаров-сан модзет выразить по-русски,— сказал он, не выговаривая, как все японцы «л» и «ж» и по птичьи присвистывая на «с» — я есть впорьне свободно понимать русски».

«Мочаров-сан русча да әйтә ала,— диде ул. Японнарның барысы шикелле үк Охаси әфәнде дә «л» һәм «җ» авазларын әйтә алмый, ә «с» авазы кош сызгырган кебек сызгырып чыга иде.— Русчаны әйбәт беләм мин».

«Моя газета,— заговорил Охаси, не сводя взгляда с Мочалова,— дзерает знать биография Мочаров-сан».

«Мочаловка туп-туры караган килеш, Охаси тагын сүз башлады:

— Минем газетам,— диде ул, тагын «җ» һәм «л» авазларын бозып,— Мочаров-санның биографиясен белергә тели» [1].

Бу очракта русча текстның авторы Б. Лавренев япон кешесе телендә нинди фонетик бозулар барлыгын аермачык күрсәтеп биргән. Шуның өстәвенә, ул бозулар аерым сүзләрдә дә китерелә (мәсәлән, **может** урынына модзет, **желает** урынына дзерает). Оригиналда синтаксик һәм грамматик бозулар да бар. Тәрҗемәче татар теле җирлегенә сүзләрдәге фонетик бозуларны күчерергә теләми, чөнки бу хәл, беренчедән, тәрҗемәне аңлашылмый торган итәр иде, икенчедән, япон кешесе татар телен бозмый бит, рус телен бозып сөйләшә. Әйтик, япон кешесенең фонетик бозулары татар теленә дә шулай бозып күчерелсә, бу хәл татар теленең бер диалекты яки берәр төрки теле сөйләме булып кына аңлашылыр иде. (Әйтик, татар-башкорт телләрендәге «ч»-«с», «с»-«һ» кебек: «чабата-сабата, сылу-һылу.) Тагын шунысы кызыклы: тәрҗемәче татарча да, русча да бер үк төсле яңгырый һәм семантик йөк алып килми торган «Мочаров-сан»ны шул килеш калдыра, ягъни Мочалов Мочаров булып бозыла. Япон кешесенең телендәге нинди авазлар бозылганны тәрҗемәче икенче җөмләдә дә безнең исебезгә төшерә (диде ул, тагын «җ» һәм «л» авазларын бозып), шул хәл геройның сөйләмендәге чатаклыкларны укучының хәтеренә сеңдерергә җитә. Димәк, бу очракта тәрҗемәче геройның индивидуаль сөйләмендәге кимчелекне турыдан-туры тәрҗемәдә кабатлау юлы белән түгел, шуны укучыга аңлатып бирү юлы белән компенсацияли.

Оригиналда рус телен бозу очрагын тагын бер мисалда карыйк.

«Маладец! Далше...» — «Җигит икенсең! Андан...»

«Дырехтур стрычь-брыть дарам...» — «Дырехтурның чәчене бушлай алырга кирек...» [2]

Таулы черкесның бугаз арты авазлары белән сөйләшүе фонетик бозуларга алып килә. Грамматик бозулар да бар. Синтаксик бозулар аз, алары тәрҗемәдә искә алынмаган. Ибраһим углы романда шактый урынны алып торган персонаж, шуңа күрә тәрҗемәче аерым фонетик бозуларны күчерү белән генә чикләнмичә, компенсация методын киң куллана. Без «Хәсрәт дәрьясы»ның ике китабын да карап чыктык, дөресен әйтергә кирәк, таулы черкесның сөйләм телен К. Миңле-

---

[1] Б. Лавренев. Зур жир. М. Габдрахманова тәрҗемәсе.
[2] В. Шишков. Хәсрәт дәрьясы. Казан, 1963. Қ. Миңлебаев тәрҗемәсе.

баев әйбәт бирә алган. Беренчедән, бугаз арты авазлары сакланса, икенчедән, татарчада ясамалылык, оригиналга туры китерәм дип телне юри, мәгънәсез итеп бозу, черкес теленә хас фонемаларны татар теле калыбына өстәү юк. Грамматик яктан да юрамалый бозулар күренми, тәрҗемәче тау ягы халыкларының тел үзенчәлекләрен нык кына өйрәнеп, компенсация өчен яраклы элементларны оста сайлап ала белгән.

Әмма локаль компенсация методы рус телен бозуларны тәрҗемә итүдә генә кулланылмый, лексиканың башка катламнарында да очрый.

«Сорняк из семи букв,— перебивая друг-друга, загалдели мальчишки,— по горизонтали... Погоди, я знаю, сурепка, коровяк, круглец.

— Пупавка,— сказал босой мальчик.

— Крапива... Василек...

— Икотник,— сказал босой мальчик.

— Липучка... молочай».

« — Сигез хәрефтән торган чүп үләне,— дип, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, малайлар шау-гөр килделәр,— горизонталь буенча: тузганак, кырмавык, ак билчән...

— Эт какысы,— диде ялан аяклы малай.

— Кычыткан... Күк тәтәй...

— Кыркырый,— диде ялан аяклы малай.

— Сырганак... сөтлеген» [1]

Бу очракта тәрҗемәче, әлбәттә, төшенчәләрнең рус вариантын — җиде хәрефтән торган чүп үләне исемнәрен алып, аска искәрмә китерә алган булыр иде. Әмма текстның оригиналдагы яңгырашын табу өчен ул «җиде хәрефле чүп үләнен» «сигез хәрефле чүп үләне» белән компенсацияли. Әйтергә кирәк, татарча текстта әнә шул компенсация аркасында чүп үләннәренең исемнәре дә русчадагыга туры килә язалар: крапива — кычыткан, василек — күк тәтәй, липучка — сырганак, молочай — сөтлеген.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, локаль компенсация методы кулланып, тәрҗемәдә оригиналның байтак нюансларын саклап калырга була. Без моны бер сүз күләмендә күреп үттек. Ләкин монда чама хисе, стиль белән исәпләшү булырга тиеш. Уңышсыз компенсациянең аерым сүзне бозып, аның мәгънә йөген үзгәртеп җибәрү очраклары да бар. Югарыда уңай яктан телгә алган К. Миңлебаев тәрҗемәсендә без, мәсәлән, менә мондый уңышсыз тәрҗемәгә тап булдык:

«Вошел верзила в форме тюремного ведомства. Морда бычья, с перекосом.

— Письмо-с!»

«Төрмә ведомствосында эшләүчеләр киеме кигән, колгасар буйлы берәү килеп керде. Бога кебек таза чырайлы, чалыш авызлы.

— Хат китергән идем» [2].

Оригиналда «верзила тюремщик», димәк ки, усал чырайлы, нык кеше, каты тәртипләргә өйрәнгән кеше, җитмәсә, «морда бычья, с перекосом», рәсми рәвештә керә, дәрәҗәсен бик яхшы белеп, өзеп кенә әйтә: «Письмо-с!» Татарча тәрҗемәдә исә «колгасар буйлы берәү» керә, якын дустына, күптәнге танышына кергәндәй керә, гүяки: «Дус кеше, ни йомыш?» дигән сорауга җавап биргән төсле, дустанә аңлатып бирә: «Хат китергән идем». Авторның «верзила»сы бу очракта юашлана, димәк, бу берничек тә компенсация була алмый, ирекле тәрҗемә булып кына кала. Локаль компенсацияне аңлы рәвештә түгел, интуитив рәвештә генә куллану К. Миңлебаевны да вакыт-вакыт уңышсызлыкларга алып килә. «Хәсрәт дәрьясы»ннан тагын бер мисал алып карыйк:

— Наденька, сходи в погреб за рыжычками... И наливочка там... понимаешь, в бочоночке... нацеди в графинчик...

— Наденька, нәүрәпкә төшеп гөмбә алып менәр идең... Шәраб тә шунда... беләсеңме, мичкәдә... Графинга агызып ал шуннан...

Рыжычки, наливочки, бочечки, графинчик — пристав Амбреевны, үз корсагы өчен генә яши торган тәмле тамакны, исерекбашны, азгын кешене бик әйбәт ачып

[1] С. Антонов. Аленка. Хикәяләр җыентыгы, Казан, 1968, Ш. Максудова тәрҗемәсе.
[2] В. Шишков. Хәсрәт дәрьясы. Казан, 1963, К. Миңлебаев тәрҗемәсе.

бирә торган сүзләр, ул аларны уйлап та тормастан әйтә, алар аның канына сеңгән. Тәрҗемәдә боларның берсе дә юк. Юк, чөнки бездә берәү дә: гөмбәкәй, мичкәкәй, шәрәбкәй, графинкәй дип сөйләми. Нишләргә? Төшереп калдыру белән образ кими, пристав Амбреев югала. Менә шушындый очракларда компенсация методы ярдәмгә килә дә инде. Амбреев шушы сүзләр тирәсендә авыз суын корыта бит. Шуңа күрә пристав Амбреев ул әйберләр тирәсендә татарча да авыз суын корытсын иде.

Безнең карашыбызча, локаль компенсация методы татар тәрҗемәчеләре эшендә киң куллану таба ала. Аннан да бигрәк, татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә иткәндә бу метод зур уңышка китерүе мөмкин. Чөнки русчага тәрҗемә ителгән байтак кына проза әсәрләребездә татар теленең русчада булмаган үзенчәлекләре коеп төшереп калдырылалар.

Без тикшерә торган компенсация методының икенче бер төре — ялгызак компенсация. Бу оригиналдагы аерым сүзне татар теленең үз чаралары белән компенсацияләү. Бу очракта да төп бурыч — мәгънәне, рухны, тәэсирне бирү. Оригиналдагы мәгънә берәмлекләренең шушы аспектлары оригиналдан ерак булган сүзләр белән дә, аерым җөмләләр белән дә бирелә ала. «Хәсрәт дәрьясы»ннан тагын берничә мисал китерик.

«Прохор с утра удалился в тайгу без ружья и шел неведомо куда, ошалелый».

«Прохор иртә таңнан, мылтыксыз гына, урманга китте, кая барганын белмичә, әйләнчек сарык шикелле, йөрде дә йөрде».

Бу очракта «ошалелый» сүзе «әйләнчек сарык шикелле» дигән чагыштыру тәгъбире белән компенсацияләнә.

Ялгызак компенсация татар тәрҗемәләрендә шактый күп очрый.

«И так хорошо, так тихо стало на душе: огонек мелькает, **перебулькиваются** капельки в ночи».

«Күңеленә шул чаклы рәхәт, шул чаклы тыныч булып китте: ут җемелди, төнге тамчылар **чулт-чулт сөйләшәләр**». («Хәсрәт дәрьясы»ннан.)

«Перебулькиваются» дигән автор неологизмы татарчада тавыш уйнату сүзе белән компенсацияләнә.

Истән чыгармаска тиешбез, неологизмнар русча оригиналда бик еш очрыйлар. Әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрү аркасында неологизмнар сәнгать чарасы булып эвереләләр. Бу бигрәк тә балалар ясаган неологизмнарда шулай. Неологизмнарны тәрҗемә итү ифрат авыр, чөнки алар үзләре белән семантик, эмоциональ, ассоциатив йөк алып киләләр. Неологизмнарны төшереп калдыру оригиналны фәкыйрьләндерүгә, уңышлы компенсацияләнгән неологизм тәрҗемәне баетуга алып килә.

«Ну уж, какой из тебя крыльщик!» — «Һи, синең түбә ябуың!» [1]

«Я инде, син нинди түбә ябучы!» [2]

Неологизм — «крыть» сүзеннән. Беренче тәрҗемәдә Я. Халитов кыенлыктан грамматик әйләнмә белән чыга (синең түбә ябуың!), ягъни неологизмны грамматик әйләнмә белән, мәгънәдәге усал чеметеп алу төсмере белән бирә. Ш. Камал оригиналга ябышып кала, шул сәбәпле неологизм да югала, оригинал да бигүк чын татарча булып чыкмый. (Син нинди түбә ябучы!)

Атаклы балалар язучысы Корней Чуковскийга мөрәҗәгать итеп карыйк:

«Ой, как живет больнуло!» — Бу җөмләне «Икедән бишкә кадәр» дигән атаклы китаптан алдык. Бу грамматик неологизм бала хисенең кинәт һәм кискен булуын хәбәр итә («кольнуло» белән бәйләнгән). Татарчада моны турыдан-туры бирердәй тәңгәл сүз табу шактый кыен эш, компенсация методы кулланган чакта, баланың ассоциативлыкны тиз отып алуын истә тотып: «Ай, эчемне авырттырды» — дип компенсацияләп булыр иде.

Неологизмнарның кайбер төре фразеология белән, образлы әйләнмәләр белән кушылалар. Китерелгән тәгъбир неологизмны яки образлы әйләнмәме икәнен дә әйтеп бирү кыен була.

[1] М. Шолохов. Күтәрелгән чирәм. Казан, 1966. Я. Халитов тәрҗемәсе.
[2] М. Шолохов. Күтәрелгән чирәм. Казан, 1935. Ш. Камал тәрҗемәсе.

«Ты — хлебный токарь». — «Икмәк корты гына бит әле син».

«...хлебные токари...» — «...ипи черткечләр...» [1]

Күреп торабыз, бер үк тәгъбир ике очракта ике төрле тәрҗемә ителә, әмма аларның мәгънәсе икесенеке дә бер төсле. Тегесендә дә, монысында да «хлебный токарь» татарча образлы әйләнмә белән компенсацияләнә.

Әмма ялгызак компенсациянең барлык очракта да уңышлы булып чыкмавы да бик ихтимал. Г. Ахунов тәрҗемәсендә А. Макаренконың «Педагогик поэма»сыннан бер мисалны тикшереп карыйк.

«— Драствуйте, с праздником... а как же это так, разрешите полюбопытствовать, на каком мандате основано такое самовольное втручивание, что разбиваете у людей аппараты, которые вы права не имеете».

«— Исәнмесез, бәйрәм белән... бу ничек була инде бу, кызыксынырга рөхсәт итегез әле, мондый үзбаш тыгылып йөрүегез нинди мандатка нигезләнгән, кешеләрнең аппаратларын ватып йөрергә ни хакыгыз бар?»

А. Макаренко романындагы украин кулагының бик кызыклы, кулакка хас сөйләме, дөресен әйткәндә, бик төссез тәрҗемә ителгән. Украинизмнан «втручение»нең «тыгылып йөрүегез» дип бирелүе белән генә азмы-күпме килешергә була.

Автор эпитетларын, образлы тезмәләрне тәрҗемә итү өчен татар теленең үткен чагыштырулары кулланыла, кайчагында, киресенчә, оригиналдагы образлы чагыштыруларны тәрҗемәченең үзе генә эзләп тапкан конструкциясе дә алмаштыра. Югарыда берничә мәртәбә мисалга алынган «Хәсрәт дәрьясы»ннан тагын бер мисал:

«— ...Эх, ты... елеха-воха... Чижик!»

«— ...Их, син, гөмбә гөбәдиясе!»

Гади сөйләмдә әйтелә торган «елеха-воха... Чижик!» — оригинал сүз тезмәсе булган «гөмбә гөбәдиясе» белән компенсацияләнә. Татарчада бу үзенә күрә бер оксиморон! Оригиналдагы кебек үк, сәер яңгырашлы, мәгънәсе дә бигүк аңлашылып бетми. «Кәҗә катыгы», «әрекмән боламыгы», «туклыклы күзикмәк» кебек аксимороннар халык телендә байтак очрый, аларны иренмичә җыйганда, тәрҗемәчеләр үзләренә яхшы ук байлык туплый алырлар һәм тәрҗемәгә бирешми торган очраклардан котыла алырлар иде.

Алда әйтеп киткәнебезчә, татарчага тәрҗемәләрдә ялгызак компенсация алымы әйләнмәле компенсациянең башка барлык төрләренә карaганда да күбрәк кулланыла. Моның кайвакыт кире нәтиҗәләре дә була. Андый чакта оригиналның мөстәкыйль образлары төссезләнеп калалар. Әйтик, гөмбә гөбәдиясе бик матур, ләкин ул безне тормыш-көнкүрешкә алып кайта, ә «елеха-воха... Чижик!» урманнарны, табигать дөньяларын искә төшерә. Безгә калса, оригиналның аерым мәгънә берәмлекләрен тәрҗемә итү тәрҗемәчеләрдән күп көч куюны таләп итә.

**Җөмләне компенсацияләү.** Бу төр компенсация оригиналның тулы бер җөмләсен компенсацияләүгә кайтып кала, татарчада җөмлә озынрак килеп чыгамы, кыскаракмы, хикмәт анда түгел, тәрҗемә рухы, образы ягыннан тәңгәл булырга тиеш. Шундый компенсациянең тәрҗемә практикасында мөмкин икәнлеген түбәндәге мисал белән раслый алабыз:

«Какое-то давящее предчувствие легло под его ногами».

«Күңеле хәвеф сизә, йөрәге сыкрый иде».

Күренә ки, бер генә сүз дә оригиналдагы сүз белән тәрҗемә ителмәгән, әмма эчке мәгънәсе белән тикшереп карасаң, тәрҗемә оригиналның мәгънәсен, рухын бик әйбәт бирә, сүз агышында үз урынына бик әйбәт кереп утыра һәм геройның рухи халәтен дөрес ача. Бу мисалны без К. Миңлебаев тәрҗемә иткән «Хәсрәт дәрьясы»ннан алдык.

Контекст компенсациясе. Бу төр компенсацияне без тәрҗемә өчен кыен булган бөтен бер контекстны татар теле чаралары белән компенсацияләү дип аңлыйбыз.

«— Дайте мне, черти, кусочек матери, дайте мне какой-нибудь уют. Мучительно жить так... Тьфу на вас, черти!..»

---

[1] А. Макаренко. Педагогик поэма. Казан, 1957. Г. Ахунов тәрҗемәсе.

«— Бирегез миңа бераз гына булса да ана җылысы, пәриләр, бирегез миңа чеметем генә рәхәт. Газап чигәм бит!.. Газап чигеп яшим... Төкерәм мин сезгә, пәри кавеме!..»

Тәрҗемәче Кыям Миңлебаев фельдшер Носков монологын саф татарча фразалар һәм тәгъбирләр белән биргән. Әмма геройның гасабилануы, текстның образлылыгы тулысынча сакланган.

Татарча тәрҗемәләрдә контекст компенсациясе гадәттән тыш аз очрый, әмма, безнең карашка, бу төр компенсация алга таба рус теленнән татарчага тәрҗемә иткәндә уңай нәтиҗәләр бирер дип ышанырга кирәк.

Без карап-тикшереп узган мисаллардан бер нәтиҗә чыга: тәҗрибәле тәрҗемәчеләр, компенсация методын белү-белмәүләренә карамастан, аны уңышлы гына кулланалар, тик әле бу хәзергә әзлекле рәвештә эшләнми, чөнки системага кермәгән. Шуңа күрә, безнең уйлавыбызча, тәрҗемәдә компенсация методын нигезләү һәм аны гамәлгә кертү хәтта тәҗрибәле тәрҗемәчеләребезгә дә файда китерә алыр иде. Алар моның аша тәрҗемә хезмәтенә формаль карый торган белгечләрдән котыла алырлар, шул теориягә таянып, тәрҗемәдә үз вариантларын, үз принципларын яклый алырлар иде. Тәрҗемә әсәрләрен компенсация методына нигезләнеп анализлау профессиональ тәрҗемәчегә үз өлкәсендәге тәҗрибәне нәтиҗәлерәк файдаланырга, осталыгын тизрәк үстерергә ярдәм итәр иде. Әмма тәрҗемәдә компенсация методыннан иң зур файданы башлап тәрҗемә итүчеләр алачаклар, чөнки бу методны белгән сурәттә алар әдәби осталыкларны үстерү юлындагы кайбер этапларны, мөстәкыйль рәвештә бик зур авырлык белән ирешеп була торган тәҗрибәне әзер килеш алачаклар.

**Габдрахман Таһирҗанов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНДА ИҖТИМАГЫЙ-МӘДӘНИ МӨНӘСӘБӘТЛӘРНЕҢ РОЛЕ

Узган мәкаләбездә[1] әдәбият тарихын төгәл яктырту өчен зарури булган шартлардан этник тарихка, шул этник үзенчәлекләр нигезендә барлыкка килгән тел хосусиятләренә тукталып узган идек. Хәзер исә социаль-иҗтимагый үсешнең аерылгысыз өлеше булган халыкара һәм дәүләтара мөнәсәбәтләргә, шул мөнәсәбәтләрнең гомум культура үсешенә ясаган тәэсиренә, аның әдәби процесстагы нәтиҗәләренә игътибар итәчәкбез.

## ЧАЛ ТАРИХ БИТЛӘРЕН АКТАРГАНДА

Борынгы грек тарихчылары Төньяк Кавказдагы болгарларны «варварлар» дип атаганнар. Ләкин социаль-иҗтимагый үсешнең билгеле бер дәрәҗәсенә ирешеп, «Олуг Болгар» дип аталган зур дәүләтне төзи алган халыкка мондый исем тагу дөрес түгел, әлбәттә. Өстәвенә болгарларның бабалары булган хуннулар башка культуралы илләр, җөмләдән, Кытай һәм Урта Азия халыклары белән тыгыз икътисади, сәяси һәм мәдәни мөнәсәбәттә яшәгәннәр. Болгарлар үзләре дә Төньяк Кавказдагы иран телле сарматлар белән якыннан аралашканнар, хәтта этник мөнәсәбәткә дә кергәннәр. Археологик тикшеренүләр бер сарматларның гына түгел, бәлки болгарларның да матди культуралары нык алга киткән булуын раслый.

Гунн-болгарларга Византия мәдәнияте көчле тәэсир ясаган. Мәсәлән, болгарларның бер «ботагы» булган утигурлар Кече Азиядәге грек дәүләте белән ныклы сәяси һәм икътисади элемтәдә торган.

Югарыда китерелгән фактларга карап, болгарлар гел читләрнең тәэсирендә генә булган икән дигән ашыгыч нәтиҗә чыгарырга ярамый. Чөнки башка халыклар ирешкән мәдәни «җимешләрдән» файдалана алу — үзе зур казаныш. Һәм ул — социаль үсүнең, рухи җитлеккәнлекнең бер билгесе (өстәвенә күрше илләрнең һәм халыкларның культура йогынтысын татымаган бер халыкның да, бер цивилизациянең дә булмавын онытмыйк).

Болгарлар яшәгән төбәкләрдә — Төньяк Кавказ, Дунай һәм Идел буйларында — рун язулы текстлар табыла. Бу да борынгы Төрки каганлыгы чорында ук (ягъни гарәп язуы кабул ителгәнче) аларның үз язулары булганлыгы хакында сөйли. Моның шулай икәнлеген тагын бер факт раслый. Борынгы тарихчыларның әсәрләрендә, мәсәлән, Урта Азия төркиләре арасында балаларны яшьли уку-язуга, исәп-хисапка өйрәтү өчен махсус йортлар булуы, шунда булачак грамоталы сәүдәгәрләр әзерләнүе хакында бик ачык әйтелгән. Зур төрки дөньяның бер өлешен тәшкил иткән Идел буе болгарлары тормышыннан да шундый ук хәлләрне күзәтергә мөмкин. Әйтик, Х гасыр башында сәяхәт иткән Ибне Рустә аларның шәһәрләрендә генә түгел, хәтта авылларында да мәктәпләр булуын яза.

Рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәч, Урта Азия һәм Иран илләре белән тыгыз мөнәсәбәттә торган Кама-Идел болгарлары гарәп язуын куллана башлыйлар: Х йөз башында ук төрле болгар ханнары тарафыннан тәңкәләр сугылу шуны раслый. Ә акча сугуга ихтыяҗ, мәгълүм булганча, эчке товар алмашу һәм халыкара сәүдәнең үсүе нәтиҗәсендә генә туа. Бу чорда күп кенә шәрык илләрендәге зур шәһәрләрдә дә (Бохара, Сәмәрканд, Балх, Бәйһак, Сәбзевар, Амоль һ. б.) болгарларның махсус сәүдә колонияләре булуы — шуңа өстәмә дәлил.

Бабаларыбызның ерак илләр белән сату-алу итүләре хакында сөйләп тә, аларның үз күршеләре, ягъни Урта Идел буе

[1] Авторның беренче мәкаләсен журналның 1975 елгы җиденче саныннан карагыз.

һәм гомумән Көнчыгыш Европа халыклары белән булган дәвамлы мөнәсәбәтләрен читләтеп узу һич тә гаделлек булмас иде.

Мәгълүм булганча, Урта Иделгә килеп утырган болгарлар, тиз арада җирле халыкларны буйсындырып, алар өстеннән хакимлек урнаштыралар. Бу факт болгарларның матди һәм рухи культура өлкәләрендә, хәрби төзелеш мәсьәләсендә чагыштырмача югары дәрәҗәдә торулары хакында сөйләсә кирәк. Әмма бу якларда элек-электән үк яшәп, географик һәм табигать шартларына тәмам яраклашып беткән борынгы финн-угор халыкларының матди-хуҗалык культуралары да, үз нәүбәтендә, кичәге ярым күчмә болгарларның көнкүрешенә, экономикасына тәэсир ясамый калмаган, әлбәттә. Менә шулай ике төрле культураның кушылуы нәтиҗәсендә яңа өченче культура — Идел буе болгар-татар культурасы формалашуга җирлек туа.

Болгарларның экономикасы, хуҗалыгы үсүдә сәүдә зур роль уйный. Сату-алу эшләрендә болгар товарларының мөһим өлешен җәнлек тиреләре, кыйммәтле сөякләр (морж тешләре), бал һәм балавыз, балык җилеме һәм башка нәрсәләр тәшкил иткән. Бу әйберләрне җитештерүдә җирле халыклардан финн-угор кабиләләренең өлеше зур икәнлеген онытырга һич тә ярамый. Гарәп чыганакларыннан күренгәнчә, болгарлар мондый товарларның бер өлешен якын күршеләреннән алганнар, икенчеләрен ерак өлкәләрдән алып кайта торган булганнар.

Язма чыганаклардагы хәбәрләргә караганда, Болгар базарларында бик күп илләрнең сәүдәгәрләре очрашкан, алар, төрле-төрле товарлар белән бергә, ак тәнле, бигрәк тә шәрык илләрендә дан казанган сылу кәнизәк-җарияләр белән дә сату иткәннәр. Боларның зур өлешен нигездә төньяк сәкалибәләре — финн-угор һәм славян кабиләләренең сәүдәгәрләре китереп саткан (мәсәлән, Ибне Фазлан рус сәүдәгәрләренең Болгарга күпләп кол кызлар китерүен тәфсилләп яза). Гомумән, болгарлар башка күрше кавемнәрнең дә халыкара сәүдә-экономик мөнәсәбәтләргә керүенә актив булышлык иткәннәр. Төньяк Урал, Рус иңкүлекләре, хәтта Балтик буе төбәкләрендә дә күпләп-күпләп Урта Азия һәм гарәп илләре таңкәләре табылуы шуны күрсәтә. Мондый акчаларның рус-славян һәм финн-угор җирләренә Болгар аша килгәнлеге хәзер бер белгечтә дә шик-шөбһә уятмый.

Болгар дәүләтенең рус князьлекләре белән политик, экономик мөнәсәбәте аерата игътибарга лаек. Бу өлкәдә без болгарларның ифрат актив булуын күрәбез. Мәсәлән, үзләре ислам динен официаль идеология рәвешендә кабул иткәч, болгарлар, һаман мәҗүсилектә калган русларны да шул дингә керергә өндәп, Киевка махсус илчеләр җибәргәннәр. Аларның үз күршеләрен идеологик яктан да ышанычлы союзниклар итәргә тырышулары, әлбәттә, күп нәрсә турында сөйли.

Вакыт-вакыт сугышып алуларын исәпкә алмаганда, болгарлар һәм руслар арасында нигездә тыныч мөнәсәбәтләр хөкем сөргән. Хәер, ахыр чиктә сугышлар да иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләрнең бер төре генә бит. Мәсәлән, князь Святославның 968 елгы һөҗүменнән соң күп кенә болгар осталары, һөнәрчеләре Владимирга күчерелә (шулар төзегән чүлмәк ясау мастерскойларының калдыклары археологларга яхшы мәгълүм). Әлбәттә, үз нәүбәтендә болгар һөнәрчеләре дә рус осталарыннан күп нәрсәгә өйрәнгән.

Күренекле рус тарихчысы В. Н. Татищев дөрес билгеләгәнчә, Болгар иле руслар белән тыгыз экономик бәйләнештә торган. Болгар җиренең табигый байлыгы, алга киткән авыл хуҗалыгы моңа зур мөмкинлек тудырган. Әйтик, 1024 елда, Суздальда ачлык хөкем сөргәндә, руслар Болгардан бик күп ашлык алып торганнар. 1228—29 елларда бөтен Русьта, бигрәк тә Новгород һәм Белозерскийда ике елга сузылган көчле кытлык була, шунда болгарлар Идел һәм Ока сулары буенча кәрван-кәрван ашлык озаталар, ә болгар ханы Новгород кнәзенә утыз көймә икмәкне бүләк итеп җибәрә.

Архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дә болгар-рус мөнәсәбәте дәвамлы булган. Мәсәлән, 1230 елда князь Святослав Всеволодович Юрьев шәһәрендә (хәзерге Тарту, Эстониядә) бабасы салган иске чиркәүне җимереп, аның урынына болгар осталарыннан таш гыйбадәтханә салдыра. XII йөз ахыры XIII гасыр башында болгар архитекторлары Владимир-Суздальны төзүгә актив катнашалар. Әйтик, шәһәрдәге иң зур биналарның берсе — Успенский собор — болгар осталары Болгардан ук китергән ак таштан салына. Академик Б. Д. Греков ның әйтүенә караганда, рус халкының көнкүреш сәнгатенә шәрык халыклары орнаменты нәкъ менә шундый эзлекле һәм дәвамлы мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә үтеп кергән.

Мисал өчен китерелгән бу фактлар болгарларның, заманында югары культурага һәм көчле экономикага ия булып, төрле кардәшләре, якын һәм ерак күршеләре белән тыгыз бәйләнештә торуларын күрсәтә. Бәс, шулай булгач, болгарларның рухи культурасын да, шул рухи культураның бер өлешен тәшкил иткән әдәбиятын да без киң социаль-иҗтимагый тарих фонында карарга, җәмәгатьчелеккә дә шул фон белән бергә күрсәтергә тиешбез. Бары шулай эшләгәндә генә болгар культурасы ни дәрәҗәдә үскән булуын дөрес яктырта алачакбыз. Ә бабаларыбызның мәдәнияте чыннан да югары булган. Моның шулай икәнлеген түбәндәге фактлардан күрергә мөмкин.

XI гасыр башында яшәгән Идел буе галиме Әхмәд Болгари үз илендә генә түгел, бөтен Урта Көнчыгышта билгеле

булган. Аның «Әл-җамигъ», «Әт-тарика», «Әл-фәваид» кебек гарәпчә язылган китаплары бөтен шәрыкта дан казанган, аны мактап шагыйрьләр фарсыча шигырьләр язганнар.

Биләр шәһәренең баш казыйсы Ягъкуб ибне Ногман Нишапурлы бөек галим Әбелмәгали Җөвәйнинең шәкерте булган. Соңрак Болгарга кайткач, ул «Тарихы Болгар» исемле гарәпчә әсәр язган. Бу хакта сәяхәтче Әбү Хамид әл-Әндәлүси һәм энциклопедист галим Зәкәрия Казвини хезмәтләрендә әйтелә. XII гасырда яшәгән Әбелгалә ибне Идрис әл-Болгари шул чорның мәдәни үзәкләреннән булган Бохара, Нәсәф, Нишапур галимнәре белән даими элемтәдә торган, 1185 елда Сәксин шәһәрендә бер әсәр язган. (Сөләйман Ибне Дауд Сәксини аны «олуг галим», төрле фәннәрдә тиңдәше юк белем иясе дип мактаган.) 1204 елны үлгән Борһанетдин Ибраһим ибне Йосыф әл-Болгари Сәмәрканд һәм Нәсәф галимнәре иҗат иткән «Адәб», «Осул» исемле китапларга шәрехләр (комментарийлар) язып, шул хезмәтләре белән гарәпчә библиографик тупламнарга кергән. Бу мәгълүматларның һәммәсе дә Ш. Мәрҗанинең «Мостафад...» китабыннан алынды.

XIII гасыр башында Гыйрактагы Мосул шәһәрендә Болгардан килгән ике галим яшәгән: Таҗетдин ибне Йоныс әл-Болгари һәм аның энесе Хәсән ибне Йоныс әл-Болгари. Болгардан агасы иҗат иткән «Әт-тирьяк әл-кәбир» исемле дарулар, ягъни фармакология буенча китапны энесе Хәсән заманының зур врачы Бәдретдин Мәхмүд ибне Госман өчен күчереп биргән булган. Мосул шәһәрендә 1220—21 елда күчерелгән шул нөсхә Иранның Сенат китапханәсендә саклаunion калган («Мәҗлиси Сина көтепханәсе»нең каталогы. Тәһран, 1962 ел, 244 — 245 битләр).

Фармакология гыйлеменнән тыш, болгар галимнәре астрономия һәм башка төгәл фәннәр белән дә актив шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, 1135 елда Болгарга сәяхәт ясаган Әбү Хамид әл-Әндәлүси кайбер Болгар астрономнарының ерак Төньякка барып, күк җисемнәрен тикшереп йөрүләре хакында хәбәр итә. Алар, әлбәттә, астрономия буенча махсус китаплар да язганнардыр, ләкин заманның рәхимсез вакыйгалары ул әсәрләрнең үзләрен генә түгел, исемнәрен дә ялмап йоткан...

Ниһаять, болгар укымышлыларының бөтен шәрыкта ирешелгән казанышлардан файдалануларын, гыйлемнең, иҗтимагый фикернең үсешенә өлеш кертүләрен, ягъни бер дини укынулар белән генә күмелеп калмаган булуларын күрсәтә торган тагы бер мөһим факт бар. Бу — мәшһүр Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. Мондый әсәрнең Урта Иделдә барлыкка килүе Болгар җире галимнәренең фарсы телен яхшы белеп, гуманистик фарсы әдәбиятының гүзәл традицияләрен тирән ихтирам итүен, үзләштерүен раслый.

Кыскасы, X—XII гасырларда Болгар дәүләте, Көнчыгыш Европадагы алдынгы илләрнең берсе булу белән бергә, үсеше, тәрәккыяте буенча Европадан күп алда торган шәрык дөньясында да мөһим культура үзәкләренең берсенә әверелгән икән. Әле генә атап күрсәтелгән укымышлыларның Урта Идел туфрагында җитлегә алулары шуны артыгы белән раслый.

Әлбәттә, мондый казанышларга болгарлар бары «үз казаннарында гына кайнау» нәтиҗәсендә ирешмәгәннәр. Монда, һичшиксез, башка тәрәккый илләр белән тыгыз экономик һәм мәдәни мөнәсәбәттә торуның әһәмияте зур булган. Менә шуңа күрә дә Болгар җире XIII йөз башындагы коточкыч яулап алулардан соң да үзенең культурасын, бай экономикасын, этник мөстәкыйльлеген саклап калып, соңрак яңадан оеша башлаган икенче бер дәүләтнең нигезен тәшкил итә алган. Шуңа күрә әдәбиятыбыз тарихын яктырткандa шушы чал тарихның битләрен кат-кат актарырга тиешбез.

## ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘРДӘН СОҢ

Әйе, Болгар иле дөньяны тетрәткән монгол яулап алуларыннан соң, политик мөстәкыйльлеген югалтса да, үзенең хосусый сыйфатларын, яңартылган атама белән әйткәндә, милли йөзен җуймый.

Гадәттә, XIII йөз башындагы вакыйгаларны яктырткан чакта, тарихчылар монгол яулап алуларына озак тукталырга яраталар, канлы сугышларга, шәһәрләр көлгә әверелүгә зур игътибар бирәләр. Кайвакытлар буяуларны артык куерту белән мавыгып, чаманы да югалтып җибәрәләр. Монгол яулап алулары тудырган бәла-казаларның күләмен без дә беләбез, халыклар башына ишелгән афәттән күз йомарга җыенмыйбыз. Ләкин тормышның тормыш булып калуын, хәятнең үлемне җиңүен, ниһаять, тарих һәм прогресс дигән нәрсәләрнең яулап алулар, сугышлар белән түгел, бәлки җитештерү коралларының камилләшүеннән, сыйнфый-социаль үсеш нәтиҗәләреннән гыйбарәт икәнлеген дә онытырга ярамый. Монгол яулап алуларыннан соң Көнчыгыш Европада яңа дәүләт оешуын, зур-зур яңа шәһәрләр калкып чыгуын, яңа халыклар (этник төркемнәр), культуралар туууын игътибарга алсак, әлеге фикернең дөрес икәнлеген аңларбыз. Ныклы нигезгә утырып өлгергән, бай иҗтимагый һәм мәдәни традицияләргә ия булган халыклар моннан соң да үз йөзләрен югалтмаганнар, бәлки, алар, киресенчә, ябырылып килүче күчмә илбасарларның үзләрен «тыныч көрәш» процессында җиңеп, бөтенләй «эретеп», йотып алганнар. Шул ук вакытта яулап алынган илләр зур хәрби-политик үзгәрешләрдән соң туган яңа шартларда җимерелгән хуҗалыкны тергезүдә, ныгытуда, культура казанышларын саклауда, аны яңартып үстерүдә зур роль уйнаган. Ал-

тын Урда составындагы Болгар җире тарихы моңа бик яхшы мисал. Фикеребез дәлилле булсын өчен, тагы фактларга мөрәҗәгать итик.

Яулап алу процессы тәгәлләнеп, яңа дәүләт оеша башлаган чорда беренче Алтын Урда ханнарының башкаласы Болгар шәһәре булуы, Алтын Урда ханнарының беренче тәңкәләре шунда сугылуы (үзалдына акча суга башлау мөстәкыйль дәүләт формалашып җитүнең билгесе) үзе күп нәрсә турында сөйли. Дөрес, Түбән Иделдә яңа башкала — Сарай Бату шәһәре калкып чыккач, тәңкә сугу эше шунда күчерелә (1282 ел). Мәгәр, моннан соң да Болгарда акча ясау туктамый, Казан ханлыгы чорына кадәр дәвам итә.

Болгарларның Сарай Бату, Сарай Бәркә шәһәрләрен салуда да якыннан катнашулары бәхәссез. Беренчедән, моны Болгарда архитектура эшенең электән үк тәрәккый иткәнлеге расласа, икенчедән, һәр ике Сарайдагы биналарның Урта Иделдәге башка төзелешләрдән әллә ни аерылмавы исбатлый. Дөрес, кайбер археологлар Харәзем осталарының өлешен күпертеп күрсәтү белән мавыгалар. Бу— берьяклы һәм бәхәсле караш. Әлбәттә, Алтын Урда чоры Идел буендагы шәһәрләрнең салынуында харәземлеләрнең дә өлешчә катнашуларын инкарь итәргә ярамый. Сүз нисбилекне дөрес яктырту, өлеш белән мавыгып, бөтенне онытмау хакында гына бара. Әйтик, баштагы чорда Алтын Урданың экономикасы, административ үзенчәлекләре, шуларга мөнәсәбәттә шәһәрләр салыну мәсьәләләренә кагылганда, Русьтан, төрле славян кнәзьлекләреннән җыелган салым-ясакларны, шуннан китерелгән осталарны онытып җибәрү дөрес булыр идеме?! Шулай булгач, беркадәре вакыт дәүләтнең административ үзәге булып торган Болгар иленең роленнән дә күз йому бөтенләй ялгыш нәрсә.

Сарай-Алтын Урда культурасының бер генә чыганакка кайтып калмавын антропологик материаллар да раслый: Түбән Иделдәге зур шәһәрләрдә монголлар һәм монгол кыяфәтле кыпчаклар гына түгел, бәлки европеид типлы болгарлар, хазарлар, руслар, харәземлеләр, аланнар да күпләп яшәгән.

Болгар җиренең экономик хосусиятләре Алтын Урда хуҗалыгында тирән эз калдырган: көньяктагы үзәкне икмәк, җәнлек тиреләре, югары сыйфатлы күн белән тәэмин итүдә болгарлар төп рольләрнең берсен уйнаган. Гарәп авторы Әл-Мөфәддәл бер кызыклы детальне билгеләп уза: Бәркә хан биленә Болгарда эшләнгән, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән яшел каеш бәйләп йөргән.

Җыеп әйткәндә, Алтын Урданың матди культурасын формалаштыруда, үстерүдә империя составына кергән ханлыкларның барысы да, җөмләдән болгарлар да актив катнашкан икән.

Рухи культура өлкәсендә дә гыйбрәтле хәлләрне күзәтәбез. Алтын Урда оешкач та Болгарда рухи культура дәвам итүдән, үсүдән туктамаган. Мәсәлән, XIII гасырның икенче яртысында Кавказдан килгән Хәсән исемле кеше Болгарда утыз ел яшәп, төрле гыйлемнәр белән шөгыльләнгән, аннары Бохарага киткән һәм 1298 елны Тәбриздә үлгән; гомеренең соңгы чорында ул «Болгари» исеме белән дан казанган; әйтик, 1346 елны үлгән мәшһүр Бохара галиме Гобәйдулла Садр әш-Шәрига ибне Мәсгуд аны «шәехебез Хәсән Болгари» дип олылый. 1343 елны Харәземдә туган, башлангыч белемне шунда алган Хафизетдин Мөхәммәд Харәзми Кәрдари Бәззази Болгарга килеп укыган, аннары Кырымда, Әстерханда, Сарайда дәресләр биреп торган һәм, Аксак Тимер Сарай шәһәрен җимергәч, Төркиягә киткән; аның китаплары шул чорда бик күп мөселман илләрендә дан казанган. Фәрганәле Гассам ибне әл-Малик Мәргыйлани исемле галим һәм шагыйрь дә озак еллар дәвамында Болгарда яшәп, төрле фәннәр белән шөгыльләнгән, соңрак Сарайга, ә 1411 елны Әстерханга күчеп киткән. Дәмәшкъ шәһәреннән килгән мәшһүр тарихчы Ибне Гарәбшаһ да шактый вакытлар Болгар, Сарай һәм Әстерханнарда гомер кичергән (Ш. Мәрҗани туплаган мәгълүматлардан).

Болгарда уку-укыту эшенең үз заманы өчен алга киткәнлеген, гарәп теле, гарәпчә китапларның киң таралган булуын (ә ул чорда гарәп культурасы дөнья күләм иң алдынгы культуралардан була) тагы берничә факт ярдәмендә расларга мөмкин. Әдәбият тарихында мәгълүм фикер иясе, әдип Мәхмүд ибне Гали әл-Болгари әс-Сараи, төрле шәрык әсәрләреннән файдаланып, 1357 елны үзенең мәшһүр «Нәһҗел-фәрадис» әсәрен язып бетергән. Шул заманнарның күренекле педагогы Әбү Мөхәммәд Садр ибне Галяэтдин Болгари күп кенә укымышлылар тәрбияләп чыгарган; аның 1369 елны Мөхәммәт Хуҗа ибне Мәуланә Таҗетдин әл-Каратмәни дигән кешегә биргән гарәпчә шәһадәтнамәнең тексты Ш. Мәрҗани китапханәсендәге бер кулъязмада теркәлгән булган (бу «Каратмән» нисбәсе хәзерге Зеленодольск районындагы шул исемдәге авыл белән бәйле түгел микән?). Мәхмүд Болгари дигән берәүнең 1418 елны дидактика буенча язылган китабы шул чорларда Багдадта төзелгән библиографик белешмәдә телгә алына.

Кыскасы, XIII—XV йөзләрдә дә Болгар җире бер Алтын Урда күләмендә генә түгел, бәлки бөтен ислам дөньясы масштабында да рухи культура үзәкләренең берсе булып, башка мәдәни учаклар белән тыгыз мөнәсәбәттә торган икән. Һәм бу фактлар кайбер тарихчыларның Болгарны башка шәрык илләреннән, хәтта Алтын Урда дәүләтеннән дә аерып тасвирлауга омтылуларын җиргә кага. Шул ук вакытта бөтен Алтын Урда чоры культурасын бер Болгар чыганагына кайтарып калдырырга ярамас иде.

Чөнки бу дәвер рухи культурасының үсешендә төрле халыкларның вәкилләре актив катнашкан. Югарыда исемнәре аталган галим-голямәдән тыш, тагы түбәндәге философ һәм әдипләрне, филолог һәм врачларны күрсәтик: Галяэтдин әл-Ногман, шәех Галяэтдин Сәйрами, Әхмәд ибне Мөхәммәд Җәнди, мәшһүр Сәгъдетдин Тафтазани һәм башкалар Урта Азия шәһәрләреннән килгәннәр. Кавказ һәм Әзербәйҗаннан килгән кешеләр мисалында казый Мөхетдин Бардагый, шагыйрь Кәмаль Хоҗәндиләрнең исемнәрен атарга кирәк. Иранлылардан исә мәшһүр врач Ибне ән-Нәҗҗам, бөек астроном Котбетдин Рази һәм башкалар Сарайда булганнар. Алтын Урданың мөһим үзәкләренең берсеннән булган Кырымда да күренекле укымышлылар җитлеккән. Шулардан билгеле философ Ибне әл-Гараби әсәрләренә шәрехләр язган, соңрак Каһирәдәге мәшһүр Әл-Әзһар университетында лекцияләр укыган Әхмәд Мортагыйшны, мәшһүр Тафтазанига остазлык иткән Зияэтдин әл-Крымины, Бәззазидан дәресләр алып, үзләре дә Сарайда шәкертләр укыткан Шәрәфетдин, шәех Исхак һәм Сәед Әхмәдләрне күрсәтергә мөмкин.

Төрле төшләрдән Сарайга килеп эшләүче галим-голямә хакында сөйләп тә, Дәште Кыпчакның үзендә, Сарай шәһәрендә туган, шунда җитлеккән укымышлыларның исемнәрен атамасак, зур гаделсезлек булыр иде. Чөнки ул чорларда Сарай шәһәре культура өлкәсендә бүтән төбәкләр көченнән файдалану белән генә чикләнми, бәлки үзе дә җитлеккән кадрлар белән башка регионнарның мәдәни тормышларына өлеш кертә башлый. Мәсәлән, зур врач, философ, гарәп теленең мәшһүр белгече Мәхмүд Сараи исемле галим булган, ул 1373 елны Сарайда үлгән. Алтын Урданың башкаласында туган Җәмалетдин Йосыф Сараи Тәбризгә барып укытучылык иткән, ә Шәех Әхмәд Мәүланә-задә Сараи исә Сүрия һәм Каһирә мәдрәсәләрендә дәресләр биргән. Чорының зур филологы Әхмәд Сараины Аксак Тимер Сәмаркандка алып киткән. Аксак Тимер тырнагыннан качып өлгергән шәех Шиһабетдин Сараи исә Шамга (Иерусалим) китеп мөдәррислек иткән. Шагыйрь Сәйф Сараи 1391 елда Мисырда бөек Иран шагыйре Сәгъдинең «Гөлестан» китабын төрки телгә тәрҗемә иткән, шул хезмәте белән үзенең исемен мәңгеләштергән. Гарәп, фарсы телләренең зур белгече, үзе дә төрле телләрдә шигырьләр язган Мәхмүд Сараи да шул ук «Гөлестан» китабын шәрехләү, аңлату белән шөгыльләнгән, шуңа күрә аны «Гөлестани» дип тә олылаганнар: ул 1398 елны Мисырда үлгән (Хаҗи Хәлфә библиографиясеннән).

Бу исемлекне тагы да бер кадәре сузып булыр иде, ләкин китерелгән хәтлесе дә тиешле нәтиҗәләр чыгарып өчен җитеп торыр дип уйлыйбыз. Шул ук вакытта бик күп исемнәрнең, мөһим фактларның безнең көннәргә чаклы килеп җитә алмавын, җиткәннәренең исә реаль чынбарлыкның бер бәләкәй генә өлеше булуын онытмаска кирәк. Зуррак өлешенең бөтенләй эзсез югалуы өчен дә гаҗәпләнерлек түгел, чөнки Болгар, ике Сарай, Сарайчык, Гөлестан, Маҗар, Мокшы, Үкәк кебек зур шәһәрләрдәге таш биналарны тузанга әверелдергән рәхимсез вакыйгалар, рухи культура җимешләренә, ягъни китапларга, язма документларга карата тагы да шәфкатьсезрәк булган, әлбәттә.

Шулай итеп, без XIII—XV гасырларга кыскача сәяхәт ясап, шул чорда туган рухи культураның формалашуына, үсүенә төрле халык вәкилләренең өлеш керткән булуын күрдек. Димәк, ул дәвердән калган катлаулы мираска да шул халыкларның нәселләре варис булырга тиеш икән. Мәсьәләне болай киңәйтеп карауга гаҗәпләнергә ярамый, чөнки мәгълүм иҗтимагый-тарихи шартларда киң мәйданда туган зур культураны соңгы дәверләрдә генә таррак җирлектә оешкан милли кысаларның берсенә генә куып керту иң кимендә тарихи сукырлык булыр иде.

Ниһаять, югарыда китерелгән материаллар күп кенә төрки халыкларының, җөмләдән татарларның да, урта гасыр рухи культуралары шул чорда хөкем сөргән ислам идеологиясе тәэсирендә формалашканлыгын, үсканлеген күрсәтә. Тик моннан чыгып, әлеге дәвер культурасына кимсетеп карарга һич тә ярамый, бәлки дөньяви эчтәлекнең ни дәрәҗәдә дини формалардан файдалана алуын ачыклау мәсьәләне тарихирак, гаделрәк хәл кылуга китерәчәк.

Шулай итеп, бүгенге татар халкының рухи дөньясы, аның этник тарихы шикелле үк, озак гасырлар дәвамында, катлаулы һәм авыр тарихи шартларда төрле культура элементларның кушылуы, синтезлашуы нәтиҗәсендә туган. Аның соңгы дәверләрдәге халыкара мөнәсәбәтләрен яктырта-яктырта Казан ханлыгы чорына, аннары XVII—XVIII гасырларга караган этабына, ниһаять, Шиһаб Мәрҗани, Риза Фәхретдиновлар эшчәнлегенә кагылсак, тагы бер мөстәкыйль мәкалә барлыкка килер иде, шул ук вакытта элекке традицияләрнең өзлексез дәвам итүен дә күрер идек. Шуңа күрә, әйтелгән кадәресе белән канәгатьләнеп, төп мәсьәләгә якынрак килик.

## XII—XV ГАСЫРЛАРДА УРТА АЗИЯ ҺӘМ ИДЕЛ БУЕ ӘДӘБИЯТЛАРЫНЫҢ ҮСҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Һәрбер әдәбиятның нигезендә, төгәлрәк әйткәндә, аның «елга башында» халык авыз иҗаты ятуы бәхәссез.

Иң борынгы төрки кабиләләренең фольклор әсәрләре безгә кадәр килеп җитмәгән. Төрки каганлыгы (VI—VIII йөзләр) чорында төрле мифлар, легендаларның яшәгәнлеге хакында кайбер хәбәрләр бар. Ихтимал, мондый әсәрләр

каганлык составына кергән болгарлар арасында да киң таралган булгандыр. Соңгырак дәвер төрки халыкларның фольклор әсәрләренең бер өлеше Мәхмүд Кашгариның «Диваны лөгат ет-төрк» әсәрендә тупланган. Тюркология дөньясында бу истәлек барлык төрки халыкларның уртак хәзинәсе дип карала. Болгар кабиләләренә генә хас үзенчәлекле сүзләрне, кайбер шигъри әсәрләрне без шул истәлектән табабыз. Бәлки галим тарафыннан «болгарларныкы» дип махсус күрсәтелмәгән кайбер әсәрләр дә безнең бабаларга бик мәгълүм булгандыр, чөнки телләрнең якынлыгы, шул телләрдә сөйләшүче халыкларның кан кардәшлеге бик күп фольклор әсәрләренең уртаклыгын тәэмин иткән.

Соңгырак чор язма әдәби әсәрләрдән «Котадгу белек», «Гыйбәтел-хәкаикъ» һәм башкаларның кыпчак сәхраларында, димәк, кыпчаклар белән аралашып яшәгән болгарлар арасында да таралган булуы шик тудырмый. Телләр якынлыгыннан тыш, идеологик мәнфәгатьләренең уртаклыгы да мондый әдәбият алмашуга булышлык иткән. XI гасыр әсәре «Котадгу белек»нең кайбер шигырьләре Алтын Урда шәһәре Сарайчыкта табылган чүлмәкләрдә очравы, әлеге әсәрнең бер нөсхәсе Сарай һәм кыпчаклар белән тыгыз элемтәдә торган мәмлүкләр Каһирәсендә табылуы шул хакта сөйли.

Шул ук вакытта Урта Азиядә XII—XIII йөзләрдә, хәтта аннан соң да төрки телләрнең әһәмияте беркадәре кимеп, төрки әдәбиятының да торгынлык кичерү фактын истә тотарга кирәк. Мәсәлән, Караханилар чорында төркичә «Котадгу белек» әсәрен язган өчен аның авторы Йосыфка «Хас Хаҗиб» дигән зур сарай дәрәҗәсе бүләк ителсә, димәк, төрки телнең үсүенә зур игътибар бирелсә, харәземшаһлар чорында, гәрчә алар үзләре төрки династиядән чыксалар да, югары даирәләрдә нигездә фарсы теле, фарсы телендәге әдәбият белән мавыкканнар. Шуңа күрә төрки тел, төрки телле поэзия бары халык арасында яшәгән, яки һаман халык күңелен аулаучы, аны үз артларыннан ияртергә омтылучы суфилар дөньясында дини пропаганда чарасы булып хезмәт иткән. Шуңа күрә дөньяви власть ияләре игътибар итмәгән, руханилар өнәп бетермәгән элекке төркичә дөньяви рухлы язма әсәрләрнең онытылулары, юкка чыгулары бер дә гаҗәп түгел (әйтик, угызларның «Угызнамә»ләре соңгырак версияләрдә генә сакланып калган булса, кыпчакларның «Олух хан Ата билгәчи» кебек әсәрләре эзсез югалган).

Төрки телле, шул телдәге поэзия сферасын үз монополиясенә алган суфилар Урта Азия күчмә төркиләре арасында бик актив эшлиләр. Шулардан 1140 елда үлгән суфи Йосыф Хәмәдани аерата шөһрәт казана. Аның традициясен шәкертләреннән Әхмәд Ясәви (1166 елда вафат булган), Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) һәм башкалар дәвам иттерә. Гади тел, халыкчан поэтик үлчәү белән иҗат итүче, шул ук вакытта гарәп, фарсы поэзияләренең гомум казанышларыннан оста файдаланучы бу авторларның әсәрләре тиз арада киң төрки дөньяда — Сыр-Дәрья буйларында, Харәземдә, Җидесу өлкәләрендә мәгълүм һәм мәшһүр булып өлгерә. Ә өстәвенә болар үзләренең тышкы демократизмы (гадилек, аскетлык, байлыкка нәфрәт һ. б.), шаман-бахшилар сыйфатында багучылык белән шөгыльләнеп, авыруларны дәвалаулары һәм янә башка күп кенә гамәлләре белән үзләрен «изге» кешеләр, кәрамәт ияләре сыйфатында таныта алганнар. Шундый шагыйрьләр образы тәэсирендә Дәдә Коркыт кебек халык җырчылары да соңгырак чор легендаларында суфи картлар шикеллерәк сурәтләнәләр. Әмма Урта Азиянең традицион бай культуралы төбәкләрендә исә, фарсы теле һәм фарсы әдәбияты хөкем сөргәндә, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани шикелле шагыйрьләрнең иҗатлары бик соң, нибары XVI гасыр ахырларында гына, ягъни Нәкышбәндия тарикасы (суфичылык секциясе) киң таралгач кына мәгълүм була башлый.

Болгар җирендә фарсы әдәбияты хакимлек иткән әдәбият сыйфатында тарала алмаган. Аның каравы, Ясәви һәм Бакыргани әсәрләре баштан ук киң аудитория тапканга охшый. Мәсәлән, югарыда телгә алынган мәшһүр шәех Хәсән Болгари Әхмәд Ясәви иярченнәреннән саналган. Шул ук вакытта мөстәкыйль традициягә ия болгарлар үзләре дә сәләтле шагыйрьләр үстерәләр. Мисал өчен бер Кол Гали исемен атау да җитәчәк. Ул үзенең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасын, мәгълүм булганча, Фирдәүси тәҗрибәсенә таянып язган. Шул ук вакытта, әчтәлек белән якыннан танышсаң, авторның туган халкы фольклорына, аның бай поэтик мирасына таянып иҗат итүен күрәсең. Һәрхәлдә, мондый камил әсәрнең әдәби традициясе булмаган җирдә туа алуы ихтималдан бик ерак нәрсә. Өстәвенә авторның Ясәви, Бакырганилар иҗаты белән якыннан таныш булуы да һичнинди шик тудырмый.

Ясәви, Бакырганилар традициясе Болгарда киң популярлык табуына өстәмә дәлилләр дә шактый. Әйтик, болгар руханиларның күршедәге башкортлар, кыпчаклар, чувашлар, марилар, удмуртлар арасында ислам тәгълиматы таратып йөрүләре, шул халыкларның бер өлеше мөселманлыкны кабул итүләре, аларның кайберләре тора-бара бөтенләй татарлашып бетүләре тарих-этнография белгечләренә күптәннән мәгълүм. Мари, чуваш, удмуртларның иске диндә калучыларында да «шәехләр хәрамәте» дигән төшенчәдән үзгәреп «кирәмәт» культы барлыкка килү, шулай ук аларның пантеоннарына «пигамбәр», «корбан», «фирештә» шикелле сүзләрнең керүе әлеге фикерне куәтли. Урта Азия суфилары

мәктәбендә тәрбияләнеп үскән болгар-татар шәехләренең бу традицияләре Казан ханлыгы чорында да, аннан соң да дәвам иткән. Бер кызыклы мисал алыйк. Биләр шәһәре тирәсеннән чыккан Бәлем Хуҗа исемле бер «изге» шәех гомеренең соңгы елларында ерак Төркиягә китә, андагы «юлдан яза башлаган» Бикташилар орденына реформа ясап, аны ортодоксаль суфилык юнәлешенә борып җибәрә. 1516 елны Төркиядә үлгән шул кеше соңыннан әлеге орденның «рухи атасы», башы булып танылa. Менә шул Бәлем Хуҗа безнең күрше чувашларда да Мелем Хуча, Валем Хуҗа исемнәре белән бер изге культка әверелгән.

Әдәбият тарихына багышланган хезмәттә, этногенез һәм мәдәни-иҗтимагый мәсьәләләргә кагылудан тыш, мондый ярым дини күренешләргә дә мөрәҗәгать итүгә гаҗәпләнергә урын юк. Чөнки әдәбият тарихы дигән нәрсә ул әдәби телнең дә тарихы. Ә язма әдәби тел исә элек-электән иҗтимагый-идеологик көрәш коралы буларак формалаша һәм яши. Ә Болгар җирендә XI—XII йөзләрдә мондый объектив күренешләр бар икән, димәк, аның әдәби теле дә булган дигән сүз. Моның иң әйбәт дәлиле — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы.

Бу әсәрнең әдәби сыйфаты, тел-стиль әһәмияте бер Идел буе белән генә чикләнмәгән. Мәсәлән, XIII йөзнең икенче яртысында Мәхмүд Кырымлы исемле бер шагыйрь, Кол Галигә ияреп, шул сюжетка кыпчак телендә яңа поэма язган. Кырымлының әсәрен шул ук гасырда Гали Хәлил угылы Анатолия төркисенә тәрҗемә иткән. Әмма шул ук XIII гасырда Шәйяд Хәмзә дигән төрек шагыйре Кол Гали поэмасын турыдан-туры тагы бер кат төрекчәгә тәрҗемә кылган. Әлбәттә, төрекләргә Болгар шагыйренең әсәре көньяктагы кыпчаклар һәм кырымлылар аркылы барып җиткән булырга тиеш.

Югарыда без «Котадгу белек» әсәреннән соң Урта Азиядәге дөньяви даирәләрдә төрки телнең артык тәрәккый кыла алмавын, аны фарсы теле кысрыклап чыгаруын әйтеп узган идек. Монгол яулап алуларыннан соң анда фарсы телендәге әдәбият та кризиска дучар була. Чөнки Урта Азиядә хөкем сөрүче монгол феодаллары гомум мөселман культурасына, шул юнәлештәге язма әдәбиятка да дошманлык күрсәткәннәр. Моннан тыш, XIII йөзнең башыннан алып 1370 елларга кадәр бөтен Урта Азиядә туктаусыз яулап алышулар, тәхет тирәсендәге ызгышлар, бер сүз белән әйткәндә, кан коючы сугышлар бер дә сүрелмәгән. Урта Азиягә әзме-күпме тынычлык, стабильлек, тышкы яктан гына булса да иминлек нибары дәһшәтле Аксак Тимер чорында гына килә (ләкин бу җиһангир үз биләмәсеннән читтә гел канлы сугышлар алып барган...).

Шөһрәт сөючән, үз шәхесе белән мавыккан Аксак Тимернең үз тирәсенә төрле галимнәр, бигрәк тә тарихчылар җыюы мәгълүм факт. Әмма ул, үзе төркичә дә, таҗикча да яхшы белүгә карамастан, поэзия белән кызыксынмаган. Моның шулай икәнлеген аның тирәсендәге тарихчылар арасында бер шагыйрьнең дә булмавы бик ачык күрсәтсә кирәк. Нәкъ менә шуның өчен, суфилар хөҗрәсендә яшәп килгән дини-дидактик әсәрләрне исәпкә алмаганда, Урта Азиядә XIV йөздә дә дөньяви төрки телле язма әдәбият үсә алмый. Шуңа күрә XIII—XIV гасырлар буена бөтен Урта Азиядә ике-өч бөртек кенә төрки телле шагыйрьләр булган булса (алар: Хәмид ибне Гасыйм әл-Гасыйми, Хаҗи Сәйфетдин Сәйфи, Сәйфетдин Хөттәлани һәм... тагы кемнәр?), әллә ни гаҗәп түгел. Ләкин бу чорны соңгы дәвер, ягъни XV—XVI йөзләр белән бутарга һич тә ярамый.

Урта Азиядән аермалы буларак, XIII гасыр ахырында Алтын Урдада, аның составына кергән Болгар, Кырым һәм Харәземнәрдә, киресенчә, төрки телле әдәбиятның беркадәр җанлы хәрәкәт кичерүен, әзме-күпме үсүен күзәтергә мөмкин. (Без биредә Харәземне хәзергечә берсүзсез Урта Азиягә кертеп түгел, бәлки тарихилык принцибы белән Алтын Урданың бер өлеше итеп карыйбыз.) Әмма XIV йөзгә килгәндә, мондагы төрки телле әдәбиятның шактый тәрәккый итүен дәлилли алабыз. Моны 1333 елны Сарайга килгән мәшһүр сәяхәтче Ибне Батута язмалары да раслый. Ул, мәсәлән, Сарай укымышлылары җыелган мәҗлесләрдә гарәп, фарсы һәм төрки теллләрдәге әсәрләрдән берәр юл алып шигырьләр әйтешү, ягъни «мөләммәгъ» ярышлары оештырылу хакында хәбәр итә. «Мөләммәгъ» кебек катлаулы, төрле милли әдәбиятларның нечкәлекләрен белүне таләп итә торган форманың Сарайда кулланылуы күп нәрсә хакында сөйләсә кирәк. Хәер, Алтын Урда шәһәрләрендә туып үскән, төрки телдән тыш, гарәп, фарсы телләре буенча да дан казанган филологлар хакында алда әйтелгән иде инде. Бөек фарсы поэзиясенең нечкәлекләрен аңлап, үз ана телендә шигъри җәүһәрләр иҗат итә алган Сәйф Сараи иҗаты исә әлеге фикерне тагы да үстерергә мөмкинлек бирә.

Ибне Батутаның хәбәрләренә караганда, укымышлылар (казыйлар, фәкыйһләр, филологлар һәм философлар) мәҗлесендә язма поэзия әсәрләре репертуарда булса, ханнар сараенда җырчыларның (сәяхәтче аларны «мәүаль» әйтүчеләр ди) күбрәк танылганын беләбез. Димәк, югары сфераларда язма әдәбият белән бергә фольклор әсәрләре дә игътибар үзәгендә торган икән.

Алтын Урда чоры әдәбиятының тарихын бары башкала Сарай шәһәре һәм тәхет даирәләре белән генә чикләп куярга һич тә ярамый, әлбәттә. Дөрес, дәүләтнең югары сферасындагы хәлләрдән күз йому да үз чиратында хаким идео-

игиянең, гомумән, язма культураның фактимагый процесста тоткан урынын в альсификацияләргә, ягъни борынгы дәвер культурасын идеаллаштырып сурәтләүгә китерер иде. Бездә кайчандыр хөкем сөргән «ханнар, сарайлар поэзиясе» дигән төшенчә борынгы катлаулы мирас турында шулай берьяклы, хәтта примитиврак фикер йөртүнең галәмәте генә. Алтын Урдада Сарайдан башка да әдәби үзәкләр булуын түбәндәге бәхәссез фактлардан күрәбез.

1311 елда харәземле Рабгузый «Кыйсасел-әнбия», шул ук елны аның бер якташы «Мөгыйнел-мәрид» әсәрен тәмамлый. 1341 елда Котб исемле шагыйрь Низаминең «Хөсрәү вә Ширин» исемле поэмасын иҗади тәрҗемә итә. 1353 елда дәүләтнең бер өлеше булган Ак Урдада Харәзминең «Мәхәббәт-намә»се языла; аннан дүрт ел соңрак болгарлы галим Мәхмүд ибне Галинең «Нәһҗел-фәрадис», 1369 елны исә Хөсам Кятиб дигән кешенең («Хисам» түгел, чөнки гарәпчә андый сүз юк, бәлки «хөсам» — кылыч бар) «Җөмҗөмә солтан» поэмасы тәмамлана. Менә шушы «Җөмҗөмә» әсәреннән рухланган икенче бер автор мәшһүр «Кисекбаш» поэмасын тудыра. Ниһаять, дөньяга Сәйф Сараиның атаклы «Китабе Гөлестан бит-төрки» әсәре туа, аны автор Иранның бөек шагыйре Сәгъдинең «Гөлестан» китабыннан иҗади тәрҗемә иткән. Һәм шулай ук «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанын язган. Болардан тыш Алтын Урданың төрле төшләрендә яшәп иҗат иткән, ләкин биографик материаллары бөтенләй аз сакланган шагыйрьләрдән түбәндәгеләрне атарга мөмкин: Мәүла Казый Мөхсин, Мәүлана Исхак, Бәркә Фәкыйһ, Мәүлана Гыймад Мәүләви, Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Габделмәҗид, Туглы Хуҗа һ. б. Боларның берәм-берәм шигырьләре генә сакланып калган.

Әлбәттә, Алтын Урдада яшәп иҗат иткән бөтен әдипләрнең, шагыйрьләрнең исемлеге бер болар белән генә чикләнми. Сәйф Сараиның «вәзең тутыру» өчен сүз мәгънәсен бозып йөрүче, кеше шигырьләрен «үземнеке» дип, плагиат белән шөгыльләнүче шагыйрьләрнең күплеге хакындагы сүзләре шуны раслый. Кыскасы, XIV гасыр Алтын Урдада төркичә каләм тибрәтүчеләр күп булган булса, дөньяга туган төркичә әдәби әсәрләрнең саны да аз булмаган. Нәкъ менә шушы сыйфаты белән ул Урта Азиядән аерыла да. Һәм XIV йөздә Урта Азиядә хөкем сөргән бу әдәби кытлык «мирас билгеләүдәге» кайбер сузыптартуларның дөньяга туурына сәбәп, җирлек бирә кила.

Сакланып калган биографик мәгълүматларның азлыгы кайбер шагыйрьләрнең чыгышлары хакында төрлечә фикер йөртергә урын калдыра. Мисал итеп шул ук Сәйф Сараины алырга мөмкин. Ул үзенең туган җирен Камышлы дип атый. Кайберәүләр моны Харәземдәге Сарыкамышка тарталар, мәгәр Сарай шәһәренең нәкъ борын төбендәге Камышлыны (хәзерге Камышин шәһәрен) никтер онытып җибәрәләр. Әгәр Сәйф Сараи Харәземдә, яисә башка җирдә туган булса, ул үзенә ни өчен «Сараи» нисбәсен алды икән? Шул ук вакытта урта гасыр шәрык авторларының үзләренә нисбә итеп (нисбә — әдәби псевдонимның бер төре) туган яисә, аерым очракта гына, бик озак яшәгән җирләрнең исемнәрен алу гадәтләре мәгълүм. Шуңа күрә дә читтән килеп Сарайда хезмәт иткән галимнәр, икеләнеп тормыйча, үзләрен Рази, Мосули, Харәзми, Кәрдәри, Сәйрами, Тафтазани, Хөҗәнди, Бәрдагый, Җәнди, Мәргыйлани, Кырыми, Болгари дип атаганнар. Димәк, шагыйрь Сәйфнең нәкъ Камышлы янындагы Сарайның исемен нисбә итеп алуы тикмәгә түгел икән. Шуңа күрә бүгенге Камышлыда, Сарайда Алтын Урта чоры халыкларының туры варислары булмавыннан файдаланып, үзенең туган җирен атап, ватанын ачык игълан иткән Сәйф Сараины ары-бире тарткаларга бернинди тарихи нигез юк.

Автор үзенең туган җирен яки нисбәсен ачык атамаган очракта нишләргә соң? Мәсәлән, төркичә «Хөсрәү вә Ширин»ның авторы Котб белән нәкъ шундый хәл. Шуннан файдаланып, кайберәүләр аны Харәзем ягына тарталар, ләкин Котбның ни өчен башка «якташлары» кебек үзен «Харәзми» дип атамавына җавап эзләп тормыйлар. Эзләсәләр дә, мөгаен, таба алмаслар иде. Димәк, безгә бер генә юл — авторның телен өйрәнү аркылы аның ватанын ачыклау юлы кала икән. Ә Котбның теле исә аның болгарлар составына кергән искил (ичкил, чигил) кабиләсеннән булуына ишарә ясый. Югарыда (беренче мәкаләдә) китерелгән дәлилләрдән тыш тагы берничә характерлы мисалга мөрәҗәгать итик. Беренчедән, Котб һәр вакытта да «авыл» урынына «сала» сүзен куллана. В. В. Радловның күрсәтүенчә, бу «сала» бары татарларда һәм караимнарда гына шул мәгънәдә йөри (кырымлыларда һәм төрекләрдә «сала» — ватан). Икенчедән, Котб «буе» урынына «ката» сүзеннән файдалана (төн ката, көн ката һ. б.). Борынгы төрки телләрдә ул, М. Кашгари материалларына караганда, «тапкыр, кабат, мәртәбә» мәгънәсендә кулланылган. Хәзерге төрки телләргә исә, мишәр диалектыннан каларак, бу сүз бары кыргызларда гына очрый (җолду жата — юл буе). Безнеңчә, бу факт хәзерге мишәрләр белән кыргызларның бабалары кайчандыр күрше яшәүгә ишарә итсә кирәк. Өченчедән, Котб «барасы», «кыласы» шикелле форма урынына мишәрләрдәге кебегрәк «баргу», «кылгу» формасыннан файдалана. Дүртенчедән, Котбта «барырга» формасы бик актив. Ә мондый форма, югарыда күргәнебезчә, нигездә болгар кабиләләренә хас күренеш. Бишенчедән, Котбның теле «Котадгу белек» теленә

якын. Алтынчыдан, Котб бер героеның икенче кешегә буйсыну игълан итүен бүрек салу белән аңлаттыра, ә мондый гадәт, Ибне Фазлан әйткәнчә, борынгы болгарларга хас булган. Ниһаять, әсәрдә тулаемы белән Идел буе халыкларының тормышы сурәтләнә.

Җыеп әйткәндә, төрле фаразлар белән шөгыльләнгәнче, әсәрнең телен, эчтәлеген җентекләп тикшерергә генә кирәк икән.

Аерым-ялгыз фактлар нигезендә нәтиҗәләр чыгаруның ялгыш икәнлеген без «Кисекбаш» поэмасы хакында әйтелгән фикерләрдән дә күрәбез.

Заманында Ш. Мәрҗани «Кисекбаш» әсәрен Болгар җирендә туган истәлекләр рәтенә керткән иде. 1369 елда иҗат ителгән «Җөмҗөмә солтан» поэмасыннан рухланган болгарлы шагыйрьнең сюжетны саф мөселман җирлегенә күчереп, ортодоксаль ислам мотивларын көчәйтеп, яңа әсәр тудырырга теләгән булуы бик ихтимал. Ләкин төрек әдәбиятының фундаменталь тарихын язучы Васфи Маһир Кожатөрк 1461 елда төрекчә төзелгән Кирдәчи Гали дигән авторның әсәрләрен эченә алган бер җыентыкта әлеге «Кисекбаш» поэмасы да булуга карап, аны төрек җиренең истәлеге дип атый. (В. М. Кожатөркнең 1964 елда Анкарада чыккан «Төрек әдәбияты тарихы» китабына карагыз.) Әмма В. М. Кожатөрк кулында булган нөсхәнең оригиналь әсәр түгел, бәлки тәрҗемә генә икәнлеген түбәндәге фактлардан күрергә мөмкин.

Гадәттә, борынгы төрек шагыйрьләре әсәр ахырында автор хакында мәгълүмат биргән чакта «буны язан» яки «буны диян» (моны язган, моны дигән) кебек трафарет гыйбарәләрдән файдаланганнар. («Буны диян Садыйк Вәли дорур» кебек.) Югарыдагы Кирдәчи Гали дә үзе тудырган «Аждаһа дастаны»н нәкъ шулай «Буны диян Кирдәчи Гали дорур» дип тәмамлый. Ә «Кисекбаш»ның төрекчәсендә исә «Буны идән Кирдәчи Гали дорур» дип язылган. Төрекчә «диян» (дигән, әйткән) белән «идән» (иткән, эшләгән) сүзләрен чагыштырып карасак, соңгысының тәрҗемә итүне аңлатуы ачыла. Хәлбуки, әлеге 1461 елгы төрекчә җыентыкта Хәсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанының да төрекчә версиясе бар, В. М. Кожатөрк аны да... төрек Кирдәчи Гали әсәре дип уйлый... Чынлыкта исә һәр ике поэма да болгарлар, кыпчаклар арасында туган һәм, Кырым аша Төркиягә әләгеп, шунда төрекчәгә тәрҗемә «идилән» әсәрләрдер.

Шулай итеп, югарыда китерелгән фактларның һәммәсе дә XIII—XIV гасырларда Алтын Урда дәүләтендәге төрки телле әдәбиятның башка төрки төбәкләргә караганда яхшырак тәрәккый кән булуын һәм бу зур әдәби процесс империянең үзәк өлкәләрендәге кыпча лар белән бергә Ак Урда, Болгар, Хар зем, Кырым һәм Әзербайҗан җирләрен дәге төркиләрнең дә актив катнашула рын расласа кирәк. Әлбәттә, төрле диалект вәкилләре буларак, алар әдәби телгә үз шивәләренең элементларын керткәннәр (мисал сыйфатында Котбны ук атарга мөмкин), ләкин моңа карап Алтын Урда чоры әдәбияты бер бөтен зур әдәбият булудан туктамаган. Менә шуңа күрә ул соңрак дәверләрдә формалашкан милли әдәбиятлардан татар, үзбәк, төркмән, кырым, әзербайҗан, казакъ, каракалпак, нугай, башкорт әдәбиятларына нигез — тамыр, яисә чыганак — «елга башы» булган. Ул хәтта төрекләр кебек читтәрәк, аерым яшәгән халыкларның әдәби процессына да көчле тәэсир ясаган. Мисыр кебек ерак өлкәләрдә дә аның үрентеләре үскән...

Кайбер укучыларга төрле төрки халыклар арасында мондый тыгыз әдәби мөнәсәбәтләрнең булу факты, хәтта кайбер язма истәлекләрнең, авторларның күпләр өчен уртак булулары, яисә аларның кемлекләре ачык түгеллеге гаҗәбрәк нәрсә кебек тоелыр. Ләкин монда артык сәер бер нәрсә дә юк; дөресрәге, мондый хәл килеп чыгуның объектив тарихи сәбәпләре бар. Беренчедән, ул дәверләрдә күп кенә төрки халыкларның язма телләре үзара бик якын булган; зур дәүләт составына керү бу якынлыкны тагы да көчәйткән. Икенчедән, урта гасыр әдәбиятында бер хаким идеология — ислам дине хөкем сөргән, ул миллилекне, аерымлыкны түгел, бәлки мөселман абстрактлыгын тәэмин иткән. Бу хәл бигрәк тә суфичылык рухы белән сугарылган әдәбиятта ачык күренә. Шуңа күрә, әгәр урта гасырлар язма әдәбиятының бөтен хосусиятләрен дөрес аңлатырга теләсәк, әдәбиятта суфичылык тоткан урынны да дөрес аңлау, аңлату таләп ителәчәк. Кайберәүләр кебек «дини» дип селтәнеп кенә узсак, без мәсьәләне катлауландырудан башка бернәрсәгә дә ирешмәячәкбез. Дөрес, суфичылык әдәбиятын тикшерү аны пропагандалауга, каршылыкны шомартуга әверелмәскә тиеш.

Йомгаклап әйткәндә, борынгы чор әдәбиятыбызны тикшергән чакта иҗтимагый-политик шартларны белми торып фикер йөртүләр берьяклылыкка, нигезсез дәгъваларга китерсә, төрле кардәш халыклар арасындагы экономик, мәдәни һәм идеологик мөнәсәбәтләрне исәпләмичә аерым текстларга гынаябышып яту да беркатлы, хәтта көлкеле нәтиҗәләр бирәчәк. Чынлыкта мәсьәлә күпкә катлаулы. Моның шулай икәнлеге алдагы мәкаләдә тагы да ачыграк күренер.

# ЮГАРЫ СЫЙФАТ, ИҖАДИ АКТИВЛЫК

*1972 елның 21 январенда КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карар кабул итте. «Казан утлары» журналының 1972 елгы 4 нче саны әлеге карар белән ачыла. Шул көннән башлап, әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть мәсьәләләре журнал редакциясенең игътибар үзәгендә булып килде. «Казан утлары» журналы әдәбият-сәнгать тәнкыйтен тагын да үстерү, тәнкыйтьчеләрнең иҗат активлыгын көчәйтү юнәлешендә күп төрле эшләр башкарды.*

*Үзәк Комитет карарыннан соң, тәнкыйть турындагы тәнкыйть аеруча җанланып китте. Журнал битләрендә бүгенге тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган дистәләп мәкалә басылып чыкты. Мисал төсендә Р. Мостафинның «Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты» (1972 ел, 4 сан) һәм «Әдәби тәнкыйтьнең уңышлары һәм бурычлары» (1974 ел, 10 сан), Ф. Урманчеевның «Бүгенге тәнкыйть мәсьәләләре» (1973 ел, 5 сан), Н. Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә» (1973 ел, 8 сан), Ф. Хатиповның «Җаваплылык» (1974 ел, 4 сан) кебек мәкаләләрен китерергә мөмкин. Ул мәкаләләрдә татар совет әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьнең бүгенге хәле, аның үсеш тенденцияләре ачыкланды, бу өлкәгә караган мөһим мәсьәләләр кузгатылды, күп кенә яңа һәм кызыклы фикерләр әйтелде.*

*Үзәк Комитет карары чыкканга өч елдан артык вакыт үтте. Республикабыз иҗат интеллигенциясе бу датаны яңа иҗат активлыгы шартларында билгеләп үзды. Иҗат союзларында, газета-журнал редакцияләрендә, югары уку йортларында һәм фән учреждениеләрендә өч еллык эшкә йомгак ясалды, киләчәк өчен яңа планнар төзелде.*

*Журналның бу санында басылган мәкаләләрдә дә сүз КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын тормышка ашыру буенча башкарылган эшләр турында бара. КПССның Татарстан өлкә комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы яңа карарында әдәбият фәнен һәм әдәби тәнкыйтьне тагын да үстерү буенча иҗат союзлары, фән учреждениеләре, шулай ук газета-журнал редакцияләре башкарган эшкә тулы һәм төпле бәя бирелә, алда торган конкрет бурычлар билгеләнә. Ф. Миңнуллин мәкаләсе нигездә 1974 елгы әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтькә күзәтү характерында язылган. Шуның белән бергә, автор бүгенге тәнкыйть үсешендәге үзенчәлекләрне һәм тенденцияләрне дә ачыклый. Ф. Урманчеев мәкаләсендә тәнкыйтьченең әдәби осталыгына бәйле актуаль һәм мөһим мәсьәләләр күтәрелә.*

# ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ТӘНКЫЙТЕ ТУРЫНДА

**КПСС** өлкә комитеты бюросы «КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын үтәүнең барышы турында»гы мәсьәләне карады.

Өлкә комитеты кабул иткән карарда республикабыздагы иҗат интеллигенциясенең КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын озак елларга исәпләнгән программ документ,

партиябезнең күп милләтле совет культурасының чәчәк атуы турында аталарча кайгыртуын раслый торган яңа бер мисал дип кабул итүе әйтелә. Карар иҗат коллективларында, матбугат, радио һәм телевидение, фән учреждениеләре хезмәткәрләре арасында киң күләмдә һәм зур кызыксыну белән тикшерелде. Соңыннан һәр оешмада күп төрле чараларны эченә алган конкрет планнар кабул ителде, ул планнар нигездә уңышлы төстә тормышка ашырылып килә.

Партиябезнең XXIV съезды күрсәтмәләренә һәм КПСС Үзәк Комитеты карарына таянып, иҗат союзлары, сәнгать учреждениеләре, матбугат органнары, радио һәм телевидение, аларның партия оешмалары үзләренең көчләрен әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең сыйфатын күтәрүгә, аның иҗат процессына булган йогынтысын активлаштыруга юнәлдерделәр. Тәнкыйтьнең торышы һәм үсеше, әдәби иҗатның актуаль мәсьәләләре, шулай ук тәнкыйтьчеләр, язучылар, рәссамнар һәм композиторларның иҗат отчетлары партия җыелышларында, иҗат союзларының пленумнарында һәм идарә утырышларында, иҗат хезмәткәрләренең гомуми җыелышларында даими рәвештә тыңлана башлады. Фәнни конференцияләрдә югары үсешкә ирешкән социалистик җәмгыятьтә милли әдәбият һәм сәнгатьләрнең үзара йогынтысы һәм берберләрен баетуларына, шулай ук сынлы һәм музыка сәнгате үсешенә бәйле мәсьәләләр тикшерелде. Язучылар союзы партия оешмасының матур әдәбиятта КамАЗ темасы һәм татар әдәбиятында коммунист образы дигән темага багышланган җыелышлары эшлекле төстә үтте. «Казан утлары» журналы битләрендә бүгенге татар прозасы турында фикер алышу уздырылды. Республика Язучылар союзы үрнәгендә художниклар, композиторлар, театр һәм кино эшлекләренең дә иҗади ел йомгакларына багышланган җыелышлары үткәрелә башлады. Моннан тыш, Язучылар союзында һәр ярты ел саен «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр тикшерелә. Иҗат оешмалары каршындагы тәнкыйть секцияләренең эше беркадәр активлаша төште.

Газеталар һәм журналлар, китап нәшрияты, радио һәм телевидение әдәбият-сәнгать тәнкыйтенә, культура казанышларын пропагандалауга игътибарны арттырдылар. Республиканың партия газеталары редакцияләрендә әдәбият һәм сәнгать бүлекләре, «Татарстан коммунисты» журналында фән һәм культура бүлеге, «Казан утлары» журналында сәнгать бүлеге оештырылды. Матбугатка чыга торган материалларның тематикасы киңәйде, аларны бирүнең формалары төрләнәнде. Соңгы өч ел вакыт эчендә вакытлы матбугат органнарында басылган мәкалә, күзәтү, рецензияләрнең саны бер ярым мәртәбә, Татарстан китап нәшрияты чыгарган әдәби тәнкыйть хезмәтләре исә ике мәртәбә артты. Хәзерге вакытта барлык әдәби әсәрләр диярлек матбугат битләрендә, язучылар җыелышларында, секция утырышларында һәм конференцияләрдә бәя ала. «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталары атна саен «Әдәбият һәм сәнгать» сәхифәләре биреп баралар. Иҗат союзлары һәм иҗат оешмаларының яшь талантларны тәрбияләүгә багышланган берләштерелгән пленумыннан соң, шундый ук сәхифәләрне республиканың комсомол газеталары да чыгара башлады. Радио һәм телевидение тапшыруларында яңа рубрикалар кертелде. К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре турында дигән җыентык татар телендә матбугатка чыгару өчен әзерләнде.

Иҗат оешмалары, фән учреждениеләре тәнкыйть кадрлары хәзерләү һәм тәрбияләү эшен беркадәр яхшырта төштеләр. Бу өлкәдә эшләүче 76 кешенең яртысына якыны фән докторлары һәм фән кандидатлары. Соңгы өч елда әдәбият-сәнгать мәсьәләләре буенча 5 докторлык һәм кандидатлык диссертациясе якланды, 9 диссертация яклауга әзерләнде, 18 кеше Мәскәү, Ленинград, Казан шәһәрләренең югары уку йортлары каршындагы аспирантураларга, 9 кеше Ленинград институтының сынлы сәнгать теориясе һәм тарихы бүлегенә җибәрелде, 6 тәнкыйтьче иҗат союзларына член итеп алынды. «Казан утлары» журналы, Язучылар союзы белән берлектә, даими эшләүче яшь рецензентлар түгәрәге оештырды. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында, консерватория һәм культура институтында студентлар өчен тәнкыйть буенча махсус семинарлар һәм курслар кертелде. Театрлар һәм филармониянең художество советлары, китап нәшриятының редакция советы квалификацияле кадрлар белән ныгытылды. ТАССР Культура министрлыгы каршында яңа спектакльләрне кабул итү буенча художество советы төзелде.

КПСС Үзәк Комитеты карарын тормыш-

ка ашыру юнәлешендә эшләнгән эшләр нәтиҗәсендә тәнкыйтьнең активлыгы һәм аның иҗтимагый абруе сизелерлек үсте. Тәнкыйть объективрак һәм тәпләрәк тәс алды, иҗат процессына эшлеклерәк һәм тагын да төгәлрәк партияле позицияләрдән торып тәэсир ясый, аның хәрәкәтен заман проблемаларын тирәнрәк ачуга, шул юл белән коммунистик тәрбия бирү эшенә хезмәт итәрлек әдәбият һәм сәнгать әсәрләре тудыруга күбрәк ярдәм итә башлады.

Шуның белән бергә, КПСС өлкә комитеты бюросында тәнкыйтьнең хәле әле бу мәсьәлә буенча КПСС Үзәк Комитеты карарында күрсәтелгән һәм коммунистик төзелештә әдәбият һәм сәнгатьнең үсә барган роле белән билгеләнгән таләпләргә тулысынча җавап биреп бетерми, дип билгеләп үтелде.

Тәнкыйть милли әдәбият һәм сәнгатьнең үсеш тенденцияләрен җитәрлек өйрәнми, әдәби иҗатның партиялелек һәм халыкчанлык, сәнгатьтәге уңай геройның роле кебек мөһим һәм принципиаль мәсьәләләрен еш кына читләтеп уза. Кайбер мәкалә, күзәтү, рецензияләр һаман да өстән-өстән языла. Аерым авторлар сәнгать әсәрләрен тормыш күренешләре белән чагыштырып бәяли белмиләр, сәнгать әсәрләрен бәяләгәндә шәхси симпатия һәм антипатияләрдән чыгып эш итәләр. Күп кенә музыка әсәрләре, концерт программалары, сынлы сәнгать һәм документаль кино сәнгате әсәрләре, урыннардагы иҗат коллективларының эше тәнкыйть игътибарыннан читтә калып килә. Соңгы елларда милли эстрада сәнгате мәсьәләләре буенча бер генә җитди мәкалә дә басылмаган.

Художниклар һәм Композиторлар союзларында тәнкыйтьне активлаштыру, аның сыйфатын һәм принципиальлеген күтәрү, сәнгать әһелләре арасында югары таләпчәнлек атмосферасы, тәнкыйть чыгышларына дөрес мөнәсәбәт булдыру турында җитәрлек кайгыртмыйлар.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең теория һәм методология мәсьәләләрен комплекслы өйрәнүне, бүгенге әдәби процессларны тикшерүне координацияләү буенча гыйльми үзәккә әйләнеп җиткәне юк. Өч ел вакыт эчендә әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре буенча институт чыгарган хезмәтләрнең күләме ике мәртәбә артса да, театр, сынлы сәнгать һәм музыка сәнгате буенча тирән эшләнгән, капиталь хезмәтләр һаман күренми.

Тәнкыйть кадрларын тәрбияләү һәм үстерү өлкәсендә дә җитди кимчелекләр яшәп килә. Республикада актив иҗат итүче югары квалификацияле театр белгечләре, музыка һәм сәнгать белгечләре аз. Шуңа да карамастан, Культура министрлыгы һәм иҗат союзлары аларны хәзерләү белән ныклап шөгыльләнмиләр. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында, консерваториядә булган мөмкинлекләр тиешенчә файдаланылмый. Тәнкыйтьчеләрнең профессиональ укулары тиешенчә оештырылмаган.

Республика газета һәм журнал редакцияләре үз битләрендә басыла торган материалларның югары идея-сәнгать дәрәҗәсе һәм юнәлеше турында җитәрлек кайгыртмыйлар. Сәнгать әсәрләренә һәм художниклар иҗатына җитди анализ ясыйсы урында, аларда басылган мәкаләләрнең кайберләрендә әсәрләргә гади аннотация бирү яки авторларның үткәндәге уңышларын санау белән чикләнелә, әсәрләрнең реаль әһәмияте һәм кыйммәтенә бөтен совет әдәбияты һәм сәнгате биеклегеннән карап бәя бирелми. Аерым очракларда матбугатта идея һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан йомшак әсәрләр тиешле бәя алмый кала. Кайбер авторларның мөһим эшләрен күрми узу фактлары очрый. Кайчак редакцияләр мәсьәләне тирәнтен аңламый торган, субъективизм хисеннән арына алмаган авторларны эшкә тарталар.

КПСС өлкә комитеты бюросы иҗат союзларына һәм иҗат оешмаларына, матбугат органнарына һәм аларның партия оешмаларына әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендә яшәп килгән кимчелекләрне бетерергә, тәнкыйтьнең идея-теоретик һәм профессиональ дәрәҗәсен тагын да күтәрергә тәкъдим итте.

Иҗат союзларына, ВТОның Татарстан бүлегенә, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына тәнкыйтьчеләрнең иҗат активлыгын һәм матбугатка чыккан әсәрләрнең идея һәм сәнгатьчә дәрәҗәсе өчен җаваплылыгын көчәйтү, тәнкыйтьнең художество процессына тагын да тирәнрәк йогынтысын булдыру өчен, художникның дөньяга карашын киңәйтү һәм аның осталыгын камилләштерү, совет кешеләренең югары мораль сыйфатларын ачык һәм тулы чагылдырган югары идеяле һәм сәнгатьчә нык эшлән-

гән әсәрләр иҗат итүгә рухландыру өчен конкрет чаралар күрергә кушылды. Композиторлар һәм художниклар союзында музыка һәм сәнгать белгечләре секцияләренең эшен сизелерлек яхшыртуны тәэмин итәрлек чаралар күрергә. Партия җыелышларында, иҗат работникларының гомуми җыелышларында, идарә утырышларында һәм гыйльми советларда тәнкыйть секцияләре, секторларының эшчәнлеген, аерым тәнкыйтьчеләрнең отчетларын даими тыңлап-тикшереп торырга.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына, иҗат союзларына, «Татарстан коммунисты» журналы редакциясенә тәнкыйтьчеләр игътибарын социалистик реализмның теоретик мәсьәләләрен, традиция һәм новаторлык, партиялелек һәм халыкчанлык принципларын, социалистик культураларның үзара якынаю һәм бер-берләрен баетуларын, әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең теориясен һәм методологиясен һәрьяклап тирәнтен эшкәртүгә, бүгенге художество процессларын, бигрәк тә музыка һәм рәсем сәнгатенең актуаль мәсьәләләрен өйрәнүдә, буржуаз массовый сәнгатьнең реакцион асылын фаш итүдә, әдәбият һәм сәнгатькә марксистик булмаган карашлар белән көрәштә галимнәрнең көчен активлаштырырга тәкъдим ителде.

Газета һәм журнал редакцияләре әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрнең идея-теоретик һәм сәнгатьчә сыйфатына, аларның объективлыгына таләпчәнлекне арттырырга тиешләр, диелә. Аларның жанр ягыннан төрлелеген арттырырга, бу эшкә квалификацияле белгечләрне, күренекле сәнгать галимнәрен, сәләтле яшьләрне киңрәк тартырга, газеталардагы «Әдәбият һәм сәнгать» сәхифәләренең эчтәлегенә һәм сыйфатына аеруча нык игътибар бирергә кирәк.

Культура министрлыгына, Г. Ибраһимов исемендәге институтка, Казан консерваториясенә, иҗат союзларына әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендә белгечләр, бигрәк тә музыка тарихы һәм теориясе, рәсем сәнгате һәм театр сәнгате буенча кадрлар хәзерләүне яхшырту буенча практик чаралар күрергә кушылды. Партия оешмалары белән бергәләп, тәнкыйтьчеләрнең профессиональ осталыгын күтәрү буенча системалы эш алып барырга, яшь кадрлар белән эшләүне тагын да яхшыртуны тәэмин итәргә.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетына, культура институтына, Казан һәм Алабуга педагогия институтларына әдәбият-сәнгать тәнкыйте проблемалары буенча студентларны һәм аспирантларны факультатив специальләштерү буенча тагын да активрак һәм конкретрак шөгыльләнергә кушылды.

КПСС өлкә комитеты бюросы КПСС Үзәк Комитеты карарын үтәү буенча эшне тагын да активлаштыру чаралары планын яхшы дип тапты.

## Фарваз Миңнуллин

# БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

Шикләнми әйтергә мөмкин: соңгы елларда башланган иҗат активлыгы, нигездә, 1974 елда да көчәя барган, әдәбиятыбыз туктаусыз үсештә булган. Татар совет әдәбияты яңа роман-повестьлар, әйбәт-әйбәт шигырь җыентыклары белән баеган, драматурглар театрлар өчен күп кенә әсәрләр язганнар, балалар әдәбиятына караган яңа китаплар чыккан.

Җанлы әдәби хәрәкәт белән танышканда, тагын шул нәрсә ачыклана: матур әдәбиятның бер тармагында да әллә ни зур уңышлар булмаган. Ә менә әдәбият фәне белән әдәби тәнкыйть өлкәсендәге уңышларыбыз шатланырлык та, сөенерлек тә: әдәбият фәненең төрле тармакларына караган бер дистә китап, үзебездә һәм үзәк газета-журналларда басылган йөзләрчә мәкалә, язучыларыбызның яңа әсәрләрен тикшерүгә багышланган бик күп рецензияләр... Әдәбият галимнәребезнең моңарчы беркайчан да бу кадәр күп продукция биргәне булмагандыр. Н. Юзиевның «Шигырь гармониясе» һәм «Хәзерге татар поэтикасы» исемле хезмәтләре республикабызның Габдулла Тукай исемендәге пре-

миясенә лаек булды. Сүз дә юк, боларның һәркайсы куанычлы һәм күңелле күренеш. Образлы тел белән әйтсәк, безнең урамга да бәйрәм килде!

Бәйрәм былтыр гына килсә дә, аңа әзерлек шактый күптән башланган иде.

Моннан өч ел элек КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карары чыкты. Әлеге карардан соң әдәби тәнкыйть мәсьәләләре җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә менде, туры сүзле, принципиаль тәнкыйть хезмәтләренә ихтыяҗ нык артты, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрнең нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудырылды.

Үзәк Комитет карары чыгып күп тә узмады, партиянең Татарстан өлкә комитетында, барлык иҗат союзларында, радиотелевидение һәм газета-журнал редакцияләрендә, югары уку йортларында һәм фән учреждениеләрендә шул карарны тормышка ашыру буенча махсус планнар төзелде. Ул планнарда әдәбият-сәнгать тәнкыйтен тагын да үстерү, тәнкыйтьчеләрнең иҗат активлыгын көчәйтү юнәлешендә конкрет чаралар билгеләнде. 1975 елның 21 гыйнварында КПССның Татарстан өлкә комитеты кабул иткән карардан күренгәнчә, әлеге чараларның күпчелеге уңышлы төстә тормышка ашырылып килә. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә узган ел ирешкән казанышларыбыз да — шуның нәтиҗәсе. Җәмәгатьчелекнең, партия һәм совет оешмаларының кайгыртучан мөнәсәбәтенә әдәбият галимнәре иҗади активлык белән җавап бирделәр. Алар бүгенге әдәбият мәсьәләләренә, җанлы әдәби процесска якыная төштеләр. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтькә караган хезмәтләрнең сыйфаты яхшырды, фәннилек дәрәҗәсе һәм ышандыру көче артты.

1974 елның җәендә Татарстан язучыларының чираттагы съезды булып үтте. Съездга хәзерлек уңае белән басылган мәкаләләрдә, шулай ук съездда сөйләнгән докладларда һәм чыгышларда әдәбиятның бүгенге хәленә төпле бәя бирелде, татар совет әдәбиятының үсеш тенденцияләре ачыкланды, язучылар коллективы алдында торган бурычлар билгеләнде. Съезд тәнкыйть фикерен тагын да җанландырып, көчәйтеп җибәрде.

1971 елдан башлап, «Казан утлары» журналы иң яхшы тәнкыйть мәкаләләренә махсус премияләр биреп килә. Тәнкыйть фикерен активлаштыруда, тәнкыйтьчеләрнең хезмәтен стимуллаштыруда бу чара да мәгълүм бер роль уйнады дияргә була.

Әгәр республикабызда элек-электән әйбәт иҗат атмосферасы яшәп килмәгән булса, бер-ике ел эчендә генә әдәби тәнкыйть әллә кая китә алмас иде. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә узган ел ирешелгән казанышлар турында сөйләгәндә, мәсьәләнең бу ягын да онытмаска кирәк.

Тәнкыйтьчеләр урамына бәйрәм килде, дидек. Бу кадәресе бәхәссез. Ә менә шул бәйрәмгә кемнәр нинди уңышлар белән килә? Әдәбият фәне һәм тәнкыйтьнең аерым тармаклары ни хәлдә? Тәнкыйть ниндирәк юнәлештә үсә? Бу өлкәдә хәл ителмәгән нинди мәсьәләләр, нинди кыенлыклар бар?.. Әлеге сорауларга төгәл җавап бирү өчен, ел дәвамында дөньяга чыккан хезмәтләрнең эченә керергә кирәк. «Эчкә керү»не әдәбият тарихына караган хезмәтләрдән башлыйк.

Узган ел Мәскәүнең «Наука» нәшриятында күп милләтле совет әдәбияты тарихының соңгы томнары басылып чыкты. Һәр ике томда безнең әдәбиятка да шактый урын бирелгән. Алтынчы томга татар совет әдәбиятының хроникасы урнаштырылган (аны филология фәннәре кандидатлары А. Әхмәдуллин белән Р. Сверигин төзегән). Бишенче томда әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйринең зур гына мәкаләсе бар.

Бөтен союз укучысын бүгенге татар әдәбияты белән таныштыру ниятеннән чыгып язылган ул мәкаләдә соңгы 10—15 ел вакыт эчендә басылган әсәрләр тикшерелә, татар әдәбиятының үсеш тенденцияләре күзәтелә. Мәкалә тулылыгы, язучыларыбыз иҗатына объектив бәя бирүе белән аерылып тора. Автор соңгы елларда иҗат ителгән әсәр исемнәрен, хәзерге әдәби процесска актив катнашучы күпчелек язучыларны телгә ала. Шуның белән бергә, бу мәкаләдә сөйләнгән нәрсәләрнең күбрәк 50 нче елларның ахыры һәм 60 нчы елларның башы өчен, тагын да конкретлаштырып әйткәндә, татар әдәбиятында авыл тормышына караган әсәрләр өстенлек иткән чорлар өчен хас булуын билгеләп үтәргә кирәк. Аннан бирле хәлләр нык үзгәрде. Татар әдәбияты йөз белән бүгенге заманга борылды, авыл әдәбиятыннан шәһәр әдәбиятына, бүгенге эшчеләр тормышын сурәтләүче әдәбиятка әйләнде. Үкенечкә каршы, соңгы еллар әдәбиятын-

дагы әлеге үзгәрешләр бу мәкаләдә җитәрлек чагылыш тапмаган.

Һәр елдагыча, «Казан утлары» журналы битләрендә әдәбият тарихына караган кызыклы гына материаллар басылган. Аларга бәя бирергә керешкәнче, аклану тәртибендәге бер аңлатма биреп үтәсе килә. Элеккерәк елларда журналны тарихи материаллар белән мавыгуда гаеплиләр иде. Ихтимал, мавыгып китүләр чыннан да булгандыр. Соңгы елларда тарихи материаллар басу кими төште. Аннан соң әдәбият-сәнгать тарихына караган материалларның характеры нык үзгәрде. Журнал хәзер конкрет документлар басарга тырыша, әдәбият тарихына караган материалларны бүгенге көн, бүгенге тормыш ихтыяҗлары белән бәйләргә омтыла. Журнал битләрендә узган ел басылган мәкаләләр дә әнә шул фикерне раслый.

Ү. Гыймадиевның «Чикерткә» — татар телендә беренче сатирик журнал» (2 сан), С. Хафизовның «Онытылган бер әсәр турында» (5 сан), М. Мөлековның «Галиябану» ничек язылган...» (8 сан), Ф. Ибраһимованың «Тәрбиятел әтфаль» һәм «Ак юл» журналларында балалар әдәбияты» (12 сан), С. Рәимованың «Г. Ибраһимовның бер хикәясе турында» (5 сан) исемле мәкаләләрендә әдәбият тарихына караган кызыклы мәгълүматлар китерелә. «Анкета битләреннән» (3 сан) дигән материалда күренекле әдип һәм журналистларның иҗат биографияләрен ачыкларга ярдәм итәрлек фактлар, аерым детальләр бар. Я. Абдуллин суфичылык һәм мәгърифәтчелек философиясенең галимнәребез игътибар биреп җиткермәгән кайбер якларын тикшерә (2 һәм 10 саннар), Х. Миңнегулов XIV йөздә яшәгән өч шагыйрь белән таныштыра («Әхмәд Үргәнҗи һәм аның ике чордашы», 7 сан). Журнал битләрендә болардан башка да кызыклы материаллар басылган. Шуларның һәммәсе арасыннан Фатих Махиянов мәкаләсе аеруча әйбәт тәэсир калдыра. Соңгы тамчы канына кадәр бөтен көчен авылда яңа тормыш төзү эшенә багышлаган Галим Насыйровның ифрат гыйбрәтле һәм фидакарь тормышы, иҗаты турындагы бу язманы тетрәнми укып булмый. Журнал тарихи материалларны бүгенге тормыш иҗтыяҗлары белән бәйләргә омтыла дигәндә, мин әнә шундый мәкаләләрне күздә тоттым.

1974 елда Татарстан китап нәшрияты тарихи пландагы өч китап басып чыгарды. Турыдан-туры әдәбият тарихына карамасалар да, аларны бөтенләй читләтеп узу килешмәс.

Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги» исемле монографиясе әдәби җәмәгатьчелек һәм укучылар арасында зур кызыксыну уяткан иде. Авторның яңа хезмәте дә китап тарихына багышланган. Беренче хезмәте кебек үк, бусы да күп көч куеп, ифрат бай материалга нигезләнеп язылган. Автор XX йөз башында татар китабын басу белән шөгыльләнгән күпчелек типографияләр тарихын, ул типографияләрдә басылган китапларны өйрәнеп чыккан. Хезмәтнең «Цензура татарской книги» дип исемләнгән өченче бүлеге аерым бер пафос һәм тәнкыйтьчел рух белән язылган.

Ә. Кәримуллин китабы кызыклы яңа мәгълүматларга бай. Ул безгә күп белем бирә, күп нәрсәләргә безнең күзебезне ача. Шуның белән бергә, күңел төбендә кайбер сораулар да туа: автор, типографияләр эшчәнлеген өйрәнүгә күп игътибар биреп тә, нәшриятлар эшчәнлеген читләтебрәк үтмиме? Хезмәттә аерым типография һәм нәшрият хуҗаларының (И. Н. Харитонов, Г. Шәрәф, Ф. Кәрими һ. б.) эшчәнлеге идеаллаштырылмыймы?

Ә. Кәримуллин китабын укыганда, шундыйрак сораулар белән баш ватарга туры килгән иде. Фатих Урманчеев хезмәтенә килеп җиткәч, эшләр нык җиңеләйде. Җиңеләйтүче кеше Дамир Гарифуллин булды. Аның «Социалистик Татарстан» газетасында басылган рецензиясендә (1975 ел, 17 гыйнвар саны) «Халык авазы» китабындагы кимчелекләрнең һәммәсе: эресе дә, вагы да, принципиале дә, принципиаль булмаганы да рәттән санап чыгылган. Газета битләрендә шундыйрак бер рецензия 1974 елда да басылган иде [1].

Характерлары, язылышлары белән бу ике рецензия ифрат аваздаш булып чыккан. Һәр ике рецензиядә нигездә әйбәт язылган хезмәтләр турында сүз бара. Рецензентларның берсе дә үзләре тикшерә торган хезмәтләренең әйбәт булуын инкарь итми. Ләкин ике рецензент та баштан ахырга кадәр кимчелек эзләү белән мавыгалар. Нигә шулай эшлиләр? Сәбәп нәрсәдә? Миңа калса, алар әдәби тәнкыйтьнең бурычын берьяклырак аңлап калганнар, ан-

[1] Мин Хатип Миңнегуловның «Җитди тикшеренү» исемле рецензиясен (29 декабрь саны) күздә тотам. Ул рецензиядә Ш. Садретдиновның «Сәгыйт Рәмиев иҗаты» турындагы монографиясе тикшерелә.

нары «мин беләм»лек дәгъвасы да комачаулаган булса кирәк.

Инде Ф. Урманчеев китабының әйбәт якларына килгәндә, алар анда чыннан да бар һәм байтак. Китап бәет жанры турында моңарчы чыккан барлык хезмәтләрне искә алып, совет фольклор фәненең бүгенге казанышлары югарылыгында торып язылган. Автор бәет жанрының туу, формалашу тарихына туктала. Аның шул уңай белән әйткән фикерләре — хәтта фараз кылу рәвешендә әйткәннәре дә — игътибарга лаек. Ф. Урманчеев аерым бәетләрнең (мәсәлән, «Нәүрүз бәете»нең) язылу дәверен һәм авторларын («Шаһгали ханның вәзирләре хакында чыгарган йыруы») ачыклый. Ул жанрның һәр тарихи чордагы хәлен һәм үсеш тенденцияләрен тикшерә, бәетләрне төркемнәргә бүлә, һәр төркемгә фәнни характеристика бирә. Хезмәт белән танышканда татар бәетенең үсеш юлы һәм бөтен тарихы күз алдына баса, бәетнең безнең тормыштагы ролен, әһәмиятен тирәнрәк аңлый башлыйсың, укучы каршында жанрның бәясе күтәрелә, кадере арта. Ф. Урманчеев китабының төп кыйммәте әнә шунда.

Д. Гарифуллин рецензиясендә әйтелгән фикергә килсәк, аңарга мин дә кушылам. «Халык авазы» исемле китапта бәет жанры турында соңгы сүз әйтелгән дип булмый, билгеле. Бәетләрне җыю һәм фәнни өйрәнү эшен дәвам иттерергә кирәк.

Галия Хантемированың «Оригиналның милли үзенчәлеге һәм тәрҗемә мәсьәләләре» дигән бәләкәй генә китабы тәрҗемә фәненең бөтен тармакларына: тарихка да, теориягә дә, хәтта тәнкыйтькә дә карый дияргә була.

Хезмәтнең беренче бүлегендә 20—30 һәм 40—50 нче елларда рус теленә тәрҗемә ителгән проза әсәрләре турында сөйләнә, әлеге тәрҗемәләрнең сыйфаты тикшерелә. Аның бу бүлеге нигездә тарихи характерда язылган. Соңгы икенче бүлектә әдәби тәрҗемәнең теоретик мәсьәләләре күтәрелә. Автор рус теленә тәрҗемә ителгән аерым әсәрләрне тикшерә, шул әсәрләр мисалында, тәрҗемә теориясенә караган фикерләр әйтә, әдәби тәрҗемәдә милли үзенчәлекне саклау белән бәйле күп төрле алымнар һәм закончалыклар турында сүз алып бара. Мин хезмәтнең ул якларына бәя бирергә кыенсынам. Әмма авторның шактый усал телле тәнкыйтьче дә булуы, тәрҗемә эшенең нечкәлекләрен аңлап фикер йөртүе бәхәс уятмый.

Хезмәт белән танышканда, тагын бер нәрсә сизелеп кала: Г. Хантемирова, әдәби тәрҗемә эше елдан-елга, чордан-чорга, һичшиксез, яхшыра, камилләшә барырга тиеш, дигән өзер тезиска таянып фикер йөртә. Мисаллар сайлауда ул алга сөргән принциплар, һәр төрле тартып-сузып китерүләр шуның белән аңлатыла.

*
* *

Без күп еллар буе: «Әдәбият теориясе эшләнми, әдәбият теориясенең эшләнмәгән булуы әдәби тәнкыйтьнең дә үсешен тоткарлый», дип зарланып килдек. Үзәк Комитет карарыннан соң бу өлкәдә дә мәгълүм бер җанлану сизелә башлады. Һәм 1974 ел безгә теория мәсьәләләренә караган кызыклы хезмәтләр алып килде. Шуларның берсе «Совет сәнгатендә миллилек һәм интернациональлек» дип атала.

Философия фәннәре докторы Камил Фасеевның «Социалистик Татарстан» газетасында (1975 ел, 26 январь) басылган рецензиясендә бу китапка шактый тулы һәм төпле бәя бирелә. Рецензент хезмәтнең әһәмиятен һәм яңалыгын ачып бирә, тагын да ачыклауны һәм тирәнәйтүне сорый торган кайбер мәсьәләләргә туктала. Мин аның күпчелек фикерләре белән килешәм.

Философия фәннәре кадидаты Казбек Гыйззәтовның әлеге китабында сәнгатьтәге миллилек һәм интернациональлек, аларның үзара мөнәсәбәте һәм үсеш диалектикасы, милли форма һәм социалистик эчтәлек, социалистик җәмгыятьтә милли әдәбият һәм сәнгатьләрнең үзара йогынтысы һәм берберләрен баетулары, эстетик критерийларның интернациональләшә баруы кебек мәсьәләләр, марксистик-ленинчыл эстетиканың һәм философиянең бик күп башка мәсьәләләре яктыртыла.

Күп булулары өстенә, алар гаять авыр һәм катлаулы, ифрат нечкә һәм четерекле дә. Китап автордан күп көч, зур хезмәт куюны сораган. Эстетика һәм философия мәсьәләләреннән тыш, галим совет сәнгатенең бүгенге хәлен һәм үсеш тенденцияләрен ныклап өйрәнергә тиеш булган, Казбек Гыйззәтовтан эстетик зәвык һәм сәнгатьчә сиземләү таләп ителгән. Шиклләнми әйтергә була: ул үз өстенә төшкән авыр бурычны нигездә уңышлы башкарып чыккан. Хезмәт баштан ахырга кадәр зур игъ-

тибар белән укыла. Аның сәнгатьтәге миллилек, милли характер, милли форма һәм социалистик эчтәлек, эстетик критерийларның интернациональләшә баруы турындагы өлешләре аеруча әйбәт тәэсир калдыра.

Казбек Гыйззәтов китабының тагын бер үзенчәлекле ягы шунда, ул баштан ахырга кадәр полемик дәрт, сугышчан рух, публицистик ялкын белән сугарылган. Автор үз карашларын кыю төстә яклый белә, фикерен өзеп, ачык итеп әйтә. Әмма урыны-урыны белән К. Гыйззәтов галимнән тәнкыйтьчегә әйләнеп китә. Мәсьәләнең асылын аңлатасы, теге яки бу күренешне китереп чыгарган сәбәпләрне ачыклыйсы урында, ул тәнкыйть итү, тиргәү белән мавыга башлый. Хезмәттә ахыргача уйланып җитмәгән, шуның аркасында төрлечә уйларга юл калдыра торган җөмләләр очрый.

Ибраһим Нуруллинның «Реализм турында» дигән китабы да күпмедер дәрәҗәдә хәзер генә тикшереп узган хезмәтне хәтерләтә. Беренче чиратта, аңлаешлы, җиңел телдә язылуы, сугышчан рухы һәм полемик дәрте белән.

Ибраһим Нуруллин — иҗат методлары турындагы хезмәтләре белән танылган галим. Аның критик реализм һәм мәгърифәтчелек реализмы турындагы тикшеренүләре ил күләмендә яңгыраш тапты. Авторның яңа китабы да иҗат методларына багышланган. Хезмәттә өч реалистик метод (мәгърифәтчелек реализмы, критик реализм, социалистик реализм) турында сүз бара.

Китапта һәр метод турында ике мәкалә урнаштырылган. Аларның берсе, гомумтеоретик характерда булып, теге яки бу методның асылын аңлатуга багышланган, икенчесендә шул методны характерлый торган конкрет әсәрләр тикшерелә.

Бездә реалистик иҗат методларының конкрет эчтәлеге, алар арасындагы уртак сыйфатлар һәм аермалы яклар юньләп өйрәнелмәгән. И. Нуруллин китабында нәкъ әнә шул мәсьәләләргә игътибар ителә. Мәгърифәтчелек реализмын алыйк. Әлеге методны өйрәнүгә багышланган мәкалә тулылыгы, конкрет характерда булуы белән аерылып тора. Галим методның асыл сыйфатларын ачып бирә, мәгърифәтчелек реализмы принципларыннан чыгып язылган бик күп әсәрләрне анализлый.

Шуның белән бергә, мәкаләдә тагын да ачыклауны, конкретлаштыра төшүне сорый торган урыннар да очрый. Әйтик, мәгърифәтчелек реализмын ул аның үзенә кадәр булган иҗат методлары белән түгел, ә үзеннән соң килгән иҗат методы, ягъни критик реализм белән генә янәшә куеп, чагыштырып тикшерә. Шуңа күрә мәгърифәтчелек реализмының кимчелекле, йомшак якларына гына басым ясала, бу метод алып килгән яңалык тиешенчә ачылмый кала. Аннан соң, артык конкрет булырга тырышуның да зыяны сизелә шикелле. Галим бер реалистик методны икенчесеннән аера торган сыйфатларга күп басым ясый, теге яки бу иҗат методының кысаларын артык кискен билгели. Нәтиҗәдә, төрле реалистик методлар арасындагы уртак яклар ачылмый кала. Реалистик методлар арасындагы мөнәсәбәт И. Нуруллин аңлатканнан катлаулырак, билгеле. Хезмәттә иллюстрация өчен тикшерелгән конкрет әсәрләр үк шул турыда сөйли. Мәгърифәтчелек реализмының характерлы үрнәге дигәне мәгърифәтчелек методына гына сыеп бетми, критик реализм үрнәге дигәне критик реализм булып җитмәгән. Шундыйрак бер нәрсә социалистик реализмның башка иҗат методларына мөнәсәбәтен аңлатканда да сизелеп кала. Критик реализм белән мөнәсәбәт җиңел хәл ителә. Автор, бернинди икеләнүләргә һәм шик-шөбһәләргә урын калдырмыйча, болай дип яза: «Әгәр инде без критик реализм дигәннән яшәп килүче стройның үзен тәнкыйтьли, җәмгыятьнең нигез ташларын какшата торган реализмны аңлыйбыз икән (Көнбатыш Европа һәм рус критик реализмы, шулай ук үзебезнең критик реализм шундый иде), үзеннән-үзе аңлашыла, совет әдәбиятының бу иҗат методы белән бернинди алыш-биреше була алмый» (73 бит).

Ә менә романтизм мәсьәләсенә килеп җиткәч, ул ничектер аптырабрак кала шикелле. «Романтизмга (прогрессив, революцион романтизмга) килгәндә исә, — ди автор, — мәсьәлә катлаулана төшә. Әдәбиятның бурычы тормышны танып-белү генә түгел, бәлки тәрбияләү һәм эстетик ләззәт тә бирү икәнлеген искә алсак, принципта романтизмның мөстәкыйль иҗат методы буларак яши алуы турында сүз алып бара алабыз» (72—73 битләр).

Критик реализмның совет әдәбияты белән алыш-биреше юк икән, нигә әле романтизм методыныкы булырга тиеш?! Сүз, мөгаен, критик реализмныкы кебек үк, романтизмның да аерым алымнары турында гына барырга тиештер. Авторны романтизм методының «прогрессив», «рево-

люцион» дигән эпитетлары адаштырган булса кирәк...

Узган ел «Казан утлары» журналында әдәбият теориясенә караган берничә мәкалә басылган. Күбесе төрле иҗат методларын һәм әдәби стильләр тарихын өйрәнүгә багышланган. Язылышлары, фәнни тирәнлекләре төрлесенеке төрле дәрәҗәдә. Әмма һәркайсында игътибарга лаек фикерләр әйтелә, кызыклы мәсьәләләр кузгатыла. Шуларның икесенә аерым тукталып үтәсе килә. Берсе — Хәлиф Курбатовның «Иркле шигырь» ( 7сан) дигән мәкаләсе. Исеменнән үк күренгәнчә, мәкаләдә сүз шигырь төзелеше мәсьәләләре турында бара. Автор безнең матбугатта иркле шигырь уңае белән әйтелгән төрле фикерләргә йомгак ясый, күп кенә буталчык мәсьәләләргә аныклык кертә. Мәкаләдә иркле шигырь язуның катлаулы һәм авыр эш булуына басым ясала. Х. Курбатов мәкаләсе иркле шигырь турында дөнья күләмендә басылган күп хезмәтләрне искә алып язылган. Ул тагын әнә шул ягы белән игътибарны җәлеп итә. Фән үсешендәге бу башлангыч тирәнәергә һәм көчәя барырга тиеш.

Р. Мостафинның «Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат» дигән мәкаләсе (8 сан) социалистик реализм методы хакындагы бәхәсләр уңае белән язылган. Мәкалә бөтен рухы белән социалистик реализмны артык тар, догматикларча аңлаучы һәм аңлатучы галимнәргә каршы юнәлдерелгән. Автор социалистик реализм методының чикләнмәгән мөмкинлекләре булуга, аның үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат икәнлегенә басым ясый. Мәкалә гади һәм аңлаешлы телдә, популяр стильдә язылган булуы белән аерылып тора.

Теоретик хезмәтләрнең күбәя төшүе — күңелле хәл. Ләкин бу өлкәдә эшләнмәгән эшләр, хәл ителмәгән мәсьәләләр дә күп әле. Әдәбият теориясенең аерым тармаклары тигез үстерелми. Кирәклеге күптән расланган «Әдәбият теориясе» китабының әле һаман очы-кырые күренми. Татар әдәбият тәнкыйтенең тарихы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди кебек тәнкыйтьчеләрнең иҗат мирасы рәтләп тикшерелми.

Үзәк Комитет карарында: «СССР Фәннәр академиясенә, министрлыкларга, ведомстволарга үз карамакларындагы институтларның игътибарын әдәби тәнкыйтьнең теория һәм методология проблемаларын өйрәнүгә юнәлдерергә... тәкъдим ителде» дигән юллар бар. Миңа калса, әдәби тәнкыйтьнең теория һәм методология проблемаларын тирәнтен өйрәнү бурычы, беренче чиратта, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре өстенә төшә. Төшә генә түгел, бу — алар эшчәнлегенең төп юнәлешен билгеләргә тиеш иде. Кызганычка каршы, нәкъ шул юнәлештәге эшләрнең байтагы әлегә эшләнми килә. Моннан өч ел элек расланган планга караганда, 1972—1975 елларда татар совет әдәбият-сәнгать тәнкыйте тарихы буенча очерклар бастырып чыгару күздә тотылган, «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре турында» дигән җыентык әзерләнергә тиеш булган. Хәлбуки, теория һәм методология мәсьәләләренә фәнни ачыклык кертергә тиешле һәм принципиаль әһәмияткә ия булган әлеге җыентыкларның язмышын ачыклау артык озакка сузылды. Беренчесенең очы-кырые һаман күренми. Икенчесе яңа гына производствога төшерелгән. Әбит беркемгә дә сер түгел, бездә әдәбият фәне буенча язылган аерым хезмәтләргә нәкъ менә методологик ачыклык җитми, аларның философик нигезе йомшак була. Кыскасы, әдәбият теориясе мәсьәләләренә киләчәктә дә иң җитди игътибар бирелергә тиеш.

* * *

Үзәк Комитет карарыннан соң тәнкыйть турындагы тәнкыйть аеруча җанланып китте, бүгенге тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган уннарча мәкалә басылды. Н. Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә» («Казан утлары» журналы, 1973 ел, 8 сан), Ф. Хатиповның «Җаваплылык» («Казан утлары», 1974 ел, 4 сан), М. Госмановның «Иң кирәклесе — сыйфат» («Социалистик Татарстан» газетасы, 1973 ел, 12 май), Р. Мостафинның «Әдәби тәнкыйтьнең уңышлары һәм бурычлары» («Казан утлары», 1974 ел, 10 сан) кебек мәкаләләрендә, Ф. Урманчеевның «Казан утлары» (1973 ел, 5 сан) һәм «Литературное обозрение» (1974 ел, 5 сан) журналларында, шулай ук «Советская Татария» газетасында (1974 ел, 20 январь) басылган мәкаләләрендә безнең тәнкыйтьнең көчле һәм йомшак якларына төпле бәя бирелде. Әлеге мәкаләләрдә әйтелгән фикерләрнең байтагы былтыргы тәнкыйтькә карата да туры килә.

Бүгенге тәнкыйтьтә иң зур урынны күзәтү характерында язылган мәкаләләр алып тора. Тәнкыйтьнең бу төре язучылар

союзы идарәсенең оештыру эшчәнлеге белән якыннан бәйләнгән. Журнал тикшерүләр, әдәби ел йомгаклары безнең тәнкыйтьтә күзәтү жанрының активлашуына китерде. Узган ел исә алар аеруча күп язылган. «Казан утлары» журналында басылган 27 мәкаләнең яртысына якыны күзәтү характерында. Андый мәкаләләр «Социалистик Татарстан» газетасында да шактый. Сан ягыннан бик нык арту белән бергә, аларның сыйфаты да елдан-ел яхшыра бара. А. Әхмәдуллин «Заман героен эзләү юлында» дигән мәкаләсендә («Казан утлары», 1974 ел, 4 сан) бер ел эчендә иҗат ителгән сәхнә әсәрләренә нигезләнеп бүгенге драматургиягә хас күп кенә закончалыкларны ача алган. Т. Галиуллинның «Буыннар һәм язмышлар» исемле мәкаләсенә дә («Казан утлары», 1974 ел, 5 сан) шундый ук сыйфатлар хас. Өстәвенә, бу мәкалә үзенең тулылыгы, татар шигъриятенең зуррак чорын иңләве белән аерылып тора. Р. Нуруллинаның «Киң юлга чыгарга вакыт» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 16 май), Р. Төхфәтуллинның «Юлны кичәр атлаган» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 17 ноябрь) кебек мәкаләләре дә нигездә матур тәэсир калдыра. Татарстан язучыларының VIII съездында аерым жанрлар буенча сөйләнгән докладларга тукталып тормыйм. Әлбәттә, доклад белән доклад арасында да аермалар бар. Әмма нигездә аларның барысы да тиешле югарылыкта, тулы һәм төпле итеп язылган.

Күзәтү характерындагы мәкаләләрнең активлашуы нәтиҗәсендә без җанлы әдәби процесска тагын да якыная төштек, нигездә барлык яңа әсәрләргә үз вакытында бәя биреп баруга ирештек. Хәзер безнең язучыларның бер генә җитди әсәре дә тәнкыйть игътибарыннан читтә калмый дияргә була. Бу — безнең тәнкыйтьнең зур уңышы. Күзәтү жанрының активлашуы әдәби тәнкыйтьнең башка тармакларына да мәгълүм бер йогынты ясады, иң элек рецензия жанрына. Күзәтү характерында язылган мәкаләләрдә кайбер яңа әсәрләргә шул кадәр төпле һәм тулы бәя бирелә, аларга кабат рецензияләр яздырып торуның хаҗәте дә калмый.

Күзәтү рухы проблематик мәкаләләргә үтеп керде. Мисал төсендә Р. Мостафинның «Яңа теманы үзләштерү юлында» («Казан утлары», 1974 ел, 1 сан), И. Ахунҗановның «Круговорот лирического героя» («Советская Татария», 1974 ел, 15 һәм 22 сентябрь) исемле мәкаләләрен күрсәтергә була. Күзәтү рухы хәтта монографик пландагы китапларда да сизелә башлады. Ф. Мусинның «Тарих һәм заман» исемле китабы шул хакта сөйли торган характерлы бер мисал була ала.

Тәнкыйтьченең яңа китабы соңгы елларда басылган проза әсәрләренә тематик күзәтү, обзор рәвешендә язылган. Ф. Мусин бер-бер артлы тарихи темага караган, авыл тормышын чагылдырган, эшчеләр тормышына һәм бүгенге интеллигенциягә багышланган роман-повестьларны күзәтеп чыга, ул әсәрләрдә сурәтләнгән образларны тикшерә. Автор теге яки бу әсәрне тикшерү уңаенда туган фикерләре белән уртаклаша. Китапның һәр өч бүлегендә күп кенә кызыклы мәсьәләләр күтәрелә, татар совет прозасының үсеш тенденциясенә бәйләнешле гомумиләштерүләр ясала. Китап белән танышканда, бүгенге татар прозасының тулы картинасы күз алдына баса. Ф. Мусинның барлык мәкаләләре тыныч, салмак тонда язылган. Тәнкыйтьче безнең роман-повестьларны ил күләмендәге әдәби хәрәкәткә бәйләп, башка милләт язучыларының әсәрләре белән янәшә куеп, чагыштырып бәяли. Бу — аны күтәренке бәяләр бирүдән, һәр төрле шапырынулардан саклап калган. Китап зур таләпчәнлек ноктасыннан торып язылган. Шуның белән бергә, автор тәнкыйть итү, кимчелек эзләү белән артыграк та мавыгып киткән кебек. Таләпчәнлекне арттырабыз дип, әдәбиятыбызның булган кадәр уңышларын күрми башласак, дөрес булмас. Кимчелекләрне тәнкыйть итү белән бергә, тәнкыйтьче язучыларның уңышларына куана, әдәбият ирешкән казанышлар белән горурлана да белергә тиеш.

Күзәтү жанры бик активлашты дигәч тә, татар тәнкыйтендә проблематик мәкаләләргә бөтенләй урын калмаган икән, дип уйлый күрмәгез. Узган ел андый мәкаләләр дә шактый язылган. «Социалистик Татарстан» газетасында Х. Хәйри, М. Мәһдиев, Р. Мостафин, Б. Гыйззәт, Ф. Мусин мәкаләләре чыккан. «Советская Татария» газетасында Әхәт Гаффаровның «Спроси у сердца» исемле усал гына мәкаләсе басылган. Проблема күтәргән мәкаләләр «Казан утлары» журналында да булмаган түгел. Ш. Әхмәдуллинның «Киләчәкне уйлап» (1 сан) һәм З. Нуриның «Яшьләргә — яшел урам» (3 сан) исемле мәкаләләрендә әдәби алмаш тәрбияләү мәсьәләләре турында сүз бара. А. Айнетдиновның «Батырлар эзеннән» (2 сан) исемле мәкаләсе докумен-

таль очеркларда көчәеп киткән бер тенденциягә — яңа герой ачу белән мавыгуга каршы язылган. Х. Сарьянның «Алай да була! — булмасын» дигән мәкаләсе бүгенге әсәрләребезнең телен тикшерүгә багышланган. Мәкалә әдәби тел үсешенең законлылыкларын тирәнтен белеп, телнең тәмен-ямен нык тоеп язылган. Х. Сарьян мәкаләсе журналның махсус премиясенә лаек булды. Бу факт үзе күп нәрсә турында сөйли. Х. Сарьянның әдәби тел турында язылган мәкаләләренә хас бер кимчелек турында да әйтим. Аның мәкаләләре буенча фикер йөрткәндә, кем әдәби телне шәп белә, шул кеше иң яхшы язучы да булып чыга. Хәлбуки, алай ук түгел бит...

Былтыр басылган проблематик мәкаләләрне күпме генә мактасак та, Фатих Хөснинең «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» дигән китабын укуга аларның күбесе шактый төссезләнеп, тоныкланып кала. Яңа җыентыкка күренекле әдипнең гомер буе язган мәкаләләре тупланган. Аларның иң күбе проблематик характерда. Нинди мәсьәләләр, нинди проблемалар гына борчымый аны! Сәнгать әсәрләренең милли үзенчәлеге һәм эстетик кыйммәте, язучының иҗтимагый йөзе һәм иҗат активлыгы, әдәби тел, әдәби тәнкыйть мәсьәләләре... Исәпләп тә, санап та бетерә торган гына түгел. Өстәвенә, һәркайсы янып-көеп, әрнеп-борчылып, мавыгып һәм дуамалланып, укучыны үз артыннан ияртерлек итеп язылган, чын йөрәктән, ихлас күңелдән язылган.

Гомәр Бәшировның «Бүген дә, иртәгә дә» исемле китабы турында фикерләремне әйтеп, чыгыш ясаган идем. Биредә аларны кабатлап тормыйм. Фатих Хөснине күбрәк әдәбият язмышы, әдәби осталык мәсьәләләре кызыксындырса, Г. Бәширов мәкаләләренең тематик колачы киңрәк. Әдәбият, әдәби тел, фольклор мәсьәләләреннән тыш, авторны халык тормышының бик күп башка яклары борчый. Җыентыкта табигатьне саклау һәм авыл төзелеше мәсьәләләренә караган публицистик мәкаләләр дә, күренекле әдипнең каләмдәш дуслары һәм замандашлары турында язылган истәлекләре дә урын алган. Кыскасы, китаптагы мәкаләләрнең һәркайсында берәр мөһим мәсьәлә күтәрелә. Һәм аларның һәркайсы диярлек Гомәр Бәшировның тынгысыз җанлы гражданин булуы хакында сөйли.

Нәби Дәүлинең «Ак янында кара» дип исемләнгән җыентыгында әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә урын алган. Ул мәкаләләрдә автор язучының тормыштагы җаваплылыгы, әдәбиятның иҗтимагый роле турында уйлана, каләмдәш дуслары турындагы истәлекләре белән уртаклаша. «Бизәк өчен түгел, кирәк өчен» дигәне укучыларга таныштыр. Ул әдәби ел йомгакларында сөйләгән доклады нигезендә язылган. «Мусалар дивизиясеннән солдат кайтты» дигән җыйнак кына мәкалә Рәхим Саттар истәлегенә багышланган. «Поэзиянең ватаны — җир һәм тормыш» исемле мәкалә әдәби бәхәс уңае белән язылган. Җыентыктагы күпчелек мәкаләләр поэзиягә карый, аларның барысы да Нәби Дәүличә язылган...

Узган ел аерым язучылар иҗатына багышланган, шулай ук теге яки бу әсәр уңае белән язылган тәнкыйть мәкаләләре күп булмаган. Шулай да чыккалаган. Күп кенә бәхәсләр, капма-каршы фикерләр уяткан ике мәкаләгә тукталыйк. Аларның берсе — «Безгә ак болыт булырга язмаган шул» дигән мәкалә. Р. Фәйзуллинның «Наз» исемле китабы чыгу уңае белән язылган. Авторы — яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев. Икенчесе — Илдус Ахунҗановның Ренат Харисов иҗатына багышланган мәкаләсе.

Равил Фәйзуллин иҗаты турында күп язылды. Аны күп мактадылар, тәнкыйть итүчеләр булды. Ләкин моңарчы беркем дә шагыйрь иҗатын аның үз буыны белән, Фәйзуллин иҗатының үзенчәлекләрен шагыйрьнең әдәби-эстетик карашлары формалашкан чорның рухы белән бәйләп карамаган иде. Мансур Вәлиев, беренче булып, шул эшне башкара... Равил Фәйзуллин шигырьләрен мин дә яратам. Аның иҗаты турында мәкалә язсам, ихтимал, шагыйрьнең башка шигырьләренә, шагыйрь иҗатының башка якларына тукталыр идем. М. Вәлиев үзе яраткан шигырьләрне сайлаган. Һәм шагыйрь иҗатының без игътибар итеп җиткермәгән яңа якларын ачып биргән. Барыбыз да бер төсле уйлый, бер төсле яза башласак, күңелсез булыр иде. Илдус Ахунҗановның Ренат Харисов иҗатына караган мәкаләсе турында да якынча шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин.

...Безнең көннәрдә бер генә әдәбият та үз кабыгына гына бикләнеп үсми, үсә алмый. Менә шуңа күрә республика газета-журналларында халыклар дуслыгына, әдәбиятлар дуслыгына караган материалларның елдан-ел күбрәк урын ала баруы — табигый күренеш. Г. Рамазановның «Үкендермәс мине үткән гомерем» («Казан утлары», 1974 ел, 2 сан), Н. Мурадымовның «Бетмәс чыганаклар» («Социалистик Та-

тарстан», 1974 ел, 24 февраль), В. Гончаровның «Фронтташ дустым» («Казан утлары», 1974 ел, 2 сан), С. Васильевның «Татар шигъриятенең остасы» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 13 октябрь), Л. Мәхсумованың «Татар-үзбәк әдәби мөнәсәбәтләре» («Казан утлары», 1974 ел, 6 сан) кебек мәкаләләре әнә шул үтә мөһим һәм актуаль темага багышланган.

Күрәсез, былтыргы әдәби тәнкыйть бай һәм кызыклы булган. Тәнкыйть әдәби хуҗалыгыбызны барлау, язучылар иҗатына бәя бирүдә оператив эшләгән. Татар тәнкыйте житди игътибарга лаек яңа китаплар белән баеган, әдәби хәрәкәт барышына йогынты ясарлык бик күп мәкаләләр язылган. Ул мәкаләләрне кемнәр язган? Кемнәр ничек эшли? Тәнкыйть кемнәргә таяна?

Баштан ук әйтеп китәргә кирәк, бездә тәнкыйтьне үстерү эшенә элек-электән язучылар да актив катнашып килә. Язучы каләме белән язылган тәнкыйть эмоциональ яңгырашлы, җиңел укыла торган була. Шуның белән бергә, берьяклырак мавыгып китүләр, шәхси симпатия һәм антипатияләрдән чыгып эш йөртүләр дә, гадәттә, язучылар язган мәкалә-рецензияләрдә очрый. Һәрхәлдә, тәнкыйтьнең төп көче әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр булырга тиеш. Г. Халит, И. Нуруллин, Х. Хәйри, Р. Мостафин, Н. Юзиев, М. Мәһдиев, Т. Галиуллин, Ф. Урманчеев, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин кебек әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр элекке еллардагы кебек үк актив эшлиләр. Соңгы елларда тәнкыйтьчеләр сафы Ф. Хатипов, И. Ахунҗанов, Йолдыз һәм Энгель Нигъмәтуллиннар, Ш. Әхмәдуллин, Р. Сверигин, З. Рәмиевләр исәбенә тагын да тулылана төште. Әдәби тәнкыйть мәйданына М. Вәлиев, Н. Гамбәров, М. Галиев, Р. Абдуллина, Ә. Дәминов, Рөстәм Фәйзулин, Р. Мөхәммәдиев кебек яшьләр килде. Шуның белән бергә, бу өлкәдә безне борчуга сала торган нәрсәләр дә шактый әле. Яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү өлкәсендә күп кенә конкрет чаралар күрелде. Әмма яшь алмаш без уйлаганнан азрак килә, без теләгәннән акрынрак үсә.

Элеккерәк елларда татар тәнкыйтьчеләре үзәк газета-журналларда аз басыла дип сөйли идек. Хәзер бу өлкәдә дә эшләр ярыйсы кебек. Р. Мостафин, Т. Галиуллин, Ф. Урманчеев, Ф. Мусин, И. Ахунҗанов, М. Мәһдиев, Ә. Мәхмүдов кебек тәнкыйтьчеләр үзәк матбугат битләрендә шактый еш басыла. Активлыкны киметмәстән, үзәк матбугатта басыла торган мәкалә-рецензияләрнең сыйфатын күтәрү турында ныграк кайгыртырга кирәк.

* * *

Тәнкыйтьнең бер тармагы булган рецензия жанры турында, бүгенге рецензияләрнең сыйфаты турында шулай ук күп язылды. Бу өлкәдә яшәп килгән бөтен кимчелекләр күрсәтелде, дияргә була. Матбугатка чыккан китапларның күбесе бәяләнми кала, диделәр. Бүгенге көнгә бик үк туры килмәсә дә, бу фикердә дә күпмедер дөреслек бар. Күренекле язучыларыбызның том-том «Сайланма әсәрләр»е, шигырь китапханәсе сериясеннән уннарча җыентыклар чыкты. Аларның берсе дә тәпле рецензия күрмәде. Әдәбият дәреслекләре, тәрҗемә әсәрләр, балалар өчен чыгарылган китапларның байтагы бүгенге көнгә кадәр шундый ук язмышка дучар булып килә. Рецензия өлкәсендә бертөслелек, шаблон көчле, аларның күбесе коры эчтәлек әйтелүгә корылган, диләр. Бу да дөрес фикер. Проза әдәбиятында — хикәя, әдәби тәнкыйтьтә рецензия жанры өзлексез тиргәлү объекты булып йөри..

Ләкин никадәр генә зарланмыйк, соңгы 1—2 ел эчендә рецензия язу эше дә яхшыра төште. Сүзне рецензияләрнең саны турындагы мәсьәләдән башлыйк. Узган ел республика газета-журналларында чама белән 80 рецензия басылган. Мин нигездә матур әдәбиятка һәм культура өлкәсенә караганнарын гына алдым, ихтимал, һәммәсен күреп тә бетермәгәнмендер. Татарстан китап нәшриятының тематик планына караганда, былтыр матур әдәбият буенча, кабат басмаларны санамыйча, рус һәм татар телләрендә 85 китап чыккан. 85 китап һәм 80 рецензия. Бу — һич тә аз түгел. 6—7 ел элек бездә һәр биш китапның берсе генә, 1972 елда һәр ике китапның берсе рецензияләнгән булган.

Инде ул рецензияләрнең сыйфатына килгәндә, арада әйбәтләре шактый, уртачалары күп. И. Абдуллинның «Әдәби тел тарихы һәм бүгенге көн» («Казан утлары», 1974, 6 сан), И. Ахунҗановның «Автора надо уважать» («Советская Татария», 1974 ел, 8 май), Т. Миңнуллинның «Тәнкыйтьчеләр өлгергәнче» («Казан утлары», 1974 ел, 3 сан), З. Рәмиевнең «Күңелдә чор хисләре» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 21 июль) һәм Р. Мөхәммәдиевнең «Шагыйрь күкрәүләре» («Татарстан яшьләре»,

1974 ел, 26 ноябрь) исемле рецензияләре хәтердә аеруча нык сакланган. Р. Мөхәммәдиев белән З. Рәмиев — чагыштырмача яңарак исемнәр. Ихтимал, аларның рецензияләре бигрәк тә шул ягы белән истә калгандыр. Т. Миңнуллин һәм И. Ахунҗанов рецензияләре капма-каршы характерда булулары белән аерылып торалар. Берсе чын күңелдән шатланып, икенчесе борчылып һәм нәфрәтләнеп язылган. Арадан иң кызыклысы — Искәндәр Абдуллин рецензиясе. Рецензиядә сүз филология фәннәре докторы, профессор Вахит Хаковның «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» дигән хезмәте турында бара. Ул тыныч, салмак тонда, төгәл фәнни тел белән язылган. Рецензент үзен иркен тота, авторга ияреп йөрми, аның алдында ялагайланмый. Сүз җаеннан шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, бүгенге рецензентлар арасында фән кандидатлары һәм фән докторлары шактый күп очрый. Алар каләме белән язылган рецензияләргә тулылык һәм дәлилле булу хас. Алар рецензия өлкәсенә тыныч, салмак тон, фәнни стиль, шул ук вакытта фән өлкәсендә киң таралган кайбер шаблон алымнарны да алып килделәр. Әйтик, диссертацияләргә «отзыв» язгандагы кебек, баштан ахырга кадәр әсәрнең яки китапның эчтәлеген сөйләп һәм юл уңаенда туган фикерләр белән урталаклашып бару... Күп кабатлана торгач, мондый алым туйдыра башлый.

Газета-журнал битләрендә төпле итеп язылган әйбәт рецензияләр болардан башка да байтак. (Кайберләрен санап узыйм: Ф. Хатипов. «Канатланыр чак»ның яңа варианты; Х. Сарьян. Кыскалык — әдәби осталыкның бер шарты; Ә. Дәминов. Учак урыннары; Н. Гамбәров. Гөрләвекләр яз алып килә; Ф. Урманчеев. Фикер гармониясе; Ф. Сафиуллина. Язучының тел осталыгы һәм тәрҗемә; Г. Шәрәфетдинов. Арадан бер һәйкәл; Р. Фәйзуллин. Китап укыганда; Т. Галиуллин һәм Ф. Урманчеев. Радость сопереживания; Г. Муханов. Дело, которому служишь; А. Авдеев. Большой мир поэта; Н. Сальтина. Право выбора; М. Мәһдиев. «Карурман»ны чыккан чакта; Р. Миңгалимов. Шигырьдән миңа ни кирәк; Ә. Рәшитов. Бизәлмәгән хакыйкать; Х. Мәхмүтов. Шигырь теориясенә яңа өлеш; В. Хаков һәм Х. Курбатов. Белем әлифбадан башлана һ. б., һ. б...)

Күпчелек очракта рецензентлар үзләре тикшерә торган әсәр турында төпле, ышандырырлык фикер әйтәләр. Н. Фәттахның «Этил суы ака торур» романы гына безнең рецензентлар өчен каты чикләвек булып чыкты.

Зур бер төркемне гади аннотация рәвешендә язылган рецензияләр тәшкил итә. Алар укучыларны теге яки бу яңа әсәр белән таныштыру ниятеннән чыгып языла-лар. Ул рецензияләрдә китапның характеры, эчтәлеге турында сөйләнә. Әсәргә кыска һәм җыйнак кына бәя бирелә. Мондый рецензияләр шулай ук кирәк. Шулай да рецензияләрнең сыйфатын, рецензентларның принципиальлеген күтәрү юнәлешендә башкарасы эшләр шактый.

Моңарчы без: «Рецензент үзе тикшерә торган әсәрне әлеге язучының гомуми иҗаты белән бәйләп, татар әдәбиятының гомуми фонына куеп бәяләргә тиеш», дип сөйли идек. Тәрҗемә эше нык алга киткән, милли әдәбиятлар арасында элемтәләр бик көчәйгән безнең чорда рецензент өстенә тагын бер бурыч йөкләнә: ул үзе тикшерә торган әсәрне ил күләмендәге әдәби фонга куеп бәяли алырга тиеш.

Шул уңайдан тагын таләпләр һәм критерийлар мәсьәләсе көн тәртибенә баса. Проза турындагы сөйләшүгә йомгак рәвешендә басылган мәкаләдә шул мәсьәлә кузгатылгач, кайбер тәнкыйтьчеләр көлгән иде. Янәсе, безнең тәнкыйтьтә нинди дә жирле, милли таләпләр һәм критерийлар хакында сүз дә булуы мөмкин түгел. Хәлбуки, аерым язучылар иҗат бәяләүдәге кискен аерымлыклар мәсьәләнең шактый катлаулы булуы хакында сөйли. Мин Д. Брудныйның «Когда глаз буйствует от смеха» дигән мәкаләсен («Детская литература» журналы, 1974 ел, 9 сан), Т. Мацнованың (12 сан) Ш. Рәкыйпов китабына язган рецензиясен һәм безнең тәнкыйтьчеләрнең әлеге язучылар иҗатына караган мәкалә-рецензияләрен күздә тотам. Әгәр татар тәнкыйтьчеләренең күпчелеге Җ. Мостафин һәм Ш. Рәкыйпов иҗатын уңай яктан гына бәяләп килгәннәр икән, моны принципиальлек җитмәү белән генә аңлатып булмый. Без үз әдәбиятыбыз мана-расыннан гына карап фикер йөрткәнбез, әлеге язучылар иҗатын ил күләмендәге гомуми фонга куеп карый белмәгәнбез. Менә шунда инде, бөтен җитдилеге белән, тәнкыйтьчеләрнең белемнәрен һәм профессиональ хәзерлекләрен күтәрү, аларның дөньяга карашын киңәйтү мәсьәләсе килеп баса. Бәяләрдә ялгышмас өчен, тәнкыйтьче күп белергә, бөтен дөнья һәм ил күләмендәге әдәби процесс белән таныш бу-

лырга тиеш. Безнең заманда бу — җиңел эш түгел. Моннан өч ел элек СССР Язучылар союзы яшь тәнкыйтьчеләрнең белемен күтәрү буенча ике айлык курслар оештырган иде. Шундый курслар хәзер яшьләр өчен генә түгел, милли республикаларда яшәүче барлык тәнкыйтьчеләр өчен кирәк.

* * *

Әдәби тәнкыйть үстә, нык алга китте дигәч, бәлки тәнкыйть өлкәсендә яңа Белинскийлар туган, татар тәнкыйтендә Белинскийча, Добролюбовча язылган хезмәтләр күбәйгән икән, дип уйлаучылар булыр. Юк, кызганычка каршы, яңа Белинскийлар тумаган.

Бүгенге тәнкыйтьнең үсеше башка юл белән бара. Шау-шулы, бәхәсле тон — салмак стиль, тәэсир уртаклашу—фәнни анализ белән алмашынды. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьтә заманга хас фәнни стиль, эшлекле тон урнашты. Һәм әнә шул стиль елдан-ел көчәя, тирәнәя бара. Тәнкыйть мәкаләләрендә фәнни анализ, тикшерену рухы артты. Бу исә, үз чиратында, безнең тәнкыйтьтә дә шактый урын алган комплиментарьлыкның кими төшүенә китерде. Төпле һәм гадел булу, объективлыкка һәм тирәнлеккә омтылу— тәнкыйть үсешендәге төп тенденция. Әдәби тәнкыйть алга таба да фәнни тирәнәю һәм специальләшү юнәлешендә үсәчәк. Әдәбиятның бөтен жанрлары һәм бөтен мәсьәләләре турында бердәй җиңеллек белән язарга ярата торган галим һәм тәнкыйтьчеләрне бер генә тармак турында яза торган, аның каравы, мәсьәләнең төбенә төшеп, асылын аңлап яза торган кешеләр алмаштыра. Специальләшү, эш бүлешү хәтта газета-журнал редакцияләре эшчәнлегендә дә нык сизелә.

Дөресен әйтергә кирәк, әдәбият һәм сәнгать тәнкыйтен үстерү эшенә Татарстан китап нәшрияты, республиканың барлык матбугат органнары, шулай ук радио һәм телевидение зур өлеш кертте. Шуның белән бергә, һәр газета-журнал бу эшкә үз мөмкинлекләреннән чыгып якын килә. «Социалистик Татарстан» газетасында яңа китапларны пропагандалау эше яхшы куелган. (Дөрес, «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарында, шулай ук «Татарстан коммунисты» журналында сәнгать мәсьәләләре әйбәт яктыртыла.) «Казан утлары»нда, барыннан да бигрәк, әдәбият күзәтү, теория мәсьәләләрен яктырту әйбәтрәк тора. «Ялкын» журналы балаларны сәнгать белән таныштыруга игътибар бирә, «Яшь ленинчы» газетасы балалар өчен чыгарылган китаплар белән таныштырып бара. «Татарстан яшьләре» газетасы әдәби сәхифәләр чыгара башлады, бүгенге прозаның яшь герое турында сөйләшү алып барды.

Соңгы вакытта «Советская Татария» газетасында да хәл тамырдан үзгәрде. Хәзер анда татар әдәбиятына караган материаллар күп басыла. Һәм ул материалларның сыйфаты да көннән-көн яхшыра бара...

Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьнең фәнниләшә баруы хакында сөйләгәндә, бу процессның күләгәле якларын да читләтеп узарга ярамас, дип уйлыйм. Тәнкыйть хезмәтләренең ышандыру көче арту яхшы нәрсә. Шуның белән бергә, аларның эмоциональ тәэсир көче, сәнгатьчелек дәрәҗәсе кими бара төсле. Эшлекле, салмак стиль дигәнебез тора-бара сүлпәнлеккә, салкынаюга алып килмәсме?..

Тәнкыйть мәкаләләренең күләме артык зурайды. Иҗат портреты икән, ул кимендә 40—45 бит булыр. Берәр җитди проблема күтәргән мәкалә икән, 60—70 биткә җитәр.

Элегрәк елларда әдәби тәнкыйтьне язучыларга ияреп йөрүдә, әдәби хәрәкәттән артта калуда гаепли идек. Хәзер әдәби тәнкыйть язучыларны куып җитте, алар белән бер сафта атлый. Ләкин ул гына җитми. Әдәби тәнкыйть сафның алдынарак чыксын, өлгергән мәсьәләләрне вакытында күреп алып, язучыларның игътибарын шуларга юнәлтә белсен иде.

Без татар әдәбияты йөз белән заман темасына борылды дип сөйләргә яратабыз. Бу чыннан да шулай. Әдәбиятны тормышка якынайтуда тәнкыйтьнең дә шактый өлеше бар. Шуның белән бергә, әдәбият әсәрләрен тормыш белән бәйләп бәяләү мәсьәләсендә тәнкыйть һаман да артка кала әле.

Өлкә комитетында кабул ителгән карарда әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть алдында торган күп кенә бурычлар санала, аларны тормышка ашыру юллары күрсәтелә. Ул карарга 1975—77 елларда башкарылырга тиешле эшләрнең конкрет планы да теркәлгән. Әдәби тәнкыйтькә хәзерге кебек игътибар булганда, туры сүзле, принципиаль тәнкыйть хезмәтләренә ихтыяҗ үсеп торганда, тәнкыйтьчеләребез һәм әдәбият галимнәребез ул бурычларны да уңышлы хәл итеп чыгарлар дип ышаныйк.

## Фатих Урманчеев

# ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ ОСТАЛЫГЫ

Соңгы елларда әдәби тәнкыйть бермә-бер җанлана һәм активлаша төште. Бу — күп мәкаләләрдә әйтелгән[1] һәм хәзер инде беркемдә дә шик уятмый торган бәхәссез нәрсә. Шуның белән бергә, тәнкыйтьнең абруе, тәнкыйть мәкаләләренең ышандыру көче күтәрелә, бүгенге тәнкыйтьтә эстетика мәсьәләләренә, язучыларның әдәби осталыгына игътибар арта бара. Тик без әлегә бу җитди казанышлар хакында гомуми планда гына сөйләшәбез, аларга юл уңаеннан гына кагылып үтәбез. Хәер, монда әллә ни гаҗәпләнерлек урын да юк. Тәнкыйтьченең әдәби осталыгы бер безнең әдәбиятта гына түгел, хәтта бай традицияләре һәм бөек тәнкыйтьчеләре булган рус әдәбиятында да ныклап өйрәнелмәгән. Болай артта калуның мәгълүм бер объектив сәбәпләре дә юк түгел. Иң элек тәнкыйть өлкәсендә безнең әллә ни мактанырлык бай традицияләребез бар дип булмый. Икенчедән, тәнкыйтьченең осталыгы турында язу — гомумән бик кыен эш. Әмма ни генә булмасын, хәзер бездә дә тәнкыйтьченең осталыгы турында сүз кузгатырга вакыт җитте кебек. Чөнки тәнкыйть продукциясе күбәйгән саен, аның сыйфатына игътибар да арта барырга тиеш.

*

* *

Тәнкыйтьнең иҗтимагый-политик әһәмияте һәм әдәби-эстетик сыйфаты, әдәби хәрәкәттә тоткан урыны, барыннан да элек, аның эчтәлегенә, проблематикасына бәйле. Тәнкыйтьченең осталыгы да, иң элек, ул күтәргән мәсьәләләрнең колачы, җитдилеге һәм актуальлеге белән билгеләнә.

XX йөз башында һәм 20—30 нчы елларда бездә зур проблемалар күтәргән, әдәбиятның гомуми үсеше, төп тенденцияләре, аның сыйнфый йөзе белән бәйләнеш мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр еш басылып торган. «Безнең юл», «Совет әдәбияты» журналларының ул еллардагы саннарында басылган материаллар шул хакта сөйли. Бу күренешнең, уңай яклары белән бергә, тискәре яклары да булмаган түгел. Әдәби җәмәгатьчелеккә бу мәгълүм. Әйтик, ул чорларда, бигрәк тә 30 нчы елларда, вульгар социологизм чиренең йогынтысы шактый көчле була. Хәзер без аннан акрынлап котылып киләбез. Тик, шуның белән бергә, ул еллардан килгән кайбер уңай тенденцияләрне дә онытып барабыз түгелме икән? Һәрхәлдә, соңгы елларда бүгенге әдәбият белән сәнгатьнең төп проблемаларын философик планда күтәргән, иҗтимагый-политик һәм әдәби-эстетик категорияләрне бергә бәйләп тикшергән мәкаләләр чыкканы юк дияргә мөмкин. Анда-санда зур исем белән басылган материаллар күренгәли күренүен. Тик дикъкать белән укый башласаң, аларның байтагы рус галимнәренә ияреп язылган булып чыга. Әйтик, бүген без социалистик реализм мәсьәләләрен бөтенләй оныттык диярлек. Дөрес, күптән түгел Р. Мостафинның социалистик реализм хакындагы бәхәсләр уңае белән язылган бер мәкаләсе чыкты[1]. Бу мәкалә бүгенге татар әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләренә багышланган зур сөйләшүләрнең башы булыр, алга таба мондый характердагы мәкалә-тикшеренүләр тагы да язылыр, дип ышанырга кирәк. Җитди мәсьәлә шуны таләп итә.

Бүгенге тәнкыйтьтә билгеле бер «специальләшү» процессы бара. Берәүләр күбрәк проза әсәрләре хакында яза, икенчеләр поэзиягә өстенлек бирә. Өченче төркем тәнкыйтьчеләр драматургия һәм театр белән шөгыльләнә. Моның үз сәбәпләре бар. Леонардо да Винчи, Микельанджело,

---

[1] Нил Юзиев. «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә. «Казан утлары», 1973 ел, 8 сан; Фарит Хатипов. Җаваплылык. «Казан утлары», 1974 ел, 4 сан; Миркасыйм Госманов. Иң кирәклесе — сыйфат. «Социалистик Татарстан» газетасы, 1974 ел, 12 май, һ. б.

[1] Р. Мостафин. Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат. «Казан утлары», 1974 ел, 8 сан.

хәтта В. Г. Белинский заманалары да күптән үтте. Безнең көннәрдә әдәбият һәм сәнгатькә караган әсәрләр искиткеч күп басыла. Хәзер бер генә тәнкыйтьче дә әдәбиятның һәм сәнгатьнең барлык тармакларын иңли алмый. Аңардан үзе сайлаган конкрет бер өлкәдә киң эрудиция, тирән белем сорала.

Бүгенге газета-журналлар битендә басылган мәкалә-рецензияләрнең күпчелеге проза белән поэзиягә туры килә. Драматургия, театр, бигрәк тә музыка сәнгате һәм сынлы сәнгать турында зур мәсьәләләр күтәргән проблематик мәкаләләр азрак һәм сирәгрәк языла. Театр сәнгате, музыка һәм рәсем сәнгате хакында дискуссияләр дә оештырылмый. Бу күренеш шулай ук культурабызның үзенчәлекле үсеш тарихы белән бәйләнгән булса кирәк. Татар әдәбиятының мең еллык тарихы һәм бай традицияләре бар. Профессиональ музыка, театр һәм сынлы сәнгать исә мәдәниятебезнең чагыштырмача яшьрәк өлкәләре. Аннан соң сәнгатьнең әлеге төрләре буенча бездә белгечләр дә күп түгел, махсус журнал яки газета да юк...

Проблематик мәкаләләрнең төп өлеше әдәбиятка карый, дидек. Фикеребезне конкрет мисаллар белән дәлилләп китик. 1972 елда «Казан утлары» журналында, «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарында татар әдәбиятының башка милләт әдәбиятлары белән бәйләнешен яктырткан күп кенә материаллар басылган иде. Бу уңай традиция хәзер дә дәвам итә. Мәсәлән, 1974 елда «Казан утлары»нда татар-үзбәк әдәби бәйләнешләренә багышланган матур мәкалә чыкты [1]. Мондый материалларның зур күпчелегендә ике халык (татар-удмурт, татар-чуваш, татар-кумык һ. б.) арасындагы әдәби элемтәләр хакында сүз бара. Совет әдәбиятының, шул исәптән татар әдәбиятының да ерактан килгән интернациональ элемтәләрен тикшерүгә багышланган һәм мәсьәләне киң итеп яктырткан мәкаләләр сирәк очрый. Шундыйлардан М. Хәсәновның «Интернационализмның дәнлы градицияләре» дигән мәкаләсен күрсәтергә мөмкин [2]. Анда Идел буе, Урта Азия һәм Казагыстан халыклары культураларының еракләрдан килгән тыгыз бәйләнешләре турында сүз бара. Янсә Ф. Әгъзамовның «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» исемле мәкаләсен алыйк. Ул «Казан утлары» журналының 1972 елгы 12 нче санында басылган иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, аның дөньяга чыгуы СССР төзелүнең 50 еллык бәйрәменә туры килде. Мәкалә әлегә бәйрәмгә хәзерлек уңае белән матбугат битләрендә барган сөйләшүләргә үзенчәлекле йомгак ясый. Ул публицистик рухта язылган. Бүгенге әдәбиятта мондый мәкаләләрнең сирәк очравын дә исәпкә алсак, мәкаләнең әһәмияте тагы да арта төшәр.

Җитди мәсьәлә күтәргән мәкаләләр арасында бүгенге әдәби хәрәкәтнең төрле якларына караганнары да бар. Бу уңайдан Р. Мостафинның «Укучы һәм язучы» исемле мәкаләсе игътибарга лаек [1]. Автор укучы фикерен өйрәнү турында сөйләп килә-килә дә ахырдан болай ди: «... Без укучы фикерен өйрәнергә һәм аңа сак караш булдырырга тиеш. Бу — бик мөһим мәсьәлә. Совет власте елларында без әдәбиятны аңлый һәм бәяли белә торган укучылар массасы тәрбияләдек. Мондый укучы башка бер илдә дә юк...»

Дөрес, мәкаләдә каршылыклы фикерләр дә очрый. Ләкин гаять җитди һәм актуаль мәсьәлә күтәргән мәкаләнең әһәмиятен алар гына киметә алмый.

Ш. Әхмәдуллинның «Киләчәкне уйлап...» дигән мәкаләсе дә кызыксыну уята [2]. Авторны әдәби алмаш тәрбияләү, яшьләрдә, киң катлау укучыларда әдәбиятка тирән ихтирам хисе уяту мәсьәләләре борчый.

Яки менә Хәсән Сарьянның «Алай да булай — булмасын» исемле мәкаләсе [3]. Автор бүгенге язучыларның теле турында яза. Иң элек шунысы игътибарга лаек, мәкалә киң эрудиция һәм тирән белем нигезендә язылган. Күрәсең, мәкалә өчен материал күп еллар буе җентекләп җыелган булса кирәк. Шуңа күрә бу мәкаләнең иҗтимагый яңгырашы да зур булды. Х. Сарьян мәкаләсе басылгач, РСФСРның атказанган укытучысы С. Гыйләмханов кайбер җырчыларыбыз, аларның әдәби телгә мөнәсәбәте турында язып чыкты [4]. Кукмара районыннан Н. Зарипова да шул ук мәсьәләләр борчый икән [5].

[1] Л. Мәхсумова. Татар-үзбәк әдәби мөнәсәбәтләре. «Казан утлары», 1974 ел, 6 сан.
[2] Шунда ук, 1973 ел, 5 сан.

[1] Шунда ук, 1972 ел, 5 сан.
[2] Шунда ук, 1974 ел, 1 сан.
[3] Шунда ук, 1974 ел, 2 сан.
[4] С. Гыйләмханов. Ничек теләсә, шулай... «Социалистик Татарстан», 1974 ел, 7 апрель.
[5] Н. Зарипова. И туган тел... Шунда ук.

Гомуми характердагы күзәтүләрдән соң, әдәби тәнкыйть мәкаләләренә якынрак килеп, аларның характерын, төп үзенчәлекләрен билгеләргә тырышып карыйк. Бүгенге тәнкыйтьтә берничә тенденция яшәп килә. Беришә мәкаләләрдә **тирән фәнни анализга омтылыш** беренче планда тора. Нил Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә» дигән мәкаләсе шуның ачык мисалы була ала[1]. Ул 1972 елгы әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменә багышланган. Автор материалны яхшы белә, әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият белеменең төп мәсьәләләрен, үсеш тенденцияләрен нигездә дөрес билгели. Мәкаләнең гомуми яңгырашы, рухы, тоны яшь тәнкыйтьчеләр өчен яхшы үрнәк була ала. Ул киң эрудиция һәм төзек композиция нигезендә язылган. Бу сыйфатлар тәҗрибәле тәнкыйтьче Н. Юзиевның башка мәкаләләре (бигрәк тә соңгы елларда язылганнары) өчен дә хас. Соңгы елларда дим, чөнки моннан 5—10 ел элек Н. Юзиев мәкаләләренең эмоциональлеге көчлерәк була иде.

Әдәби тәнкыйтьтәге әлеге тенденциягә тагын бер характерлы мисал итеп Гали Халитның «Әдәбиятның төп үзәнен һәм үзенчәлеген күреп» исемле мәкаләсен китерергә мөмкин[2]. Бу мәкалә дә әһәмиятле теоретик мәсьәләләргә багышланган. Беренче карашка, сүз анда Й. Нигъмәтуллина һәм И. Нуруллинның конкрет хезмәтләре турында гына бара кебек[3]. Чынлыкта исә автор, әлеге китапларның уңай якларын ачыклау белән бергә, үзенең дә мәгълүм бер концепциясен тәкъдим итә. Мәкалә теоретик хезмәт рухында язылган.

Бүгенге тәнкыйтьтә тамыр җәйгән икенче тенденция — **хис-тойгылар белән үрелеп барган анализга омтылу**. Мондый мәкаләләрне гадәттә профессиональ әдипләр яза. Г. Бәширов мәкаләләрендә, мәсәлән, җитди уйланулар, борчылулар беренче планда тора. Ф. Хөсни исә халыкчан юморга өстенлек бирә. Р. Фәйзуллин мәкаләләренә көчле эмоциональ яңгыраш, фикер тирәнлеге хас... Биредә язучы каләме белән язылган тәнкыйть мәкаләләренең үзенчәлекләре хакында сөйли торган бик күп мисаллар китереп булыр иде. Урын һәм вакыт мәсьәләсенең чикләнгән булуын истә тотып, С. Хәким язган мәкаләләр белән чикләнергә туры килә. Сибгат Хәким — барыннан да элек шагыйрь, тирән хисләр, җитди кичерешләр дөньясына чумган шагыйрь. Аның мәкаләләренә дә шул ук сыйфатлар хас. Мәкаләләренең һәркайсы диярлек шигъри күренешләр, образлы фикерләү, тирән хисләр дөньясыннан үсеп чыккан кебек. Һәм аларның эстетик кыйммәте дә шунда. Шигырь турында (ә Сибгат Хәким нигездә шагыйрьләр хакында сөйли) шагыйрь язгач, ничек инде хиссез булсын! Нәкъ әнә шуңа күрә Сибгат Хәким язган мәкаләләр шигырь кебек укыла. Алай гына да түгел, авторның кайбер мәкаләләрендә шигырьгә хас алымнар да күзгә бәрелеп тора.

Сибгат Хәким мәкаләләренең тагы бер үзенчәлеге шунда, аларда аерым тәгъбирләр, шигырьдәге рефрен кебек, буйданбуйга кабатланып киләләр. Мәсәлән, «Шигырь ничек туа?» дигән мәкаләнең үзегеннән «эзләнүләрнең чиге юк» дигән тәгъбир үтә. Хәзерге поэзиянең асыл сыйфатын билгеләгән «күп кырлы безнең поэзия» дигән сүзләр «Безнең көннәр поэзиясе» исемле мәкаләдә шулай ук рефрен ролен үти[1].

Әдипләр тарафыннан язылган әдәби тәнкыйть мәкаләләре гадәттә җиңел һәм мавыгып укыла. Чөнки алар укучыда яңа фикерләр генә түгел, ә бәлки җылы хистойгылар да уяталар, аларның эстетик зәвыгын тәрбиялиләр. Мондый мәкаләләрнең формасы да, теле дә ифрат дәрәҗәдә камил була. Эмоциональ яңгырашлы мәкаләләр язарга омтылу — хәзерге тәнкыйтьнең тәмам формалашып җиткән төп юнәлешләреннән берсе. Нәкъ шуңа күрә профессиональ тәнкыйтьчеләрнең дә кайберләре үз мәкаләләрен шушы рухта язарга тырышалар.

Бүгенге тәнкыйтьнең гомуми рухын билгеләгән **өченче тенденция** әнә шул хакта сөйли. Ул ярыйсы ук катлаулы һәм **алдагы ике тенденцияне билгеле бер дәрәҗәдә берләштерә** дип әйтергә мөмкин. Р. Мостафин, И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Т. Галиуллин мәкаләләрендә бу аеруча ачык сизелә. Биредә без шулардан бер генә автор, әйтик, Р. Мостафин белән чикләнергә булдык.

Профессиональ тәнкыйтьче буларак, ул бүгенге әдәби хәрәкәттә актив катнаша,

---

[1] Мәкалә әдәби ел йомгакларында сөйләнгән доклад нигезендә язылган. «Казан утлары», 1973 ел, 8 сан.

[2] «Казан утлары». 1973 ел, 5 сан.

[3] Ю. Нигматуллина. Национальное своеобразие эстетического идеала. Изд. Казанского университета, 1970; И. Нуруллин. Путь к зрелости. Таткнигоиздат, 1971.

[1] Мисаллар С. Хәкимнең «Үз тавышың белән» исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгыннан алынды. Казан, 1969 ел.

күп яза, еш басыла. Р. Мостафин мәкаләләренең проблематикасы ярыйсы ук киң. Ул бүгенге әдәбиятның теоретик мәсьәләләре турында да, проза, поэзия һәм әдәби тәнкыйть, аларның җитди казанышлары һәм төп бурычлары хакында да яза. Иң әһәмиятлесе шунда ки, ул һәрбер әсәргә, һәрбер шагыйрь яки прозаик иҗатына җитди эстетик таләпләр югарылыгыннан торып якын килә. Икенче төрле әйткәндә, аның мәкаләләрендә эстетик критерийлар, әдәби осталык мәсьәләләре һәр вакыт беренче планда тора.

Р. Мостафин мәкаләләренең формасы да еш кына шактый үзенчәлекле була. Аларда җанлы күренешләр, тормыш-көнкүреш картиналары зур урын алып тора: «Татар авылларының берсендә күп еллар элек, әле революциягә кадәр үк, бер егет яшәгән. Батыр йөрәкле, таза, матур сынлы, шук табигатьле, шул ук вакытта нечкә күңелле, моңлы егет булган ул. Сандугач булып бик оста сайраган, шуңа күрә авылдашлары аңа Былбыл Хәбир дигән кушамат биргәннәр»,— дип башлый ул рецензияләренең берсен [1].

Бу алым мәкаләне укуны җиңеләйтә, укучының кызыксынуын арттыра, автор фикерләрен, аның күзәтүләрен тормышка якынайта.

Хәзерге тәнкыйтьнең йөзен зур күләмле мәкаләләр генә түгел, төрле китапларга язылган рецензияләр дә билгели. Бүгенге рецензияләрнең байтагы тирән эчтәлекле була. И. Ахунҗанов, Р. Мостафин, Т. Галиуллин, М. Вәлиев кебек тәнкыйтьчеләр тарафыннан язылган рецензияләр аерым китапның, җыентыкның эчтәлеген дә, формасын да төрле яклап иңлиләр һәм мөстәкыйль мәкалә дәрәҗәсенә күтәреләләр. Шундый рецензияләрнең бер мисалы рәвешендә М. Вәлиевнең «Безгә ак болыт булырга язмаган шул...» дигән мәкаләсен алыйк [2]. Ул Равил Фәйзуллинның «Наз» исемле китабы чыгу уңае белән язылган. Гәрчә сүз анда нигездә конкрет бер китап турында гына барса да, аны гадәти рецензия кысаларына сыйдырып булмый. Автор үзе дә аны бик хаклы рәвештә мәкалә дип атый. Аның эчтәлеге тирән, Р. Фәйзуллин поэзиясе кебек үк җитди һәм катлаулы. Алгарак китеп булса да әйтик: мәкаләнең композициясе нык уйлап төзелгән. Башта автор «Лермонтов һәм Сибгат Хәким шигырьләренең зур көчкә ия булуы, тормышның чын моңына әйләнүе турында» сөйләп килә дә, шуннан «Наз» китабына һәм Равил Фәйзуллин шигырьләренә күчә, аларга тәпле анализ ясый. Киң һәм тирән анализ нәтиҗәсендә автор әһәмиятле фикер әйтә: «Равил Фәйзуллин поэзиясе дә классик поэзиянең күп кенә төп сыйфатларына ия, аның иң кадерле һәм олы идеалларына тугры поэзия». Әгәр рецензия шушы җирдә өзелеп калса, ул тәмамланмаган булыр иде. Рецензент моны бик яхшы аңлый һәм сүзен түбәндәгечә дәвам итә: «Ләкин, шул ук вакытта, күңел шагыйрь шигырьләренең ничектер бүтәнчәрәк икәнен, икенче яңа сыйфатларга ия булуын да сизми калмый. Һәм китапны укып чыккач, әнә шул тойгы — шагыйрь иҗатының үзенчәлеген аңларга тырышу тойгысы тынгы бирми башлый». Шул рәвешчә, мәкаләнең соңгы битләрендә сүз Р. Фәйзуллин поэзиясенең «яңа сыйфатлары» хакында бара.

М. Вәлиевнең логикасы эзлекле, фикерләре тирән һәм төпле. Тәнкыйтьче бүгенге поэзиянең табигатен яхшы аңлый. Шуңа күрә мин уңышлы рецензияләрнең икенче бер мисалын да шул ук автордан китерергә булдым. Сүз «Карлыгач күктә очсын» дигән рецензия хакында бара [1]. Ул Т. Камалиевның яңа җыентыгы уңае белән язылган [2]. Иң элек тәнкыйтьче шагыйрьнең үсеш этапларына туктала. Аннан соң рецензия язу өчен алынган конкрет җыентыкка күчә. Шагыйрьнең иҗади уңышлары аны шатландыра. Бу хакта ул дулкынланып яза. Әмма соңгы елларда шагыйрьнең бер урында таптана башлавы аны борчый, шагыйрьгә карата ул кискен тәнкыйть сүзләре әйтә. Ихлас күңелдән язылган һәм принципиаль тәнкыйть рухы белән сугарылган бу рецензия дә матур тәэсир калдыра.

Билгеле булганча, бездә Х. Туфан, С. Хәким, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Еники кебек халыкның тирән ихтирамын казанган олы әдипләрнең китаплары әледән-әле басылып тора. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил китаплары да еш чыга. Әмма, нигәдер, мондый китаплар әдәби җәмәгатьчелек игътибарыннан читтәрәк кала киләләр кебек. Аларга рецензияләр сирәк языла. И. Ахунҗановның «Поэзиянең ышанычлы көче» әнә шундый сирәк рецензия-

---

[1] Р. Мостафин. Былбыл Хәбир чишмәсе. «Казан утлары», 1974 ел, 2 сан, 173 бит.
[2] Шунда ук. 1974 ел, 6 сан.

[1] Шунда ук. 1973 ел, 2 сан.
[2] Т. Камалиев. Хәләл көчем белән. Казан, 1972 ел.

ләрнең бер үрнәге [1]. Ул С. Хәким әсәрләре рус телендә басылып чыгу уңае белән язылган [2]. Биредә автор иң элек С. Хәким поэзиясенең милли үзенчәлекләренә туктала: «Сибгат Хәким — чын мәгънәсендә татар шагыйре. Аның һәр йөрәк тибеше милли үзенчәлек белән сугарылган, бөтен рухи дөньясы гүзәллек белән тулы». Шагыйрь иҗатының төп тенденцияләрен ачыклаганнан соң, рецензент тәрҗемәләргә күчә, алардагы җитди кимчелекләрне күрсәтеп үтә. Принципиальлек, әйтелгән фикерләрнең дәлилле булуы рецензиянең ышандыру көчен арттыра...

М. Рафиковның «Шигърият үрләре» дигән рецензиясе дә шул ук темага язылган [3]. Анда да сүз С. Хәкимнең русча җыентыгы турында бара [4]. Дөресрәге, шулай булырга тиеш иде. Чөнки рецензия С. Хәкимнең рус телендә яңа җыентыгы басылып чыгу уңае белән язылган. Ләкин тәнкыйтьче баштан ук болай дип искәртеп үтә: «Китап рус телендә чыкса да, бу юлы тәрҗемәләрнең сыйфатына тукталып тормаска булдым... Шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләре турында сүз йөрткәндә, аның бу җыентыгына кермәгән әсәрләренә игътибар итү дә зыянлы булмастыр...» Мәсьәләгә зур җаваплылык белән килгәндә, шагыйрь әсәрләренең барысын да истә тотарга кирәк, билгеле. Әмма биредә бит сүз конкрет бер китап турында бара. Җитмәсә, ул журналның «Китап күзәтү» бүлегендә басылган. Ләкин рецензиянең эчтәлеге китаптан күп тапкыр киңрәк булырга тиеш иде кебек: автор шагыйрь иҗатына тулаем бәя бирергә җыена. Миңа калса, өч битлек рецензиядә бу бурычны үтәп булмый...

Принципиаль тәнкыйть белән сугарылган рецензияләр дә сирәк булса да чыккалап тора. М. Маликованың «Тормышчанлык өчен» дигән рецензиясе шуның бер мисалы [5]. Ул М. Харисовның «Ватан нидән башлана» (Казан, 1971) исемле хикәяләр җыентыгына багышланган. Гадәттәгечә, биредә дә иң элек язучы әсәрләренә гомуми бәя бирелә. Аннан соң автор конкрет анализга күчә. Рецензент М. Харисов хикәяләрен кискен тәнкыйть итә. Һәм аның бу тәнкыйте ышандыра. Чөнки ул дәлилле.

[1] «Казан утлары», 1972 ел, 12 сан.
[2] С. Хәким. Вечные ветви. Стихи и поэмы. М., 1971; С. Хәким. По зову Ленина. Стихи и поэмы. Казань, 1971.
[3] «Казан утлары», 1973 ел, 9 сан.
[4] Сибгат Хаким. Стихи последних лет. М., 1973.
[5] «Казан утлары», 1972 ел, 7 сан.

Шундый ук тәнкыйтьчел рух белән сугарылган материаллардан М. Зариповның «Каты токымнарны үткәндә» дигән рецензиясен күрсәтергә мөмкин [1]. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы безнең тәнкыйтьтә нигездә уңай бәя алды. Ә менә М. Зариповның төп игътибары әсәрнең йомшак якларына юнәлтелгән. Әйтергә кирәк, аның фикерләре төпле, тезислары дәлилле. Рецензияне, романны укыган кебек үк, кызыксынып укыйсың.

Олы әдипләребезнең китапларына рецензияләр аз языла, дидек. Чыннан да, басылып чыккан рецензияләрне игътибар беләнрәк тикшерә башласаң, аларның төп өлеше урта һәм яшь буын әдипләр иҗатына караганлыгы ачыклана. Еш кына рецензияләрнең күпчелеге урта кул китапларга багышлана. Мондый рецензияләрдән нинди дә булса җитди проблема таләп итеп булмый, билгеле. Н. Юзиев сүзләре белән әйтсәк, аларның зур күпчелеге «мактау дулкынында» языла. Мисал итеп Ш. Маннаповның «Шагыйрьне мин шулай ачтым...» дигән рецензиясен алыйк [2]. Биредә сүз Р. Мингалимов китабы турында бара [3]. Иң элек, рецензиянең исеме ризасызлык уята, аңа тыйнаклык җитми кебек. Өстәвенә, рецензия баштан ахырга кадәр тоташ мактаудан, шагыйрьгә мәдхия җырлаудан тора. Мин шагыйрьне, һичшиксез, тәнкыйть итәргә кирәк дип әйтергә җыенмыйм. Мәсьәлә анда түгел. Тик рецензия тыйнаграк тонда булса, шагыйрьгә дә файдасы күбрәк тияр иде.

Төрле газета-журналлар битендә сирәк-сирәк бернинди әдәби-эстетик кыйбласы булмаган мәкалә-рецензияләр очрап куя. Мондый материаллар бүгенге тәнкыйтьнең йөзен билгели алмый, билгеле. Димәк, аларга махсус тукталып торуның да кирәге юк. Тик бер җитди күренешне генә телгә алып китәргә кирәк. Моннан 5—10 ел элек, әйтик, халык иҗаты мәсьәләләренә кем теләсә, шул кагылып, ни теләсә, шуны сөйләп йөри иде кебек. Хәзер шундыйрак хәл җыр текстлары иҗат итүдә һәм әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендә туды шикелле. Җыр текстлары һәм рецензия авторлары арасында кемнәр генә очрамый! Каләм тотып, хәреф таныган һәркем җыр яза, рецензия яза. Биредә кайбер редакцияләрнең талымсызлыгы да билгеле бер роль уйный торгандыр. Бу яктан

[1] «Социалистик Татарстан, 1973 ел, 14 январь.
[2] «Казан утлары», 1972 ел, 7 сан.
[3] Р. Мингалимов. Алкын су. Казан, 1971 ел.

«Казан утлары» журналы, мәсәлән, әзлекле әдәби-эстетик политика алып бара. Әдәбият-сәнгатьне һәм үзен ихтирам иткән һәрбер журнал нәкъ әнә шул юл белән барырга, ягъни үз тирәсенә талантлы әдипләрне тупларга тырыша. Журналистика тарихы моның күп мисалларын белә... Тагы шуны да искәртеп үтәргә кирәк. Сыйфаты яхшы булган мәкалә яки рецензияне беренче редакция дә кире борып чыгармый. Димәк, талантлы әдипләр белән бер рәткә басу, барыннан да элек, авторның үзенә, аның сәләтенә һәм тырышлыгына бәйләнгән.

*
* *

Әлегә кадәр сүз нигездә тәнкыйть материалларының проблематикасы, **гомуми яңгырашы**, бүгенге тәнкыйтьнең **төп тенденцияләре** турында барды. Хәзер мәкалә-рецензияләрнең әдәби эшләнешенә һәм формасына игътибар итеп карыйк.

Укучы барыннан да элек әдәби әсәрнең, шулай ук тәнкыйть мәкаләсенең һәм рецензиянең дә исеменә игътибар итә. Без дә шул юлдан барыйк. Чөнки бирәдә, чыннан да, игътибарга лаек үзенчәлекләр бар. Мәсьәләгә фәнни яктан килсәк, мәкалә исемнәрен берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин...

«Язучы. Заман. Герой»[1]. Мәкаләләрне болай атау моннан 2—3 ел элек гаять киң таралган иде. Үзенә бер мода буларак, ул безгә рус тәнкыйтеннән килеп керде. Ләкин һәрбер мода кебек, тиз арада искереп өлгерде. Бүгенге мәкаләләрдә мондый исемнәр сирәк очрый.

Кайбер тәнкыйтьчеләр үз мәкаләләрен шагыйрь-язучыларның әсәрләреннән яки халык иҗатыннан алынган канатлы сүзләр белән атарга яраталар. Бу алым гадәттә уңай нәтиҗә бирә, мәкалә-рецензиянең исеме поэтик яңгыраш ала. Менә кайбер мисаллар: «Узсын гомер сагынып сөйләрлек» (Ә. Маликов), «Матурлыкка бай ул безнең заман» (Т. Галиуллин), «Үкендермәс мине үткән гомерем» (Г. Рамазанов) һ. б. Бу юл белән ясалган исемнәрнең кайберсе ярыйсы ук катлаулы булып чыга. Хәсән Сарьянның «Алай да була! — булмасын» дигән сүзләренең конкрет мәгънәсен аңлар өчен, мәкаләнең эчтәлеге белән танышып чыгарга кирәк. Н. Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә» мәкаләсенең исемен аңлау тагы да авыррак.

[1] «Казан утлары», 1973 ел, 11 сан.

Кайвакыт бу төр исемнәрдә кабатлаулар да очрап куя. Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасы басылып чыккач, «үрләр» модага кереп китте. Бу сүз төрле мәкалә-рецензияләрнең исемнәрендә дә кабатлана башлады: «Шигърият үрләре» (М. Рафиков), «Үр артында яңа үрләр бар» (Р. Фәйзуллин), «Күтәреләсе үрләр күп әле» (Й. Гәрәй).

Узган гасырның 40 нчы елларында В. Г. Белинскийның бер-бер артлы «1846 елгы рус әдәбиятына бер караш», «1847 елгы рус әдәбиятына бер караш»[1] исемле ике мәкаләсе басылып чыга. XX йөз башында бу типтагы исем безнең әдәбиятка да килеп керә. 1914 елда Гали Рәхим үзенең бер мәкаләсен «Халык әдәбиятымызга бер караш»[2] дип атый. Ярты гасырдан артык вакыт үткәч, М. Мәһдиев, бу исемне беркадәр яңартып, «Халык иҗатына бер караш» дигән рецензия белән чыкты[3]. Шуннан соң «бер караш»лар кабатлана башлады: «Әдәби хәрәкәтебезгә бер караш», «Хикәягә бер караш»...

Аерым очракларда мәкалә-рецензияләрнең исеме артык гомуми яңгырый, аны ничек теләсәң шулай аңлап була. Мәсәлән, М. Харисовның «Театр һәм драматург» мәкаләсе. Әгәр берәр монография әлеге исем белән аталса, аны аңлап булыр иде. Зур булмаган репортажда мондый җитди мәсьәләләрне ачыклап булмый, билгеле. «Уңышлы эзләнү» (Җ. Сафиуллин), «Зур таләпләр югарылыгыннан» (В. Воздвиженский) кебек исемнәрнең дә конкрет мәгънәсе аңлашылмый.

Ара-тирә мәкалә исемнәрендә дидактика, акыл сату кебек әйберләр дә күренеп китә: «Заман темасы өчен» (Ф. Ибраһимова), «Югары сәнгатьлелек өчен» (Ф. Мусин), «Тормышчанлык өчен» (М. Маликова).

Берәр мәкаләнең исеменә һәм эчтәлегенә каршы куелган «парлы» исемнәр дә очрый. Р. Мостафинның «Укучы һәм язучы» исемле мәкаләсе басылып чыккач, И. Нуруллин «Укучы бер генә төрлеме?» дигән реплика белән чыкты. И. Нуруллинның «Аяк белән йөрүгә ни җитә?» мәкаләсенә җавап рәвешендә Ф. Мусин «Югары сәнгатьлелек өчен» мәкаләсенең бер

[1] В. Г. Белинский. Взгляд на русскую литературу 1846 года. «Современник», 1847 ел, 1 том, 1 сан; Взгляд на русскую литературу 1847 года. Шунда ук, 1847 ел, VII том, 1 сан.
[2] «Аң» журналы, 1914 ел, 14, 15, 16, 19, 20, 22 саннар.
[3] «Казан утлары», 1968 ел, 11 сан.

бүлеген «Аяк белән дә төрлечә йөрергә була...» дип атаган.

Соңгы елларда басылган мәкаләләрнең тышкы «кыяфәтендәге» тагы бер кызыклы үзенчәлек күзгә ташлана. Сүз күләмле мәкаләләрне аерым бүлекләргә бүлү һәм аларның һәркайсын махсус исем белән атау хакында бара. Бу практика, гадәттә, тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр тарафыннан кулланыла һәм нигездә матур тәэсир калдыра, күләмле мәкаләне укуны җиңеләйтә.

Мәкалә-рецензияләрнең тышкы кыяфәтеннән эченәрәк кереп аларның гомуми төзелешенә, композициясенә игътибар итеп карыйк. Китап-журналларда басылган мәкаләләрнең байтагында җитди проблема үзәккә алына. Ул баштан ахырга кадәр логик яктан эзлекле рәвештә дәвам итә. Бу сыйфат бигрәк тә И. Нуруллин, Г. Халит, Н. Юзиев, Р. Мостафин мәкаләләренә хас.

Мисал төсендә Т. Галиуллинның «Буыннар һәм язмышлар» исемле мәкаләсен алыйк. Ул фәлсәфи уйланулар белән башлана[1]. Үзенчәлекле керештән соң, автор үзенең төп бурычларын билгели, тәнкыйтьче буларак аны борчыган сораулар турында яза: «Чор сулышы һәм кеше хисләре соңгы еллар татар поэзиясендә нинди көч һәм сәнгатьчә тулылык белән гәүдәләнде? Татар поэзиясенең тарихи казанышлары югарылыгында иҗат ителгән әсәрләребез күпме? Тукайлар кабызган утның ялкыны сүрелмиме?» Әлеге сораулардан соң автор бүгенге поэзиягә гомуми характеристика бирә. Мәсьәләнең эченәрәк кереп, тәнкыйтьче бүгенге шагыйрьләрне дулкынландырган төп проблемаларга тукталa, аларның сәнгатьчә гәүдәләнешен күзәтә. Мәкаләнең ахырында сүз бүгенге поэзиянең күләгәле якларына һәм шагыйрьләрнең төп бурычларына күчә.

Икенче бер төркем мәкаләләрнең композициясе хронологик принципка нигезләнә. Мәсәлән, Р. Мостафинның «Җаваплылык хисе» дигән мәкаләсе әнә шул принцип нигезендә язылган[2]. Р. Мостафин өчен гадәти булганча, мәкалә җанлы бер күренештән башлана: «Казанның Актерлар йортында яшь шагыйрьләр иҗатына багышланган әдәби кичә бара. Зал шыгрым тулы, зал тып-тын. Эшче яшьләр, студентлар, иҗат интеллигенциясе вәкилләре йотлыгып шигырь тыңлый. Сизеп, тоеп-күреп утырам: зал белән шагыйрьләр арасында тулы аңлашу, якынлык һәм теләктәшлек хөкем сөрә...» Бу күренеш бүгенге поэзия турында җитди сүз кузгату өчен билгеле бер этәргеч ролен үти. Акрынлап автор үзенең төп проблемасына — яшь буын шагыйрьләре иҗатына күчә. Автор бүгенге шагыйрьләрне өч буынга бүлә һәм хронологик тәртиптә аларның иҗатын тикшерә. Мәкаләнең төп проблемасы логик эзлеклелек белән ачыла. Тәнкыйтьченең фикере тирәнәйгәннән-тирәнәя бара. Мәкалә-рецензияләрне хронологик принцип нигезендә төзү безнең тәнкыйтьтә ярыйсы ук киң таралган форма.

[1] «Казан утлары», 1974 ел, 5 сан.
[2] Шунда ук, 1972 ел, 1 сан.

Сирәк кенә булса да, оригиналь формада язылган материаллар очрый. Мәсәлән, «Язучы. Заман. Герой» исемле мәкалә. Бу — тәнкыйтьче Мансур Вәлиев белән язучы Аяз Гыйләҗев әңгәмәсе. Бирдә яшь тәнкыйтьче тәҗрибәле язучы белән матур гына сөйләшү алып бара. Алар бүгенге прозаның җитди мәсьәләләрен күтәрәләр һәм игътибарга лаеклы фикерләр әйтәләр...

Рецензияләр арасында да үзенчәлекле формада язылганнары бар. Менә Сибгат Хәкимнең Роберт Әхмәтҗанов җыентыгына язган рецензиясе[1]. Олы әдип үзенчәлекле алымга мөрәҗәгать итә — Р. Әхмәтҗанов әсәрләрен үз шигъри дөньясы белән чагыштыра, олы кешеләргә хас тыйнаклык белән яшь шагыйрь иҗатын югары дәрәҗәгә күтәрә: «Тегермәннәр... Күпме әйләнделәр алар минем шигырьләрдә. Бөтен гомерем буена шул тегермән канатларының җиле бәрелеп торганын тойдым үземә. Ачлык еллар... Канаты салынган кошлар, оча алмый утырган кошларга охшаттым мин аларны. Әмма күңелдә ризасызлык, шигырьне ахырына җиткермәүдән туган ризасызлык яшәп калды. Роберт шул хисләрне очлап бетерел бирде кебек».

Мостафа Ногманның «Канатлы җырлар» дип исемләнгән рецензиясе дә үзенчәлекле формада язылган[2]. Рецензиянең исеме астына автор «Башкортстан шагыйре Нәҗар Нәҗмигә ачык хат» дип куйган. Ачык хат булгач, рецензиянең тоны да үзенчәлекле булырга тиеш. Рецензент шагыйрь белән дусларча сөйләшә, шигырьләренең үзенчәлекләре, шигъри сыйфатлары турында яза. Билгеле булганча, халык арасында хатның күптән урнашкан традицион формасы бар. М. Ногман хаты да шуңа якын. Ул ихлас

[1] Сибгат Хәким. Кайдадыр зур мәйданнар. «Социалистик Татарстан», 1973 ел, 10 июнь. Рецензиядә сүз Р. Әхмәтҗановның «Идел-йорт» исемле җыентыгы турында бара.
[2] «Социалистик Татарстан», 1973 ел, 16 ноябрь.

күңелдән әйтелгән җылы сүзләр белән тәмамлана.

Барлас Камаловның «Киңәшкә колак салып» дип исемләнгән рецензиясен дә мактап телгә аласы килә[1]. Моннан бер ел элек Татарстан язучылар союзының проза секциясе Мәгъсум Хуҗинның «Йомры тау итәгендә» исемле хикәяләр җыентыгын тикшергән иде, дип яза автор. Тикшерү вакытында тәҗрибәле язучылар М. Хуҗинга файдалы киңәшләр әйтәләр, хикәяләрнең сыйфатын күтәрү юлларын күрсәтәләр. Шуннан соң язучы җыентык өстендә тагы да эшли, хикәяләрен камилләштерә. Җыентык нык үзгәртелгән килеш басылып чыга. Рецензиядә Б. Камалов проза секциясендә тикшерелгән кульязманы һәм басылып чыккан китапны чагыштыра. Рецензия ахырында ул җитди нәтиҗәгә килә: «Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителгән әсәрләрне иҗат союзында күмәкләшеп тикшерү практикасын киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк. Мондый чараның файдасы тими калмый. Мәгъсум Хуҗинның әле күптән түгел генә чыккан китабы — шуның ачык мисалы».

Шулай да үзенчәлекле формада язылган рецензияләр чагыштырмача сирәк очрый. Аларның байтагы бер-берсенә игезәкләр кебек охшаган була. Бу—рецензияләрнең катып калган шаблон композициясендә аеруча ачык күренә. Менә бездәге рецензияләрнең беренче юллары: «Мәскәүнең «Наука» нәшриятында мишәрләр турында яңа тарихи-этнографик хезмәт басылып чыкты»[2]. Икенче бер рецензиядә дә шуңа бик якын юллар бар: «Мәскәүнең «Советская Россия» нәшрияты Максим Горький исемендәге премия лауреатлары сериясендә С. Хәкимнең соңгы елларда язылган шигырьләр җыентыгын басып чыгарды»[3]. Казанда басылып чыккан китапларга язылган рецензияләр дә бу яктан бер-берсеннән әллә ни аерылмый. «Татарстан китап нәшрияты яңа шигырь җыентыгы чыгарды. Исеме—«Юл башы»[4]; «Татарстан китап нәшрияты, «Мәктәп китапханәсе» сериясендә, филология фәннәре докторы, профессор Ибраһим Нуруллинның Габдулла Тукай турындагы хикәяләренең яңа, тулыландырылган басмасын чыгарды»[5].

Менә шундый типик керешләрдән соң гадәттә рецензиянең төп өлеше башлана. Аның төрле дәрәҗәдә, төрле тирәнлектә булуы мөмкин. Кайвакыт рецензия «традицион формада» язылса да, эчтәлеге ягыннан тирән була. Тирән фикерләр бигрәк тә фәнни хезмәтләргә карата язылган рецензияләрдә урын ала. Чөнки мондый рецензияләрне белгечләр, гыйльми дәрәҗәсе булган галимнәр яза.

Гадәттә рецензияләрнең беренче өлешендә китапның яки әсәрнең уңай сыйфатлары турында сөйләнә. Рецензентлар тәнкыйть итәргә артык яратмыйлар. Шулай да рецензиянең ахырына таба гадәттә китапның бер-ике кимчелеге дә күрсәтелә. Моны хәзерге рецензияләрдә киң таралган шаблон композиция таләп итә. Әнә шуңа ишарә ясап, «Күңел бөреләре» дигән рецензиясен Хисам Камалов түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Инде җыентыкның кимчелекләре нәрсә?— диярләр. Әлбәттә, ник алай түгел, ник болай?— дип дәгъвалар куярга булыр иде, мин дәгъвачыланмадым, бары тик күңел бөреләренең кайсы чәчәккә бөреләнгән, кайсы яфракка төенләнгән икәнен бераз билгеләп чыктым...»[1].

Кагыйдә буларак, китапның бер-ике кимчелеген күрсәткәч, рецензент китап авторыннан гафу үтенә башлый. Конкрет алганда, ул түбәндәгечәрәк килеп чыга: «...Әмма ни генә булмасын, Р. Вәлиевнең бу китабы Бөек Октябрь социалистик революциясе турындагы хезмәтләр арасында үзенең тиешле урынын алыр дип ышанабыз»[2]. Рецензияләрне әнә шундый сүзләр белән тәмамлау бездә искиткеч киң таралган. Берәр китапның яисә әдәби әсәрнең кимчелекләре хакында бер сүз әйтелмәсә дә, шундый типтагы җөмләләр барыбер рецензиягә килеп керәләр. Рәфкать Кәрамиевның «Тормышчан образлар» дигән рецензиясе Ф. Мансуровның «Яктытауда бүз тургайлар» дигән повестена багышланган[3]. Тулысынча «мактау дулкынында» язылган бу рецензиядә әсәрнең кимчелекләре турында бер сүз дә юк. Шуңа карамастан, ул «традицион алым» белән тәмамлана: «Әлбәттә, һәр әдәби әсәрнең дә ниндидер кимчелеге, килеп бетмәгән яклары була. Алардан Мансуров повесте да азат түгел. Әмма, тулаем алганда, җылы, мавыктыргыч итеп язылган бу әсәрне

[1] «Казан утлары», 1973 ел, 9 декабрь.
[2] Ә. Булатов. Мишәрләр турында яңа хезмәт. «Казан утлары», 1973 ел, 9 сан, 154 бит.
[3] М. Рафиков. Шигърият үрләре. Шунда ук, 180 бит.
[4] Н. Гамбәров. Юлчы юлда сынала. Шунда ук, 1973 ел, 7 сан, 168 бит.
[5] Шунда ук, 1972 ел, 1 сан, 182 бит.

[1] «Социалистик Татарстан», 1973 ел, 25 март. Рецензиядә сүз Ә. Рәшитовның «Хатирә» җыентыгы турында бара.
[2] М. Мөлеков. Революция тарихына яңа сәхифә. «Казан утлары», 1973 ел, 9 сан, 184 бит.
[3] «Социалистик Татарстан», 1972 ел, 27 сентябрь.

олылар да, балалар да бер үк дәрәҗәдә яратып укырлар».

Рецензия язу эшендә штамплар шул кадәр нык тамыр җәйгән ки, аерым очракларда оста гына тәнкыйтьчеләр дә аларны атлап үтә алмыйлар. М. Вәлиевнең Р. Мостафин китабына язган рецензиясен алыйк [1]. Ул, һичшиксез, оста һәм матур язылган, китапның чын мәгънәсен аңлап язылган. Ләкин бу рецензиягә дә «традицион бетем» килеп кергән: «Ә тулаем алганда, диңгез көндәлеген укып чыккач, үз күңелеңнең әллә никадәр баеганын тоясың, сөенәсең һәм авторга ихлас күңелдән рәхмәт әйтәсең».

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, хәзерге рецензияләрдә билгеле бер традицион композиция урнашты. Бу яктан алар безнең борынгы бәетләрне хәтерләтәләр. Анда да бит «Тарих мең дә сигез йөз дә...» яки «Бисмилләһи вә билләһи...» дигән традицион башлам һәм «газиз улмыш күршеләрем, бәндин бәхил булыңыз, исләрегезгә төшереп, хәер-дога кыйлыңыз!» кебегрәк традицион бетемнәр хөкем сөргән. Бәетләрдә мондый композиция һәм традицион шигъри алымнар табигый яңгырый, алар жанрның поэтикасы белән бәйләнгән. Рецензияләрдәге традицион композиция нәрсә белән бәйләнгән соң? Аның нинди дә булса әһәмияте бармы? Билгеле бер әһәмияте бардыр бәлки. Шулай да, минемчә, резенцияләрдә таралган традицион композиция турында ныклап уйланасы бар. Рецензия язудан баш тартырга кирәк дип булмый, билгеле. Алар кирәк, еш һәм күп язылырга тиеш. Тик аларның формасын һәрбер автор үзенчә уйлап тапсын иде. Рецензияләрдәге штамплар фикер ярлылыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Берәр китапка, әдәби әсәргә рецензия язарга керешкәнче, аның эчтәлеге турында гына түгел, формасы хакында да ныклап уйлау таләп ителә. Шул очракта гына башкаларны кабатламый торган, штамплардан азат рецензияләр язылуы мөмкин.

*

*   *

Башта ук әйтеп киттек: безнең көннәрдә тәнкыйтьнең абруе, дәрәҗәсе үсте. Әдәби-тәнкыйть материаллары белән хәзер тәнкыйтьчеләр һәм язучылар гына түгел, киң катлау укучылар да кызыксына. Культурабыз тарихына, аерым әдипләребез иҗатына багышланган җитди монографияләр тиз арада халык арасына тарала. Заман әдәби китапларның гына түгел, мәкалә-рецензияләрнең дә тирән эчтәлекле һәм камил формалы булуын таләп итә. Конкрет материалны күзәтү күрсәткәнчә, югары сыйфатлы мәкаләләр һәм рецензияләр бездә шактый күп басыла. Аларны гадәттә тәҗрибәле һәм талантлы әдипләр яза. Дөрес, безнең тәнкыйтьчеләр арасында әдәбиятны яхшы аңлый торган һәм киң эрудициягә ия булган кешеләр шактый. Тик биредә бер закончалык турында да әйтеп китәргә кирәк. Эрудиция, белем киңәйгән саен, тәнкыйтьчеләр бүгенге көн тәнкыйтеннән, җанлы әдәби хәрәкәттән ераклаша баралар, үзе яраткан берәр өлкәгә кереп калын-калын китаплар язарга керешәләр. Сүз дә юк, бусы да кирәк, әлбәттә! Ләкин тәҗрибәле тәнкыйтьчеләребез бүгенге әдәби хәрәкәттә да актив катнашып барсалар, тәнкыйтьнең авторитеты тагы да югарырак күтәрелер иде.

Тәнкыйтьнең абруе турында сүз кузгалгач, бүгенге әдәби хәрәкәттә тамыр җәйгән тагын бер күренеш турында әйтеп китәсе килә. Мәгълүм ки, олы әдипләребез һәм галимнәребез чыгарган китапларга гадәттә яшь буын вәкилләре рецензия яза. Әйтик, мәшһүр шагыйрь китабына берәр башлап язучы әдәбиятчы, профессор хезмәтенә — фән кандидаты яки аспирант. Гадәттә аларның тәҗрибәсе аз, белемнәре дә саерак була. Нәкъ менә шуңа күрә рецензияләрнең байтагында фикер ярлылыгы һәм шаблон алымнар хөкем сөрә.

Фән дөньясында, әйтик, мәсьәлә башкачарак тора. Аспирантның фәнни җитәкчесе мәҗбүри рәвештә фән кандидаты, доцент яки профессор булырга тиеш. Кандидатлык диссертациясе яклаганда оппонентларның берсе фән докторы булып, икенчесе тәҗрибәле кандидат булса, докторлык диссертациясе яклаганда, оппонентларның өчесе дә фән докторы булырга тиеш.

Әдәбият-сәнгать тәнкыйтендә дә шулайрак булырга тиеш иде кебек. Ягъни яшь, урта һәм олы буын әдипләре уртак кайгыртучанлык күрсәткәндә генә тәнкыйтьнең абруен саклап, мәкалә-рецензияләрнең сыйфатын, киңрәк алганда, бүгенге тәнкыйтьнең дәрәҗәсен тагы да югарырак күтәрергә мөмкин.

---

[1] «Казан утлары», 1972 ел, 10 сан.

# СӘНГАТЬТӘ МИЛЛИ ҺӘМ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ЯКЛАРНЫҢ ДИАЛЕКТИКАСЫ

Социалистик җәмгыятьнең коммунизм юлыннан алга таба үсеше, аның экономикасындагы һәм социаль структурасындагы мөһим үзгәрешләр милли һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә күп кенә яңалыклар, яңа тенденцияләр алып килә, ахыр чиктә бу процесс илебез халыкларының мәдәни үсешенә дә йогынты ясамый калмый. Шуңа күрә безнең көннәрдә совет сәнгатендә милли һәм интернациональ якларның диалектикасын, күп милләтле совет сәнгатенең, шулай ук илебездәге аерым милли культураларының үсеш характерын һәм үсеш перспективасын өйрәнү ифрат мөһим төс ала. Бу исә, үз чиратында, философлар һәм сәнгать белгечләре алдына тормышта барган әлеге процессларны өйрәнү буенча зур, яңа бурычлар куя. К. Гыйззәтовның «Совет сәнгатендә милләтлек һәм интернациональлек» исемле китабы [1] әнә шул мөһим һәм катлаулы мәсьәләләрне өйрәнүгә багышланган.

Әлеге тема буенча үзәктә һәм урыннарда байтак хезмәтләр язылган. Ләкин аларның күпчелегендә милләтлек һәм интернациональлек мәсьәләсе мәдәниятнең теге яки бу конкрет төре (әдәбият, сынлы сәнгать, театр яки музыка) мисалында гына карала. Дөрес, сәнгатьтәге милли һәм интернациональ яклар теге яки бу күләмдә философик хезмәтләрдә дә өйрәнелә. Әмма аларда ул мәсьәләләр, кагыйдә буларак, тагын да гомумирәк категория, атап әйткәндә, гомум культура составында өйрәнелә. К. Гыйззәтов китабы бу яктан нык аерылып тора, сәнгать анда турыдан-туры философик тикшерү предметы итеп алынган. Өстәвенә, һәр яктан философик хәзерлекле булу, тикшерелә торган мәсьәлә буенча һәм гомум теоретик, һәм махсус әдәбиятны яхшы белү авторга үз өстенә төшкән авыр эшне уңышлы башкарып чыгарга, укучы игътибарына кызыклы һәм эчтәлекле хезмәт тәкъдим итәргә мөмкинлек биргән. Китапта философик һәм эстетик категорияләрнең үзара мөнәсәбәте, аларның диалектик бәйләнеше дөрес күрсәтелә. Марксистик-ленинчыл методология принципларын кулланып һәм совет философия фәне ирешкән казанышларга таянып, галим совет сәнгатендә милли һәм интернациональ якларның диалектикасын тирән итеп ача алган.

Рецензияләнә торган китап белән танышкач, аның авторы күп милләтле совет әдәбиятын һәм сәнгатен ныклап өйрәнгән, төрле халыкларның мәдәният өлкәсендәге казанышларын яхшы белә дигән нәтиҗә ясарга була. Бу аңа хезмәттә күтәрелгән мәсьәләләрне күп санлы конкрет мисаллар нигезендә яктыртырга мөмкинлек биргән.

Үзе тикшерә торган һәр мәсьәләне яктыртканда, К. Гыйззәтов әлеге мәсьәлә буенча чыккан фәнни хезмәтләргә тәпле күзәтү ясый, аларга карата үз мөнәсәбәтен белдереп бара. Бу — китапка полемик төс бирә. Үз позициясенең дөреслегенә нык ышанган хәлдә, автор оппонентлары белән дәлилле бәхәскә керә, аның күпчелек фикерләре һәм дәлилләре белән килешми мөмкин түгел.

[1] К. Гиззатов. Национальное и интернациональное в искусстве. Рус телендә, Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел.

Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, китапның композициясе нык уйлап төзелгән, күтәрелгән мәсьәләләр логик бәйләнгән һәм эзлекле төстә анализлана. Хезмәт гади, аңлаешлы телдә язылган, публицистик рух белән сугарылган.

Безгә калса, К. Гыйззәтов фәнни әдәбиятта файдаланыла торган терминнарга ачыклык кертү юнәлешендә дә зур эш башкарган. Бу мәсьәлә белән якыннан шөгыльләнгән кешеләр яхшы белә: «сәнгатьтә милли үзенчәлек», «милли специфика», «милли форма», «милли колорит» кебек төшенчәләрне, шулай ук совет сәнгатендә «социалистик эчтәлек һәм милли форма» дигән билгеләмәне төрлечә аңлау һәм аңлату аркасында күпме бәхәсләр булып үтте. Автор хәзер генә телгә алынган һәм кайбер бүтән терминнарның күп мәгънәле булуын ача, аларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә һәм аларның һәркайсына фәнни билгеләмә бирә.

Хезмәтнең игътибарга лаек тагын бер ягы сәнгатьтәге миллилек төшенчәсенә һәм аның мөһим сыйфатларына төпле анализ ясауда. Автор «миллилек» дигән гомум социологик категориянең җәмгыятьтәге реаль мөнәсәбәтләрне чагылдыруын ача. Әлеге анализ аны сәнгатьтәге миллилек «категориясе объектив эчтәлеккә ия» дигән нәтиҗәгә китерә. «Сәнгатьтәге миллилек, — ди ул, — сәнгатьнең эчке закончалыгына хас сыйфат; ул художникның тарихи үсеш процессында формалашкан халык тормышын шул халыкка хас милли аныклык белән, үзенең сыйнфый карашы һәм сәнгатьтәге милли традицияләр яктылыгында образлы-эмоциональ итеп сурәтләвенең нәтиҗәсе» (12 бит). Автор милли якның халыкчанлык белән бәйләнешенә, миллилектә милли тормышның специфик шартлары һәм прогрессив тенденцияләре чагылуга басым ясый, һәм бу очракта да аның белән килешми калып булмый.

К. Гыйззәтов сәнгатьтәге миллилек проблемасына милли форма һәм милли үзенчәлек ноктасыннан карап анализ ясый, бу аңа миллилек төшенчәсенең эчтәлеген тирәнрәк ачарга мөмкинчелек бирә. Соңгы елларда социологик эзләнүләр өлкәсендә киң таралган алымнарны куллану да нәтиҗәле булып чыккан диясе килә. Хосусан алганда, мәсьәләне өйрәнүгә системалы якын килү алымын мисалга китерергә мөмкин. Бу авторга миллилекнең яңа үзенчәлекләрен, аның күп кырлы булуын, чынбарлыкта һәм сәнгатьтә миллилекнең үз эчендә яңа бәйләнешләр һәм мөнәсәбәтләр барлыгын ачарга ярдәм иткән. Миллəткә марксистик-ленинчыл билгеләмәдән чыгып, автор чынбарлыкта милли якны тәшкил иткән алты элементны аерып күрсәтә. Алар — тел, социаль-экономик, психологик, этнографик, табигый-географик һәм эстетик элементлар. Шул ук вакытта галим чагылдырылган нәрсәнең структурасын чагылдыра торган нәрсәнең структурасы белән абсолют рәвештә тәңгәлләштерергә ярамаганлыгына да басым ясый. Ул мәсьәләнең әлеге мөһим аспектына В. И. Ленинның чагылыш теориясе яктылыгында якын килә, чынбарлыкны чагылдыра һәм мәгълүм дәрәҗәдә объектның структурасын яңадан тудыра торган сәнгать әсәрләрендә объектның барлык элементлары да түгел, ә кайберләре генә, конкрет алганда, социаль-психологик, социаль-этнографик һәм табигый-географик яклары гына иңләнә дигән нәтиҗәгә килә. Алга таба автор аларның һәркайсына тәфсилле анализ ясый һәм аларның структурасын ача. Шуның белән бергә, ул сәнгатьтәге миллилек элементларының үзара тыгыз бәйләнешен һәм бер-берләренә тәэсир итүләрен билгеләп үтә. «социаль-этнографик һәм табигый-географик элементлар бер-берләреннән аерылган, ниндидер «мөстәкыйль» хәлдә яшәмиләр, алар бары тик синтез, димәк ки, мәгълүм бер рәвештә бәйләнгән хәлдә яшиләр», дип яза (99—100 битләр).

Сәнгатьтәге барлык миллилек элементларын бергә берләштерә, синтезлый торган фактор сәнгатьчәлек, ди автор. Соңгысын ул миллилекнең мөһим элементы, аны турыдан-туры гәүдәләндерә торган сыйфат дип саный. Галим сәнгатьчәлекнең эчке структурасың ача һәм ул, аның фикеренчә, үзендә сәнгатьнең объектив һәм субъектив компонентларын, шул исәптән сыйнфый һәм милли сыйфатларны да, бөтен бер системага синтезларга, аларны бердәм идея-тематик эчтәлеккә цементларга хезмәт итә. К. Гыйззәтов, «сәнгатьчәлек сәнгать әсәренең бөтен эчтәлеге аша үтә, аның җаны булып тора», ди. Әмма сәнгатьчәлекне эчке структурага, шуннан чыгып, сәнгатьчә формага тиңләп калдыру әлеге дөрес караш белән ярашып бетми.

Автор сәнгатьтәге миллилек проблемасына ныклы сыйнфый позицияләрдән торып анализ ясый. Ул сәнгатьтәге партиясезлек, сыйныфсызлык идеясенең буржуаз асылын ачып бирә. Сәнгатьтә сыйнфый һәм милли якларның аерылмас булуы, аларның тыгыз бәйләнгән булуы турындагы идея хезмәтнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла.

Сәнгатьтә милли һәм интернациональ якларның үзара мөнәсәбәте турындагы мәсьәлә китапның беренче битеннән соңгы биткә кадәр игътибар үзәгендә тора. Милли һәм интернациональ якларның диалектикасын өйрәнү методологиясенә багышланган дүртенче бүлек аеруча зур кызыксыну уята.

Автор әлеге мәсьәләне тикшерүгә күп яктан, төрле яссылыктан торып якын килә. Сәнгатьтә миллилек һәм интернациональлек мәсьәләсен тикшергәндә, автор, гадәттә кабул ителгәнчә, гомуми һәм берәмле, үзенчәле категорияләрен куллану белән генә чикләнеп калмый, материалистик диалектиканың башка категорияләренә дә (бөтен һәм кисәк, форма һәм эчтәлек, асыл һәм күренеш) мөрәҗәгать итә. Мәсьәләгә бу рәвешчә якын килү нәтиҗәле булып чыккан һәм авторга проблеманың асылын тирәнрәк ачарга булышкан.

Автор әлеге мәсьәләне яктыртуда ике капма-каршы тенденция, бер яктан, миллилекне санга сукмау һәм, икенче яктан, миллилектә интернациональ якны инкарь итү белән фәнни бәхәскә керә. Аның бу бәхәсе дә, тулаем алганда, нигезле тоела. «Марксистик-ленинчыл эстетика,—ди ул,— интернациональлекне милли йөзе булмаган нәрсә белән тиңләштерүгә каршы чыга. Аңа сәнгатьтәге интернациональлекне нииндидер чырайсыз абстракция, нинди дә булса милли сыйфатлардан азат нәрсә дип карау ят. Аңа шулай ук интернациональлекне миллилек белән бәйләнешсез дип аңлату да ят» (155 бит).

Чыннан да, космополитизмнан аермалы буларак, интернационализм милли якны инкарь итми. Шуңа күрә дә без, чын сәнгать һәр вакыт — милли, милли үзенчәлектән качу космополитик сафсатадан башка нәрсә түгел, дибез.

Миллилекне милли булмаган һәр нәрсәдән аерып куярга тырышучыларны, миллилекне, характерлы сыйфат төсендә, тар итеп аңлауны яклаучыларны кискен тәнкыйть иткәндә дә галимнең позициясе нигезле һәм ышандыра. Хезмәттә дөрес күрсәтелгәнчә, мәсьәләне бу рәвешчә аңлау котылгысыз төстә искелекне, архаизмны яклауга, миллилекне метафизик төстә, бер дә үзгәрми, катып калган нәрсә итеп күзаллауга алып килә. Хәлбуки, сәнгатьтә миллилек бер урында тормый, даими төстә үсә, байый бара һәм бу очракта башка милли культураларның тәэсире хәлиткеч роль уйный.

Әлеге мәсьәләгә җентекле анализ ясау нәтиҗәсендә автор милли культураларның үзара тәэсире һәм интернациональләшә баруы социалистик җәмгыятьнең үсеш законлыкларына бәйләнгән объектив процесс дигән нәтиҗәгә килә. Ул бу процессның эчтәлеген ача, милли культураларның үзара йогынтысындагы төп моментларны билгели. Әлеге бүлеккә йомгак ясап, К. Гыйззәтов болай яза: «Интернациональләшү миллилектән «котылу», милли сыйфатларны «юкка чыгару» процессы түгел, ә аларны берләштерү, миллилекне яңа, тагын да прогрессиврак сыйфатлар белән баету процессы, миллилекнең диапазонын киңәйтү процессы, миллилекнең мәгълүм күләмдә (мәгълүм бер чикләрдә) трансформацияләү процессы, соңгысы, һичшиксез, традицион милли сыйфатларны яңадан бәяләүдән, милли яктан искергән элементларның төшеп калуыннан башка була алмый» (172 бит).

Сәнгатьтә милли һәм интернациональ якларның төсмерләрен, аларның диалектикасын аңлау, безнең сәнгатьнең бүгенге хәленә анализ ясау өчен сәнгатьнең милли үзенчәлегендәге психологик механизмны тикшерү дә зур әһәмияткә ия. К. Гыйззәтов нәкъ менә «милли хис», «милли аң», «милли характер» кебек категорияләргә күп игътибар бирә, аларны үзара тыгыз бәйләнештә, берберләренә бәйле төстә карый. Хезмәттә милли хис, милли аң һәм милли характерның эволюциясе һәм бу процессның сәнгатьтәге интернациональлекнең үсешенә тәэсире тикшерелә, өстәвенә, (бусы аеруча мөһим!) әлеге процессның каршылыклары ачыла.

К. Гыйззәтов эстетик бәяләрдә милли моментның ролен билгели, аның интернациональ яктан аерылгысыз булуын азсызымлый һәм әдәби зәвыкларның интернациональләшә бару процессын күрсәтә. Безнең карашча, ул бик дөрес рәвештә халык массаларының эстетик аңында һәм карашларында акрынлап микъдар һәм сыйфат үзгәрешләре туплана килүе турында сөйли, соңгысы исә милли культураларның тәрәккый итүе өчен зур әһәмияткә ия. Шушы уңайдан милли хисне, эмоцияләрне, бигрәк тә аларның сәнгатьтә (иҗатта, башкаруда, кабул итүдә) чагылышын тикшерүгә багышланган бүлекнең артык кыска булуы гына канәгатьсезлек хисе уята.

Сәнгатьтә милли һәм интернациональ якларның диалектикасын тикшергәндә, милли форма һәм социалистик эчтәлек төшенчәләрен дөрес аңлау зур роль уйный. Билгеле булганча, 1950 елларның ахырыннан алып

«эчтәлек» һәм «форма» дигән философик төшенчәләрне эстетика өлкәсенә механик рәвештә күчерү, эчтәлек дигәндә еш кына тормыш материалын гына, ә форма дигәндә сәнгатьчә форманы гына (структура, тасвир чаралары һәм башкалар) аңлау нәтиҗәсендә сәнгать галимнәре күп еллар буе урынсыз бәхәс куерттылар. К. Гыйззәтовның бу мәсьәләләргә карата үз карашы бар, һәм ул отышлы булырга охшый. Аның фикеренчә, совет эстетика фәнендә «милли форма» термины ике мәгънәдә кулланыла, тар мәгънәсендә ул традицион төстәге милли сәнгать формаларын белдерә (12 бит), киң мәгънәсендә сәнгатьтәге миллилекне, аңа хас үзенчәлекләрне аңлата торган җыелма төшенчәне белдерә (14 бит). «Милли форма» терминының күп мәгънәле булуына нигезләнеп, автор совет сәнгатендәге бердәмлек һәм күптөрлелекне характерлаучы «социалистик эчтәлек һәм милли форма» формуласын, мәдәнияттә эчтәлек һәм форманың диалектик бәйләнешен дөрес ача алган. Шул уңайдан ул (һәм безгә калса, бик хаклы рәвештә) социалистик эчтәлек һәм милли форма арасындагы диалектиканы совет сәнгатенең үсеш чыганагы дип аңлатучыларны тәнкыйть итә, совет сәнгатенең үсеш чыганагы — безнең чынбарлык үзе, анда барган тирән үзгәрешләр, ди.

Г. Апресян, А. Егоров, Г. Ломидзе һәм башка авторларның карашларын яклап, үз фикерләрен совет сәнгате практикасыннан алынган конкрет мисаллар белән ныгытып, К. Гыйззәтов «милли форма» төшенчәсен киң мәгънәсендә аңлау гына сәнгатьтә миллилек һәм интернациональлек мәсьәләсен сыйнфый позицияләрдән торып, марксистларча хәл итәргә мөмкинлек бирүен күрсәтә. Методологик яктан бу бик мөһим күрсәтмә. Мәсьәләгә бу рәвешчә якын килү миллилекнең эволюциясен, аның үсеш процессын, милли якның интернациональләшә һәм интернациональ якның «миллиләшә» баруын дөрес күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, теманы өйрәнү барышында К. Гыйззәтов сәнгать һәм иҗат процессы кысаларында чикләнеп калмый, бәлки катлаулы теоретик мәсьәләләрне дә хәл итә һәм социализмда милләтара мөнәсәбәтләрнең үсеш законнарына төрле яктан анализ ясый. Китапта милләтләрнең һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең тарихи үсеш тенденцияләре киң планда күрсәтелә, халыклар тормышының интернациональләшә һәм катлаулы диалектик процесста якыная барулары ачып бирелә.

Автор интернациональләшү, милли культураларның якынаюлары һәм үзара йогынтылары кебек төшенчәләрнең эчтәлеген өйрәнә, аларның бер-берләренә булган мөнәсәбәтен ача һәм коммунистик җәмгыятьнең интернациональ культурасы формалашуда үзара якынаю һәм үзара тәэсирләрнең әһәмиятен күрсәтә. Шуның белән бергә, ул СССР халыкларының эстетик критерийлары үсешендәге төп юнәлешләрне ачып бирә. Шулай да бу процессны бары тик аерым регионда (әйтик, Европада) иҗат ителгән эстетик байлыкларны үзләштерү нәтиҗәсе генә итеп аңлату һәм сәнгатьтәге аерым юнәлешләрне башкалардан өстен кую белән килешеп булмый. Шушы уңайдан музыкаль драманы драмадан операга күчү юлындагы бер баскыч кына дип бәяләүнең дөреслеккә туры килмәвен дә әйтергә кирәк. Музыкаль драма һәм музыкаль комедия — сәхнә сәнгатенең мөстәкыйль жанрлары, алар бүген дә опера, балет, трагедия белән янәшә яшәргә хаклы. «Яңа жанрлар һәр халыкта нәкъ менә милли жанрлар буларак формалашалар» (211 бит) дигән тезис та төгәл үк түгел. Әйе, совет чорында татар, башкорт, чуваш халыкларының опера һәм балет сәнгате туды. Әйе, алар милли сәнгать традицияләре нигезендә барлыкка килделәр. Ләкин, жанр буларак, татар операсы чуваш, башкорт яки рус операларыннан принципиаль төстә аерыламыни?..

Хезмәттәге кайбер бүтән кимчелекләр һәм җитешсезлекләр хакында да сөйләргә мөмкин. Әйтик, автор фикеренчә, «Йосыф һәм Зөләйха» (XIII йөз) поэмасындагы Йосыф образына явызлыкка каршы тормау, һәр төрле җәберне гафу итү кебек реакцион идея салынган. Шуңа күрә поэманың халык арасындагы популярлыгы, янәсе, бу образның мөлаемлыгы белән түгел, ә бары мәхәббәт коллизиясе, Зөләйханың кайнар мәхәббәте халык күңеленә хуш килү белән генә бәйләнгән. Сүз дә юк, поэмада мәхәббәт линиясе искиткеч көчле бирелгән, һәм аның укучы күңелен үзенә тартуы табигый. Шулай да поэмада икенче линия, конкретрак әйткәндә, гаделлек һәм гуманизм, намуслылык һәм тугрылык, яхшылыкның явызлыктан өстен чыгуы төп урынны алып тора һәм боларның барысы да Йосыф образында гәүдәләнә. Мәхәббәт линиясе белән бергә, нәкъ шул хис-фикерләр 800 ел буена халык күңелен җилкендергән һәм хәзер дә җилкендереп тора. Халык арасында поэма күбрәк «Йосыф һәм Зөләйха» дип түгел, ә «Йосыф кыйссасы» яки «Йосыф китабы»

буларак киң таралган икән, бу очраклы хәл түгел. Инде Йосыф образының мифологик тышчага төренгән булуына килсәк, бу шул заманга һәм Шәрык поэзиясендә күп гасырлар буенча өстенлек итеп килгән традицияләргә ташлама ясаудан башка нәрсә түгел. Авторның Дәрдмәнд мирасы буенча Й. Нигъмәтуллина белән бәхәсе, бүгенге поэзиядә очраган «гөл һәм былбыл» образларының искергән, гомерен кичергән милли традицияләрнең чагылышы дип каравы да (242 бит) ышандырып бетерми. Шагыйрьнең сандугач яки гөл образларына мөрәҗәгать итүе, кызны былбыл һәм туган айга тиңләве, аны күңелләрнең патшасына әйләндерүе генә әле һич тә милли чикләнгәнлек хакында сөйләми. Һәм гасырлар буена камилләшеп килгән әлеге алым һәм образларны иҗатта куллануның ул кадәр куркынычы юк.

Китапта, бигрәк тә аның музыка сәнгатенә караган өлешләрендә, төгәл үк булмаган терминнар очрый. Автор китергән кайбер мисаллар да максатка ярашлы түгел. 23 биттә «сәнгатьтә миллилек, барыннан да бигрәк, халык тормышы, аның гражданлык хисләре, идеаллары тирән һәм киң булып гәүдәләнгән әсәрләрдә ачык чагыла» дип әйтелә дә, мисал рәвешендә «Освобождение» һәм «Укрощение огня» исемле фильмнар китерелә. Әмма аларны совет сәнгатенең интернациональ характеры турында сөйләгәндә телгә алу урынлырак булыр иде, янсә авторга, әлеге фильмнарга ишарә ясап, ни әйтергә теләгәнен ачыграк аңлатырга кирәк иде. Ибсен драмасындагы Норага каршы куеп, ул рус хатын-кызының үз-үзен тотышына мисал рәвешендә «Гроза»дагы Катерина образын китерә. Бу мисал да ышандырып җиткерми. Анна Каренина да бит рус хатын-кызы, ул да, Нора кебек үк, гаилә мөнәсәбәтләрен өзә. Ә Татьяна Ларина өзми, әмма Катеринадан аермалы буларак, үз-үзен дә үтерми. Күрәсең, биредә милли характер булудан да бигрәк, социальсыйнфый тәрбия, иҗтимагый-тарихи шартлар мөһимрәк роль уйнаса кирәк.

Шулай да, кимчелекләр генә К. Гыйззәтов китабының уңышлы якларын юкка чыгара алмый. Киресенчә, аның көче дә шунда, полемик рухта язылган булуы белән ул бәхәскә тарта, ә төп, принципиаль мәсьәләләрдә ышандыра һәм нинди урыннарда уйларга мәҗбүр итә, бәхәсләшергә әтәрә. Китап дулкынландыргыч тоны, публицистик рухы, катлаулы мәсьәләләрне гади итеп аңлата белүе белән аерылып тора. Ул кызыксыну һәм мавыгу белән укыла, аны белгечләргә генә түгел, әдәбият һәм сәнгатьне яратучы барлык укучыларга тәкъдим итәргә мөмкин.

Дөньядагы күп кенә изелгән халыклар тулы азатлыкка ирешү һәм үз илләрен бәйсез юлдан үстерү өчен көрәш алып барган безнең заманда миллилек һәм интернациональлек иң мөһим теоретик мәсьәләләрнең берсенә әйләнде. Безнең ил кебек күп милләтле илдә милли мәсьәләне хәл итү, элек бәйле хәлдәге милләтләрнең һәм социалистик республикалардагы милли культураларның чәчәк атуы, алар арасындагы туганнарча дуслыкның ныгуы — боларның һәркайсы хәйранга калдыра һәм яшь дәүләтләрнең карашын Советлар иленә төбәтә. Безнең тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү көннән-көн мөһим мәсьәләгә әйләнеп бара. Заманның шул актуаль мәсьәләләренә күпмедер җавап биргән К. Гыйззәтов китабы бүгенге идеологик көрәштә таяныч була ала. Менә шуңа күрә, әлеге мөһим теманы эшләүгә алынып, К. Гыйззәтов мактаулы миссия башкарган һәм үз өстенә алган бурычны уңышлы үтәп чыккан дияскилә. Аның дөньяга чыгуы күпмедер күләмдә совет сәнгатенең үсешен яктырткан теоретик хезмәтләргә булган ихтыяҗны канәгатьләндерде, ә автор сәнгатьнең аерым төрләрендәге интернациональ һәм милли якларның үсеш үзенчәлекләрен өйрәнү нигезендә социалистик культура үсешенең гомуми закончалыкларын яктырта алган.

**Я. АБДУЛЛИН,**
**философия фәннәре кандидаты,**
**Ч. БӘХТИЯРОВА,**
**сәнгать фәннәре кандидаты.**

квартира өчен тарткалашучы туганнары Чепчиковлар элеккеге кулаклар дип бирелә иде. Тәрҗемәдә аларның кулак булулары искә алынмый. Алар хәзер растрата ясаган өчен төрмәдә утырып кайткан кешеләр булларак тәкъдим ителә. Автор, күрәсең, замандашрак, типиграк конфликт, характерлар алырга теләгән.

Шулай да барлык үзгәрешләр дә тик уңай нәтиҗә биргән дип әйтеп булмый. Кайбер җирдә очы-очка ялганмаган урыннар да калган. Оригиналда Валяның имгәнүендә Рәфикъның үзен беркадәр гаепле санавы, шул уңайдан «Суга баткан Гайшә бәете»н искә төшерүе табигый иде. Тәрҗемә вариантында исә Валя салкын тиюдән чирли. Монда да шушы ук бәет юллары китерелә. Әмма бу укучыга аңлашылып җитми, акланмый.

Болардан тыш, әсәргә әһәмиятле генә өстәмәләр кертелгән. Шундыйларның берсе — совет кешеләренең Рәфикъ язмышын йөрәкләренә бик якын кабул итеп алганлыкларын күрсәткән юллар. Хат авторлары Рәфикъ Баймурзинның чын коммунист булуын бернинди икеләнүсез, тулы ышаныч белән беләләр, яланы алып ташларга ярдәм итәргә әзер торалар, хакыйкать җиңәргә тиеш дип саныйлар.

Тәрҗемәдә тагын Рәфикъның романтик, легендар батырлыгын күрсәткән картиналар, сугыш кырында үз самолеты зарарлангач, пленга алырга теләүче фашист самолетына утырып очу күренешләре өстәлгән. Бу эпизод финалның прологы, көрәш өлеше буларак кабул ителә, укучыны психологик әзерләүгә хезмәт итә.

Өстәмәләр турында тагын нәрсә әйтергә? Үләр алдыннан язган соңгы хатында Валя Рәфикъ белән Мәдинәгә турыдан-туры: балаларны әни һәм апа кулында калдырмагыз, дип әйтә. Үзе үлгәч, бу сүзләр васыять көченә керә. Мәрхүмәнең соңгы ихтыяры берсүзсез үтәлергә тиеш була. Шуннан соң бездә уй туа: әгәр дә Рәфикъ кулында шундый документ, шундый васыять булса, ул балаларын даулап шул кадәр интегеп йөрер иде микән?

Тулаем исә тәрҗемә басмасындагы үзгәрешләр әсәрне нык кына яхшыртуга китергән. Ике төрле аңлауга юл куя торган кайбер каршылыклы фикерләр төшереп калдырылган. Автор патриотизм, халыклар дуслыгы, интернационализм, коммунистик идеялелек хисләренең сәнгатьчә сурәтләнешен көчәйтә төшкән, әсәргә яңа яңгыраш биргән.

**ФӘРИТ ХАТИПОВ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Традицион шигырь бәйрәме быел Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап үткәрелде.

25 апрельдә язучыларның утыз кешедән торган зур бригадасы махсус автобус белән Арча районына чыгып китте. Алар Г. Тукайның Тукай-Кырлай авылындагы музеен карадылар, Тукай-Кырлайда һәм Арча педагогия училищесында укучылар белән очраштылар.

Язучыларның С. Шакир, Ф. Шафигуллин һәм Зөлфәтләр составындагы икенче бер төркеме шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта булып кайтты.

Шул ук көнне кич язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында шигырь бәйрәменә багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә шагыйрьләр үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

*

* *

Бәйрәм 26 апрельдә дә дәвам итте. Республикабыз әдипләре, Мәскәү, Рига, Уфа шәһәрләреннән шигырь бәйрәменә килгән кунаклар Казандагы В. И. Ленин, М. Горький, Г. Тукай һәм М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Аннары 1 Май мәйданындагы Муса Җәлил һәйкәле янында шигърп митинг башланып китте.

Митингта шагыйрьләребездән Ә. Исхак, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Ш. Маннур, З. Нури, Н. Дәүли, М. Садри, Х. Камалов, И. Юзеев, М. Нигман, С. Шакир, Г. Зәйнашева, Г. Рәхим һәм башкалар үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

Бу көннәрдә шундый ук шигырь бәйрәмнәре республикабызның башка шәһәрләрендә дә уздырылды.

## ТАНТАНАЛЫ ҖЫЕЛЫШ

5 майда Татарстан язучыларының Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган тантаналы җыелышы булды. Аны, Татарстан язучыларының сугыш елларындагы фидакарь хезмәте турында кереш сүз сөйләп, Язучылар союзы идарәсенең председателе Гариф Ахунов ачты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев җыелышта катнашучыларны Бөек Җиңүнең 30 еллык бәйрәме белән котлады һәм аларга иҗат уңышлары теләде.

Сугыш ветераннарының Совет комитеты президиумы бер төркем фронтовик язучыларны Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап чыгарылган истәлек медальләре белән бүләкләгән иде. Тантаналы утырышта отставкадагы генерал-майор Ф. Булатов язучыларга шул медальләрне тапшырды.

## ОЧРАШУ КИЧӘСЕ

Казанның Актерлар йортында республикабыз театрлары һәм Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең фронтта һәм фронт бригадаларында катнашкан хезмәткәрләренең очрашу кичәсе булды. Кичәне кереш сүз белән Татарстан АССРның культура министры Ә. С. Миндубаев ачты. Очрашуда катнашучыларны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, офицер В. П. Переведенцев, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе, РСФСРның атказанган артисткасы Р. А. Җиһаншина, Республика күчмә театрының баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Тумашев котлады.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

Татарстан язучылар союзы партия оешмасының апрель ахырларында уздырылган җыелышында коммунист тәнкыйтьче Р. Мостафинның иҗаты турында сөйләшү булды. Филология фәннәре докторы, профессор И. Нуруллин җыелышта катнашучыларны Р. Мостафинның күпкырлы иҗат эшчәнлеге белән таныштырды. Фикер алышуда С. Хәким, В. Нуруллин, Ф. Миңнуллиннар катнашты.

Соңыннан Р. Мостафин каләмдәш дусларын үзенең иҗат планнары белән таныштырды.

*

* *

19 майда Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан язучылар союзы партия оешмасының тагын бер ачык җыелышы булып үтте. Җыелышта Ю. Белостоцкий «КПСС Үзәк Комитетының «Тамбов өлкә партия оешмасында тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьнең торышы турында»гы карары һәм шул карар яктылыгында Татарстан язучыларының бурычлары» дигән темага доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуларда

С. Хәким, Ш. Маннур, Г. Ахунов, Н. Дәүли һ. б. катнашты.

Аннан соң 1974—75 уку елы йомгаклары турында партия оешмасы секретаре урынбасары К. Тимбикова доклады тыңланды һәм тикшерелгән мәсьәләләр буенча карар кабул ителде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясенең бюро утырышында КамАЗ төзелешендә эшләүче яшь шагыйрь Хәниф Хөснуллинның «Чорлар аргамагы» исемле шигырьләр циклы тикшерелде. Утырышта Х. Туфан, И. Юзеев, Ә. Баянов, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин һәм Г. Садә катнашты. Алар Х. Хөснуллин шигырьләренең уңай һәм кимчелекле яклары турында сөйләделәр.

*
* *

Балалар әдәбияты секциясенең 16 апрельдә уздырылган утырышы А. Тимергалин иҗатын тикшерүгә багышланган иде. Фикер алышуларда унбишләп кеше катнашты. Аларның барысы да А. Тимергалинның матур әдәбият өлкәсендә нәтиҗәле эшләп килүен билгеләп үттеләр.

*
* *

Драматурглар секциясенең чираттагы утырышында башлап язучы Ю. Сафиуллинның «Ни эшләсен кыз бала?» исемле трагикомедиясе укып тикшерелде. Фикер алышуларда Р. Ишморат, Ә. Камал, Ш. Зәйни, А. Гыйләҗев, Т. Миннуллин, Ә. Баянов, И. Юзеев, С. Шәкүров һәм Э. Гаделевләр катнашты. Алар авторга әсәрен камилләштерү юнәлешендә файдалы киңәшләр әйттеләр.

*
* *

Тәрҗемәчеләр секциясенең 22 апрельдә уздырылган утырышында сүз И. С. Тургенев повестьларының татар теленә тәрҗемәләре турында барды. Утырышта Я. Халитов, Х. Сарьян, К. Миңнебаев, Р. Даутов, Ш. Рәкыйпов, С. Сибгатуллина, Р. Юсупов һәм Т. Нурмөхәммәтовлар чыгыш ясады. Фикер алышуда катнашучылар И. С. Тургенев әсәрләренең нигездә әйбәт тәрҗемә ителүен әйтеп үттеләр.

## ЯШЬЛӘР СЕМИНАРЫ

Идел буендагы Халыкара яшьләр лагерендә яшь иҗат көчләренең өч көнлек семинары үткәрелде. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм республика иҗат союзлары тарафыннан оештырылган бу семинарда яшь язучылар, композиторлар, художниклар һәм яшь артистлар катнашты. Алар төрле темаларга лекцияләр тыңладылар, совет сәнгатенең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алыштылар, бер-берләренең иҗаты белән таныштылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

## ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ НӘШРИЯТЛАРДА

Белоруссиянең «Мастацкая литература» нәшрияты Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н 7000 данә тираж белән белорус телендә басып чыгарды. Җыентыкка кереш сүзне Зәки Нури язган.

*
* *

Мәскәүнең «Известия» нәшрияты вакытында «Новый мир» журналында басылган мәкалә һәм очерклардан төзелгән «Набережные Челны» исемле җыентык чыгарды. Төзүчесе һәм редакторы Ф. Видрашку. Кереш сүз авторы Г. Марков. Тиражы 50 000 данә. Бәясе 75 тиен.

*
* *

«Художественная литература» нәшрияты 50 000 данә тираж белән Фатих Әмирханның «Сайланма әсәрләр»ен басып чыгарды.




Җыентык Л. Климовичның зур гына кереш мәкаләсе белән ачыла. Ф. Әмирханның хикәяләрен һәм повестьларын рус теленә Г. Хантемирова тәрҗемә иткән.

## ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БӘЙРӘМНӘР

### ӘХМӘТ ИСХАККА 70 ЯШЬ

Совет әдәбиятын үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән СССР Верховный Советы Президиумы язучы **Әхмәт Исхакны «Халыклар дуслыгы» ордены** белән бүләкләде.

*
* *

22 майда Мәгариф хезмәткәрләре йортында Әхмәт Исхакка 70 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Ки-

һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы, шагыйрь Зәки Нури ачты. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев **Ә. Исхакка «Халыклар дуслыгы» ордены** тапшырды һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Татарстан АССР Министрлар Советы исеменнән юбилярны кайнар котлады. Шагыйрьнең иҗат эшчәнлеге турындагы докладны Н. Арсланов ясады. Кичәдә Ә. Исхакка кыйммәтле бүләкләр, илебезнең бик күп почмакларыннан килгән тәбрик хатлары һәм телеграммалар тапшырылды.

Ахырдан яшь башкаручылар көче белән концерт бирелде. Концертта Ә. Исхак шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды.

## НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Май аенда күренекле татар совет шагыйре Нур Баянның тууына 70 ел тулды. Шул уңай белән республика газета-журналларында шагыйрь иҗаты турында мәкаләләр басылды, телевидение һәм радио аша аның иҗатына багышланган тапшырулар яңгырады.

Фронтовик шагыйрьнең 70 еллыгын якташлары — Актаныш районы хезмәт ияләре аеруча киң күләмдә билгеләп үттеләр.

15 майда Нур Баян исемендәге колхоз (шагыйрь туып үскән Әнәк авылын һәм Пучы авылларын берләштерә) клубында район мәктәпләре укучылары катнашында шигырь бәйрәме үткәрелде. Анда кырыклап укучы шагыйрьнең шигырьләрен сөйләделәр. Конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Район хезмәт ияләре вәкилләре һәм пионерлар шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Кичен колхоз клубында Нур Баян истәлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Шагыйрьнең иҗаты турында район балалар китапханәсе хезмәткәре Гамбәрия Гәрәева доклад ясады. Кичәдә шагыйрь Ә. Маликов, «Яшь ленинчы» газетасы сотрудникгы, яшь шагыйрь Р. Миңнуллин, Минзәлә педучилищесы укытучысы В. Һадиев, Нур Баян исемендәге колхозның председателе М. Заманов һәм шагыйрьнең якыннары, сабакташлары, авылдашлары чыгыш ясады. Ахырдан район үзешчән сәнгать коллективлары көче белән зур концерт бирелде.

## АКТЕРЛАР ЙОРТЫНДА

25 апрельдә Казан шәһәренең Актерлар йортында Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, сәхнә ветераннары һәм Актерлар йорты советлары «Сәяр», «Нур», «Ширкәт» труппаларының олы буын артистлары Зөләйхә Богданова һәм Нури Сакаевларның тууына 90 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе үткәрделәр.

## ЯНКА КУПАЛА ИСТӘЛЕГЕНӘ

Белоруссиянең халык шагыйре Янка Купала Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан АССРның Югары Ослан районы Печищи авылында яши. Шушы елның май урталарында бу авылда Янка Купаланың Минск шәһәрендәге әдәби музееның филиалы ачылды.

## СӘНГАТЬ АТНАЛЫГЫ

Әлмәт шәһәренең Техника йортында традицион сәнгать атналыгы үткәрелде.

Быел ул фашистлар Германиясен Җиңүгә 30 ел тулуга багышланган иде. Әлмәт татар дәүләт драма театры шушы уңай белән тамашачыга алты спектакль күрсәтте. Репертуарда А. Гыйләҗевнең «Җан җылысы» драмасы, чуваш драматургы Н. Терентьевның «Син кайтмадың», рус драматургы А. Салынскийның «Кайда күрдем мин сине?», чех драматургы И. Буковчанның «Таң әтәче кычкырганчы» драмалары, башкорт язучысы И. Абдуллинның «Их, Уфа кызлары», З. Шәһиморатовның «Хәзрәт үгетләргә килә» комедияләре бар иде. Әсәрләрне театрның баш режиссеры Л. Садриев, ТАССРның халык артисткасы З. Туишевалар сәхнәләштергән. Бу атналык тәмамланганнан соң комиссия членнары белән театр коллективы арасында эшлекле сөйләшү булды. Иҗади сөйләшүдә театр белгече Һ. Мәхмүтов, драматург А. Гыйләҗев, Татарстан Культура министрлыгы инспекторы Р. Галиева, ТАССРның атказанган артисты А. Масаутова, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллиннар катнашты.

*

* *

Казанның Актерлар йортында Республика күчмә театрының соңгы сезонда куйган яңа спектакльләре турында сөйләшү булды. Фикер алышуларда тәнкыйтьчеләрдән Г. Кашшаф, Д. Гыйнмранова, Һ. Мәхмүтов һәм драматург И. Юзеев катнашты.

## ӘМИНӘ ҖӘЛИЛОВА КАЗАНДА

Татарстан язучылар союзы чакыруы буенча Җиңүнең 30 еллык бәйрәменә Казанга Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова килде. Ул шәһәребезнең истәлекле урыннарында булды. 1 Май мәйданындагы Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куйды.

## БЕЗНЕҢ ДЕПУТАТЛАР

Билгеле булганча, 15 июньдә җирле Советларга сайлаулар булып үтте. Татарстанның атказанган культура работнигы, прозаик В. Нуруллин Казан шәһәр Советына, язучы Ә. Маликов Әлмәт шәһәр Советына, Г. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Ш. Галиев Бауман район Советына депутат итеп сайландылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Апрель аенда язучы Р. Төхфәтуллинның «Китә казлар» исемле яңа повесте тикшерелде. Әсәр Бөек Ватан сугышы чорында тылдагы кешеләрнең кырыс тормышын, батыр хезмәтен сурәтли. Язучылардан Ю. Әминов, Ә. Маликов, М. Хәсәнов, яшь язучылар А. Хәсәнов, Н. Әхмәдиев, Ф. Галиева һ. б. әсәрне яхшырту юнәлешендә авторга төпле фикерләр, файдалы киңәшләр әйттеләр.

*

* *

Бүлек язучылары һәм Әлмәт татар дәүләт драма театры вәкилләре катнашында «Әдәбиятта, сәнгатьтә заманчалык һәм художникның гражданлык позициясе» дигән темага сөйләшү булды. Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе С. Өметбаев төп доклад белән чыкты. Ул М. Хәсәновның һәм яшь язучы Ф. Садриевның яңа пьесаларына эчтәлекле анализ ясады, драматургия алдында торган бурычларга тукталды, сәхнә законнары турында сөйләде. Язучылардан Ю. Әминов, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, М. Хәсәнов, яшь язучылар А. Хәсәнов, Н. Әхмәдиев, Әлмәт татар дәүләт драма театрының баш режиссеры Л. Садриев, артистлар И. Мәсгутов, Д. Хисаметдинова докладчы фикерен куәтләп чыгыш ясадылар.

*

* *

25 апрельдә Әлмәт нефтьчеләренең Техника йортында поэзия көненә багышланган зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов «Сугышчан һәм төзүче поэзия» дигән темага чыгыш ясады. Шагыйрьләрдән Э. Мөэминова, К. Булатова, яшь шагыйрьләр Г. Кашапов, Ф. Галиева, В. Туктарова Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт темасына багышланган яңа шигырьләрен укыдылар.

Кичәнең икенче бүлегендә Әлмәт татар дәүләт драма театры артистлары башкаруында Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәрим шигырьләре, татар композиторларының көйләре һәм халык җырлары яңгырады.

*

* *

Әлмәт шәһәренең 1 номерлы балалар китапханәсендә «Сугыш кырында туган утлы юллар» дигән темага әдәби кичә үткәрелде. Шәһәр пионерлары төрле милләт шагыйрьләренең Бөек Ватан сугышы чорында язган шигырьләрен сөйләделәр. Кичәдә Ә. Маликов үзенең солдат шигырьләрен, фронт көндәлекләреннән өзекләр укыды, пионерларның күп сорауларына җаваплар бирде.

*

* *

Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы китап сөючеләр арасында тиз таралып өлгерде, аларның яраткан әсәренә әверелде. Сугышлы авылының культура йортында роман буенча уздырылган конференциядә укытучы Р. Әюпова сүзен әнә шуннан башлады. Аннары укытучылар Р. Нуретдинов, Җ. Гарипова, Х. Галимова, авыл Советы председателе М. Мифтахов, 50 нче елларда ук нефть эзләүдә эшләгән С. Морадымов, М. Гайнетдиновлар әсәрнең аерым образлары турында сөйләделәр. Конференциядә автор үзе дә чыгыш ясады һәм күп кенә сорауларга җавап бирде.

Авторның шушы романы буенча китап укучылар конференциясе Лениногорск шәһәр балалар больницасында да булды.

*

* *

## ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан журналистлар союзы идарәсе Хөсәен Ямашев исемендәге республика премияләрен авыл хуҗалыгы производствосының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм тигызынчы бишьеллыкның социалистик ярыш алдынгылары турында «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләләре һәм публицистик материаллары өчен «Социалистик Татарстан» газетасының үз корреспонденты **Мәрдгаләм Галләм улы Рафиковка** һәм КамАЗ төзелешендә, шулай ук Татарстанның башка төзелешләрендә социалистик ярышны үстерү һәм алдынгы тәҗрибәне җәелдерү мәсьәләләре буенча «Советская Татария» газетасында басылган мәкаләләре өчен «Советская Татария» газетасының промышленность, төзелеш һәм транспорт бүлеге мөдире **Альянс Бәдри улы Сабировка** бирергә карар итте.

*

* *

СССР Журналистлар союзы идарәсе секретариаты район, шәһәр һәм күп тиражлы газеталар редакцияләренә М. И. Ульянова исемендәге премияләр бирү турындагы мәсьәләне тикшерде.

Бүләкләнүчеләр арасында Зеленодольск шәһәренең «Зеленодольская правда» газетасы редакциясе коллективы да бар. Аңа Икенче дәрәҗә диплом һәм акчалата премия бирелде.

# ҖЫРЫМ ЮЛДАШ БУЛСЫН

**МӨХӘММӘТ САДРИ** җыры

**ИСМАЙ ШӘМСЕТДИНОВ** музыкасы






Алмагачлы биек ярдан карыйм
Җем-җем иткән Идел өсләрен;
Кояш кебек җылы, Иделдәй саф
Минем сезгә якты хисләрем.

Ак җилкәнле җитез ак көймәләр
Идел суын коштай кичәләр;
Җилкәннәргә искән җилләр кебек,
Хисләр мине сезгә илтәләр.

Сандугачлар һәм тургайлар җырын
Дәвам итәм йөрәк кылымда:
Сезгә, дуслар, барлык гашыйкларга,
Юлдаш булсын минем җырым да!

# Хөрмәтле укучыбыз!

1976 ел өчен газета-журналларга язылу вакыты җитә.

Бу ел Сез «Казан утлары» журналын ел буе алып килдегез һәм киләсе елда да аңа язылырга онытмассыз дип ышанабыз.

1976 ел илебездә һәм республикабызда булып узачак зур вакыйгалар, әдәбият һәм сәнгать бәйрәмнәре белән аерылып тора. Журнал редакциясе үзенең эш планын әнә шул вакыйгалар чагылырлык итеп төзи һәм сезнең игътибарыгызга Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең 25 съездына караган очерклар, Г. Тукайның 90 еллыгы, М. Җәлилнең 70 еллыгы, Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының 70 еллыгы һ. б. бәйрәмнәргә бәйле материалларны тәкъдим итәчәк.

Гадәттәгечә журналыбызның зур өлешен язучыларыбызның проза һәм поэзия әсәрләре, сәхнә сөючеләр өчен яңа пьесалар, яңа җырлар алып торыр. Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә», Гариф Ахуновның «Идел кызы», Атилла Расихның «Айлы төннәр» («Ямашев» романының икенче китабы) романнары, Фатих Хөснинең «Язмыш», Әхсән Баяновның «Төлке тоту кыен түгел», Барлас Камаловның «Йөрәкнең янулары», Әхәт Гафаровның «Тege гозер», Илдар Низамовның «Өмет» повестьлары инде редакциягә килде.

Алдагы елда поэзия бүлеге дә бай һәм күп төрле поэма, шигырьләр бирәчәк. Хәсән Туфан, Сибгать Хәким, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим һ. б. яңа әсәрләрен яратып кабул итәрсез дип ышанабыз. Әдәбият белеме белән кызыксынучыларны галимнәребезнең яңа хезмәтләре, Татарстан китап нәшрияты чыгарган китапларга рецензияләр, китап күзәтүләр һ. б. белән таныштырып барачакбыз.

Хөрмәтле укучыбыз! Сез «Казан утлары» журналын үзегез генә алып калмассыз, журналыбызны алдыруда башка иптәшләргә дә булышырсыз, аларга журналга язылу тәртипләрен аңлатып бирерсез дип өметләнәбез.

Журналыбызга Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Ул Бөтенсоюз газета-журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Язылу бәясе бер елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210